Флүс
Латыйфи

Хыянәт

ББК 84(2Р-Тат)-4
Л 27

Рәссамы Д. ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ

Латыйфи Флүс

Л27 Хыянәт: Роман.— Казан: Татарстан кит. нәшр., 1993.— 286 бит.
ISBN 5—298—00375—3

Роман, беренче битләреннән үк, укучыны Казан ханлыгында барган кызыклы һәм гыйбрәтле маҗаралар дөньясына алып кереп китә. Әсәр татар тарихының моңа кадәр яктыртылмаган гаять катлаулы бер дәверен чагылдыру белән бергә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең сафлыгын, мәхәббәт һәм дуслыкның тирәнлеген, хыянәтнең ачылыгын тасвирлаудагы осталыгы, тормышчанлыгы белән дә игътибарны җәлеп итә.

Л $\frac{4702560201-050}{М132(03)-93}$ 30—93 ББК 84(2Р-Тат)-4

ISBN 5—298—00375—3
© Татарстан китап нәшрияты, 1993.

СЕРЛЕ ТАМГА

Шәһре Кашан — җиһан гөшә,
Халаегы һөнәр пишә;
Кеми сәуваг, кем зәргәр,—
Бу сүзгә кыйлмаг әндишә.

Болгар дәүләте чорында яшәгән
билгесез шагыйрь.

Хәзерге телгә тәрҗемәсе

Шәһре Кашан җиһан күрке,
Халкы оста вә һөнәрле,
Кем корыччы, кем көмешче,—
Шикләнмә, ышан, бел инде.

— Даң-даң-даң...
— Доң-доң-доң!..

Иртәнге тынлыктан уянып кына килүче шәһәрне сискәндереп, Нугай дәругасы* ягындагы капкалар өстендә олы дум-думбакларның** дәртле тавышлары яңгырап үтте. Көйчеләр, бер-берсен уздырырга тырышкандай, агач кысага тарттырылган үгез тиресенә ярсып-ярсып бәрәләр:

---

* *Дәруга* — юл, өлкәгә илтүче юл.
** *Дум-думбак* — бәрмә музыка уен коралы, барабан.

нинди хәл-хәбәр ул? Куаныч китерә торганымы, әллә көенечлесеме?

Йомышчы егетне озаткач, мәрткә киткәндәй күзен йомып, озак уйланып утырды Сәет. Үзенең кылган гамәлләрен кат-кат хәтереннән уздырды, кемгәдер зыян салмаганмы, гаделсез эше белән кемне дә булса рәнҗетмәгәнме? Күпме генә уйланмасын, үз өстендә гөнаһ таба алмады һәм җиңел сулап әзерләнергә кереште.

Озатырга чыккан җәмәгате Гөлйөземне маңгаеннан үпкәндә җаны тынычланган, күңеле урынына утырган иде инде.

— Озакламам, Гөлем,— диде ул. Хатынының йомшак ак кулын алып, үзенең маңгаена куеп торды, яраткан, аңлашып-сөешеп гомер кичергән, җанына тиң күргән затның бармакларыннан, әйтерсең, аңа рухи тынычлык, күңел бөтенлеге саркыды.— Озакламам,— дип янә кабатлады ул һәм чыгып китәр алдыннан борылып, шаярып күз кысты.— Базарбашы чакыра икән, иреңнең дәрәҗәсе үсте дигән сүз... Шулай бит!

Гөлйөземнең бите алланып китте, таң белән килеп кергән хәбәрдән каушап калган хатын сүз дәшмичә генә күз сирпеде — керфекләре арасыннан Сәеткә нур коелгандай булды.

«Борчылма! Ни булса да мин синең белән. Язганын бергә күрербез», дигәнне аңлата иде аның бу карашы.

Никадәр генә тыныч күренергә тырышмасын, барыбер Сәетнең йөрәген шик корты кимерә иде. Уен эшмени?! Базарбашы хозурына махсус чакырулы кешегә ике генә юл барлыгын белми түгел ул. Берсе аның — дәүләткүләм эшләрдә катнаштыру кебек дәрәҗәле юл булса, икенчесе — хурлыклы куылу, сәүдә эшеннән, малтабарлыктан читләштерелү. Бусы — үлем җәзасына тиң! Андый хөкем алган адәмгә хезмәтчелеккә төшүдән гайре чара калмый. Тамгачылар* килеп малын язып алыр, ясавыллар** төяп хан казнасына озатыр. Әнә шундый хөкемгә тарыганнар да булмады түгел, булды. Андый хәлләрне дә белә Сәет. Шикшөбһәгә төшәрлек чакыру иде бу.

Нургали аганың ак таштан салынган зур йорты шәһәрнең аксөяк морзалар яши торган мәхәлләсендә дә матурлыгы, байлыгы белән аерылып тора иде. Төсле пыяла куелган якты тәрәзәләре, зифа чыршылар белән ярышып, дүрт почмагын-

---

* *Тамгачы* — таможня чиновнигы.

** *Ясавыл* — атлы каравыл, карар үтәүче.

нан күтәрелгән нечкә, төз, алтын уклы манаралары, калын имән ишекләре аны тагын да мәһабәтрәк итеп, саллы итеп күрсәтә. Хан карачыларына* тиң, дәрәҗәле бу кешенең өенә керү югары катламга күтәрелү белән бер. Моны Казандагы ярлы-ябагай да яхшы белә.

Ишектән алып түр башына кадәр келәмнәр җәелгән, ачык яшел төстәге бизәкле ефәк белән эчләнгән кунак бүлмәсендә Казанның иң атаклы унлап малтабары, кәрваннары белән дөньяны аркылыга-буйга гизгән сәүдәгәрләр җыелган иде. Аларны күрүгә Сәетнең бөтен тәне буйлап эчке бер калтырану йөгереп узды. Шанлы кешеләр арасына тиң итеп чакырылудан туган горурлану хисенә инде дистә елдан артык күңел чоңгылында яшәгән икенче бер тойгы — шикләнү һәм икеләнү килеп уралды. Дөрес, атларына мал төяп юл йөргәндә, Идел буйлап көймәләрдә, салларда акканда, аякларына чаңгы тагып төн ягында яшәүче кабиләләр янына чапканда ул хисләр югала, онытыла. Әмма Казанга кайтып төшүгә шул тойгы баш калкыта, әкрен генә, сиздерми генә җанын кимерә, Гөлйөзем янында, балалары арасында узган кадерле сәгатьләрнең тәмен агулый иде. Юкса, ул хиснең күптән үләргә, бетәргә тиешлеген дә белә. Сәбәпләре юк ителгән, андый борчулар өчен тамырлар калмаган да кебек. Һай, юк бит, шик үзе белән каберенә дә керер ахрысы. Һич югы, балаларына күчмәсен иде алар.

Эче тулы шөбһә, сорауларына җавап эзләп бәргәләнү булса да, йөзенә сабырлык чыгарып сәлам бирде. Бу йортта, бу кешеләр арасында сабырлыктан да югары бәяләнүче нәрсә юк.

— Хуш киләсең, Сәет туган! Әйдә, түрдән уз!

Базарбашының ягымлы эндәшүеннән Сәетнең эченә җылы йөгерде. Юк! Шик-шөбһәләрем урынсыз. Барысы да яхшы булыр!..

Нургали ага өстәлдән кечкенә көмеш кыңгырау алды. Аның кул тибрәтүеннән кыңгырау телгә килде, гөмбәзләнеп өскә күтәрелгән биек түшәм астында көмеш чыңнар биеште. Диварлар белән бер иш ефәк чаршаулар корылган ян-як ишекләр ачылып китте, аларның берсеннән көмеш кувшиннар тотып яшь угланнар килеп керде, икенче яктан иң талымчан кешенең дә авыз суларын китерерлек хуш исләр таратучы тәгамнәр күтәреп, яшь, чибәр кызлар килеп чыкты

---

* *Карачы* — министр.

«Өнемме бу, төшемме?» Сәет үзенең базарбашы өендә икәнлегенә әле һаман ышанып җитмәгән кебек, як-ягына каранып алды. Әмма бу төш түгел, чынбарлык иде. Нургали аганың ишарәсенә буйсынып, кунаклар тезләрен бөкләп бүлмә уртасындагы тәбәнәк өстәл янына утырыштылар. Угланнар каяндыр чәмчәле бизәкләр салынган кызыл күн тышлы мендәрләр алып чыкты, һәр кешегә таяныр урынына мендәр салынды.

Өстәлдәге көмеш савытларда телемләп туралган казылык, ысланган ит, яңа гына мичтән чыккан кабартма, татлы ризыклар, чынаякларда юкә балы, нечкә билле озын савытларда куе кызгылт ширбәт күбекләнә. Шактый ил гизәргә, дөнья күрергә өлгергән Сәет барлык сыйларның исемен дә белеп бетермәвен абайлап алды. «Базарбашы яши белә икән! — дип уйлап куйды ул.— Дөрес, безнең дә өстәлдән кунак сыеның өзелгәне юк. Әмма барыбер бу кадәре үк түгел инде. Их, Гөлйөземне алып килеп күрсәтәсе иде!..»

Кергәннән бирле ишек төбендә таптанудан узмаган Сәетне Нургали ага үзе өстәл янына чакырды:

— Йә, һаман бусага төбен саклау килешмәс. Уз, табын янына утыр,— диде ул кулы белән өстәлнең бирге башында буш калган мендәргә күрсәтеп.— Таянып ал!

Сәет кабат әйттермәде — тыйнаклыкның да бер чиге була торгандыр бит. Казанлыларның кунак сыйларга, назланып, ялындырып кына сыйлатырга яратуы мәгърибтә дә, мәшрикътә да билгеле анысы. Тик бүген андый көн түгелдер. Базарбашы өендә хуҗаның һәр сүзе, ымы, күз карашы фәрман булып кабул ителә.

Сәетнең урыны Әҗем карт белән янәшә туры килгән иде. Казанда гына түгел, Кырымда,Әстерханда, нугай далаларында, Мәскәүдә һәм Новгородта, Хәрәземдә һәм Сәмәркандтә, әрмән тауларында, кыскасы, сәүдә кәрваннары сукмагы кайда илтсә, шунда ихтирам казанган, тырышлыгы, үткенлеге, мал таба белүе белән шөһрәт алган, дөньяга таш ярып чыккан бу кеше инде җиденче дистәне ваклаган булса да, һаман яшь күренә, үткен телле, зиһенле иде әле. Ул Сәеткә таба иелә төшеп пышылдады:

— Шым бул! Монда ишеткән колагыңнан керсен, авызыңнан чыкмасын. Йөрәгең тибүдән туктаганда да иреннәрең кыймылдамасын...

Ләкин Әҗем карт әйтеп бетерә алмады, тынлыкны Нургали аганың тавышы бүлде:

— Җәмәгать! Әһле базар... Мәҗлеснең сәбәбе күпләрегезгә мәгълүмдер. Шулай да кабат әйтүдән зыян юк.

«Сүзең көмеш булса, дәшмәвең алтын» тәгъбире бүгенге табынга туры килми. Шулай бит, Әҗем ага?

Базарбашының пышылдап кына әйтелгәнне дә ишетеп утыруын белеп, Сәетнең күз аллары караңгыланып китте. Күзе генә түгел, колагы да үткен икән Нургали аганың. Эңә ич, Әҗем хәтле Әҗемгә ничек төрттерә.

Әҗем картның исә керфеге дә селкенмәде. Ул базарбашына борылып, әйткәннәреңне хуплыйм дигәндәй, кулларын кушырып башын иде, әйтә башлаганы исә телендә эленеп калды.

Башка сүзләрне дә, мәҗлесне дә томанлы хәтерли Сәет. Кем ни әйткән, нәрсә белән сыйлаганнар, кем ничек котлаган — болары әһәмияткә ия булмаган вак нәрсәләр шикелле артка чигенгән, күңелдән юылган. Ә иң мөһиме — анысы йөрәккә уелган, ак кәгазьгә алтын хәрефләр белән беркетелгән ярлык шикелле баш миендә мәңгелеккә урын алган.

Бу — беркайчан дә Сәеттән чыгарга тиеш булмаган сер, яшерен вәгъдә. Ул аны теле белән генә түгел, каны белән беркетте.

Нургали аганың һәр сүзе әле дә колагында яңгырый, үзенә күрсәтелгән ышанычтан, олылаудан җаны татлы бер рәхәтлек кичерә, шул ләззәттән исерә. Бүгеннән башлап базар булган һәрбер илдә, һәр шәһәрдә Сәеткә юллар ачык, аның ул һәм базарбашы гына белә торган яшерен көче, бөек сере бар.

— Без синең кем икәнеңне дә, Казан-йортка ничек килеп төпләнүеңне дә яхшы беләбез. Без сине бик озак күзәттек, сынадык,— дигән иде Нургали ага.— Күңелеңдә хөсетлек, калебеңдә комсызлык, саранлык юкмы, кулың кәкре түгелме, телең йозактамы, күзеңне нәфес пәрдәсе капламаганмы, йөрәгеңне май басмаганмы, эчке хасиятләрең тышкысына туры киләме?.. Ни рәвешле сынавыбыз сер булып калсын. Анысын өлкән кәсептәшләрең үзләре белә. Әйткән сүзләрең, кылган гамәлләрең безгә килеп җитә торды, син сынауны үттең. Без сиңа ышандык...

Сәет базарбашының сүзләрен хәйран калып тыңлады. Йөрәге еш-еш тибә, бите уттай кызыша башлады. Тыны кысылгандай булды. Чит мәмләкәтләрдә йөргәндә дә, шушы Казанда да ул үзен кемдер күзәткәнне, кирәк чакта гына ярдәм кулы сузылганны тоеп яши иде, моны еш кына үзенең шикләнүчәнлегенә сылтый, ә эше яхшы баруны юл уңудан күрә иде.

Хәер, аңа истәлекләргә бирелеп торырга ара да калмады. Базарбашының тавышы серле бер төсмер алды, ул кулы

белән ишарәләп нидер күрсәтүгә, бүлмәдәге хезмәтче егетләр һәм кызлар юкка чыкты. Нургали ага үзе торып ишекләрне тикшерде, бары тик шуннан соң гына сүзен дәвам итте:

— Бүгеннән башлап син, Сәет Сәлим углы, Казан-йорт ның асыл сәүдәгәрләре арасына кабул кылынасың, безгә мәгълүм серләр һәм хәбәрләр синең өчен дә уртакка әйләнер... Мәгърибтән мәшрикъкача, көн ягыннан төн ягынача безгә мәгълүм базарларның ишекләре ачылыр, сәүдәң уң, юлың җиңел булыр. Инде безгә хыянәт кылсаң, серебезне ятларга чишсәң, аны үз мәнфәгатең өчен генә файдалансаң, башың чапкылыкта* бетәр. Кирәккәндә без мәрхәмәтсез дә була беләбез. Чигенер юлың юк.

Базарбашының тавышы кырысланды, күзләрендә ут чаткысы булып хыянәтчеләргә, хаиннәргә нәфрәт кабынды. Тик бу хәл озакка бармады, акрын, салмак тавыш белән ул Сәет алдына бүгеннән куелачак таләпләрне, хәзергә белергә мөмкин дип саналган серләрне бәян итәргә кереште. Күп нәрсәләрне сөйләде, моңарчы белмәгән, хәтта сизенмәгән нәрсәләргә Сәетнең күзен ачты Нургали ага. Серләр күп иде, катлаулы иде.

Вәгъдәңне, сәүдәгәр сүзенә, Казан-йортка тугрылыгыңны кан белән беркетү фарыз. Бирегә кил, Сәет Сәлим углы!

Нургали ага башы белән ымлап Сәетне үз артыннан ияргә чакырды. Саллы чаршауны күтәреп, түр башында яшерелгән ишектән тәрәзәләренә тимер челтәр тотылган ярымкараңгы бүлмәгә үттеләр. Базарбашы авыз эченнән генә ниндидер дога укыгач, куеныннан олы ачкыч чыгарды, идәндәге бакыр сандыкның йозагына тыгып борып җибәрде. Капкач шыңгырдап ачылды. Ниндидер асыл маллар, алтынкөмеш, кыйммәтле ташлар көтеп торган Сәет сандык төбендә бары берничә төргәк язу гына күрде. Шуларның иң зурысын, вакытлар үтүдән саргайганын, баш-башы мөһерләнгәнен сакланып гына алды Нургали ага һәм, төргәкне тәрәзәдән төшкән яктыга куеп, Сәеткә дәште:

— Менә монда тамгаңны салырсың...

Әҗем карт билендәге кынынннан сүзсез генә үткен хәнҗәрен суырып чыгарды, аны Сәеткә сузды һәм күзләре белән тәрәзә төбендәге каурый каләмгә ымлады.

Кан белән вәгъдә беркетүнең ни икәнен Сәет белә иде.

---

* *Чапкылык* — баш чабу урыны.

Тантаналы тынлыкны бозарга җөрьәт итмичә, тавышсыз гына хәнҗәрне алды һәм җиңен сызганып, ялтырап торган очлы тимерне беләгенә кадап алды. Ярадан сирпелеп куе кызыл кан чыкты. Аның һәр хәрәкәтен тын да алмый күзәтеп торган өлкән сәүдәгәрләр бер-берсенә караштылар. Сәет үзенең тормышында ниндидер мөһим бер борылыш буласын күптән аңлаган иде инде. Бу мизгелдә ул бернинди авырту да, икеләнү дә тоймады. Барысы да: аның үз язмышы да, Гөлйөзем һәм балалары язмышы да шушы кешеләр кулында икәнен, ул гына түгел, бүгенге һәм киләчәк тормышының ничек үтәчәге дә шушы язуга, антка бәйле икәнен дә акылы, зиһене белән, бөтен җаны-тәне белән сизенгән иде. Икеләнергә, куркырга, шик-шөбһәңне күрсәтергә ярамый. Ул, каурыйны канына манчып, Нургали ага күрсәткән урынга үзенең имзасын салды. Хәрефләр тезгән арада күзләре, төргәк кәгазьнең сүтелеп, алдына таралып төшкән өлешендәге язмаларны барлап чыгарга өлгерде. Арада гарәп һәм чин язуы да, уйгыр тамгалары да, тагын ниндидер аңлаешсыз телдә салынганнары да бар иде. Казан сәүдәгәрләренең көчен, алар сүзенең үтемлелеген, серен тагын бер кат шунда аңлады Сәет. Шушы бөек сергә кушылуыннан, сүзләре теләсә кайсы йортка үтеп керердәй кешеләр арасына алынуыннан, бу мизгелләрнең җаваплылыгыннан һәм яшерен тантанасыннан башы әйләнеп китте.

Нургали ага кәгазьне яңадан төреп сандыкка салды һәм изге бер йола башкарганлыгын тагын бер кат аңлатырга теләгәндәй, аның күзләренә текәлеп туп-туры итеп карап торды, тавыш чыгармаска тырышып тамак кырды. Куллары салмак кына Сәетнең муенына таба сузыла башлады. Әллә куркудан, әллә аның бу аңлаешсыз хәрәкәтеннән сискәнеп китте яшь сәүдәгәр, әмма башын алмады. Караңгылыкка ияләшеп өлгергән үткен күзләре базарбашының кулында ефәк җепкә тагылган көмеш тәңкәне күреп алган иде инде.

— Бу тамганы күз карасыдай гына түгел, җаныңнан да кадерләбрәк сакларсың,— диде базарбашы аның муенына тәңкәне асып.— Ул сиңа дөньядагы бөтен базарларның биген ачар, хәтта хан сараена юл ачык булыр.— Нургали аганың тавышы көчәйгәннән-көчәя барды, аның һәр хәрәкәтен тылсымлангандай күзәтеп торган Сәеткә, үзе белән базарбашы түгел, ниндидер илаһи зат сөйләшәдер кебек тоела башлады.— Тик онытма, күргән файдаңның, тапкан малыңның уннан бере Казан-йорт казнасына, тагын да бер өлешенең яртысы уртак маяга күчә барыр. Казан-йортыбыз бай, таза, нык булсын өчен алтын-көмеш, асылташлар

кирәк. Башка бар нәрсә чери, таркала, юкка чыга, тузан булып оча. Болар — мәңгелек. Болар кала капкасын ачарга да, хөкемдарлар күңеленә юл табарга да ярдәм итәр. Шунысын онытма, затлы мал дошман җанына вәсвәсә сала, үчләштерә, көнләштерә, нәфесен котырта. Казан-йорт казнасына керәсе бер генә дирһәмең дә дошманыңа мәгълүм булмасын. Бусын колагыңа киртләп куй! Аягың җитез, зиһенең йөгерек, кулың нык, сүзең акыллы, йортың таза, авызың биктә булсын! Амин!

Шәһәр капкалары өстендәге күзәтчеләрнең дум-думбакларда, давылбазларда* бәреп Казанның олы сәүдәгәрләренә яшерен телдә хәбәр биреп, базарга кай тарафтан нинди кәрван килүен белгертеп торуын да шул чакта белде Сәет. Хәзер бу тел аңа да таныш.

Озакламый Казан өстендә кояш күтәрелер, аның алтын нурлары йөзләрчә манараларда чагылып күзне иркәләр. Идел ягыннан искән йомшак җилләр меңнәрчә чакрым юл үткән кәрванчыларны назлар, күңелләренә хушлык бирер. Чишмәләрдән челтерәп аккан көмеш сулар аларның сусынын басар, буыннарына ял бирер.

Казан — базарларның базары, сәүдәгәрләрнең кыйбласы. Ил-көн барында ирекле Казан-йорт мәңге шулай малтабарларны көтеп алучы, күңелләрен хушландыручы җыеннарның җыены булыр.

Күп тә үтмәс, башка капкалар өстендә дә күзәтчеләрнең үткен күзе яңа кәрваннарны күрер, Идел өстеннән Казан суына борылучы көймәләрне абайлар. Дум-думбаклар, давылбазлар телгә килер. Кайлардан килә икән бүген арыган юлчылар? Гарәп илләреннәнме, Шам-Шәрифтәнме, Румнанмы, су өстеннән урыс көймәләре шумыймы? Барысы да аңа — Сәеткә билгеле булыр. Үз бәхетен ул да йоклап калмас. Әле базар әһелләре белән ярминкәгә китерелгән мал-туарга хак бәһа кую да алар кулында. Бер генә базаркән дә, алыпсатар да ул хакны бозарга җөрьәт итми. Базарбашының күзләре үткен, колаклары сизгер.

Сәетнең иреннәре дога урынына шушы сүзләрне пышылдады. Артык диндар кеше түгел ул, әмма намазлык өстендә дисбе тартып утыруның үз рәхәте, җанга тынычлык биргеч хасияте бар. Дөнья мәшәкатьләреннән арынып тору рухны ныгыта, канны сафландыра, зиһенне үткенләтә. Тик

---

* *Давылбаз* — бәрмә музыка уен коралы.

мена бүген беренче кат иреннәре дога сүзен түгел, дөнья малын әйтеп селкенә. Хәерлегә булсын!

Сакланып кына муеныннан тамганы алды һәм инде кемнәрнеңдер изүендә йөри-йөри шомарып беткән, бүлмәдәге сүрән яктылыкта агарып күренгән көмеш тәңкәне әйләндерер-әйләндерер карый башлады.

— И хикмәти хода! Бу тәңкәнең нинди яшерен кодрәте бар соң? — Иреннәре үзеннән-үзе шул сорауны кабатлады. Сәетнең йөрәге ашкына; һәр ике ягына нindидер аңлаешсыз билгеләр, башына таҗ кидерелгән канатлы елан сурәте төшерелгән тәңкәнең көчен сынап карыйсы кәрваны белән ерак сәяхәтләргә, каф тау илләренә, сартлар арасына, Рум базарларына сәфәр чыгасы килеп талпына. Күрсәтелгән олуг ышанычны аклау, казнага кирәк малны табу өчен ул теләсә нинди авырлыкларга да түзәргә әзер иде. Ат аунаган җирдә төк кала. Үзенең дә буш калмаячагын, иле-көне бөтәйгәннән-бөтәячәген дә сизенә Сәет. Дөньялар гына имин булсын! Әнә кызы — бер кашык су белән йотарлык Галиясе үсеп килә. Бирнә туплыйсы бар. Бүз бала Җәгъфәр дә сөлектәй егет булып җитешеп бара. Күз генә тимәсен!

Күрше бүлмәдәге кыштырдаган авазларны ишетеп, сискәнеп китте, уйларыннан бүленде, тәңкәне тиз генә куенына яшерде. Гөлйөземнең һичшиксез бу бүлмәгә кагыласын белгәнгә, җанына талгын бер рәхәтлек инде, аның иртәнге наз белән тулы йөзен күз алдына китереп елмаеп куйды.

Хатыны озак көттермәде. «Комачауламасам ярар тагы»,— дип, сакланып кына ишекне ачты, иренең үзен көтеп утыруын күреп, шелтәләп баш чайкады:

— Шушы язгы базар алдыннан чабышка әзерләнгән ат шикелле кыланасың, сиңа әйтәм. Малай чагың узган, аз гына дәрәҗәлерәк кылансаң да ярар иде... Төне буе керфек какмадың бит!..

— Их,— диде Сәет. «Нинди дәрәҗә әле», димәкче булды, ирексездән куенындагы көмеш тәңкәне сыйпап куйды, тик тотлыгып калды. Бөек серне хәтта сөекле хатынына да ачарга ярамый, тылсымлы көчкә ия тамганың мәгънәсен, асыл сыйфатларын белгертергә рөхсәт ителми иде. Әйтеп бирәсе килгәне телендә йотылып калды, иреннәре арасыннан бөтенләй башка сүзләр чыкты:

— Их,— дип кабатлап куйды ул.— Белмисең, Гөлйөзем, олы базар шул чабыш бит инде ул. Кем уза, кем уздыра...

— Ел саен була лабаса. Узсаң да, уздырсаң да, бары-

бер үзеңнән уза алмассың. Безгә артыгы кирәкми. Балалар аякка басып килә... Тормышыбыз түгәрәк...

— Иртә таңнан кире сүзләр белән шелтәләмә әле син мине, Гөлем Мин беләм, быел бөтенесе дә башкача булыр. Шулай тиеш Фәрештәләр шулай белдерде

...Йөзе агарып, беләген канлы чүпрәк белән урап кайткан көннән бирле иренең күзгә күренеп үзгәрүен, үз эченә бикләнүен, кайчакларда саташкандай авыз эченнән нәрсәдер мыгырдануын күргән саен Гөлйөземнең үзәге өзелә, җаны күбәләктәй бәргәләнә башлый иде. Сер яшерә торган кеше түгел иде бит ул. Уендагы телендә, кесәсендәге — кулында булыр иде. Ни булган Сәеткә?' Начар юлга басмагандыр лабаса! Тагын шул халәте кабатланды, әмма шиген чыгарып селкергә ашыкмады, иплэп кенә сорады:

— Авырмыйсыңмы соң син, Сәет? Әллә нишләдең кебек. Мин аңламыйммы?..

— Аңламыйсың шул, аңламыйсың,— дип тәкрарлады ире. Башка вакытта сүз әйтергә дә бирми кочагына ала иде, бүген исә аркасыннан гына сөеп куйды. Аның гайре табигый ялтыраган зәңгәр күзләрендә очыну-канатлану да, шашкын ашкыну да күреп, Гөлйөзем сиздерми генә берничә кат изүенә төкереп алды, үзалдына пышылдады:

— Изгелеккә генә булсын инде. Аллам сакласын... Аллам сакласын...

Тик күңелендәге шик-шөбһә кимемәде генә түгел, киресенчә, тагын да куера төште. Үзенең унҗиде ел бергә гомер сөргән ирен танымый иде ул. Игътибарсызланды, илтифатсызланды.

— Әллә боздылармы үзен? Кемнәр?.. Нигә? Сабыр холыклы, басынкы Сәетнең бозылуы кемгә кирәк булган?..

Сорауларына җавап таба алмады Гөлйөзем. Шәһәр капкасы өстендәге манарада дум-думбакларның аваз бирүе булды, Сәетне алыштырып куйдылар диярсең, йөзендәге елмаю юкка чыкты, җитди бер кыяфәткә кереп, атларга күтәрелгән аягын да идәнгә төшермичә тынып калды.

— Доң-доң-доң-доң...

— Даң-даң...

Дум-думбакларның кайтаваз булып диварларга бәргәләнүче авазлары ишетелгән саен Сәетнең йөзе үзгәрә, башта ул шым калып, иреннәрен кысып, күзләрен зур ачып торган иде, аннан һәр авазга җавап биргәндәй, башын селкеп, «Ыһы, ыһы, ыһы»,— диярга кереште, саргылт мыегы

астыннан ялтырап ак тешләре күренде, битенә елмаю галәмәте чыкты.

Гөлйөземнең исә һәр аваздан йөрәгенә җәрәхәт ясала, һәр аваз авырттыргыч ук булып бәгыренә кадала иде.

Кинәт Сәет шашкын бер көч белән Гөлйөземне кочаклап алды һәм күтәреп бүлмә буйлап әйләндергәч, озак кына җиргә төшерми кысып торды.

Борчылма, Гөлем,— диде ул аны күкрәгенә тагын да катырак кысып,— барысы да без дигәнчә бара Артыгын әйтә алмыйм. Барысы да яхшыга... Әйдә, табын әзерлә Базарга иртәрәк чыгасы булыр.

— Җәгъфәрне уятыйммы?

Башка вакытта эшкә өйрәнсен, кул арасына керсен дип улын үзеннән бер адымга да калдырмый торган Сәет бу юлы ашыгып кул селтәде.

— Юк, юк. Йокласын әйдә. Алып чыгармын әле,— диде ул каударланып.

Бу сүзләре белән Гөлйөземнең бәгыренә тагын утлы күмер салганын ул үзе, әлбәттә, белми иде.

Икесе ике уйдагы ир белән хатын сүзсез генә тәгам җыярга* утырдылар.

ЧАКЫРЫЛМАГАН КУНАКЛАР

Ин әхсәнтүм — әхсәнтүм лиәнфусикум вә ин әсәәтүм фәләхә.

Коръәннән.

Татарчага тәрҗемәсе:

Игелек эшләсәгез дә – үзегезгә,
явызлык эшләсәгез дә үзегезгә.

Мул сулы, йөгерек елга ярындагы болынлыкта көнетөне учаклар дөрли. Таганга асылган җиз казаннарда шулпа быгырдый, ахактай күмер өстендә ит кыза, кайнар көлдә балык мәмри. Елга аръягыннан йомшак җил шомырт һәм болын чәчәкләре исен китерә, алар киндер капчыклардагы йөзем, өрек, күрәгә, исемнәрен белеп бетергесез башка җимешләрнең хуш исе белән аралашалар да баш әйләндергеч бер ымсыну, шушы муллыкка чуму теләге уята-

---

* *Тәгам җыю* — ашау, тамак ялгау.

лар. Төрле-төрле телләрдә, шивәләрдә сөйләшүче базаркәннәрнең шау-шуын күмеп дөяләр кычкыра, сыерлар мөгри, ишәкләр бакыра, атлар кешни... Бу — бөтен җиһанга билгеле атаклы Ташаяк ярминкәсе, казанлыларның мактанычы, горурлыгы.

Үткен сәүдәгәр бу базарда еллык мая туплый, малын алыштыра, бәхәсләшә, тарткалаша, сата, ала, алдый, алдана. Кулдан-кулга елга булып алтын-көмеш ага, базар иясенең ящерен сандыкларына, капчыкларына, янчыкларына күзгә күренмәс чишмә булып саркып керә.

Киштәләрдә камка*, җофар тиресе, гәрәбә, савыт-саба, сәхтиян читекләр, затлы бүрекләр... тәпәннәрдә сары бал, тау-тау өелгән капчыкларда бодай, тары, арпа, көтү-көтү аяклы мал... Тимерче осталарда, һөнәрчеләрдә — шам кылыч, хәнҗәр, көбә, ук-җәя, сөңге очы, түтәләре көмешләп бизәлгән мылтык, тимер баш киемнәре...

Кәрваннарның берсе килә, берсе китә. Тамгачыларга тын алырга да вакыт юк. Һәр яңа килгән кәрванның малын барлап, тиешле күләмдә салымны исәпләп, тиенен-тиенгә хан казнасына алырга кирәк. Мәйдан уртасындагы зур таш аякка** салым акчасы агыла. Аны көн капчыкларга шыплап тутырып, тамгалап хан сараена озата торалар.

Инде иртәнге якта ук эшен бетергән Сәеткә боларны карап йөрү рәхәтлек бирә; озын-озак кыш айларында кыбырсыган җаны ләззәт кичерә иде.

Иртәдән бирле этисенә ияреп, ярдәмләшеп йөргән Җәгъфәргә мондый хисләр таныш түгел әле. Ул инде берничә мәртәбә әйтеп карарды:

— Әти, кайтыйк инде. Эш бетте бит...

— Ашыкма, улым! Кайтырбыз. Эшең пешсә, битең пешми...

Сәетнең һәр сүзендә вәкарь, үз дәрәҗәсен белгән кешеләрнекечә салмаклык, олылык сизелә. Әтисен мондый итеп белмәгән Җәгъфәр аптырый, андагы үзгәрешне күреп, сизеп тора, сәерсенә. Әмма ата кеше моңы үзе белми, улының җилкәсенә кулын салып, тормыш сабагы өйрәтә-өйрәтә атлый.

— Күр, өйрән, мыегыңа чорна. Бу кәсеп сиңа каласы... Бер нәрсәне дә күзеңнән ычкындырма. Кара, хәтереңә сеңдер: кемнәр ни ала? Кемгә нәрсә кирәк? Боларны белеп

* *Камка* — чин ефәге.

** *Аяк* — савыт, *ташаяк* – таш савыт. Ташаяк ярминкәсе дигән сүз шуннан килеп чыккан.

тору — безнең эштә уңышка ирешүнең ярты сере. Оста сәүдәгәр, чын базаркән беркайчан да мондый мөмкинлекне кулыннан ычкындырмас.

Тагын бик күп нәрсәләрне сөйлисе килә Сәетнең. Төшемле булды аңа быелгы базар. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында кайдан нинди мал килүен белеп торуы, тамгачылар күзәтүенә бәйсезлеге аркасында ул туплаган нәрсәләрен бик тиз генә табышлы итеп урнаштырды. Инде туктарга, тынычланырга да мөмкин иде. Әмма базарда көтелмәгән хәлләр туып кына тора. Берсен дә күз уңыннан ычкындырасы түгел. Нургали агага биргән вәгъдәсе, өстенә йөкләнгән йомышы да бар бит әле аның. Сәетнең ышанычны аклыйсы, үзеннән көтелгәнгә караганда да саллырак өлеш белән базарбашы катына барасы килә. Күрсен! Ышансын! Кем белә, алла боерса, киләчәктә тамганы Җәгъфәргә тапшырырга да насыйп итәр. Хәзергә аңа моны белдерергә ярамый. Яшь әле. Кавырсыны йомшаграк, күңелендә яшьлек вәсвәсәсе... Егетне өйрәтергә кирәк. Үзбаш тормыш корасы, дөнья йөген җигелеп тартасы көннәре алда...

Сәетнең уйлары чуала. Җәгъфәрнең бөтен килеш-килбәте белән Гөлйөземгә тартым йөзеннән бөркелгән сабырлыкны, улының басынкылыгын, тырышлыгын күреп, күңеленә тагын рәхәт булып китә. Әйе, юка күлмәге аркылы беленеп торган беләкләрендә көч сизелә, күзләрендә акыл тоемлана малайның. Картлык көнендә таянычы, караучысы булачак кеше үсә. Бәхете, тәүфыйгы гына булсын!..

Ата белән ул акрын гына сәүдә рәтләре арасыннан атлыйлар. Күзләре үткен, колаклары сизгер. Кайда нәрсә бар?

Әнә коралчылар янында ике кеше бәхәсләшә. Җилкәсенә төшеп торган җиту чәчле, көрәктәй сакаллы, өстенә озын кара чирмеш чикмәне кигән сәүдәгәр як-ягына карап ала да янәшәсендәге иптәшенә нидер пышылдый. Аннан соң алар тимерче остага нидер аңлатырга, төшендерергә тырышкандай икесе берьюлы диярлек сөйләргә тотыналар. Күрәсең, бәяне төшертергә телиләр. Әмма кире оста алдына тезеп куйган затлы коралларына кулы белән ишарәли дә баш селки. «Юк! Мондый малны бүтән беркайда да таба алмассыз»,— ди кебек ул.

Сәет аларның сатулашуы белән кызыксынып китүен сизми дә калды. Якынрак килеп, читтән генә күзәтергә кереште, сүзләренә колак салды.

— Бөтен коралыңны тулаем алабыз. Әйдә, кул сугышыйк та — бетерик!

Җиту чәчленең сүзен иптәше куәтләде:

— Без биргәнне сиңа бүтән беркем дә бирми. Саф алтын белән түлибез. Бәһасе нәкъ шулай — ун алтын.

Коралчының йөзенә ачу галәмәте чыкты.

— Сез нәрсә... Корган агачка бәрелүгә яньчелә торган тимер дип белдегезме әллә? Шам корычыннан ясалган кылыч бит алар. Чәч бөртеген урталай яра...

Әйткәннәрен расларга теләп булса кирәк, ул җыерчыкларына күмер-корым сеңгән бармаклары белән чигәсеннән бер бөртек чәч йолкып алды, икенче кулындагы сөяк саплы, бизәкләп эшләнгән хәнҗәрне алдына куеп, чәчне өреп төшерде. Кара төк урталай өзелеп ике якка төшеп китте.

— Күрдегезме? Мондый хәнҗәрне сез бүтән базарда мәңге таба алмыйсыз,— диде ул канәгать елмаеп.— Сере менә монда. Башка җирдә юк.— Һәм ул үзенең маңгаена төртеп күрсәтте.

Сатулашучылар бер-берсенә мәгънәле карашып алдылар.

— Яхшы, тагын бер алтынга арттырабыз,— диде яшьрәге.

Сәүдәгәрләр татарча сөйләшсәләр дә, калын авазларны нечкәртеп, сүзләрне тырышып әйтүләреннән аларның казанлы да, чирмеш тә түгеллеген аңларга була иде. Шулай ук алар Кырым, Әстерхан иленнән дә, Сәмәрканд яисә Себердән дә түгел, ят бер кавемнән иде. Румнан да булмаслар. Алар башкачарак. Әрмәннәр түгел дә түгел. Алар кара була, олы күзле була. Боларның исә чәчләре җитенсыман, чырайлары кояшта кызарып өлгерсә дә, яка турындагы муеннары агарып күренә иде.

Сәетнең йөрәге дерт итеп китте. Әллә нинди, үзе дә аңлатып бирә алмас бер сизенү белән ул аларның кай яктан икәнен чамалап алган иде. Алар белән аралашудан качарга тырыша, күп еллар элек булган вакыйгаларны күңелендә бер дә яңартырга ашкынып тормый иде. Өзелгәнне кире ялгыйсы килми, авыр хатирәләрнең кабатлануын теләми. Үткән, беткән. Шушы Казанда Гөлйөзем белән, балалары белән тыныч кына яшәргә иде бит!.. Очрашу, аралашу җанына шик-шөбһә иңдерәчәк, сүндерергә тырышкан вәсвәсәле уйларны азындырачак иде.

Дулкынлануын янында гына басып торган Җәгъфәргә сиздермәскә тырышып, аны җиңеннән тартты.

— Китик, улым!

Көтмәгәндә Җәгъфәр каршы төште.

— Хәтерлисеңме, эти, балигъ булгач, сөяк саплы хән-

җәр бүләк итәрмен дигән идең. Мин менә шундыйны теләр идем,— диде ул коралчы кулындагы хәнҗәргә ишарәләп.— Тагын ун көннән миңа уналты тула...

Җаны карышса да, малаеның сүзен аяк астына салырга базмады. Әйткәне хак иде, вәгъдә биргән иде. Сүзендә тора белүе белән дә улында тугрылык, ихтирам тәрбияләргә теләгән ата буйсынмыйча булдыра алмады.

Сатулашучылар янына килделәр. Җәгъфәр коралчы оста алдындагы хәнҗәрләрдән иң затлысын — саргылт шома сөяк сабына уеп чәчәк-бизәкләр төшерелгәнен, күгелҗемзәңгәр төс белән балкыган корычлысын алды.

— Купме сорыйсың? — диде Сәет.

Сатулашудан, әйберләрен мактаудан аерым бер тәм таба торган коралчы җавап бирергә ашыкмады.

— Мин аларны мал рәтен белгән кешегә генә сатам,— диде ул ачулы тавыш белән.— Андый хәнҗәрне көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Уенчык түгел ул...

Күңелендә авыр хатирәләр уяткан сатулашучылар яныннан тизрәк китәргә теләгән Сәет җавап биреп тормады, кесәсеннән ике алтын чыгарып коралчыга сузды.

— Сатулашмыйк. Шушыңа ризамы?

Останың шатлыгы йөзенә бәреп чыкты. Ул мондый бәһагә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, сүзсез калды. «Менә күрдегезме?» дигәндәй каршындагы сәүдәгәрләргә төбәлде. Шул мизгелдә Сәет тә аларга борылды һәм... җиту чәчле, кара киемлесенең текәлеп үзенә каравын абайлап алды. Куе, калын кашлары астындагы яшькелт күзләр аны бораулый сыман иде. Кем диярго соң моны? Кайдадыр күргәне дә бар түгелме? Исенә төшерә алмады. Җәгъфәргә ым кагып, бу сәер сәүдәгәрләр яныннан китәргә ашыкты.

Кемнәр иде соң болар?! Әгәр таныш булсалар, нигә үзләре эндәшмәде? Чыннан да, урысламы соң алар? Гадәттә урыс сәүдәгәрләре Казанда болгари күн эзли, сәхтиян читек, көмеш савыт-саба, алка, йөзек, беләзек ала, ашлык төятә. Ә болар коралчы янында. «Бәлки ялгышамдыр» дип куйды Сәет, онытылыр өчен, шатлыгын уртаклашырга теләгәндәй, хәнҗәр белән уйнап баручы улына карады. Ләкин тынычлана алмады. Күңелендә борын төрткән сорауларга җавап табасы килә иде.

Кинәт аның башына уй килде.

— Син, улым, кайта тор! Гарәп сәүдәгәрләрен күреп сөйләшәсем бар икән. Онытып җибәргәнмен,— диде ул һәм малаен озатырга ашыкты.

Кулына чып-чын хәнҗәр эләгү шатлыгыннан дөньясын

оныткан Җәгъфәр аны-моны сорап тормады, шәһәр капкасына таба йөгерде. Сәет исә кеше-кара күзенә бик чалынырга теләмичә, акрын гына атлап, бөтенләй икенче якка — яңадан коралчылар рәтенә таба китеп барды.

Корал — кыйммәтле мал. Аны, гадәттә, сайлап, җентекләп тикшереп алалар. Корал янында яшь-җилкенчәк, азамат ирләр кайнаша. Сәет тавышсыз-тынсыз гына шул төркемгә кушылды.

Коралчылар рәте каланың колач җиткесез юан имән бүрәнәләрдән бурап күтәрелгән биек коймасы ягыннан Казан суына кадәр сузылган иде. Осталар башка сәүдәгәрләр шикелле кеше чакырып кычкырмыйлар, дәрәҗәләрен белеп, язгы кояшта җылынып утыра бирәләр. Базардагы һәр хәрәкәтнең, айпалу-чайпалуның мәгънәсен төшенеп алырга күнеккән Сәет ныклабрак караган, күзәткән саен мондагы яшерен җанлылыкны тоя барды. Башка вакытта хөкем сөргән сабырлык, вәкарь, тәкъвалык беткән кебек иде. Табигый ки, моны базарга беренче тапкыр килгән кеше күрмәс-сизмәс иде. Әмма бүз бала чагыннан бөтен гомерен сату-алуда үткәргән Сәетнең үткен күзләре башкалар күрмәгәнне күрә, колагы күпне ишетә, акылы һәр чалымда мәгънә таба иде.

Әнә йомышчы малайлар әрле-бирле йөренә. Йөзләреннән балаларча гамьсезлек качкан. Әле бер, әле икенче төркем янына нидер китерәләр, алып китәләр. Тагын бер нәрсәгә игътибар итте сәүдәгәр — сатып алучылар арасында кайдан кем икәнлекләрен танытмаслык итеп тоташ карадан киенгән елгыр адәмнәр күп. Алар артык сатулашмый, күп әйберне тулаем алалар булса кирәк, нигездә сүзне кул сугышып бетерсәләр дә, тоткан нәрсәләре күренми. Моны да аңлый Сәет — кичен аларның олауларына килешенгән таварлар китереләчәк. Төнлә яисә таң алдыннан ул олаулар тавыш-тынсыз гына каядыр юкка чыгачак.

Бу начар фал. Коралны күпләп алучылар изгелектә йөрмәс. Хәрамзадәләрнең* кайсы кавемнән икәнен тәгаенләсә дә, нинди таифәдән, нинди максат белән йөрүләрен аныклый алмый. Кемнәр алар? Идел өстеннән көймәдә, салда агучы сәүдәгәрләрне дер селкетеп тотучы елга юлбасарлары — ушкуйникларсы, әллә патшаларына баш бирмәскә талпынучы берәр урыс кенәзенең кешеләреме? Әллә

---

* *Хәрамзадә* — бозык кеше, ялгыш юлда йөрүче.

Казанның үзенә үк куркыныч яныймы? Дөньялар имин түгел. Казанлыларга хөсетле Шаһгали дөньяны бутап киткәннән бирле кырмыска оясыдай гөжләгән каланың тынычланып җитә алганы юк. Хәер, шөкер, соңгы вакытта Әстерхан белән дә, Кырым белән дә дуслык ныгыды. Алар артында бөек һәм изге солтанның куәтле калканы бар. Шаһгали дә борынын тыгарга җөрьәт итмәс, иншалла. Тагын сәүдәгәрләр турында уйлый башлады. Боларның Казанда бистә булып яшәүче урыслар белән бер-бер бәйләнеше юкмы? Кемнәр генә булмасын, коралны күпләп алу өчен алтын-көмешне кызганмаулары хак иде.

Иң беренче теләге күргән-белгәннәрен түкми-чәчми тизрәк базарбашына җиткерү булды. Күңелендә укмашып килгән шик-шөбһәләрне аңа җиткерәсе, нииндидер сәер хәзерлек турында кисәтәсе иде бит! Әмма башына икенче бер уй да килде: Казаннан алып Әстерханга, Кырымга гына түгел, Чин дәүләте чикләренәчә таралган базарларда шылт иткәнне дә белеп торучы базарбашы бу хәлләрдән хәбәрдар түгелдер дисеңме?! Юк-бар шигең белән олуг кешеләрне бимазалап йөрү килешерме? Иң яхшысы Әҗем карт белән сөйләшү булыр иде дә, аны иртәдән бирле базарда очратканы юк. Әллә сырхап киткән, әллә эшне йомышчылары, ярдәмчеләре аша гына йөртә? Кем белсен, һәр базаркәннең, малтабарның үз йоласы, үзенчә эш йөртү рәвеше бар. Ярминкәнең иң кызган чагында берничә көнгә югалып тору Әҗем карт өчен ят нәрсә түгел. Югалып торыр да, күз күрмәгән, колак ишетмәгән ят мал белән базар теленә керер.

Аптырашка калды Сәет. Белгән хәтлесен башкалар белән дә уртаклаша алмый. Сарай әһелләре аңа ят: биләр, карачылар Сәет-сәүдәгәр белән аралашырга бик атлыгып тормый. Эре халык!

Шулай да күзәтүләрен ахырынача җиткерергә карар бирде. Коралчылар рәтенең буеннан-буена ашыкмый гына узды да, гадәттә урыс сәүдәгәрләре урнаша торган якка — Болак буена төшеп китте. Монда — ашлык сәүдәсе. Казан ханлыгының туфрагы уңдырышлы. Бәрәкәтле, ашлы җирләр. Базарда арышы, бодае, тарысы, арпасы дисеңме, ногыт яисә борай дисеңме — барсы да бар. Аллаһы тәгалә мәрхәмәтле булды. Соңгы ике-өч елда явым-төшем җитәрлек; яз-җәйләре вакытын белеп кенә, көттермичә генә килде, игеннәр каерылып уңды.

Ул яхшы белә: иген уңмаган, алла рәхмәтеннән читкалган илләр дә бар. Алар ашлык өчен алтынын да, көмешен

дә, газиз хатынын да кызганмас. Ничәнчедер сәндә Болгарга хатыннарын-кызларын китереп, кол, кәнизәк итеп сатып йөргән урысларны казанлылар әле һаман да гыйбрәт итеп сөйли. Ачлык — мәрхәмәтсез, аннан да явыз нәрсә юктыр! Шөкер, казанлылар тилмерми...

Болак буенда сату-алу кайнамакта. Ярдан су эченә сузылган агач басмалар икешәр батманлы* капчык күтәргән йөкчеләрнең йөгерә-атлый узуыннан сыгылып-сыгылып кала. Амбар-келәтләрдә тау-тау өелгән ашлык әкренләп көймәләргә күчә.

Көймәләр күп. Аларның икешәр-өчәр җилкән күтәргән биниһая олылары да, тар күкрәкләре белән Идел суын ярып коштай алга җилкенерлек тиз йөрешле — ишкәклеләре дә бар. Егерме-утыз колны чылбырлар белән ишкәк янына богаулаган андый көймәләрне күрүгә Сәетнең йөрәге дерт итеп куя:

— Аллам сакласын! Коллыкка әсирлеккә төшүдән дә кызганыч, үкенечле хәлне ул белми

Үткен күзе тагын шуны абайлап өлгерде: көймәләрнең күбесе урысныкы. Ашлык җыя, корал туплый урыс. Юньлегә түгелдер!.. Аянычлы көннәр артта калды, тыныч кына, иминлектә яши башлаганнар иде түгелме соң?! Казан өстендә тагын кара болытлар куерамы әллә?

Сәет үзенең генә башы җитмәслек авыр уйлардан уфтанып куйды һәм ичмасам күзем күрмәсен дип, кире калага таба борылды. Аяк астындагы сукмакны да, тирә-ягында шаулашучы базаркәннәрне дә, күк йөзендә ишелеп-ишелеп кургашын төсендәге болытлар уйнаганны да ул күрми иде. Миендә мең төрле сорау бәргәләнә. Тагын кемнәрнеңдер каны коелачак, кемнәрнеңдер яшьләре, каргышлары, аһзарлары белән җир тулачак. Мин нишлим?! Мин нишләргә тиеш?

Бик сорашасы, белешәсе килсә дә, урыс сәүдәгәрләре янына бара алмый иде Сәет. Алар арасында күренмәскә, аралашмаска тырышуының үзе һәм бөтен калада берничә генә кеше белгән яшерен, кемгә дә әйтә алмаслык сере бар. Күрәсең, ул үзе белән бергә каберенә дә керер.

Сәет шулай дип уйлый, шуңа ышана, шул ышаныч белән яши. Улы Җәгъфәрнең, кызы Галиянең бәгырьләренә тоз салырга, гөнаһсыз чиста җаннарына кагылырга, шик яисә үкенү уятырга теләми.

---

* *Батман* — дүрт пот чамасы авырлык үлчәве.

Баһадир гәүдәсе бердән кечерәеп калгандай булды, башы аска иелде. Иртәнге шатлыгының, уңышлы сәүдә сөенеченең эзе дә калмады. Шик корты кешене эчтән кимерә, күзгә күрсәтми генә бәгырен ашый, тәнен киптерә.

Каршында кинәт үсеп чыккан шәүләдән сискәнеп китте Сәет. Юлга җәелгән имән такталарның нәкъ ул барган сайгагында кара киемле сәүдәгәр басып тора иде. Коралчы белән сатулашкан яшькелт күзле кеше түгелме сон бу? Әнә ич, күзләре тагын аны бораулый, кызыксынып, җанына үтәрдәй булып чекерәйгән.

Шикләнүе йөзенә чыкты булса кирәк, кара киемле аны тынычландырырга теләгәндәй, кулын күтәреп сак кына ишарә ясады, тавышы да шыпырт чыкты:

— Син миннән курыкма, юлбасар түгелмен,— диде ул тирә-ягына каранып.

Базар белән шәһәр арасын тоташтырган җәяүлеләр сукмагында кеше-фәлән күренми иде. Кара киемле якыная төште һәм сүзен дәвам итәргә теләп авызын ачты.

Сәетнең бер генә кеше белән дә сөйләшәсе, бигрәк тә үзе шикләнгән адәмнәр белән аралашасы килми иде, бүлдерергә ашыкты.

— Минем сезнең белән бүлешер малым да, сөйләшер сүзем дә юк,— диде ул шушының белән очраклы кешедән аерылып китәргә теләвен аңлатып.

— Ашыкма... Ашыкма,— дип кабатлады яшькелт күзле.— Куенымда таш түгел. Әйтеремне тыңла да, үзең хөкем чыгарырсың. Ни кылу — анысы синең кулда.

Кызыксынуы шөбһәсен җиңде, Сәет тыңларга әзерлеген белдереп башын иде.

— Әйтеп кара! Тыңлыйм...

Кара киемле көтмәгәндә аның колагына пышылдады:

— Савелий Кузьмичны беләиденме?

Сәетнең башына суктылармыни, тын алуы авырлашты, битенә, колакларына кан йөгерде, муенына хәтле тимгел-тимгел кызарып чыкты, ни әйтергә белмичә, тораташтай катты да калды. «Менә, унҗиде ел үткәннән соң!» — дип уйлап куярга гына өлгерде ул. «Юк!» дияр иде, үзен тотышы, битенә йөгергән кан аның белгәнлеген кычкырып тора. «Әйе» дияр иден, ул сүз артыннан тагын нинди хәбәрләр ишетәчәге өркетә, җанына күтәргесез таш булып баса иде. Ләкин күпме генә каушамасын, ул үзенең бу кеше яныннан тиз генә китә алмаячагын да аңлый. Савелий Кузьмич дигән бу исем аның бөтен ихтыярын богаулап куйган, аны үзенә чакыра, тарта, кара киемле артыннан

теләсә кая барырга мәҗбүр итә иде. Үзе дә сизмәстән, Сәет ике ут арасында калды. Ләкин теле әйләнмәде, моннан күп еллар элек ясалган яшьлек хатасы аның телен бикли, сүз әйтергә комачаулый иде. Кыяфәтенә битарафлык чыгарырга тырышып, сүзсез генә кара киемленең йөзенә текәлде.

Шактый озак басып торгач, ниһаять, ул телгә килде:

— Кайдадыр ишеткәнем бар иде кебек...

Теле тотлыкты, бәйсез һәм җиңел генә әйтеп салырга теләгәне килеп чыкмады.

Кара киемле исә, шулай булырга тиешлеген көткән, ни булачагын алдан белгән кешедәй, артык каушау галәмәте күрсәтмәде, шулай ук йөзендә сөенү әсәре дә юк иде.

— Шулайдыр дип уйлаган идем аны,— диде ул һаман да тавышын күтәрмичә генә.— Ни булса да, минем сиңа әйтер сүзем бар. Савелий Кузьмичның гөнаһысына кермим, әйбәт адәм иде... Йә, тыңлыйсыңмы?..

«Нигә «иде» дип сөйли? Нигә һаман сер яшерә бу?» Сәет кара киемленең сүзләреннән бөтенләй тәкатьсез калган иде, бар белгәнен тыны белән суырып алырдай булып, күзләренә текәлде.

— Кеше күзенә бергә чалынуыбыз хәерлегә булмас... һәрхәлдә сиңа... Әнә яңгыр да яварга җыена,— диде кара киемле күк йөзенә ишарәләп.— Аулаграк җирдә сөйләшсәк сиңа да, миңа да мәслихәтрәк булыр.

— Соң... алланың рәхмәте,— дип икеләнебрәк башлаган Сәеткә артык сүз озайтырга ирек бирмәстән, ул ышандырырлык итеп, кырыс кына берничә сүз әйтте:

— Исмәгыйль бай кәрван-сараенда! Унҗиденче бүлмә... Көтәм.— Һәм күтәрелеп тә карамыйча ашыгып китеп барды.

«Барыргамы, бармаскамы?» Сәет икеләнеп калды. Күңел төбендә бөреләнгән шик тойгысы яңадан канат җәйде, яндыргыч авырту белән йөрәген кысып алды. «Тукта! Болар нindидер мәкер белән Сәетне тозакка кертергә маташмыймы?!»

Кара киемле артыннан атларга күтәрелгән аягы кире җиргә төште, үзе генә хәл итә алмаслык четерекле сорау сызландырып миен бораулый башлады. «Әллә соң туптуры Нургали ага янына китәргәме? Аңлар иде, бер-бер чара күрер иде бит. Белгәннәрен үзендә яшереп калдырса, мәңге үкенеп яшәргә туры килмәсме?!» Кистереп кенә «Юк!» дип чакыруны кире какмавына үртәлеп, үз-үзен белештермичә иреннәрен чәйнәргә керешә.

Хәер, шулай уйланса да, котылгысыз тоелган хәлдән чыгу юлын эзләп бәргәләнсә дә, ул үзенең ни өчен буынсыз калганлыгын яхшы белә, баш тарта алмаячагын да ачык тоемлый иде. «Уф! — дип куйды Сәет.— Бәла агач башыннан йөрми... Күрәчәгең булса...» Уйлаганының, чуалчык фикерләренең очына чыга алмады, кул селтәде дә мәҗбүри барган кеше төсле акрын гына атлап, шәһәр капкасына таба, таныш түгел кеше артыннан кузгалды. Билгесезлек дип аталган тәшвишле уй-шөбһә җанын кыйный, ачык җәрәхәткә салынган тоз шикелле бәгырен телгәли, сулкылдата иде.

Кәрван-сарай шәһәр капкасыннан ерак түгел. Урта кулданрак исәпләнгән бу кунак йортына хәллерәк сәүдәгәрләрнең сирәк тукталганын белә иде Сәет. Бик үк чиста куллы булмаган кешеләрнең җыелу урыны дип тә ишеткәне бар. Уй-максатын уртага салып сөйләшергә күнеккән малтабарлар белән эш итәргә яратучы Сәетнең күңеле тартмый, аягы атларга теләми. «Шәһәр капкасы ерак түгел. Ул-бу булса... андагы сакчылар ярдәмсез калдырмас. Бер чакыру җитәр» дип үз-үзен тынычландырырга тырышты, аягын сөйрәп, сугымга алып барылучы мал шикелле тартылып атлады да атлады. «Савелий Кузьмич әйбәт адәм иде» дигән сүзләр аны үз ирегеннән башка алга өстери иде.

Бөтен җиһан кинәт караңгылыкка чумды, әйтерсең лә кара болыт убылып җиргә төште. Юка тузан элпәсе белән капланган сайгаклар өстендә эре-эре тамчылар биешә башлады. Тыгыз һәм куе яңгыр пәрдәсе тирә-якны томалап алды, күз күреме ераклыкта бер генә нәрсәне дә абайлап булмаслык эңгер-меңгер урнашты.

Таш капкадан ничек узганын да, кәрван-сарай ишегалдындагы шау-шу, атлар кешнәвен, хезмәтчеләрнең тыз-быз йөгерешүен, биек баскычтан күтәрелеп, гөмбәз түшәмле алгы якка ничек килеп керүен дә сизми калды Сәет. Алгы яктан өч тарафка сузылган тар аралыкта ут юк, кешекара күренми, тыштагы гарасаттан соң бар нәрсә үле тынлыкка чумган кебек иде. Кая барырга белмичә аптырап калды. Бераздан күзләре иялəшә төште, бүлмә ишекләрендәге саннарны абайларлык хәлгә килгәч, күңелендәге шомны җиңәргә тырышып алга атлады.

Унҗиденче бүлмә уртадагы бүлемтекнең иң азагында, җир астына уелып кергәндәй, тар бер аралыкка урнашкан иде. Сакланып кына ишекне этте. Калын имән такталар тавышсыз ачылды, төсле пыялалар аша саркыган сүрән як-

тылыкта ул әлеге дә баягы кара киемле кешене күреп алды.

— Әйдә, уз, Александр Савельич,— диде бүлмә хуҗасы карлыккан тонык тавыш белән.— Шикләнмә! — Һәм туптуры итеп күзенә карап торгач, ашыкмый гына өстәде.— Килереңне белә идем...

Сәетнең бугазына төер килеп тыгылды, тагын базардагы халәте кабатланды — башына кан йөгерде, үз-үзен белештермичә ишек катындагы урындыкка килеп төште.

— Син... син ялгышасың! Мин Сәет Сәлим углы,— дип пышылдады ул якасын ычкындырырга тырышып. Тавышы гыжылдауга охшап чыкты. Тыңлаусыз бармаклары күлмәк сәдәфләрен таба алмый интекте

— Исемеңне алыштырсаң да, кыяфәтеңне алыштыра алмагансың, Санька! Мин таныдым сине... Ә син... хәтерлисеңме?..

Кара киемле кеше артык тыныч иде. Аның бу тынычлыгы акрынлап Сәеткә дә күчә башлады, бернинди куркыныч янамавын тоемлап, сәүдәгәр үз-үзен кулга алды һәм иплэп кенә бөтенесен дә ачыкларга дип, күңеленә беркетеп куйды.

— Йә, шулай да булсын ди. Сузмыйк. Сиңа миннән ни кирәк? — диде ул битараф күренергә тырышып.

— Берни дә кирәкми, Санька,— диде кара киемле.— Ни өчен үзеңне танытмаска тырышуыңның сәбәбен белмим, нишләп исемеңне-җисемеңне алыштыргансыңдыр — анысы да миңа мәгълүм түгел. Гөнаһыңа кермим. Теләмисең икән, сөйләмә...

Урыс сәүдәгәре сөйләвеннән туктап калды һәм кулларын артка куеп ишекле-түрле йөренергә тотынды. Аның дагалы итекләре шыгырдый, авыр гәүдәсеннән идән сайгаклары сыгылып-сыгылып кала иде.

— Әйе, миңа синнән берни дә кирәкми,— дип кабатлады ул Сәет янына ук килеп.— Әмма этиеңә биргән сүзем бар, васыятен үтәми калып, гомер буе күңелемдә гөнаһ ташы йөртәсем юк.

Сәет аның күкрәгенә ишелеп төшкән куе кара сакалына, төк баскан зур битенә, яшькелт күзләренә күтәрелеп карады һәм кинәт эчендә еллар буе хәтерен бәйләп торкан ниндидер җеп шартлап өзелгәндәй булды

— Син... син Иван дәдәй түге ме соң? — дип пышылдады ул үз-үзен белештермичә. Бите чин кәгазедәй агарып калды, бармаклары дерелди башлады.

Кара киемленең исә битендә бер төге дә селкенмәде, ул Сәетнең күзләренә текәлгән һәм моннан унҗиде ел элек

Идел дулкыннары кочагында югалган серне белергә теләгәндәй, бәгыренә үтәрдәй булып бораулый иде.

Авыр тынлыкны күтәрә алмады Сәет, күзләрен читкә күчерде, карашы бүлмә эчендәге җиһазлардан, түшәм, тәрәзә буйларыннан йөгереп узды. Мие котырынып эшли башлады. Очраклы рәвештә генә аның кемлеген, нинди юлда йөргәнлеген, вөҗүде шапшаклыгын белгән, сизенгән иде. Бу кеше теләсә нинди мәкерне дә калтыранмыйча эшли алачак иде. «Әгәр ишеккә ташлансам»,— дигән уй чагылып үтте. Ләкин кара киемленең бер кулы билендәге хәнҗәренә таянган, ул тын да алмый Сәетнең ни әйтерен көтеп тора. Сәет уеннан кире кайтырга мәҗбүр булды. Көч ягыннан аңа бирешмәслеген белсә дә, мәсьәләне ничек тә тыныч хәл итәргә кирәк, серле тамга иясенең базар башбаштаклыгында катнашырга хакы юк. Чигенер юл юк иде. Бөтен кәрван-сарай кара киемле урыс кешеләре белән мыжлап тора. Моннан чыгып китә алса да, караңгы борылышларның берсендә аркасына пычак килеп кадалмаячагын беркем дә әйтә алмый. Үзенең хәле белән килешергә мәҗбүр Сәет, ашыкмыйча гына әңгәмәне дәвам иттерергә булды. «Инде буласы булган, кайчан да бер кылган җинаятең өчен җавап бирергә дә кирәктер. Хәер, җинаятьме соң ул?! Котылгысыз бер яшьлек шаяруы гына түгел идеме? Иван-сәүдәгәрнең үз өстендә тагын да пычраграк җинаятьләр бар түгелме?» Уйларының очына чыга алмады. «Һәр адәм баласы үзе өчен үзе җавап бирергә тиеш. Иваннан да сорарлар әле ул әҗерне...»

— Мин китергән зыянымны уны белән каплый алам. Бәхилләтермен. Дөнья булгач, төрле хәлләр була тора. Тау белән тау гына очрашмый. Адәми зат юллары исә бер аллага гына мәгълүм,— диде ул, ниһаять, сабырлыгын, батырлыгын җыеп.

Кара киемле җиңел сулап куйды.

— Таныдың! Миһербаның бетмәгән икән әле,— диде ул читкәрәк китеп.— Әйдә, түрдән уз. Бабайлар әйтмешли, аяк өстендә хакыйкатьне ачыклап булмый.— Канәгать кыяфәт белән кулларын угалагач, тагын өстәп куйды.— Мин синнән акча юллап килмәдем. Түләргә теләсән, гаебеңне йолар өченгә башка юллар да бар... Сөйләшербез...

Сәет өстәл янына күчеп утырды. Кара киемле кемнедер көтә идеме, әллә кемнән дә булса шикләнә идеме — ишек янында колак салып тыңланып торгач кына, аның каршында урын алды.

— Әйе, мин синнән акча юллап килмәдем,— дип кабат-

лады ул тагын бер мәртәбә.— Үткән эшкә салават. Шулай бит... Әтиең мәрхүмнең теләге шундый иде...

— Ә ул кайчан... ничек?..— Сәетнең күзләренә яшь тыгылды, әмма үзенең халәтен Иван-сәүдәгәргә сиздерәсе килми, бөтен түземен җыеп, бәгыреннән күтәрелеп килүче ачы дулкынны тыярга тырыша, тышына чыгармый иде.

— Анысын да ишетерсең... Иң элек атаң васыятен үтим. Үлгәндә дә синең Иделгә батуыңа ышанмады ул. Һаман көтте, кешеләргә белдерми генә, аһ-зарсыз, канъяшьсез генә елады. Көтте. Әйе, синең үлемеңә ышанмады, нидер сизенеп яшәде. Васыяте дә шул: кайда да булса, кайчан да булса юлларыгыз очрашса — төпчегемә, улыма, Санькага ярдәм ит, туры юлга чыгар, мәрхәмәтеңнән ташлама, диде. Алдангандыр ул, күзен ач, диде.— Иван-сәүдәгәр авыр сулап куйды, бу хатирәләрдә казыну аның үзенә дә җиңел түгел идеме, кулы белән авызын каплап йөткереп куйгач, тагын дәвам итте.- Синең монда ничек килеп эләгүең, ничек яшәвең миңа караңгы. Әмма күрәм, яхшы ук дәрәҗәле, маллы, хәлле кеше булгансың. Кыяфәтең дә безнекечә түгел,— диде ул Сәетнең өстендәге Казанча киемнәргә, мөселманча калдырылган сакал-мыегына ишарәләп.— Ата-баба юлыннан читкә тайпылгансың... Әмма аларда минем эшем юк. Аларын... үзегез хәл итәрсез...

«Кем белән хәл итәрбез. Кем ул тагын?» дип сорамакчы булган Сәетне күз карашы белән генә туктатты һәм иелә төшеп, як-ягына карангалап, пышылдарга кереште.

— Сер сыйдырыр кешеме син? Бу сүзләрнең моннан беркая да чыкмаячагына ант итәсеңме? Артыгын сорашмаячаксыңмы?.. Ант ит! Итәсеңме?..

Иван-сәүдәгәрнең серне акрынлап-акрынлап кына, җанын суыргандай газаплап, әйтеп бетермичә чыгаруыннан үртәлгән Сәет ни эшләргә белми иде. Әтисе, туганнары, әнисе хакында ишетәсе килү, моннан унҗиде ел элек өзеп ташланган җепне ничек тә булса ялгап карау теләге аның ихтыярын сындыра иде.

— Ант, ант, ант,— дип кабатлады ул үзе өчен әле һаман сер булып калган кара киемленең сүзләреннән сихерләнгәндәй.

— Алайсаң, тыңла! Кыяфәтең үзгәрсә дә, тәнеңдә безнең кан — урыс каны агадыр. Онытма! Кем булсаң да киңәшемне тот: Казанга олы афәт яный. Үзең генә китәсеңме, балаларыңны, хатыныңны аласыңмы — анысы синең эш. Әмма исән калыйм дисәң, якты дөньяда яшим дисәң, сузма, кит. Мәскәү иленә кайтасыңмы, башка берәр якка чыгып югаласыңмы — әйтә алмыйм. Бер нәрсәне төгәл беләм, Ка-

зап өстенә моңарчы булмаганча афәт килә, кан-яшь килә. Шәһәрегезнең ташын-ташка, агачын-агачка актарып ташларлык көч килә. Күк йөзен канлы болыт каплар. Исәпне өзәр чак җитте. Башкасын әйтә алмыйм, сорама да, төпченмә дә. Телем йозакта. Хыянәткә кереп җанымны пычратасым килми...

Кара киемле изүеннән көмеш тәре чыгарды, аны үбеп чукынып куйды һәм үзалдына пышылдады:

— Савелий Кузьмичка биргән вәгъдәм үтәлде. Җаным тынычланды. Йа ходаем, үзең сакла, дошманнарның күзен капла, күңелемдәге тәшвишне алып ташла. Үлгәннәр алдындагы бурычымнан азат ит! О мәрхәмәтле Иисусе Христосе...

Сәетнең күңелендәге шом, караңгы уйлар таралмады гына түгел, ә тагын да куерып, каты таш булып бәгыренә ятты, авырттырып йөрәген кыса башлады. Ант белән телен бәйләп куйган бу адәмнән башкасын сорашып та, белешеп тә булмый иде инде. Китәргә җыенып урыныннан күтәрелде.

— Өстемнән авыр йөк төште,— диде кара киемле җиңел сулап һәм Сәетнең китәргә җыенуын, аптыраулы карашын күреп, янәдән утырырга ишарә ясады.

— Аз гына сабыр ит! Хәзер... күрерсең! Мин комачауламыйм...— һәм каударланып, үзеннән һич көтелмәгән җитезлек белән чыгып та китте.

Шактый озак утырды Сәет. Төсле пыяла аша бүлмәгә кичке эңгер керде, еракта дөяләр бакыруы, базардан кайтучыларның чыр-чу килеп сөйләшүе, бер-берсенә кычкырып эндәшүләре ишетелде. «Әллә ташлап китәргәме?» дип уктался да, серле җепләр белән бәйләнгән, ант сүзе белән үзен шушы адәмгә беркетеп куйганлыктан, бер карарга да килә алмады, бер ноктага текәлеп утыруын белде. «Тагын ниләр булыр? Язмыш аңа тагын нинди сынаулар әзерли? Иван-сәүдәгәрнең сүзләре чынмы? Чын булса миңа нишләргә?»

Шартлап ишек ачылды. Сискәнеп башын күтәргән Сәет ишек катындагы кешене күреп кычкырып җибәрүен сизми дә калды.

— Васька!.. Синме бу?..

— Санька! Брат ты мой непутевый...

Берничә мизгелдән бер-берсенә бер тамчы судай охшаш, баһадир гәүдәле бу кешеләр үз-үзләрен белештермичә кочаклашалар, аркаларына шап-шоп бәрешәләр иде.

— Чынлап та синме соң бу, Санька, Санек?

— Мин булмый кем булсын, Василий. Ә бу синме соң?!

Васька бераз читкәрәк китеп карап тора да тагын Сәетне кочагына ала, туктаусыз сөйләнә:

— Их, Санька, Санька!.. Батып үлгән кеше идең бит әле син!..

Туганнар сөешеп туймастай булып, күзләре талганчы бер-берсенә карашып тордылар. Ниһаять, Васька күрешү хисләреннән айныды булса кирәк, бармагын шартлатып куйды.

— Нигә болай шаккатышып торабыз соң әле!.. Таң атканчы төн безнеке... Әй, йомышчы!..

Ул ишеккә тибеп җибәрде һәм караңгылыкка кычкырды:

— Йомышчы! Кадалып киттеңме әллә! Кайда йөрисең?

Кесәсеннән чакма чыгарып өч япьле бакыр шәмдәлгә ут элдерде һәм тиз арада хезмәтчеләрдән кемнең дә булса керүенә тәкате бетеп, бәрелә-сугыла чыгып та китте. Бераздан аның балкыган йөзе күренде.

Өстәлгә ак керәчтән эшләнгән савытлар белән төрле тәм-том кереп утырды, олы җамаяктагы пешкән иттән борыннарны кытыклап хуш ис таралды. Василийның бер бармак шартлатуыннан ни әйтергә теләвен аңлаган йомышчы малай нечкә борынлы озынча балчык кувшиннар кертеп утыртты.

Ширбәт, кымыз, ачы балдан гайре эчемлек татып карамаган, ислам кануннары кушканча яшәргә гадәтләнгән Сәет ул савытларда шәраб китерелгәнлеген бик яхшы белә иде. Кәрван-сарайда Румнан, урыс иленнән, Әрмәнстаннан килүчеләр өчен шәраб та тотылу беркемнән дә сер түгел. Һәркемнең үз йоласы. Казанлылар чит-ятларның гореф-гадәтенә тыкшынмый. Әмма эчәсе, үзен исерткеч белән ярсытасы килми иде Сәетнең. Шулай да каршы төшүне яхшысынмады. Уналты ел бер болыннарда аунап, бер чишмә суын эчеп, бер ятакта тәгәрәп үскән газиз туганының бер генә теләгенә дә каршы килә алмый иде ул.

Өстәл янына утырыштылар. Василий касәләргә нечкә кувшиннан эчемлек койды. Туганнарның берсе почмакка борылып чукынып алды, икенчесе авыз эченнән генә: «Бисмиллаһе иррахман иррахим»,— дип пышылдады. Аның нидер укынганын күреп, Васяның күзләре сәер ялтырап алды, тик ул аны сиздермәде, энесен хуплагандай баш селкеп, эчемлекне авызына койды. Сәетнең сынатасы килми иде, ул да абыйсының хәрәкәтен кабатлады. Бераздан тәне җылынып китте, башы әйләнеп киткәндәй сәер җиңеллек гәүдәсен төреп алды. Ничә еллар күрешмәгәненә, кош теле

хәтле генә хәбәр җибәреп карт атасын, анасын, туганнарын тынычландыра алмавына үкенү хисе каядыр очты, рәхәт булып, күңелле булып калды. «Әә исеңдәме? Хәтерлисеңме?..» дип бер-берсен бүлдерә-бүлдерә истәлекләр дөньясына чумдылар.

Таш диварларда шәм яктысы уйный. Көндезге мәшәкатьтән, шау-шудан соң кәрван-сарай төнге тынлыкка чумган. Ә ике туганның күзенә йокы керми. Сөйләшәсе сүзләр исәпсез, аңлашасы, озак еллар каңгырап яшәгәннән соң яңадан туганлашасы бар.

Балчык кувшиннардагы шәраб кимегән саен, Василийның күзләре ныграк елтырый, сүзләре кими. Менә ул ит кисәргә дип кулына алган пычагына карап уйга чумды һәм каш астыннан Сәеткә текәлде. Карашы авыр, томанлы иде. Кинәт ул бөтен ачуын чыгарырга теләгәндәй кизәнеп, пычакны өстәлгә кадады.

Чыңлап калган пычак йөзендә ут шәүләләре биеште.

— Син... синең аркада китте батя якты дөньядан. Югалуыңны күтәрә алмады,— диде ул ыңгырашып.— Соңгы сулышынача сине көтте. Ышанмады ул синең үлгәнеңә... Хыянәтеңә ышанмады...

Сәетнең тыны кысылды.

— Хыянәт?! Нинди хыянәт? Кемгә? Авызыңны үлчәп ач, туганкаем! Кайда утырганыңны онытма! — Эчемлектән каны уйный башлаган Сәет көне буе күңелендә җыелып килгән шом, ачу, үртәлү, әрнүне бер тында чыгарды да салды.— Кемгә хыянәт? Сиңамы? Батягамы? Кемгә зарар салганым бар?!

Аның олы йодрыгы дыңк итеп өстәлгә килеп төште. Мөлдерәмә тулы касәләр сикереште, чайпалып түгелгән куе кызыл шәраб өстәл кырыеннан кан тамчыларын хәтерләтеп идәнгә тама башлады.

Бүлмәдә үле тынлык урнашты. Хәтта тамчыларның идәнгә төшеп бәрелүенә хәтле аермачык булып ишетелә иде.

Тынлыкны өлкән туган бүлде. Аның алара башлаган күзләренә яңадан элеккеге нуры кайтты, энесенең каты сүзе, өстәл тактасын сындырырлык итеп китереп сугуы, аны бердән айнытып җибәрде. Тыныч итеп, әмма бәгыренә үткәрергә теләгәндәй катылык белән, һәр сүзен теш арасыннан чыгарып әйтеп куйды:

— Син безнең белән китәсең. Юкса...

— Нәрсә юкса? Куркытасыңмы? — Сәет кычкыруга күчкәнен сизми дә калды.— Кая китим? Ник китәргә тиеш

ди мин. Оям монда, хатыным, балаларым монда... Мин Казан кешесе. Казан җире минем өчен газиз туфрак, газиз ил-йорт...

— Ә Углич? Ул синең өчен читме? Анаң сөтен имгән йорт хәзер ят булдымы? Оятыңа көч килер...

— Мин алай димәдем. Каршы куйма!

— Ә мин каршы куям. Мин куймасам, аны тормыш үзе куя,— дип ярсыды Василий.— Акылыңа кил!

Әле күптән түгел генә кочаклашып үбешкән, араларыннан җил дә үтмәслек тоелган туганнарны алыштырып куйдылар диярсең, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә бәхәсләшергә тотындылар, битләре кызарып чыкты, күзләрен кан басты.

— Һәрнәрсәнең киресе бар,— дип кычкырды абый кеше пычагына тотынып.— Мыегыңа чорна. Моңарчы кермәгән икән, хәзер миеңә сеңсен. Утка — су, көнгә — төн, җиргә — күк... Урыс дигәч — татар бар, татар барда хәтәр бар.

— Көн төнгә комачауламый, җир белән күк аерылгысыз...

— Ә ут суга комачауламыймы? Алар да аерылгысызмы?

— Таяк белән бармакны чагыштырма. Утсыз йә сусыз яшәп кара! Кайсысы кирәгрәк? Үзең дә әйтә алмыйсың ич, дип каршы төште Сәет.

Аның «Мин Казанда яшәгәннән ни була? Табышканбыз икән, инде бергә-бергә аралашып яшик, ярдәмләшик. Казанда минем сүзем үтсә, Угличта синеке... Ачуланышмыйк. Безгә ни җитми?» — диясе килә. Әмма Василийның менә-менә күкерттәй кабынып китәргә әзерлегән күрү, ярсып пычагына ябышуы зиһенен чуалта, теленә ачулы сүзләр килә дә керә:

— Татар белән бүлешмәгән нәрсәң бар? Нигә Казанга каныгасың? Җитте сиңа!

— Юк инде. Җитмәде. Аңлатып бир миңа: урыска туган булгач, нигә унҗиде ел буе качып яшәдең? Кемнән курыктың? Газиз атаңа, күкрәк сөтен имезеп үстергән анаңа хәбәр бирмәслек дәрәҗәдә нәрсәдән өректең? Әллә өркетеләрме?

Василийның соңгы сүзләре Сәетне телсез калдырды. Ул мондый җавапка, мондый борылышка әзер түгел иде. Асыл сәбәпләрен аңлату өчен көннәр генә түгел, бәлки айлар да җитмәс. Каны уйнаган үгездәй өстенә ташланырга әзер туганына ни әйтергә? Дөньяда туганлык хисеннән дә көчлерәк башка бер хисләр барлыгын ничек төшендерергә? Әллә үзе дә ялгышканмы?! Бер йөрәккә ата-ана мәхәббәте

белән янәшә башка мәхәббәт тә, тугрылык та сыймас идемени? Кызган башында кайнаган уйларының берсенә дә җавап таба алмады. Хәер, ул элек тә бу турыда баш вата, әмма очына чыга алмый кул селтәргә мәҗбүр була иде. Ул үзен хыянәт иткән дип санамый, әмма бик үк туры юлда булмаганлыгын да белә. Дөрес, мал белән, акча белән, кемнеңдер мөлкәте белән эш иткәндә гадел куллы, туры сүзле булды, хәрамга бармады. Кайда юлдан язды соң ул, кайда ялгышты? Әллә соң болар берсе дә ялгыш түгел, ә Василий үзе ялгышамы? Тәмам чуалып беткән Сәет эчендәге утка чыдый алмый ыңгырашып куюын сизми дә калды, тешләрен кысып, килешергә теләгәнен белдерде:

— Сөйләшмик бу турыда, Вася. Җитәр! Бүлешмик инде. Әйдә, касәләрне тутыр да... Газиз әткәбезне искә алыйк...

Василий кутәрелеп бәрелде:

— Әһә, хәзер исеңә төштеме?..

Ул сикереп торып хөҗрә буйлап урап килде дә Сәетнең күзләренә текәлде, аңлатырга, төшендерергә теләп сөйли башлады:

— Менә бүлешмәгән нәрсәң бар дисең. Ә син уйла, наданлыгыңа барма. Күзеңне ач! Үҗәтлек яхшылыкка илтми. Мин ханнар, кенәзләр тормышына катышмыйм, шулай да беләм. Татар ханы Олуг Мөхәммәд Мәскәүне таламадымы? Тагын Устюг каласын, Муромны, Владимирны кем басты? Казанлылармы... Тагын саныйммы? Җиттеме?!.

— Санама! Мин дә синнән ким белмим. Без дә... казанлылар да саный алабыз. Теләсәң, мин ераграктан да башлый алам. Аннан алдарак кына бер сәбәпсез Болгарны, Казанны, Җукәтауны, Кирмәнчекне кем харап итте? Илһам ханны, аның анысы Суфияны кем әсирлектә черетте? Шул ук елны Казанга тагын кем җәфа алып килде, халкын канга батырды?! Урысның ун явына татар бер тапкыр җавап биреп килмәдеме? Бер булды, берәгәйле булды. Сүз юк. Син үзең, йә, ни зыян күрдең казанлылардан? Йә, әйт... Әле хәзер дә Казан пайтәхетендә кунак булып утырасың түгелме?

— Җитте!..— Василий ярсып, өстәл сугып кычкырып җибәрде.— Үзеңне «Без казанлылар» дип сөйлисең икән. Сатылуың җиткән. Татар белән каберең якын булмасын! Мин сиңа туган түгел. Урыс татарга туган була алмый.

— Ашыкма! Кенәзегез Иоанн Васильевичның әнкәсе Елена үзе дә татар нәселеннән дип сөйлиләр... Глинскийларның Мамайлардан чыкканын гына беләсеңдер. Шул сөйрәлчекнең көчеге...

Василий әйтеп бетерергә ирек бирмәде, сикереп торып Сәетнең бугазына ябышты.

— Патша хәзрәтләренә тел тигертмәм...

Ачулы ысылдап буарга, җан көченә җилтерәтергә тотынды. Сәет сикереп торып басты, бөтен гәүдәсе белән киерелеп селтәнде. Аннан мондый елгырлык көтмәгән абзасы лапылдап хөҗрә почмагына барып төште.

— Үтерәм, кабахәт! Сатлык...

Тешләрен шыкырдата-шыкырдата торып басты һәм кыргыйларча үкереп Сәеткә ташланды.

— Гөнаһыңны каның белән юарсың...

Пәһлевандай көчле ике олы гәүдә идәндә бәргәләнә башлады. Алар тәгәрәп китәләр, бер-берсенең өстенә чыгарга тырышып, таяныр урын эзлиләр. Әмма шәраб аккан идән шома, аяк-куллары таеп-таеп китә иде. Көчләре бер чамадарак булгангамы, берсе дә җиңә алмый озак тартыштылар. Менә Василийның аягы диварга килеп терәлде. Ул бер селтәнү белән гәүдәсен өскә ыргытып, чалкан төшкән Сәеткә менеп атланды, шәрабка манылган кулы белән билендәге хәнҗәрне суырып чыгарды.

Сәетнең бугазына ялтырап торган очлы тимер килеп терәлде. Аз гына каршылык күрсәтсә дә, хәнҗәрнең муенына килеп керәчәген аңлап, ул хәрәкәтсез калды. Абзасы гыж-гыж мышнады, аның кан баскан күзләреннән шәфкать, кызгану көтәрлек түгел иде. Менә очлы тимер кысканнан-кыса, авырттырып тәнгә керә бара. Бөтен дөнья кинәттән тарайды, күк йөзе, җир-сулар, елгалар-күлләр, Казан каласы, Углич, ерактагы Мәскәү — барысы да тузан бөртегедәй кечерәеп, шушы хәнҗәр очына сыеп бетте сыман.

— Йә, әйт... кем сөйрәлчек?.. Кем көчек? Күпмегә ссатыл-ды-ы-ың?..

Борынына абзасының авызыннан шәраб, сарымсак исе килеп бәрелде, аны укшытып җибәрде. Гәүдәсе таш булып катты, ул телен әйләндереп бер сүз әйттә алмаячагын, ялынмаячагын, ялвармаячагын да белә. «Мәхәббәтем хыянәт дип санала икән, яшәвемнең кемгә кирәге бар?» Баш сөяген тишеп чыккандай авырттырып шундый уй чагылып узды. Икенче мизгелдә Гөлйөземне, улы Җәгъфәрне, кызы Галияне күз алдына китерде, тешләрен кысып «Уф!» дип куюын сизми дә калды. Алар хакына яшәргә, өстә албастыдай баскан Васяны селтәп атарлык көч табарга кирәк иде. Кирәк иде!

Нәфрәт утында янган, сукыр ачудан күзләре томаланган Василий да, канга буылып сулышы тынычак мизгелне көт-

кән Сәет тә тирә-яктагы һичбернәрсәне күрмиләр, ишетмиләр иде.

Кинәт бүлмә ишеге ачылды, бер-берсенең күзенә керердәй булып берекән ике гәүдә янына озын кара шәүлә сикерде. Очкан шәпкә ул Василийның кулына тибеп җибәрде, пычак атылып китте һәм ике бертуганны айнытып, түр башындагы тәрәзә пыяласын челпәрәмә китерде. Шул ук мизгелдә көчле куллар Василийны идәннән суырып торгызды.

— Нәрсә бүлешә алмадыгыз? Шушылай аңлатырга идемени? — диде ул ачу белән.— Сагынуыгыз шундыймыни?!

Василийны бер якка этеп, ул кулын Сәеткә сузды.

— Тор! Туган кулыннан үлүдән дә яман нәрсә юк. Аллам сакласын!..

Кулларының, гәүдәсенең калтыравын басарга, җанында кайнаган ачуны сүндерергә тырышкан Сәет еш-еш сулыйсулый аның кулын читкә этте һәм идәннән күтәрелде. Каршысында Иван-сәүдәгәр басып тора иде.

Коткаручы аларга күтәрелеп тә карамыйча өстәл янына килде, кувшинның авызыннан гына берничә йотым ясагач, туганнарны табын янына чакырды.

— Йә, җитте сезгә, көзге әтәчләр. Бүлешәсе малыгыз юк. Туганлашу хакына берне җибәрәсез дә Аннан күземә күренмәгез!

Василий белән Сәет бер-берсенең күзләренә карамаска тырышып, кулларына көчләп тоттырылган касәләрне чәкештерми генә эчеп куйдылар. Василийның куллары калтырый иде, кызыл шәраб сакалы буйлап агып төште. Кинәт ул савытын кизәнеп идәнгә бәрде һәм илереп Сәетнең күкрәгенә ташланды, кочаклап үбәргә кереште.

— Кичер, туганым! Шайтан бутады. Энем кадәр энемне үз кулым белән һәлак итә яздым... Ки-че-е-ер!.. Кич-е-е-р мине, бердәнбер абзаңны...

Аның күзләреннән тамган яшьләрнең тозлы тәме Сәетнең иреннәрен көйдереп-көйдереп ала иде. Әле генә җан ачуы белән изәргә, сытарга, юк итәргә теләгән абзасының халәте аңа да күчте шикелле, күңеле йомшады. Иреннәре исә:

— Без бит бер каннан... Без бит туганнар, бер ата, бер ана балалары,— дип кабатлый иде.

Сәетне озатырга Иван үзе чыкты. Кәрван-сарай капкасы янында туктап як-ягына карангач, иелеп колагына пышылдады:

— Монда күргәннәреңне оныт! Бу юлы түләү башкача

булыр. Колагыңа киртлә, келәтеңдәге бар малны чыгарып салсаң салырсың, без әйткәнне эшләрсең... Дары, корал... барысы да синең кулга күчә барсын! Ал, яшер! Акчаңны кызганма. Урыс патшасы игелек күрсәткәннәргә мәрхәмәтле... Казанның дары базлары кайда, белеш, барысын да хәтереңә сеңдер. Гаскәрләре күпме? Кайдан ярдәм килү ихтималы бар... Озакламый болар безгә кирәк булачак. Ә инде ханның якыннарына, ясавылларга серне тишсәң, синең белән менә бу сөйләшер.— Иванның кулында үткен хәнҗәр күренде.— Үзең булмасаң, углыңның йөрәгенә кадалыр. Күрдек. Кем икәнен беләбез... Табарбыз!

Чыкканнан бирле иренен кысып килгән Сәетнең тез буыннары калтырап китте. Башында мең төрле уй бәргәләнде. «Менә куркыныч кайдан яный икән. Шигем дөрес булган...»

Аның дәшмәвен Иван ризалык билгесе дип кабул итте булса кирәк, аркасыннан какты.

— Бар! Без әле очрашырбыз... Ә абыеңа үпкәләмә. Дуамал, кайнар булса да, әйбәт, тугрылыклы кеше...

Төнге урамда аның аяк тавышлары гына яңгырап калды.

Башта Казаннан китәргә кыстаган, дус булып, әтисе васыятен үтәргә килгән киң күңелле, изге булып күренгән, соңыннан иң кадерлесенә — улына үлем белән янап, хыянәткә этәрүче кешене Сәет аңлый алмый интекте. Авыр уйларына бирелеп акрын гына атлый бирде. Кинәт зиһене ачылып китте: Иван — сәүдәгәр түгел. Әтисе белән йөргән чакларда да янчык тулы алтыны-көмеше булган бу кеше базар тирәсендә артык чуалмый иде. Димәк, элек тә ниндидер яшерен йомышы, үзе генә белгән эше булган. Кем ул? Бу соравына җавап таба алмаса да, Василий белән күрешкән-сөйләшкәндә аның кайдандыр тыңлап, ишетеп торуын аңлады. Шулай булмаса, иң хәтәр мизгелдә килеп керер идеме?! Сәет үлде ни дә, үлмәде ни — аңа барыбер түгел идемени? Ә Сәет аңа кирәк булган, хәзер дә кирәк. Ул ниндидер мәкерле теләкләрен тормышка ашыруда аңа өмет баглый, ярдәм итәр дип ышана.

Баштан ук үзенә мөрәҗәгать итмәвенең сәбәбе дә аңлашылды Сәеткә. Вася җиткерер дип өметләнгән. Ә абыйсы ул көткәнчә салкын кан белән, туганнарча сөйләшәсе урында дуамалланып пычакка ябышты, бөтен эшне харап итеп ташлый язды. Менә шунда инде Иванның үзенә катнашудан башка чара калмагандыр. Ни кайнар Вася, ул килеп керүгә, чүпрәккә әйләнде дә калды. Юкка түгел бу! Иван-

сәүдәгәр артында нindидер үтә дә көчле, мәкерле, максатына ирешү юлында бернинди җирәнгеч үтерүдән дә курыкмый торган дәһшәтле көчләр тора.

Сәетнең аркасы чымырдап китте. Кара киемленең фикер сөрешенә төшенү бер яктан сөендерсә, саклану чаралары күрү мөмкинлеген ачса, икенче яктан шомландыра, куркыта, канын катыра иде. «Мондый кеше бернәрсә алдында да тукталып калмас. Бертуганнар арасында үч, мәкер ялкыны дөрләтә алган адәм, һичшиксез, азау ярган җаһилләрдән. Бер гөнаһсыз сабый каны коелганда да аның кулы калтырамас, җаны тетрәмәс!»

Бар дөньясы бер көн эчендә асты-өскә килгән Сәет кайтып җитүен сизми дә калды. Тыңлаусызга әйләнгән бармаклары озак капшанды, ишекне ача алмый интекте. Башка вакытта ул кайтмыйча ябылмаган ишек эчтән бикле иде. Менә йомшак аяк тавышлары, Гөлйөземнең сакланып кына эндәшкәне ишетелде:

— Сәет, синме?

— Мин... мин. Ач,— диде Сәет. Тавышы үзенеке түгел иде.

Келә шалтырады, шәм яктысында хатынының агарынган йөзе күренде, күзләре зур булып ачылды.

— Ни булды? Кемнәр нишләтте сине? — дип пышылдады ул куркынып. Кулыннан шәме төшеп китте. Алгы якны куе караңгылык басты.

Үз кайгыларына чумган ир белән хатын урамның каршы ягында катып калган сыңар шәүләне күрмиләр, аның һәр сүзне йотып баруын башларына да китермиләр иде, әлбәттә.

— Борчылма... Берни дә булмады.— Сәет Гөлйөземне тынычландырырга ашыкты.— Керик. Эшем күп булды... тоткарландым...

Аның бу сүзләре яңгырауга урамдагы шәүлә хәрәкәткә килде, өрәк шикелле тавыш-тынсыз гына тар тыкрыкларга шуып кереп китте

Гөлйөзем икенче шәм алып чыкты һәм иренең куе кызыл шәрабка буялган киемнәренә, тузгыган кыяфәтенә карап тораташтай катып калды, илереп кычкырып җибәрде:

— Кан!.. Муенында яра... Бәгърем, ни булды?..

Көне буе үзен тыеп, ачуын, шиген җыеп, тешен кысып түзгән Сәет җикереп куюын сизми дә калды:

— Житте диләр сиңа! Әйттем бит, соңыннан... соңыннан!..

Унҗиде ел бер тән, бер җан булып яшәгән бербөтен икегә бүленде, араларына беренче тапкыр кара күләгә ятты.

Төн. Бизәкле келәмнәр, укалы шәмаилләр белән бизәлгән, идәненә болгар паласлары җәелгән зиннәтле бүлмәдә шомлы тынлык. Көмеш шәмдәлдәге ялгыз шәм ялкыны намазлык өстендәге ак шәүлә хәрәкәтеннән тирбәлеп-тирбәлеп куя, диварларда күләгә булып бии.

Кеше илаһи затлар белән сөйләшә, үзенә ярлыкау сорый, мәрхәмәтле күк иябәреннән ярдәм көтә. Иреннәре дога сүзләрен пышылдый:

— Лә илаһе иллаллаһе, Мөхәммәт рәсулуллаһы... Йа аллам, кылган гөнаһларымны кичер. Кодрәтең илә юктан бар иткән, тәнебезгә җан өргән, күзебезне ачкан, җаныбызга иман иңдергәнсең... Инде дә рәхмәтеңнән ташлама! Бәнем гөнаһларымда хәләл җефетемнең, газиз углым илә кызымның кәррә катнашы, гаебе юктыр. Алар хакына булса да гаебемне кичер. Аларны сакла! Күземне ач! Инде ни кылыйм? Ике ут арасында калып көлгә әйләниемме? Телләре, диннәре төрле булса да бер аллаһы тәгаләгә табынучы, Гайса пәйгамбәр илә Мөхәммәт рәсулуллаһы юлыннан син бөеккә сыгынучы колларыңның зиһеннәрен ач, җан кыяр коралларын юк ит. Барысы да синең кодрәтеңдә... Җаннарына мәрхәмәт, шәфкать иңдер...

Йа аллам, бәндәләреңә туры юл күрсәт!

Сәҗдәгә китеп, бөтен уен-зиһенен туплап, бәгырен телгәләгән ялваруларын күккә иңдерергә тырышты Сәет. «Диннәр, табыну-ышану төрле булса да, аллаһы тәгалә бердер, шәриге вә тиңдәше юктыр. Кем белә, бәлки аңа башкача да мөрәҗәгать итеп карарга дыр?..»

Ул бүлмә буйлап йөренеп килде, намазлыкны төреп читкә алып куйгач, нишләргә белмәгәндәй, башын тотып бик озак уйланып утырды һәм тәвәккәлләде. Яшереп эшләнгән эш башкарган кебек як-ягына каранып алды һәм түр почмакка барып тезләнде, иреннәре ашыгып-ашыгып дога сүзләрен кабатларга кереште:

— О боже, знаю о тебе, яко милостив еси и праведен; не на лице зриши человеком, но и правды сердца их испытуеши. Вижль ныне скорбь и беду, и помози нам, рабам твоим, будь нам истинный судя, и суди в правду меж братьями, ослепленными враждою и кровью — казанцами и русскими, и обличи вину коегождо. Все мы равны пред тобою... О боже, яко милостив еси праведен..

Таң атканчы илаһи затлар белән сөйләште Сәет. Күз алдыннан үкенечле дә, сөенечле дә, газаплы да, татлы да булган хатирәләр узды, бер төн эчендә ул моңарчы яшәлгән бөтен гомер юлын яңадан узды.

ПӘРИ КЫЗЫ

Ул сурәт күземә күренү кәлди,
Хәтеремне, һушымны җөмлә алди,
Гаклым алуб, сабрыми гарәт кылди,—
Пәйвәстә нәфсем аны эстәр имди.

Кол Гали. «Кыйссаи Йосыф»

Агым уңаена җай гына аккан көймәләр Идел кушылдыгына җитәрәк тизлекләрен акрынайттылар, иртәдән бирле өреп, ак җилкәннәрне кабартып килгән талгын җил дә исүдән туктады. Каршы агым, көймәләрне үткәрергә теләмәгәндәй, үзәнне тутырып дулкынлана, әрәмәләр каплаган ярларга сугылып бәргәләнә иде.

— Ишкәкләрне төшерергә-ә-ә!

Көймәченең карлыккан тавышы иртәнге җылы кояшка битләрен куеп изрәгән мөсафирларны айнытып җибәрде. Капчыклар арасына сыенып йокымсыраган Санька сискәнеп сикереп торды, йодрыклары белән күзләрен угалады.

— Нәрсә? Әллә ушкуйникларммы?

Егетнең сугышырга әзерләнгән яшь этәчтәй муенын сузып, кулларын йодрыклап як-ягына карануыннан көймәдәгеләр шаркылдап көлештеләр.

— Йоклап калдың. Үттек инде,— диде берсе, шаркылдавын тыя алмыйча.

— Син генә булмадың. Җирәкләрен бирә идең! — дип көлемсерәде икенчесе.

Юлга чыкканнан бирле Идел юлбасарларыннан, талаучылардан шикләнеп, бөтен саклану чараларын күреп, хәтта кычкырып сөйләшергә базмыйча тын гына барган сәүдәгәрләргә җан керде, бер-берсен бүлдереп сөйләшергә, көлешергә тотындылар. Кинәт барысы да тынды, нindидер тавышсыз боерыкка буйсынгандай бер якка карап сүзсез калдылар. Үз гомерендә беренче тапкыр ерак юлга чыккан Санька әле һаман бернәрсә дә аңламый иде. Ул да башкалар борылган якка карады һәм... сихерләнгәндәй, күзләрен зур ачып, каршында пәйда булган әкияти манзарага текәлде.

— Нәрсә бу? — Иреннәре үзенә буйсынмыйча бер үк сүзләрне кабатларга кереште. — Өнемме бу, төшемме? Төш күрәмме соң әллә?

Каяндыр килеп чыккан шаян җил су өстендә тирбәлгән иртәнге сыек томанны ерткалап тарата барган саен, күз алдындагы күренеш тә үзгәрә, төсләре ачыклана, тынсыз калырга мәҗбүр итә иде. Әнә, томан өстеннән, бер-берсен уздырырга теләгәндәй, шәмдәй төз, ярымайлы, нечкә, биек манаралар күккә үрелде, аларның алтынланган очларында кояш нуры җемелдәде. Алар сансыз, исәпсез иде. Әйтерсең лә алар акрын гына үсәләр һәм күктәге ап-ак каурый болытларга тоташырга ашыккандай томан эчендә йөзәләр иде.

Ишкәкләр бер күтәрелә, бер төшә. Көймә, борыны белән суны ерып, тизлеген арттырганнан-арттыра. Максатка якынлашып килү юлаучыларның арган беләкләренә көч бирде, күңелләренә ашкыну һәм шатлыклы рәхәт өстәде.

Якынайган саен тылсымлы сурәт зурая, матурлана бара. Әнә инде төрле төсләргә буялган йорт түбәләре, ялык-йолык килүче ярымтүгәрәк гөмбәзләр пәйда булды. Каезланган юан имән бүрәнәләрдән тезелгән диварлар калкып чыкты, калын тимер капкалар күренде. Болар бөтенесе дә Санькаsuccessорны сихерли, үзенә чакыра. Гүяки калкулык өстенә утырган шәһәр иксез-чиксез диңгездә йөзүче тылсымлы көймә, ә ул үзе мәхәббәтен, үзенә тиң ярын эзләп баручы пәһлуан. Бары тик шушы көймәне куып җитәргә һәм аңа утырырга гына кирәк. Бөтен-бөтен хыялларың шунда тормышка ашар, эзләгәнеңне табарсың, көчеңне, җегәреңне күрсәтерсең, дан-шөһрәткә, мал-мөлкәткә ия булырсың. Хыялында туган сурәт аны алга әйди, йөрәге күкрәгеннән чыгып китәрдәй булып ашкынып тибә иде.

— Тизрәк, тизрәк! Алга! Хыялдагы шәһәргә! Бәхетле, матур кешеләр яшидер монда...

Томан таралуга тагын икенче күренеш ачылды. Офыкта, күз күреме еракльщтагы урманнар өстендә салават күпере пәйда булды. Ул бер очы белән урманнарга таянса, икенче очы белән артта калган Идел өстенә барып тоташты. Әйтерсең лә бинигая олы капка аларның килүен генә көтеп торган да менә хәзер тылсымлы дөньяга юл ача, керер урын күрсәтә иде.

Башкасын ачык кына хәтерләми Санька. Ул үзен сихерләгән күренештән әле бик озак айный алмады. Аның халәтен аңламаган атасы инде күптән дөнья мәшәкатьләренә

чумган, улының агач сындай катып калуын үзенчә аңлап, ана нидер сөйли иде:

— Казан каласы шушы булыр... Алдарак Кабан күле... аннан Болак суы агып чыгар... без йөзгәнен Казан суы диярләр. Балык исәпсез бу якларда. Җаның ниндиен тели... Насыйп итсә, юлыбыз уңса, барысын да күрсәтермен...

Шәһәр төбенә килеп җиткәндә генә күк гөмбәзендә кызыл, зәңгәр, яшел, сары, шәмәхә төсләргә кереп салават күпере балкуын Санька яхшыга юрады, күктәге илаһи көчләр аңа мәрхәмәт күрсәтә, бәхетенең шушы калада икәнлегенә ишарәли дип күңеленә беркетеп куйды. Ни генә булса да, бу калада аңа яманлык кылынмас, юраганы юш килер, теләгәне тормышка ашар, бәхетен табар... Тик нәрсә тели соң ул? Йөрәге нинди бәхеткә сусап канатлана? Асыл малгамы, чит илләрне күреп танышугамы, ят халыклар белән аралашып гыйлем туплаугамы, ирекле сәүдәгәр дәрәҗәсенәме?! Уналтысы әле яз башында гына тулган егет моны үзе белми, ниндидер моңарчы татымаган хисләр, тойгылар давылына сусаган җаны, тәне сулкылдый, таныш булмаган дәрьяда колач җәеп йөзәргә ашкынып тора иде.

Әтисенең сүзләре бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. Өлкәннәр сүзенә илтифатсызлыкның олы гөнаһ икәнен белгән Санька үзе белән берни дә эшли алмый, бу мизгелдә уйлары аңа буйсынмый иде.

Әтисенең ачуланыбрак әйткәне айнытып җибәрде.

— Житәр! Истукандай торма. Бер генә килмәссең әле. Гомерең булса... Өйрәнгәнеңне онытмадыңмы? Сынау тотасы көнең...

Санька, яңа гына күргәндәй, әтисенә, аның шомланып калган җете зәңгәр күзләренә, сакалын аралаштырып кыймылдаган юан бармакларына карап катты да калды. Савелий Кузьмич, берни булмагандай, улы белән татарча сөйләшеп ята иде.

— Мыегыңа чорнап куй, казанлылар белән тора салып эш турында сөйләшмә! Иң элек саулык-сәламәтлекләрен, хәл-әхвәл сораш, дөнья хәлләренә күч, акрынлап кына, ипләп кенә кызыксынганыңа җеп сузарсың. Алар кабаланганны сөйми.

— Беләм бит инде, мең мәртәбә әйттең,— диде Санька ризасыз гына.— Тагын кабатламасаң...

Ата белән улның сөйләшүенә колак салып утырган ниндидер сәүдәгәр тәкәллефсез генә аларның сүзен бүлдерде.

— Казанлылар белән сөйләшкәндә телеңдә бал, куеның-

да таш булсын. Монысын нигә әйтмисең, Савелий Кузьмич?!

Юлга чыкканнан бирле беркем белән дә ачылып сөйләшмәгән, үз дөньясына бикләнгән төксе чырайлы, яшькелт күзле бу сәүдәгәрне көймәдәгеләр бик өнәп бетерми иде. Бернинди мал төятмәгән, базарга ни максат белән баруы мәгълүм булмаган озын буйлыдан бераз гына шикләнәләр дә булса кирәк. Һәрхәлдә, аның янында ачылып бетмәгән кебек күренәләр, тел яшерәләр иде.

Әтисе ризасызлыгын бик сиздермичә, башын чайкап, басынкы гына җавап бирде:

— Юк инде, Иван. Гомерем буе намуслы сәүдәгәр булдым. Улымда да икейөзлелек күрәсем килми. Казанда да дусларым бар, Мәскәүдә дә, далада да... Берсеннән дә минем хакта яман сүз ишетмәссең... Улымның да шулай булуын телим.

Иван көлемсерәп куйды, әмма сүзне дәвам иттермәде. Ә этисе гүя үзен кемдер бүлдергәнне онытып, ачулы тавыш белән яңадан Санькага карап сөйләргә кереште:

— Мең дә бер тапкыр кабатлармын. Дөньяда кешеләр белән дус яшим дисәң, аларның гореф-гадәтен ихтирам ит, өйрән, телен бел. Чит монастырьга үз кагыйдәләрең белән кермиләр. Йә, әйт әле, базар аксакаллары белән ничек күрешәсе?..

Татлы уй-хыялларыннан бүленгәнгә үртәлүе чыгып бетмәгән Санька яратмаган сабагын кабатлаган бала шикелле әйтеп куйды:

— Әссәламәгаләйкем, базар агалары! Исәнлек-саулыкмы, дөньялар иминме, ил-көн тынычмы?

Савелий Кузьмичның киң йөзенә канәгатьләнү билгеләре чыкты, көчле куллары белән улының аркасыннан кагып алды һәм елмаю аша кырыслык чыгарырга тырышып дәвам итте:

— Аң бул! Без — сәүдә кешеләре. Кайда нинди ызгыш булу безгә кагылмый. Без — тыныч юлда. Телебез сугыш теле түгел, сату-алу, аңлашу теле.

«Шушы тел дигәне белән үтерә инде» дип уйлап куйды Санька ачусыз гына. Әле өйләрендә, Угличта чагында ук теңкәсенә тия иде. «Имеш, өйрән, бел. Безгә, малтабарларга, ике-өч тел белү фарыз. Шуларның беренчесе — татарныкы. Угличтан чыгып Иделгә ишкәк салуга аннан башка бер адым да атлый алмыйсың. Бар Казанга, бар Ханкирмәнгә, Әстерханга, Кырымга, чык нугайлар, сартлар, кыргызлар ягына, Себергә юл тот — кояш чыгышы ягындагы бар-

ча мәмләкәтләрдә шул тел. Аны белсәң, далада да, тауларда да, урманнарда да җавапсыз калмассың. Гарәпләр дә, һиндләр дә сүзеңне аңлар, әйткәнеңә колак салыр. Төрек кавеме күпсанлы, көчле... Сәүдәң уң булсын дисәң, тел өйрән!»

Борынгы купецлар нәселеннән килгән Савелий Кузьмич дөньяны ишетеп түгел, үзе күреп, йөреп таныган кеше буларак, улларында сату-алу эшенә генә түгел, гыйлем эстәүгә, телләр белүгә дә ихтыяҗ тәрбияләргә тырыша иде. Татар сәүдәгәрләре белән аралашып, эшнәләнеп беткән карт, Саньканың шәһәрдәге татар бистәсендә аунап үсүен белсә дә, үз максатында эзлеклелек күрсәтте, ничек итсә итте, балаларына үзе белгәнчә тел өйрәтте. Менә хәзер төпчегенең беренче сыналуы, тәүге кат ерак юлга чыгуы.

«Картаелды. Буыннарда җегәр бетеп килә. Инде бу малаемны да үз көнен үзе күрерлек итеп урнаштыра алсам, җаным тынычланыр иде. Дөньялар имин түгел. Сату-алу белән, мал алмашып кына яшисе иде дә бит... Хаким затларга барысы да берьюлы кирәк. Вынь да положь... Әйтерсең, җир җитми, һава җитми... Тегендә кергәч, барыбыз да бер буласы, юкса. Бер колач җир җитәсе». Улының ашкынуын карт сәүдәгәр эшкуарлыкка юрый, киек сизгән сунарчы этенең тыныч ярсуына тиңләп, эченнән генә яратып көлә иде.

Тире, житен һәм киндер сүсе тутырылган капчыкларны Болак буындагы лапасларга урнаштырганчы кояш күк гөмбәзенең уртасыннан үтеп, бату ягына авышты. Көймәчеләр, үз йомышларын юллап, һөнәрчеләр мәхәлләсенә китеп бардылар. Йокысызлыктан, ерак юлдан шактый арыган Савелий Кузьмич кәрван-сарайның җиләс хөҗрәсендә ял итәргә ятты. Сихри кала белән тизрәк танышырга ашкынган Санька гына мендәргә таянырга ашыкмады. Көймәдә ауный-ауный пычранып беткән өс-башын салып ташлады, чиста күлмәк-чалбар, аякларына әтисе узган ел Ташаяк базарыннан алып кайткан сәхтиян читек киде, билен чуклы билбау белән буды, чукынырга теләп почмакта берни дә тапмагач, ишеккә карап маңгай тирәсендә тәре сурәте ясап бармакларын уйнатты да җиңел сулап урамга чыгып китте.

Монда бөтенесе дә башкача иде. Челтәр бизәк тотылган өй кыекларына, аклыгы белән күзне камаштырган таш-пулатларга, чат саен диярлек күккә ашкынган нечкә манараларга сокланып озак йөрде Санька. Шәһәр чиста иде, пөхтә иде. Ширбәтчеләр янында сусынын басты, хәлвәчеләрнең татлы нигъмәтләреннән авыз итте, төрле илләрдән

килгән базаркәннәрнең ят киемнәренә, аңлаешсыз телләрдә сөйләшүенә, аларның күплегенә, төрлелегенә хәйран калды. Ташаяк ярминкәсе аңа, һичшиксез, дөнья үзәге булып тоела башлаган иде.

Кәрван-сарайга кайтырга чыккач кына шактый нык арыганлыгын сизеп алды. Аяк табаннары ут яна, күлмәге дә аркасына ябышкан иде.

— Их, бер чумып чыгарга иде. Әнә ич, Кабаны да, Болагы да ымсындырып, чакырып тора...

Яшел камышлык арасында көмеш көзгедәй ялтыраучы Кабанга таба егетнең аяклары үзеннән-үзе атлады.

Шомырт, балан, миләш куакларын, талларны аралап су буена үтте дә ашыгып-кабаланып киемнәрен салып ташлады, төбендәге чуерташларына хәтле аермачык күренеп торган, үтә күренмәле чиста суга сикерде.

— А-а-ай-ай-ай!..

Күл өстендә аның сискәнүле авазы гына яңгырап калды.

Үз үзен белештермичә тирәнгә чумган Санька ничек атылып чыкканын да сизми калды. Күл боз кебек салкын иде. Хәтта аннан тибеп чыккан чишмә суларының уйнаклавына хәтле тойган кебек булды. Әмма ни гаҗәп, күз ачып йомган арада су аны сафландырып та өлгерде, арыган-талганлыгын, әйтерсең, кул белән алып ташладылар. Атна буе көймәдә хәрәкәтсезлектән ялыккан яшь, көчле тәннең уйныйсы, колач салып йөзәсе килә башлады.

Коенып арыгач, яр буена чыкты да яшел чирәм өстенә сузылды. Ару-талчыгу барыбер үзенекен итте, башын бәләкләренә куюга күзләре йомылды. Шулай күпме вакыт узгандыр, янәшәдә генә чырык-чырык көлешкән тавышлардан сискәнеп уянып китте. Кул-аякларын тирә-якка ташлап чалкан яткан Санька сикереп торды. Янәшәдәге куак артында гына бер төркем шәрә кызлар уйный иде. Ялт итеп яңадан җиргә сеңде. Шәһвәте кузгалды. Үзенең дә анадан тума икәнлеге исенә төште. Оятыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булса да, ул таллар арасында чәчелеп калган киемнәре янына бара алмый иде инде. Җитмәсә, ул чишенгән куак төбендә генә, эссе җәй булуга карамастан, башына очлы бүрек кигән, кулына озын таяк тоткан бер карчык утыра. Әйтерсең, каз бәбкәләрен тилгәннән саклый.

Санька күрәчәгенә кул селтәде. Кызларның беркемнән, бернәрсәдән шикләнмичә табигый кыланулары моңарчы татылмаган рәхәт соклану тудыра, татлы ләззәт йөрәген сулкылдата иде. Тезләрен кочаклап утырды да дөньясын онытты. Кызлар яшь, берсеннән-берсе чибәр. Аларның сыгылмалы ап-

ак сыннары, аркаларына япма булып сибелгән куе озын чәчләре, талгын хәрәкәтләре сихерләде егетне. Бу мизгелләрдә ул кайда нишләп утыруын да, хәтта үзенең кемлеген дә оныткан иде. Иреннәре дога укыгандай тавышсыз гына кыймылдады:

— Йа тәңрем! Нинди илаһи затлар болар? Күктән төшкән фәрештәләрме әллә? Җир кызларының мондый гүзәлләре дә буламы икәнни?!

Кызларның буй-сыннарында бер генә кимчелек тә, камил булмаган бер генә сызык та юк иде. «Юк, юк! Болар илаһи зат... Менә кара япмалары ачылыр, тәннәре шикелле үк ак канатлар үсеп чыгар, бер талпыну белән күккә ашарлар».

Каты итеп үзенең ботын чеметеп карады, шулкадәр каты чеметте ки, хәтта суелып кан чыкты. Авыртуны сизмәде. Юк! Бу нindидер тылсым, аңлаешсыз сихри халәт иде.

Баштарак аларны тоташ бер төркем итеп күргән егет, күзләре ияләшкән саен, һәрберсенең йөз чалымнарын, гәүдә сыгылышларын, хәрәкәтләрен аера башлады. Кызлар шаян, көлешә-көлешә күлгә чумалар да бер-берсенә су чәчрәтеп уйныйлар. Күл өстендә аларның чыр-чу килүе генә яңгырап тора. Әйтерсең лә күл аларны боздай салкынлык түгел, яңа сауган сөт җылылыгы белән кочагына ала. Мондагы суның кешегә көч, дәрт өстәү хасиятен сизеп өлгерсә дә, кызларның түземлегенә, чыдамлыгына хәйран калды Санька.

Ниһаять, озаклап чупырдашкан кызлар берзаман күшегеп ярга сибелде. Күк йөзендәге бүрек хәтле генә болыт кояшны каплауга арадан берсе такмакларга кереште:

Асыл кояш, кил бире,
Кил бире, китмә кире!
Кошлар да көтә сине...

Кызлар түгәрәкләп бастылар да бер-берсенең кулларына чәбәкләп бәрә-бәрә көйләп такмакка кушылдылар.

Тавыклар да кыткылдый,
Чыпчыклар да чыркылдый,
Ак үрдәкләр бакылдый,
Ата казлар каңгылдый,
Юлга чыккан сыерчык,
Бар да чакра: кояш, чык!
Каргалар да каркылдый,
Уйнап йөри кызылтүш,
Кызыл этәч суярбыз,
Ботын сиңа куярбыз,

Асыл кояш, җәһәт кил,
Яшел җәйне тизләп кил!

Гүя шушы такмакны гына көтеп торган, бүректәй болыт колакчыннарын җыеп күз алдында кечерәйде дә, түгәрәк тәлинкәгә әйләнеп, бер якка тәгәрәде. Алан алтын нурга күмелде. Табигать балалары кул чаптылар, рәхәтләнеп көлештеләр.

— Ягез, кызлар, китик инде, кич җитә,— дип аваз салды берсе.

Аңа икенчесе җыр белән җавап бирде:

Ак киндерләр шома була
Тупылдатып тукмасаң.
Егетләр дә яратмыйлар
Иртә ятып йокласаң.

Җырлап бетерүгә үзе үк шаянланып кычкырып та җибәрде:

— Кемдер егетләр кочагына керергә ашыга. Сабырсызлар үпкәләмәсен. Кайтабыз, кайтабыз!

Аның тавышы уенчак, яңгыравык иде, ягымлы иде. Әйтерсең лә кемдер көмеш кыңгыраучыкка кагылып узды. Аның чыңнары Саньканың колагында бик озак яңгырап торды әле.

— И Гөлйөзем, син һаман шулай ашыгасың инде,— диештеләр кызлар үпкәләгән сыман.

— Кайтырбыз әле...

Әмма Гөлйөзем дигәннәре, баш-башларына кызыллы-яшелле шакмак бизәкләр төшерелгән ак тастымал алып, биленә кадәр төшеп торган чәчләрен корыта башлаган иде инде. Ул җавап кайтарып тормады, өчәрләп көмеш тәңкәләр тезелгән чулпыларын толымнарына кушып үрергә кереште.

Талчыбыктай зифа, бөтен буй-сыныннан нур балкыган бу кыз башкалардан шаянлыгы белән дә, хәрәкәтләренең талгын йомшаклыгы белән дә аерылып тора иде. Әнә тавышы да нинди матур икән! Саньканың күзенә бүтән кызлар күренмәс булды. Шушы Гөлйөзем дигәннәре сокландыргыч бер сурәт булып күңеленә керә, һәр хәрәкәте килешле, тансык иде аның. Үз-үзен белештермичә ыңгырашкандай «Аһ!» дип куюын сизми дә калды.

Хава хәлендә калган табигать балалары Адәм рәвешендәге бу егетнең монда качып утырганлыгын белсәләр, кызык өчен генә булса да аны хур итү җаен табарлар иде. Чая кызлар нишләргә кирәген белерләр иде. Бәхетенә

каршы, киемнәрен барлау белән мәшгуль кызлар аның аһ органын ишетмәделәр. Санька телен тешләде, гәүдәсе тораташ булып катты. Шушы хәлдә булса да, аның кызларны җибәрәсе килми, мәңге-мәңге шулай карап, сокланып утырырга әзер иде ул.

Куак артындагы ачыклык бушап, тынып калды. Буыннары тәмам оеган, йөзләрчә энә кадалгандай авырттырып тартышкан аякларын уа-уа Санька торып басты һәм сакланып кына кызлар утырган якка күз салды. Берәрсе калмаганмы? Китеп өлгергәннәрме?! Чү! Нәрсә бу? Алан кырыендагы ботакта эре-эре чәчәкле искиткеч матур яшел яулык эленеп калган иде. Санька аның янына ничек барып җитүен, ничек кулына алуын, бите белән яулыкка каплануын сизми дә калды. Юка, затлы ефәктән баш әйләндергеч хуш ис аңкый. Ул ис борынны кытыклый, сулыш юлларыннан җанының үзәгенә барып җитә, йөрәген еш-еш тибәргә мәҗбүр итә иде. Шушы ләззәткә исереп күпме торгандыр, белми, якынлашып килүче аяк тавышыннан сискәнеп, тиз генә куак артына сикерде. Аланга иптәшләре Гөлйөзем дип дәшкән кыз кереп килә иде.

Ниндидер ярамаган эш өстендә тотылган малайдай, Саньканың битенә кызыллык йөгерде, сокланулы, гафу үтенүле күзләрен кызга төбәп катты да калды, аяклары, әйтерсең, җиргә беректе, теле аңкавына ябышып калды кебек. Ул кыз янына чыга да, ташлап та китә алмый. Кыюсызлыктан, чарасызлыктан гаҗиз калган җаны читлеккә эләккән кошчыктай бәргәләнә башлады.

Тынлыкны кыз бозды:

— Син кем? Адәми затмы, пәри затмы? — диде ул нәрсәдәндер шикләнгәндәй як-ягына каранып.

Бер генә саксыз хәрәкәт ясаса да, кызның бүредән качкан боландай куаклар арасында югалырга әзерлеген күреп-сизеп торган Санька, кыюсызлыгын җиңеп, аны тынычландырырга ашыкты:

— Курыкма!.. Адәми зат мин...

Тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, кирәкле сүзләр таба алмады, башлаган җөмләсе авыз эчендә әвәләнеп, буталып калды. «Их шушы тел белмәүне!» дип ачыргаланып уйланды ул.

— Адәми зат булсаң, чык, яулыгымны бир! — диде кыз бераз кыюлана төшеп һәм шелтәле караш белән өстәп тә куйды.— Кызлар су кергәнне сагалап, карап тору килешми...

«Мин карап тормадым»,— димәкче иде Санька, кыз ал-

дында гөнаһлы булуын сиздерәсе килми иде. Әмма теленнән бөтенләй башка сүзләр ычкынды:

— Адәми зат булсам да, мин... чыга алмыйм... Яулыгыңны бик бирер идем дә...

Әллә нәрсә булды, ул оялу дигән нәрсәне онытты, кызның үзе кебек үк кыю сөйләшә башлады.

Беренче курку хисен җиңгән Гөлйөзем үзе дә сихерләнгән кебек гайре табигый халәт кичерә иде. Яшел яфраклар арасыннан керфек тә какмый үзенә төбәлгән күзләрдән дулкын-дулкын булып ниндидер тылсымлы көч агыла, ул кызның ихтыярын сындыра, аяк-кулларын богаулый, китмәскә, шушында калырга өнди кебек иде. Аның көч тулы беләкләре, киң күкрәге, таза иңнәреннән үсеп чыккан туры муены, җитенгә охшаш сары чәчләре күңелендә аңлаешсыз, әмма тансык бер сурәт булып оеша. Мондый ак чырайлы егетне аның үз гомерендә әле беренче тапкыр күрүе иде. Шул ук вакытта Гөлйөземнең бу оялчан егетне сөйләштерәсе, аның тавышын ишетәсе килә.

— Нигә чыга алмыйсың? — диде ул шаянланып.

— Мин... мин,— дип кабатлады Санька ни әйтергә белмичә.

Аның хәлен аңлаганын сиздереп, Гөлйөзем кычкырып көлеп җибәрде. Күл өстенә көмеш тәңкәләр сиптеләрмени...

— Ә син калдырып кит! — диде ул көлүеннән тыела алмыйча.— Мин алып китәрмен.

— Бер шартым бар,— диде кыюланганнан-кыюлана барган Санька.— Син аланнан чыгып тор, яулыгыңны үзем китереп бирермен..

Сәер халәтен әле үзе дә аңлап бетермәгән Гөлйөземнең китәсе килми, шул ук вакытта ниндидер икеләнү, егетнең үзенә якынаюыннан куркуга охшаш бер хис баш калкыта иде.

— Ю-у-ук инде. Син калдырып кит. Аннары куып җитәрсең,— диде ул кинәт кенә бер карарга килеп.

Санька яулыкны үзе яшеренгән куак ботагына элеп куйды һәм ашыгып агачлар арасына кереп китте.

Ул киенеп чыкканда аланда беркем дә юк иде инде. Тик кызларның чыннан да булганлыгын, су коенганлыгын белдереп сары ком өстендә юеш аяк эзләре генә ярылып ята. Аяныч хисе яшен ташы булып йөрәген яндырып үтте, үз-үзен белештермичә йодрыгы белән учына китереп бәрде. «Озак мыштырдадым!» Югалган кызны куып җитү өмете белән алга ыргылды. Агач яфраклары битенә бәрде, куллары сыдырылды, әмма авыртуны, сыдырылуны Санька сизми,

бер югалтса мәңге таба алмаячак тоелган кызны куып җитәргә, күңелдә кабынган өмет йолдызын сүндермәскә, әйтелми калган иң кирәкле сүзләрне җиткерергә кирәк иде.

Сукмаклар күп иде. Аларның кайсыннан китәргә белмәгән Санька анда ташланды, монда ташланды, туктап, тын да алмый тынлыкка колак салды, әмма әрәмәдә шылт иткән тавыш та юк иде. Югалту ачысы бөтен буыннарына зәһәр авырту булып таралды. Әнә Казан да кул сузымында гына. Шәһәргә илтүче юлда исә атлы олаулар, каядыр ашыгучы җайдаклардан башка беркем дә күренми. Гөлйөзем генә түгел, әле бая гына шау-гөр килеп су коенган кызлар төркеме дә җир тишегенә кереп киткәндәй юкка чыккан иде.

Өмет сүнде, ышаныч канаты сынды.

Санька үзгәрде, уйчанланды. Бер ноктага текәлеп утыра да тиктомалдан йә көлеп җибәрә, йә үзен кая куярга белмичә ишекле-түрле йөренергә тотына, чак кына буш вакыт табылуга шәһәргә чыгып китү ягын каера. Эш турында, Казанга ни өчен килүләре турында онытты. Суырылып калды. Өлкәннәрнең һәр сүзенә колак салырга күнеккән егет хәзер аларны бөтенләй ишетми кебек иде. Балта сораганга шөшле тоттырды дигәндәй, җавабының да рәте-чираты бетте.

Улындагы үзгәрешне Савелий Кузьмич үзенчә юрый: егет яшь, олы базарга беренче килүе, мәгърибтән һәм мәшрикътан, көн ягыннан һәм төн ягыннан килгән йөзләрчә сәүдәгәрләр, чит мәмләкәт кешеләре арасында югалып калгандыр... Ияләшер әле...

Көне-төне сату-алу, тавар алмашу белән мәшгуль ата баштарак артык әһәмият бирмәгән иде. Әмма егетнең сәерлеге бетмәде генә түгел, киресенчә, күзгә күренеп артты, аны бөтенләй хафага салды. «Берәр кызга күзе төшкәнме әллә? Яшь чак бит, гаеп эш түгел. Тик нигә әйтми ул аны...» Шулчак йөрәге жу итеп китте «Әллә бер-бер татар кызы белән бәйләнгәнме? Шул гына җитмәгән иде тагы...» Артык диндар кеше булмаса да, чын христиан рухында тәрбияләнгән, чиркәү кануннарына сүзсез буйсынуны иң дөрес эш дип санаган Савелий Кузьмич моны башына сыйдыра алмый иде. «Урыс егете белән татар кызы!.. Ничек итеп бар өметеңне баглап үстергән улыңны басурман кызына бирмәк кирәк?!» Угличта үзе белгән абруйлы кешеләрнең кызларын белешебрәк йөри башлаган ата моңа җаны-тәне белән каршы иде. «Менә эшемне генә бетерим дә утырып сөйләшербез, аңлашырбыз». Үзен-үзе шундый уйлар белән тынычландыра килде. Эш күп иде. Сәүдә көткәндәгедән дә уңыш-

лырак бара. Сүс тә, тиреләр дә яхшы бәягә китте. Инде Углич якларында сирәгрәк очрый торган яхшы мал табарга, аны төятергә кирәк. Санька гына ачуны китерә. Балаларына карата гадел, каты куллы Савелий Кузьмич улын акылга утыртырга да күп сорамас иде, тик җиткән егетне базар уртасында тотып яруның килешеп бетмәячәген аңлый, тагын кул селти. «Кайткач күрсәтермен мин сиңа Казанны да, өлкәннәр сүзен санга сукмауны да!»

Саньканы, чыннан да, сихерләделәр ахрысы. Шулай булмаса, бу кадәр үк интекмәс, төннәрен кулларын сузып, ымсынып уянмас иде. Тик ниндидер татлы газап, бәхетле сыкрану иде ул. Шикләнеп тә куя: «Юкка гына адәми затмы, пәри затмы син,— дип сорамагандыр ул. Бәлки үзе пәри кызы булгандыр. Әгәр кеше затыннан булса, бер күренер иде, очратыр иде!.. Юк бит! Юк...»

Кайтып китәр көннәр якынлашкан саен сызлануы арта, йөрәге өзгәләнә, китү көннәрен җиткермәс өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләргә әзер иде ул. Әтисенең үртәлүен сизә, бергә көймәдә килгән юлдашларының кырын карый башлаганнарын да тоя, әмма үзе белән берни дә эшли алмый. Аның күңелен бер генә нәрсә били Гөлйөзем, Гөлйөзем, Гөлйөзем!..

Ул аны тагын бер генә тапкыр, ерактан гына булса да күрер өчен әтисенең ярты малын чыгарып бирергә дә риза иде. Тик күңелдәге сурәтне чынга ашырыр көч, күрәсең, бу дөньяда юктыр. Мәхәббәтне акчага сатып алып булмый.

Санька бер генә мизгелне дә кәрван-сарайның тынчу хөҗрәсендә бикләнеп үткәрергә теләми иде. «Тизрәк, тизрәк калага, кешеләр арасына, Кабан буена!.. Пәри кызы булмаса, иртәдән кичкә кадәр шаулаган шәһәргә чыкмый калмас! Кабан күлен урамый түзә алмас!..»

Аркасына капчык салып көймәгә йөгергәндә дә, сыгылмалы басмадан ярга ашыкканда да күңелендә гел шул уй бәргәләнде. Авыр капчыкны көймә төбенә китереп салды да тирле маңгаен кул аркасы белән сыпырып, тау башыннан ымсындырып, чакырып торучы калага текәлде.

— И Казан! Гөлйөзем атлы гүзәлеңне кай тарафларыңа яшереп саклыйсың? Нигә серләреңне ачмыйсың, тылсымлы кала?!

Санька өчен Казан, чыннан да, серле иде, аңлаешсыз иде. Монда бөтенесе дә башкача. Монда башка ил, башка төрле халык, башка дин, башка төрле йолалар, гадәтләр Дөньяда иң матур дип исәпләп йөргән, Идел буена укма

шып утырган Углич моның янында бер авыл шикелле булды да калды.

Қалын бүрәнә коймалар, урлар, су тутырылган тирән чокырлар белән уратылган Қазан үзе әле тагын икегә — эчке һәм тышкы шәһәргә бүленә икән. Эчке шәһәрдә хан сарае, биек манаралы мәһабәт мәчетләр, икешәр-өчәр катлы таш пулатлар, манаралар белән узышып күккә үрелгән юан тирәк агачлары. Тышкы шәһәрдә яшәүчеләр дә йортларын бизәкләп, мөмкин кадәр затлырак итеп салырга тырышканнар. Тау битенә сыенган өйләр таштан, таудан үсеп чыккандай тоела. Шәһәрнең тышында әле тагын эреле-ваклы бистәләр бар иде.

Санька шуларны күздән кичерде һәм түземсезләнеп капчыкларны санарга керешә. Тагын утыз капчык. Бу йөкчеләр нигә шулкадәр акрын кыймылдый тагы! Егерме биш... Егерме... Қапчыклар кимегән саен Саньканың күкрәге киңәя, сулыш алуы җиңеләя кебек. Басма — көймә — яр буе, басма — көймә — яр буе... Аяклары үзеннән-үзе атлый. Менә соңгы капчык. Тизрәк калага! Алъяпкычын салып куйды да шәһәргә йөгерде.

— Улым, тагын яңа йөк киләсе бар. Ерак йөрмә,— дип кычкырды әтисе.

— Мин хәзер... Хәзер әйләнеп киләм..

Ярминкә чорында кала капкалары ачык. Айбалта тоткан, ук-җәяне янга аскан озын буйлы капка сакчылары яшь урыс егетенең кабаланып эчке шәһәргә үтүенә әллә ни игътибар бирмәделәр. Сату-алу кызган чакта йомышчы малайлар күп йөри. Эчке калага керүче таныш түгел һәркемне тикшереп, кемнең кая баруын ачыкларга тиеш булсалар да, йомышчыларга артык бәйләнмиләр иде.

Буй-буй итеп буялган нечкә озын манаралар, айван түбәсен күтәреп торучы ак баганалар, чатырны хәтерләткән такта түбәләр куе яшеллек арасыннан аеруча матур күренәләр, ерактан ук чакырып торалар иде. Шәһәргә килеп керүгә исә Санька адашып калды. Һәр йорт урам ягыннан таш яисә бүрәнә койма белән әйләндереп алынган. Алар тоташ дивар хасил итә. Һәр ихата кечкенә бер кирмән диярсең. Қойма артыннан агач ябалдашлары һәм бизәкле түбә кыеклары гына күренә. Урыны-урыны белән янәшә ике җайдак сыя алмаслык тарайган урамнар йә текә баскычка әйләнә, йә борылып шәһәр коймасы янына килеп чыга иде.

Аптырады, тәмам гаҗиз калды Санька. Гөлйөземне очрату гына түгел, ул хәтта калада адашмыйча йөри дә бел-

ми икән бит әле. Таш коймага сөялде дә уйланырга, үзенең чарасызлыгыннан уфтанырга кереште. Күзләре исә манараларны санады.

Менә Казанның иң үзәгендә, иң биек урында, хан сараеннан ерак та түгел сигез манаралы олуг мәчет тора. Янәшәсендә киң мәйданы да бар. Дүрт яктагы дүрт манарасы аеруча биек, озын, алар арасына урнашканнары яртылаш диярлек тәбәнәк иде. Кинәт Саньканың күз аллары яктырып китте. Мәчетнең дүрт манарасы дөньяның дүрт тарафына юл күрсәтә түгелме соң?! Шәһәрнең теләсә-кайсы почмагыннан аларга карап кайдалыгыңны чамаларга мөмкин ләбаса! Санька казанлыларның серен ачтым дип сөенде. Биек коймалы тар урам-тыкрыклар, калын диварга килеп терәлгән тупиклардан чыгу юлын шул манаралар күрсәтә ич!

Җәмигъ мәчетне үзәккә куеп, күңеленнән генә шәһәр өстеннән сызыклар үткәрде. Аларның берсе үзе белгән Арча капкасы ягына, икенчесе Нугай, өченчесе Болак, дүртенчесе Кырым, бишенчесе Алабуга капкасы ягына сузылды, башка капкаларга таба юллар билгеләде. Капкалар исә бөтенесе унтугыз булып, алар буйлап йөрергә күпме вакыт үтәчәген якынча гына чамалау да мөмкин түгел иде. Үзенчә «Мең манара каласы» дип исемләнгән Казан урыс сәүдәгәре улына серләрен ачып бирергә ашыкмый иде әле.

Эре чуерташ яисә агач сайгак җәелгән тар урамнарда йөргәндә Санька шәһәрнең матурлыгын да, аяк астында ни-нәрсә ятуын да күрми. Бер генә нәрсәне абайлап бара, монда урамнарны дуңгыз ертмачламаган, пычрак юк, куркып атлыйсы түгел. Эзләгәне исә — Гөлйөзем. Эре чәчәкле яшел яулык бөркәнгән, кара бәрхет камзуллы, көмеш чулпылы су кызы күренмәсме. Кайчан да булса бер урамга чыгарга тиеш бит инде ул! Чулпы чыңы ишетсә йөрәге дерт итеп куя. Менә-менә очынып, аландагыча җиңеллеге, шаянлыгы белән пәри кызы килеп чыгар да көлеп җибәрер:

— Куып җитә алмадың бит,— дип елмаер сыман тоела.

Чың ишетелгән якка ташлана һәм... алдана. Казан кызларының барысы да чулпылы икән ләбаса!

Табарына, очратачагына, ерактан булса да күрү бәхетенә ышанычы киселгәннән-киселә. Акылы иртә-кичен шәһәрдә айкалуның мәгънәсез икәнлегенә төшенә, үз-үзен битәрли, бөтенесенә кул селтәп кайтып китәргә куша. Әмма йөрәгендә пыскыган өмет уты аны кабат-кабат шәһәр урамнарына, мәйданнарына чакыра, көненә ике-өч тапкыр Кабан буендагы сихерле аланга барырга мәҗбүр итә.

«Тагын бер тапкыр хан мәчетеннән Кырым капкасына таба үтәм дә бүгенгә җитеп торыр». Күңеленнән шулай хәл итте Санька һәм җиңел сулап, арыганлыгын тоймыйча алга атлады. Ниндидер сизенү аңа «Бүген очратачаксың, күрешәчәксез» дип пышылдый иде.

Инде кала капкасына да күп калмаган иде. Чү! Гөлйөзем түгелме соң! Түбәсен гөмбәзләп япкан ике катлы таш йортны узуга, урам чатында үзеннән утызлап адым алдарак зифа сынны күреп Санька тынсыз калды. Иңенә нечкә борынлы озынча чүлмәк куйган кыз салмак кына атлап урам аша чыгып бара иде. Йөге авыр, күрәсең, гәүдәсе бер якка сыгыла төшкән, тик бу аны ямьсезләми, киресенчә, буй-сынының зифалыгын, сыгылмалылыгын күрсәтеп, белгертеп тора. Аяк атлаган саен чулпылары телгә килә:

— Чың-чың... чың-чың...

Биек үкчәле сәхтиян башмаклары урам ташына бәрелеп шакылдый:

— Тек-тек... тек-тек...

Шушы ике яңгыраш бергә кушылалар да әллә нинди сәер дә, матур да көй булып ишетеләләр:

— Чың-чың... тек-тек... чың-чың... тек-тек...

«И бәгырь кисәгем, аяк атлауларына хәтле килешле, нинди матур көй чыгарып атлый икән бит»,— дип уйлап куйды Санька соклануын яшерә алмыйча һәм адымнарын тизләтте. Менә-менә куып җитәр дә эндәшер, «Гөлйөзем'» дияр. Әнә ич егерме адым... тагын унбиш адым гына калды «Нигә әйләнеп карамыйсың соң инде?!»

Кычкырырга, дәшәргә дип ымсынган иде, калын койма өстеннән тышкы якка канәфер куаклары бүселеп төшкән ихатага якынлашкан кыз сузылып келәгә басты, тавышсыз ачылган капкадан аның калфак өстеннән бөркәнгән яулыгы гына җилфердәп калды.

«Ярый, кайда торганлыгыңны белдем,— дип сөенде Санька.— Шушы таш урамда кунсам кунармын, иллә син гүзәлне күрми китмәм». Өстеннән авыр йөк төштемени, күңелен рәхәтлек, канәгатьлек хисе биләп алды.

«Озак йөрмә»,— дип калган атасы, базар, көймәгә төяләсе йөкләр онытылды. Санька, күк капусы ачылуны көткән дәрвиш кебек, кече капканың ачылуын көтте. Урамның әле бер ягына чыкты, әле икенче ягына күчте, канәфер куаклары артына поскан тәрәзәләрдә күңеле теләгән нурлы йөз күренмәсме дип, аяк ачына басып, үрелеп-үрелеп карады. Йорт эчендә хәрәкәт-фәлән сизелмәде. «Әллә капка кагаргамы соң? Бәлки... Гөлйөзем үзе үк килеп чыгар» дип

берничә тапкыр капкага якынлашса да, күтәрелгән кулы кире төште. Йоласын, гадәтен белмәгән чит шәһәрдә, бөтенләй таныш түгел капкага шакуның нәрсә белән бетәчәген тәгаен белмәгәнгә, ашыкмаска карар кылды. Соңгы өметне өзәсе килми иде. Очрашу мизгелләрен сабырлык, түземлек белән дә көтеп буладыр. Сабыр төбе саф алтын, ди бит татарлар. Түземлекнең бер бүләге булмый калмас.

Иң уңайсызландырганы шул — узгынчылар Санькага игътибар итә башлады. Аның бернинди шөгыльсез һаман бер тирәдә — кибетләрдән, кәрван-сарайлардан читтәге урамда киләп сарып йөрүе, күрәсең, аларда шик уята, сары чәчле яшь урыска борылып-борылып карыйлар иде. Санька аларга илтифат итмәскә тырыша, яман уе юклыгын белгертү өчен авыз эченнән генә сызгыргалап ала иде. Янәсе, кемнедер көткән арада эч пошканнан йөри, матур өйләргә соклана, вакыт үткәрә. Читкәрәк тә китеп карады, тик озакка түгел, аяклары һаман шул якка тартты.

Баш түбәсен кыздырып торган кояш урамдагы өянкеләрнең ябалдашына кереп югалды, үтеп-сүтеп йөрүчеләр күзгә күренеп артты. «Ни булса да булыр, кеше белән кеше аңлашмый калмас». Санька тәвәккәл бер карарга килеп, таныш капка янына юнәлде. «Шакырга да сөйләшергә!»

Йөрәгенең дөпелдәп тибүен басарга тырышып, кулын күтәрүе булды, кече капка шартлап ачылды, шундук йонлач кул Саньканың изүеннән эләктереп алды һәм ишегалдына тартып та кертте.

— Әй, син, сыбызгы, ниеңне югалттың? — диде карлыккан тавыш.— Күрәм-күзәтәм, һаман безнең капка тирәсендә болганасың. Кем кирәк? — Һәм үзалдына мыгырданып куйды.— Шушы ярминкә җитсә, калага караклар килеп тула... Котылыр әмәл юк! Белеп тор, синең кулың озын булса, бездә мондый йодрык бар!..

Аның сөякчел каты бармакларыннан бер селтәнүдә ычкыныр көч тойса да, Санька каршылык күрсәтмәде, умырылып төшкән якасына игътибар итмәстән, булдыра алган чаклы тынычрак әйтергә тырышты:

— Абый кеше, җибәр, яман уй белән йөрмим.

Сабыр, тыныч әйткәне ачулы агайга тәэсир итте бугай, ул бөтенләй ычкындырмаса да, бармакларын бушата төште, ризалашкансыман эндәште:

— Йә, сөйлә! Кем кирәк булды?

Саньканың югалтыр нәрсәсе юк иде, ул кыюлыгын туплап әйтте дә салды:

— Сезнең өйгә... бер кыз кереп китте. Минем аңа әйтәсе сүзем бар иде, кем, хөрмәткә ия ага.

Сүзләре агайга бөтенләй кире тәэсир ясады, кулы яңадан киләшчә кебек егетнең изүен кысып алды.

— Ах син, фасикъ җан! Яшь хуҗабикәм артыннан сөйрәлдеңме? Аны үзеңә тиң дип белдеңме?! Әй, хуҗабикәм, чыгып күз салчы! Үзеңә нинди куркыныч янаганын белдеңме? — Аннан Санькага карап пышылдады.— Бәхетең, хуҗам өйдә юк... Күрмәгәнеңне күрсәтер иде. Кем артыннан сөйрәлгәнеңне беләсеңме соң, ичмасам!..

Каерылып ишек ачылды, болдырда кара камзол, аксыл күлмәк кигән, яшел яулыгы белән күзләрен генә калдырып йөзен каплаган баягы хатын-кыз күренде. Юк! Бу Гөлйөзем күзләре түгел! Бу ул түгел иде.

Аксыл күлмәкле кыз ни әйткәндер, Санька анысын ишетмәде, бар көчен җыеп агайның кулыннан ычкынды да, урамга атылып чыкты.

— Юк! Мин ялгышканмын,— дип кычкырды ул үртәлеп һәм куа чыгудан шикләнеп, тыкрыктан тыкрыкка борыла-борыла кәрван-сарайга элдерде.

Ялгышу үкенечле, аянычлы иде. Җиде төн уртасында торгызып сорасалар, сурәтен ясап, тасвирлап бирә алам дип уйлаган Гөлйөземне башка берәү белән бутау аянычы газапны тагын да көчәйтә генә төште.

Әтисе кайткан иде инде. Ул Санькаиың күгәреп чыккан күз төбенә, кендегенә хәтле умырылып төшкән күлмәгенә бер сүз дәшми озаклап карап торды. Куе кашлары астындагы зәңгәр күзләренә каралҗым куелык йөгерде.

— Теләгәнеңә ирештеңме, с-с-сынок? — диде ул сүзләрен теш арасыннан чыгарып.

Санька җавап бирмәде. «Башта ук сөйләсәм, бәлки яхшырак булыр иде. Ә хәзер...» Миеннән шундый уй йөгереп узды. «С-с-сынок» диюеннән үк әтисенең шаяртмавын, түземе соң чиккә җитүен аңлап алган иде инде ул.

Кәрван-сарайның караңгылы-яктылы хөҗрәсе әйтерсең лә кысан читлеккә әйләнде. Яктылыкка, нурга омтылган күбәләктәй җаны бу тарлыкка түзә алмас, рәнҗер, читлек рәшәткәләренә канга батканчы суккаланыр сыман тоела башлады. Кая барып бәрелергә, җанын кая куярга, эчендәге ялкынны ничек сүндерергә белмәэн Санька әтисенең газаплануын, борчылуын белә, әмма берни дә эшли алмый иде.

— Күзгә туры карый алмыйсыңмы? — диде Савелий Кузьмич тынлыкны бозып.— Күптән синең белән болай сөйләшкән юк иде.

Ул ярсыганнан-ярсый, калын тавышы хөҗрәгә генә сыешмый, бөтен кәрван-сарайны тетрәтәдер кебек иде.

— Йә, төшер ыштаныңны. Ят! — дип боерды ул кулы белән өстәл янындагы калын эскәмиягә ымлап.

Саньканың тәне куырылып килде, иреннәре калтырана башлады.

— Минме, минеме?.. Нигә...— дип кабатлады ул үз-үзен белештермичә.— Мин бит җиткән егет...

Ул атасының сугуыннан курыкмый, гарьлегеннән, ата ихтыяры каршында көчсезлегеннән, гаделсезлек алдында чарасызлыгыннан үртәлә, аның таләбенә каршы килә алмый иде.

— Нәрсә?.. Үзем төшериммени? — дип җикерде этисе һәм тыңлаусыз бармаклары белән билендәге калын каешны ычкындырырга керешге.— Ят! Җиткән егетләргә дә ата хөкеме бар!

Санька эскәмиягә сузылды һәм, күзләрен йомып, җан көче белән калын тактаны кысты.

Каеш тавышы сызгырып һаваны кисеп үтте.

— Монысы атаң сүзен тыңламаган өчен!

Савелий Кузьмичның таза куллары селтәнеп өскә күтәрелә дә җан ачуы белән аска ыргыла.

— Монысы эшлексезлегең, кирелегең өчен!..

— ... мал кадерен белмәгәнең өчен!..

— ... башкисәрлегең, кызрачлыгың өчен!..

— ... сугышып йөргән өчен...

Санька, тешләрен кысып, эскәмия белән бербөтенгә әйләнергә теләгәндәй, буе белән тактага сеңде. Суккан саен аның гәүдәсе калтыранып-калтыранып куя, эмма авызыннан бер бөртек сүз чыкмый иде. Тәне кара янды, суелган тиресеннән кан тамчылары саркый башлады.

Шулчак шыгырдап ишек ачылды, авыр аяк тавышлары ишетелде.

— Егетне акылга өйрәтәбезме?

Оятыннан күзләрен чытырдатып йомган Санька беренче сүзләреннән үк керүченең кемлеген танып алды. «Казанлылар белән сөйләшкәндә телендә бал, куенында таш булсын»,— дигән озын торыклы Иван-сәүдәгәр иде бу. Ул тагын бер киңәшен бирде:

— Дөрес эшлисең, Савелий Кузьмич! Өйрәт, өйрәт. Талны яшь чагында бөгәләр... Бозылды, бозылды хәзер яшьләр.

Җир ярылса җир тишегенә кереп китәрдәй булган Санька аның тизрәк чыгып китүен тели, бөтен җанын шул газаплы уй биләп алган иде. Ә Иван-сәүдәгәр чыгарга ашыкмады, үз өендәге хуҗа шикелле таралып, түр башына менеп утырды.

— Йә инде, Савелий Кузьмич, дәвам ит!

Аның бер сүзен ишетүгә караганда этисенең йөз тапкыр сугуын җиңелрәк күтәрәчәк Санька тешләрен шыгырдатып, ыңгырашып куйды:

— Чыгып ки-и-ит!..

Савелий Кузьмич малаеның хәлен аңладымы, әллә башка берәр уе бар идеме, «Монысы каршы әйткәнең өчен»,— дип, тагын бер селтәнде дә Иванга ачуланып кычкырды:

— Кит диләр сиңа! Ата белән улда катнашың булмасын!

Иван-сәүдәгәр, аның кычкыруын сизмәгәндәй канәгать елмаеп, кых-кых көлә-көлә акрын гына чыгып китте. Хөҗрәдә тагын авыр тынлык урнашты.

— Гафу үтенә дә белмисең бит, ичмасам, тискәре җан! — диде кинәт ата кеше үкенүле тавыш белән һәм Санька каршына тезләнеп, бите белән улының чәчләренә капланды.— Авырттырмадыммы?..

Саньканың күзләренә яшь тыгылды. Авыртудан яисә үкенечтән түгел, ә бугазына төер булып тыгылган җәлләү, этисен кызгану хисеннән туган яшьләр иде бу. Әмма үҗәтләнеп кысылган иреннәреннән бер сүз дә ычкынмады.

— Бар, улым, ял ит! Иртәгә өйләдән соң кузгалабыз. Көймәчеләргә әйтелгән,— диде йомшарып калган Савелий Кузьмич.— Атаңа ачуланма... Шайтан котыртты...

Бу сүзләре белән Саньканың тәненә түгел, җанына тагын да авыррак яра ясаганын ул, әлбәттә, белми иде.

Санька, сыкрануын онытып, сикереп торганын сизми дә калды. Тән җәрәхәтләре дә, авырту-сызлану да, Иван-сәүдәгәрнең кыланышы да, этисенә рәнҗү катыш кызгану да онытылды, артка чигенде.

— Ассаң ас, киссәң кис... Мин иртәгә Казаннан китә алмыйм. Эшем бетмәгән,— дип ярып салды ул.

Улының үҗәтлегеннән тәмам гаҗиз калган, бәгыреннән өзелеп төшкән соңгы тамчысын — төпчеген аерата яраткан, шуны берничек тә белдерә алмаган ата кеше йөрәгенә чыдый алмыйча уфтанып куйды һәм шартлатып өстәлгә китереп сукты.

— Китте! Шәһәргә аягыңны да атламыйсың!.. Мин сине... бәйләп алып китәм...

* * *

Менә ничәнче көн инде Гөлйөземнең күңелен үкенү хисе телгәли, менә ничәнче көн инде аны зур булып ачылган җете зәңгәр күзләр эзәрлекли. Ятса да, торса да һаман шул күзләр аны каядыр чакыра, ымсындырып тылсымлы нурлар җибәрә кебек, нәрсәдер әйтергә, аңлатырга тели, бергә-бергә каядыр еракка, алсу томаннар артындагы киңлекләргә өнди. Су буенда үз гомерендә беренче тапкыр күргән егетнең сурәтен ул никадәр теләсә дә, күңеленнән йолкып ата алмый иде. Төшләрендә күрә. Имеш, кулгакул тотышканнар да аллы-гөлле чәчәкләр каплаган иксезчиксез болыннар буйлап йөгерәләр. Алда нәкъ аның күзләредәй җете зәңгәр булып җәелгән олуг диңгез шаулый. Менә алар йөгереп килә дә дулкыннар кочагына ташланалар, салмак кына тирбәлгән су өстендә бергәләп чайкалалар, бәхетгән, тәннәренә бәрелеп уйнаган талгын җылы агымда ләззәтләнеп изриләр.

«Барысына да үзем гаепле,— дип уфтана Гөлйөзем.— Яулыгымны алгач та кызлар артыннан җитәм дип җир асты юлына ташланмасам, аның белән бергә кайткан булыр идек. Куып җитәр иде. Сөйләшер идек...» Киң күкрәкле, көчле бу егетнең үзенә бер генә кәррә дә яманлык кылмаячагына ул җаны-тәне белән ышана иде. Андый чиста, моңсу һәм самими күзләр әшәкелек ияләрендә — хәрамзадәләрдә булмый, була да алмый.

Каланың Болак капкасы янындагы манара эченә илтә торган яшерен юл су буендагы текә яр астыннан башлана. Аңа керү урыны куе гөлҗимеш куаклары, калын-калын өянкеләргә үрелгән колмак үсентеләре белән томаланган, сукмакны исә котырып үскән әрекмән яфраклары каплаган. Табигать аны кеше күзеннән качырырга теләгәндәй, бөтен хыялын эшкә җиккән, бер генә ачык җирне дә калдырмый яшел үсентеләр сипкән иде. Дөрес, яшерен юлны калада бик сирәк кешеләр белә. Әмма абыйсы хан хезмәтендә — чагдавыл* булып торучы Гөлйөзем өчен ул сер түгел иде.

Сеңлесен үлеп яраткан абый кеше аны кат-кат антлар иттерә-иттерә генә әйтте.

— Үлгәндә дә серне ятларга ачма! Яу килгәндә, Казан-йортка һәлакәт янаганда гына файдалана торган юл ул. Борынында киртләп куй,— дип кат-кат кисәтте.— Бел, аның белән шаярырга ярамый.

---

* *Чагдавыл* — сакчы.

Шаярырга ярамый! Ә Гөлйөзем сүзендә тормады. Су буенда очраган егетне шаярту, күктән төшкән зат шикелле аның күз алдында гаип булу теләге җиңде — яулыгын алуга аяк очларына гына басып яр астына йөгерде дә куаклар арасына чумды. Тәпи йөри башлауга табигать кочагында үскән кыз өчен бер ботакны да селкетми, шылт иткән тавыш да чыгармый әрәмәдә йөрү артык катлаулы түгел иде.

Менә хәзер шуның җәзасын күрә, «Нигә качтым икән, нигә көтмәдем икән?» дип өзгәләнә. Ләкин үткәнне кире кайтарып булмый. Исемен дә белмәгән бу ят егетне кайда да булса очратачагына өмете юк диярлек. Казанныкына да охшамаган үзе. Кем белә, бәлки чит-ят илләрдән килгән шаһзадәдер! Азмыни базарда килгән-киткән кеше!

Гөлйөзем чигү чигә. Әти-әниләре аңа кул эшен дә ныклап өйрәтергә ниятлиләр, шуның өчен махсус чигүче оста яллаганнар иде. Көн дә килеп ул тегү, чигү, каю, чәмчәләү кебек хатын-кызга лазем эшләрдән сабак бирә. Укалап чигү, энҗе, сәйләнь тезү кебек шөгыль Казан кызларының яраткан эше генә түгел, аларның данын ерак-еракларга таратуга сәбәпче дә иде. Гөлйөземнәрнең өе иркен. Дус кызларын да чакырып утыру бер гадәткә әйләнгән иде.

Үзе чигү чигә, күз алдында исә Акканат сурәте. Зәңгәр күзле яшь пәһлеванга ул үзенчә шулай исем кушып өлгергән иде инде. Кара бәрхетнең уртасына ике зур энҗе беркетте, алар тирәсенә зәңгәр сәйләннәрдән түгәрәк чигеп куйды. Бу — Акканат күзләре. Аннан тары бөртеге чаклы гына вак сәйләннәрне җепкә тезеп, кыйгачланып күтәрелүче канатлар ясарга керешге. Ак сәйләннәр арасына сирәкләп кенә зәңгәрләрен салып чыкты. Чиста күк йөзендә талпынучы кошка охшаш сурәт пәйда булды. Чигеп бетергәч, калфагын чәчләренә беркетеп, өстенә ак ефәк яулык салды да кулына көзге алды.

— Аһ, Гөлйөзем, син нинди чибәр! — дип куйды дус кызларының берсе. Кинәт кулыннан эшен ташлап, Гөлйөземне кочаклап алды. — Тукта, тукта! Син бит бөтенләй чит-ят бизәк төшергәнсең. Остазым-ханым безгә мондыйны өйрәтмәде бит. Каян алдың?

Гөлйөзем серле генә елмайды:

— Таптым инде...

Дусты үпкәләп баш чайкады:

— Шуны миңа күрсәтмәгәнсең... Мин дә чиккән булыр идем.

— Аның ничек килеп чыкканын үзем дә белмим. Куллар үзеннән-үзе чикте бугай...

Калфак бизәге, чыннан да, матур иде. Кара бәрхет өстенә төшкән сәйлән-нәкышлар таныш түгел, әмма онытылып кына торган җанга якын бер сурәтне хәтерләтә иде. Анда күк зәңгәрлеге дә, кышкы кар аклыгы да, чишмә суларының үтә күренмәле сафлыгы да бар иде сыман.

— Бәхет кошым шундый минем,— дип пышылдады Гөлйөзем һәм ашыкмый гына сөйләшеп торган җиреннән кинәт кенә чигү энәләрен бер якка ташлады, ашыгып-каударланып ишек тоткасына барып ябышты, ялваргандай эндәште:

— Остазым-ханым, ачуланма мине! Бик азга гына калага чыгып керәсем бар. Рөхсәт итче!

— Әллә нишләдең, сәерләндең син, Гөлйөзем. Әллә гашыйк булдың инде,— диде чигүче ханым аптыраулы караш ташлап.— Әниләрең сизмәсен. Ачуланырлар... Бар, тиз йөре...— Яраткан шәкертенә ул берничек тә каршы төшә алмый иде.

Гөлйөземнең битенә куе кызыллык йөгерде, керфекләре, зур кара күзләрен каплап, сирпелеп алды.

«Коенырга бер килгән егет тагын килми калмас. Кабан күленең сихәтен, сафландыргыч хасиятен татыган кеше анда кайтмый калмый». Кыз шулай уйлый. Акканатның анда киләчәген күңеле сизенә. Ул моны берничек тә аңлата алмый, әмма егетнең күзләре һаман шунда, аланлыкка чакыра кебек тоела.

Йөрәге очар коштай талпынган Гөлйөзем шәһәр капкасы янына килеп җитүен сизми дә калды. Шыпырт кына манара астына чумарга, турыдан — яшерен юлдан йөгерергә исәпләгән кыз кирмән коймасыннан алдына сикереп төшкән күләгәдән сискәнеп китте, куркынып авызын каплады.

— Кая йөгерәсең, Гөлйөзем? Болай чибәрләнеп... Ешладың әле...

Каршында авызын ерып капка сакчылары башлыгы — тоткавыл Шәһит басып тора иде. Аның йөзе балкый, чем-кара мыеклары астыннан ап-ак тешләре елтырый. Ул шаяртуын белде:

— Әллә безне сагынып киләсең инде? Шулай бит, Фәрит,— дип кычкырды ул капка өстенә карап.

Биек имән бураның тәрәзә сыман калдырылган уентыгында абыйсының йөзе күренде. Ул баш чайкады.

— Белмим, белмим... Кемне сагына торгандыр...

Егетләр мәгънәле карашып көлештеләр. Аларның кызны шаяртасы килүләре әллә каян сизелеп тора иде.

Тизрәк ычкынырга зар булган Гөлйөзем ялварулы карашын абыйсына текәде.

— Зинһар дим, җибәрегез инде. Мин бик азга гына... Эш күп икәнен беләсең ич!.. Күл буена гына...

Абыйсы ярар сана дигән шикелле кул селтәде. Әмма Шәһитнең җибәрәсе килмәгәне йөзенә чыккан, ул һаман үзенекен туглады:

— Бүген кич чыксаң, җибәрәм. Бергә биибезме?.. Вәгъдәме?

Гөлйөзем иңсәләрен җыерды да аның яныннан читләтеп узып, манара эченә кереп китте. Моннан Кабан буе кул сузымында гына. Тизрәк! Тизрәк! Акканат аны көтәдер, күзләрен текәп юлга багадыр...

Колмак ботакларын аралап текә яр астына килеп чыкты, саклык белән генә эзләрен яңадан каплап куйды да комлы аланга ашыкты. Алан буш иде. Ул яр буйлап берничә кат урап килде, күл өстенә озаклап карап торды. Тирәякта шылт иткән аваз да юк. Табигать мәрткә киткәндәй куе, тыгыз тынлыкка күмелгән иде.

Очынулы адымнары сүлпәнәйде. «Күңелем алданды микәнни? Юкса чакыруын сиздем, тойдым бит» дип өзгәләнде. Акрын гына яңадан шәһәргә атлады.

Акканатсыз үткән һәр көн Гөлйөземгә әллә нинди сагышлы газап өсти, моңланырга, үз эченә бикләнергә мәҗбүр итә иде. Шуңадырмы, ахирәт кызлары хәзер сирәгрәк керә. Аларның да күбесе һөнәрчеләр затыннан. Күп вакытларын кул эше белән үткәрәләр. Хәер, кызларга ул серен чишмәде. Күл буендагы тылсымлы очрашуны аның үзе генә беләсе, үзе генә хыялланасы килә иде.

Алда ярминкә бизәге — җомга җыены бар бит әле. Ташаякның гөрләп торган чагы. Әнә Казан суы буендагы болыннарда чаң-кубызлар чыңлый, сорнай-кәрнайларның*, кубызларның дәртле тавышлары яңгырый, курай моңлана, сазлар өздерә, думбаклар бәргәләнә-бәргәләнә биергә чакыра.

Казанлылар тар күңелле түгел. Ярминкәгә килгән сәүдәгәрләр, малтабарлар, һөнәрчеләр, ерак сәяхәтләрдән ямь табучыларның барысын да сөрән салучылар бәйрәмгә чакыра. Бүген җомга җыены, бүген олы бәйрәм! Күп тә

---

* *Чаң-кубыз, сорнай-кәрнай* — музыка уен кораллары.

үтмәс, чаң-кубызларга тагын дистәләрчә ят уен коралларының авазлары кушылыр, туң бәгырьләрне дә эретерлек, очынып биерлек дәртле көйләр яңгырар.

Гөлйөзем шунда ашыга. Юк! Бүген биисе дә, җырлыйсы да килми аның. Күңеленең иң төбендә яшерен өмете бар — Акканатны күрү, аның күзләренә багу. Тәнендә җаны булган егет Ташаяк ярминкәсенә килеп тә, кичке җыенга чыкмый калмас. Ул шуңа ышана, шуны тели. Акканат булмаса — җыенның яме, уенның тәме качар...

Ахирәт дуслары янына да кереп тормады, болынга ялгыз төшәсе итте Гөлйөзем. Ул килеп җиткәндә уенның иң кызган чагы иде инде. Ыспай киенгән, чая, көяз егетләр бер-берсенең иңнәренә кулларын салганнар да кызлар алдында тыпырдыйлар. Казан суы өстендә аларның шаян җырлары тарала.

Куаныч агай үгез суй,
Өстәп кызыл туның куй.
Илдән-илгә йөрербез,
Матур кызлар күрербез,
Даулап алып бирербез,
Яулап алып бирербез.

Теге яки бу халыкның борынгылыгын, зәвыгының камиллек дәрәҗәсен белергә теләсәң, аның хатын-кызларына, аларның да кием-салымына, үз-үзен тотышына игътибар ит, дигән акыл ияләре. Бу җәһәттән Казан кызлары бик күп кавемнәргә, тирә-яктагы эреле-ваклы ыруларга үрнәк булырлык иде. Кул эшенә, төрле-төрле һөнәрләргә ия булу белән бергә, аларга тыйнаклык, басынкылык, һичкем алдында каушап калырга ирек бирмәслек дәрәҗәдә горурлык, чамасын белеп кенә уенчаклык хас иде. Кием-салымнары да шул хасиятләренә туры килеп, бик күп мөсафирларны сокландырырдай чибәр иде. Киң җиңле озын күлмәкне, гадәттә, ак өстенә сыек зәңгәр, алтынсу сары, яшел һәм алсу төстәге буй-буй сызыклар катыштырып тукылган киндер, җитен яисә ефәктән тегәләр, өс киемнәренең җиң очын, якасын, изүен һәм чабуын укалы тасма белән кырлау гадәте дә бар иде. Әмма хатын-кызның төп бизәге — калфак. Анысын инде һәркем үзенчә чигә, көмеш яки алтын тәңкә, энҗе һәм асылташлар белән матурлый. Бусы — Казан дәүләтендәге төрле ыруларның йоласына бәйле. Ләкин, ничек кенә булмасын, очлыйм рәвешендәге шушы баш киемнәре Казан кызларының үзара ярышу, осталыкта көч сына-

шуына да сәбәп була иде. Кыз бала урамга калфаксыз чыкмас.

Гөлйөземнең дә үзе чиккән, энҗеләр тезеп бизәгән калфагын киеп мәйданны бер урыйсы, кемнәрнедер көнләштереп, кемнәрнедер сокландырып үтәсе килгән иде. Әмма уенга кушылмады, күзләре һаман тирә-яктан таныш чалымнарны, ак чырайлы яшь баһадирны эзләде. Чая, көяз егетләрнең берсе дә хәзер аны кызыксындырмый, хыялындагы Акканат урәте аларның барысын да томалаган, каплаган иде.

Авырлык белән, ялган белән чыкты Гөлйөзем җыенга. Шунысы да эчен пошыра. Бүген беренче тапкыр карт нәнәсенә дөресен әйтмәде. Үкенү хисе йөрәген кыса, ямьле кичнең матурлыгына сокланырга, ишләре арасында уенкөлкегә кушылырга ирек бирми иде кебек. Бишектән багып үстергән, дөньяга күзен ачкан, беренче сабакны укыткан, әнисеннән кала иң якын сердәше, ахирәтенә әйләнеп беткән нәнә апасына алдашты, каты дәште. Хәзер менә аңа ни дип әйтер дә, ни йөз белән каршына басар?! Дөресен әйтсә, бәлки нәнәсе аңлар, җыенга ялгызын чыгару җаен табар, әнисе каршында да бер-бер сылтау белән аны аклар иде. Элекке елларда гелән-гелән җыенга алып чыгып, бәйрәм күрсәтеп йөрергә күнеккән нәнәсе көне буе әзерләнде, сабырсызланып Гөлйөземне көтте юкса. Иң соңгы мизгелдә генә әллә нәрсә булды, Гөлйөзем үзе дә көтмәгән сүзне әйтте дә ташлады:

— И нәнәм, мин иптәш кызларым белән сүз куештым. Атлар җигеп көтеп торалар... Мине алар йөртер, алар алып кайтыр,— диде.— Син күренеп йөрмә, бүлмәңә кер дә биклән, әни күрсә ачуланыр,— диде.— Кара аны, серемне сиздермә,— дип тә өстәде.

Гөлйөземнең һәр адымы өчен эти-әниләре каршында җавап тотарга өйрәнгән нәнәсе коелды да төште. Гомердә булмаган бу сүзләрдән йөзе караңгыланды, әмма кистереп бер сүз дә әйтмәде.

Бу анын рәнҗүе икән. Гөлйөзем моны җыенга килеп җиткәч кенә аңлады. Бала тәрбияләргә алынып, йортта торып калган, гаиләдә үз кешегә әйләнгән нәнә апасы кайчандыр кол кызы булган ласа.

Бүген Гөлйөзем шуны исенә төшерде, теле белән әйтмәсә дә, гамәле белән белгертте: — «Син кол хатын. Урыныңны бел! Мин җиткән кыз. Мин үзем хуҗа. Кемлегеңне онытма!» — диде.

Йортта кирәксезгә әйләнгән колларның гадәттә базарга

чыгарылуын белгән Гөлйөзем бүген үзенең карт нәнәсенә нинди яра ясавын әле генә аңлап алган иде. Дөрес, ул аңа юл куймаска тырышыр. Әмма каты куллы, сүзен үткәреп әйтә белүче атасы аны тыңлармы?!

Менә шунлыктан да Гөлйөзем яшьләр уенына кушылыр дәрәҗәдә түгел иде.

Бәйләнчек чебен кебек борчып, йөдәтеп торган икенче бер уе да бар әле аның. Соңгы вакытта абыйсының дусты — абыйсы белән дә, ялгызы да килер дә керер. Үзе абыйсы белән сөйләшер, күзе Гөлйөземдә булыр. Дөрес, төшеп калган егет түгел үзе. Нәсел-нәсәбе дә җиргә нык басып, дөнья корып яши белүчеләрдән, ди. Казан янында гына утарлары, урман-болыннары, иген игеп көн күрүче авыллары бар имеш. Җәйләрен сәйфиягә шунда чыгалар ди. Боларын аңа абыйсы сиздергән иде. Сумаладай кара чәчле, кара күзле, сызылып киткән кара мыеклы бу егет бер күз кысуга теләсә кайсы кызның йөрәгендә ялкын кабыныр иде. Тик нишләптер өнәп бетерми аны Гөлйөзем. Элек тә шулайрак иде. Ә хәзер, Акканатны очраткач, йөрәгендә башкаларга урын калмаган иде инде.

Унбишен яңа гына тутырган, уеннарга да яңарак кына катнаша башлаган Гөлйөземнең пакь күңеле башка егетләргә күтәрелеп карарга да рөхсәт бирми, хыялый сурәтенә тугрылык саклый. Шәһит килеп чыкмасын дип шикләнә, ул очраса, Акканатка юл куймас, күрешергә дә, сөйләшергә дә ирек бирмәс. Теләсә-кайчан кылычка тотынырга әзер мәргән егет, шиксез, Акканатны да бәхәскә чакырмый калмас иде.

Морзалар нәселенең горурлык, егетлек көндәшлеге, кызлар намусы турында үз төшенчәләре бар. Алар күп нәрсәне кылыч белән хәл итә.

— Акканатым минем, ак нурым,— дип кабатлый ул эчтән генә.— Кил инде. Бер күрим дә хәлеңне белим. Син чыннан да бар идеңме соң, әллә күл төбеннән күтәрелгән пәри егете идеңме?..

Имештер күл төбендә су кызлары, җен-пәриләр яши дип әкиятләр тыңлап үскән кызның кайчагында күңеленә вәсвәсә иңә Куак өстеннән башы белән киң күкрәге генә күренеп торган ап-ак тәнле сәер егет — пәри зат булса да гаҗәп түгел. Төпсез күл бит ул! Күңеленә мондый шөбһә керүгә белгәннәрен укый, шомлы уйларны куарга тотына:

— Юк! Юк!.. Пәри егетеннән андый да җылылык, кайнар тарту көче бөркелмәс иде!..

Алан өстендә җыр авазлары сирәгәя төште, чаң-кубызлар талды, курайчыларның тыны бетте. Яшьләр берәмберәм дә, парлашып та, төркем-төркем булып та кала ягына китә башлады. Мәйданда иң чая, иң дәртле егетләр, җырлап, уйнап туймаган кызлар гына калыр, алар таң йолдызы калыкканчы йөрерләр. И бәхетлеләр!

Өметенең акланмавын аңлаган, хыялындагы егетнең чынлыгына шикләнә башлаган Гөлйөзем дә шәһәргә таба атлады. Күзләрен моң басты. Әллә яшь иде ул, әллә инде... Кинәт томан пәрдәсе каплаган күзләре зур булып ачылды, йөрәге тозакка эләккән болан баласыдай бәргәләнергә тотынды, аякларының хәле бетте. Кала ягыннан талпынып очкан кошны хәтерләтеп Акканат ашыга түгелме соң?! Ул моны ачык күрмәсә дә, җаны-тәне белән сизде, зарыгып көткән кешесен ничек каршыларга белмичә баскан урынында катты да калды. Тау өстеннән төшеп килүче, чыннан да, Акканат иде.

Менә ул Гөлйөземгә якынлашты һәм... кызның үзе шикелле үк, аннан берничә адымда тораташка әйләнде. Телләре түгел, бер-берсенә төбәлгән күзләре генә сүзсез аңлаша, серләшә, моң-зарларын уртаклаша иде.

— Мин сине эзләдем,— диде, ниһаять, егет.

— Мин сине көттем,— дип җавап кайтарды кыз.— Мин килереңне белдем. Сагынып көттем...

Үз гомерендә беренче мәртәбә сагыну сүзен әйткән кызның битләренә алсулык йөгерде, чаткыланып нур уйнаган күзләре керфек астына кереп качты.

— Чынлапмы? Көттеңме? — Бәхетенә үзе дә ышанмаган Санька бер талпыну белән кызның кулларын учына алганын сизми дә калды. Кыз бармакларындагы кайнарлык бөтен тәненә йөгерде, башы әйләнеп китте.— Көттеңме? — дип кабатлады ул.— Шатлык белән тулган йөрәге күкрәк читлеген ватып чыгарга теләгәндәй талпына, гаҗәпле бер рәхәттән сулкылдый башлады.

Кыз кулларын тартып алмады, алар җитәкләшеп үзләре дә белмәгән тарафка китеп бардылар. Төркем-төркем яшьләр дә, көйчеләр дә аларга күренми, көлешү-җырлашу аларга ишетелми. Аларның икесе генә белгән, ике җан бергә кушылып талпынган аерым дөньясы бар иде.

— Без иртәгә китәбез, Гөлйөзем. Ләкин мин әйләнеп кайтырмын. Көт, яме,— диде Санька кызның кулларын җылытып.

Гөлйөзем, аны җавапсыз калдырып, беренче тапкыр күргәндәй, кинәт читкә тайпылды, тавышы үзгәрде.

— Син минем исемне каян беләсең? — диде ул чиксез гаҗәпләнеп.— Әйткәнем юк лабаса!..

— Беләм инде... Анысы сер...

— Ах, юньсез, без коенганны карап торгансың ич син,— диде, ниһаять, Гөлйөзем, үз исеменең ничек мәгълүм булуының серенә төшенеп.— Оялмадыңдамы?

— Оялдым да инде...— Саньканың бите кып-кызыл булды, колаклары кызышып яна башлады. «Ярый әле караңгы. Битләремне күрми»,— дип сөенеп уйлап куйды ул.

Кызның аны ачуланасы, оялтасы килә, әмма теле әйләнми иде. Ул үзе оялды, җир тишегенә кереп китәрдәй булып кызарды. Бөтен кешедән яшеренеп су коенган кызлар үзләрен кем дә булса күзәтеп торыр дип башларына да китермәгәннәр иде ич.

Тик бу халәтләре озакка бармады. Тулган ай, болытлар астыннан чыгып, бер-берсе алдында каушап, нидер әйтергә теләп тә әйтә алмаган шикелле кыюсыз басып торган егет белән кызны яктыртты. Гөлйөзем егетнең йөзен күрергә тели иде. Аның күз төбендә шәмәхәләнеп торган урынны күрүгә кызганудан йөрәге кысылды, ярдәмчесез нәни баланы сөйгәндәй, аны йомшак сары чәчләреннән сыйпап иркәлисе, юатасы килә башлады. Куркынып кычкырып җибәрүен сизми дә калды:

— Ни булды сиңа, Акканатым? Нишләдең?

«Акканатым» сүзеннән Саньканың иңнәренә канатлар үсеп чыккандай булды. Шушы кызны яклап, саклап теләсә нинди яуга каршы ташланырлык көч тоя иде ул үзендә.

— Зарар юк! — дигән булды.— Егет кеше ярасыз булмас. Ә чын исемем минем Александр.

— Нинди сәер исем,— дип пышылдады кыз. Алек-сандыр!

— Юк инде, мине Санька гына диләр. Дөньяда иң матур исем синеке — Гөлйөзем. Мин аны ишеткәч тә мондый исем бары тик фәрештәләрдә генә була торгандыр дип уйлаган идем... Син бит минем фәрештәм, Казан фәрештәсе...

Күк йөзендә берәм-берәм йолдызлар кабынды, Идел ягыннан салкынча җиләс җил исеп куйды. Алар исә бернәрсә дә белмичә, бернәрсә дә сизмичә бардылар да бардылар. Күпме вакыт үтүе, күк йөзенең шәмәхәләнеп таң атар чак җиткәненнән хәбәр бирүе дә аларны борчымый. Бөтен дөнья, бөтен җиһан, Идел һәм Казан суы, Кабан һәм

Болак, чирәм арасына яшеренгән бөҗәкләр һәм судагы балыклар — барчасы да алар өчен гүя яшәүдән туктаган, юкка чыккан. Дөньяның үзәгендә ике генә зат — алар, Гөлйөзем белән Санька гына калган иде.

— Мин сине өеңә кадәр озатып куям, яме,— диде Санька. Аның әле һаман да бу очрашуны өзәсе килми, ул аерылырга теләми, ләкин шулай кирәк икәнлеген белә һәм Гөлйөземгә нинди дә булса зыян китерүдән куркыну йөрәген кысылып-кысылып куярга мәҗбүр итә.— Сине өеңдә ачуланмаслармы?..

— Рәхмәт,— диде Гөлйөзем һәм иңнәрен җыерып куйды.— Минем бит әле болай озак йөргәнем юк иде...

Шулчак шаулап чабып килүче ат тавышыннан сискәнеп, икесе ике якка тартылдылар. Парлап җигелгән җиңел арба өермәдәй томырылып кыз белән егет арасына килеп керде. Атлар кешнәшеп арт аякларына чүктеләр. Җиргә кара күләгә сикереп төште һәм эһ дигәнче кызны бөтәрләп, икенче күләгәнең аяк астына ыргытты, арбага сикерде. Шуны гына көтеп торган шәүлә камчы белән орды, зәһәр авыртуга чыдый алмаган атлар караңгылыкка ыргылды.

Санька арбага сикерде һәм сыңар кулы белән арттагы аратага ябышып өлгерде. Тик ыргылган атларның тартылуы шулкадәр кинәт булды ки, иреннәрен канга батырганчы тешләгән егет, ычкынып, үлән өстенә тәгәрәде.

— Ак-кана-ты-ы-ым!

Төн пәрдәсен ертып Гөлйөземнең ачыргаланып кычкырганы ишетелде.

Күз ачып йомганчы булган бу мәкерле, җан тетрәткеч явызлыктан Саньканың бөтен тәне куырылып килде, әйтерсең йөрәгенә үтмәс хәнҗәр кададылар. Ул сикереп торды һәм үкенеченнән, чарасызлыгыннан буылып, арба югалган якка ыргылды.

АТА БЕЛӘН УЛ

Агыйделнең алаңы,
Пешә икән баланы.
Ата-ана үстерә икән
Хәсрәт өчен баланы.

Халык җыры.

Сызылып таң атты. Күккә омтылган дистәләрчә манаралардан шәһәр өстенә дулкын-дулкын булып иртәнге азан тавышлары таралды.

— Бисмилла иррахман иррахим... Лә илаһе...

Ниндидер илаһи мәкам белән яңгыраган бу авазларны ишеткән саен Савелий Кузьмичның күңеле тула, күзләрен томан пәрдәсе каплый. Танып белсә дә, җанын аңлап бетермәгән казанлыларның, мөселман динен тотучыларның меңмең еллар җыелып килгән аһ-зары, моң-сагышы шулай чайпалып түгеләдер сыман тоела башлый. Хаксызга рәнҗетелгәннәр, яу кырларында ятып калганнарның җаны елыйдыр, алар шул манаралардан исәннәрне кисәтәдер: аң булыгыз, үзегез кебек бәндәләрне рәнҗетмәгез. Хак тәгалә каршында барыбыз да тигез, барыбыз да хакның бәндәләре...

Мәгънәсен аңламаган бу доганы шулай үзенчә тәгаенли карт сәүдәгәр.

— Әйе, дөрес сүзләр! — дип пышылдады ул һәм почмакка карап бармак ишарәләре белән тәре сурәте ясагач, сукрана-сукрана ятагыннан кузгалды.— Түзем җитми шул адәм баласына, сабырлык җитми...

Улы исенә төште, тагын чукынып алды, белгәннәрен укынды:

— О боже милостивый, спаси и сохрани...

Бүтән каршы әйтмәслек итеп сабак укыту өчен ул аны хөҗрәгә бикләп калдырган иде. «Уйланырга вакыты булгандыр. Артыграк җибәрдем җибәрүен... Ләкин алла гафу итәр... Ата кулы суккан җир тәмугта янмый».

Савелий Кузьмич авыр уйларыннан арына алмый иде әле. Акрын гына күрше хөҗрә ишеге янына килде һәм ачкычны тыгып борып җибәрде.

— Йә, улым! Карт атаңны гафу ит! Үзең өчен тырышам...

Эчтән тавыш-тын ишетелмәде. Күңеленә тула барган шомны җиңәргә тырышып бүлмәгә күз салды. Хөҗрә буш иде. Тик иданнән өч терсәк биеклегендә уелган тар тәрә-

зәнең пыялалары алынган, аннан саркып иртәнге томан керә иде.

Авыр гәүдәсе лыпылдап ишек катындагы урындыкка килеп төште, тыны кысылды, калтыранган бармаклары утыртма якасының сәдәфләрен ычкындыра алмый азапланды.

— И раббым! Ни гөнаһларым өчен мондый җәзалар белән газаплыйсың? — Иреннәре бертуктамый дога сүзләрен пышылдады.— Кеше җаны кыйганым юк, алыш-бирештә намус кушканча эш итәргә тырыштым. Ач күземне, ни гаепләрем бар?! Балама түгел, җәзаңны үземә бир. Түзәрмен, тик газиз төпчегемне сакла, аңа ак юл күрсәт!..

Билгесезлектән, чуалчык уйларыннан тәмам башы түнгән Савелий Кузьмич ни кылырга, кайдан ярдәм өмет итәргә белми. Горур, бәйсез холыклы малаеның чыгып качуында үзенең гаебе бар дип өзгәләнә, хатасын төзәтә алмау ачысыннан җаны кыйнала иде.

— Җиткән егетне... Җитмәсә, кеше алдында!..

Вакытлы-вакытсыз килеп кергән, урынсыз сүзләре белән яралы күңеленә тоз салган Иван-сәүдәгәргә дә ачуы кузгалып куя. «Дәшмәсә ни булыр иде ичмасам!»

Казан зур!.. Шуның өстенә күз күрмәгән, колак ишетмәгән яклардан меңнәрчә, ун меңнәрчә базаркәннәр, малтабарлар, һөнәрчеләр килеп тулган. Алар арасында, меңнәрчә кеше кайнашкан җирдә Саньканы юллау, эзләү, табу өметсез бер эш иде. Тик күңел өчен булса да эзләргә кирәк. Монысын да яхшы аңлый Савелий Кузьмич. Дөрес, Казанда урыс сәүдәгәрләре яшәп ята торган бистә бар-барын. Ләкин Санькының анда булуы шикле. Олысы-кечесе атасын белгән, хөрмәт иткән җирдә андый кыяфәт белән күренергә базмас. Хәер, әле ул аларны таныштырып та өлгермәгән иде. Тагын әрмән бистәсе, грек сәүдәгәрләре... Харәзем, Дагстан базаркәннәре бистәсе бар. Таныш булмаган җиде ят арасына ул ничек сыеныр? Монысы да акылга сыеп бетми кебек.

Озакламый көймәчеләр башлыгы да килеп җитәр. Шаулап торган сәүдәсен калдырып, качып киткәндәй ашыгычлык белән Казаннан тизрәк чыгып югалырга җыенган карт бөтенләй чарасыз калган иде. Ул Санькының барлы-юклы бер атна эчендә кулдан ычкынуын, иләс-миләскә әйләнүен, тамагыннан аш үтмәвен аңлый алмый. Шуның сәбәбен белмәү гаҗизләтә. «Сихерләделәрме соң әллә?! Тик аны сихер богаулары белән чолгаудан кемгә ни файда?! Ата белән ул арасына чөй кагып кем нәрсәгә ирешергә тели?.. Һәр явызлык кемнеңдер кара ниятеннән башлана. Кем кулы уй-

ный соң монда? Әллә бер-бер юлбасарлар, намусын шайтанга саткан, түбән хисләр колына әйләнгән җаһил бәндәләр котыртамы?»

Савелий Кузьмич җанын авырттырып, үтмәс пычак белән телгәләгән уйларына җавап таба алмады, кайсысын гына миеннән үткәрмәсен — берсенең дә тотыныр очы, Санькаының кинәт кенә танымаслык үзгәрүен акларлык, аңлатырлык нигезе юк кебек. Тыңлаучан, яшенә күрә шактый гыйлемле һәм дөнья күргән, төпле, азмаган-бозылмаган егетнең Казандагы кыланмышлары бернинди киртәгә дә сыймый иде.

Бер генә юл бар: котәргә! Ни булса да акылына килер, атасы янына кайтмый калмас. Ә ул кайтып керүгә, кулаягын бәйләп булса да, бу каһәрле Казаннан чыгып ычкынырга! Никадәр тизрәк булса, шулкадәр яхшырак...

Карт сәүдәгәр ачуыннан, чарасызлыгыннан, гарьлегеннән, улына рәнҗешеннән буылды, тешләрен шыгырдатты:

— И бала, ба-ла-а-а!.. Мин ялгыштыммы, синме?..

Йодрыклары таш диварны төйде.

Аның аяк буыннары хәлсезләнгән, куллары калтырый, ишек катындагы тәбәнәк урындыктан торып китәрлек көче юк иде. Ушкуйниклар белән очрашканда да каушамаган, үлем белән күзгә-күз килгәндә дә югалып калуны белмәгән карт сәүдәгәрнең йөрәге улының хыянәтен күтәрә алмады.

— Сәбәбен генә булса да әйтсен иде ичмасам! Ярдәм итә алмас идеммени! Бар малымны тамакларына тыгар идем, бәладән йолыр идем ич...

Кояшның күтәрелеп тәрәзәдән каравын, ярымкараңгы хөҗрәнең алтынсу нурларга күмелүен дә, кәрван-сарай ишегалдында атлар кешнәвен, дөяләр бакыруын, тәгәрмәчләр шыгырдавын, арбакәшләрнең* үзара кычкырышуын да Савелий Кузьмич сизми иде. Аңа бу дөньяның кызыгы, яме калмады, газаплы уйлары бөтен җиһанны кара болыт белән каплады, зиһенен чуалтты.

Иягенә таянып уйга чумган карт сискәнеп китте. Кинәт бүлмә яңадан караңгылыкка чумды, яктылыкны томалап, тәрәзәдә кемнеңдер тузгыган чәчле башы күренде. Киң җилкәле гәүдә тәрәзә яңакларына ышкыла-сыдырыла эчкә шуышты һәм тып итеп идәнгә сикереп төште. Тынсыз калган сәүдәгәр каршында җирдә яткырып аунаткандай тузанга

---

* *Арбакәш* — арбачы, йөкче.

баткан, киемнәре ертылган Санька басып тора иде. Аның тез башлары умырылып чыккан, чалбар ертыгыннан канлы җәрәхәтләре күренә, үзе еш-еш сулый.

Ата белән бала бер-берсенә карашып шактый озак сүзсез тордылар. Әйтерсең лә күзләре белән бер-берсен капшыйлар, ни булганын аңларга телиләр иде

Ниһаять, Савелий Кузьмич зиһенен җыйды, карлыккан, басынкы тавыш белән илереп сорады:

— Санька, синме бу?! Ни булды сиңа?..

Аның авыр сулавыннан, тавышына чыккан газабыннан Саньканың йөрәге куырылып килде, артык болай тора алмавын аңлап, әтисе каршына ташланды, җәрәхәтенең авыртуын да сизмичә тезләре белән шуышып килде. Кипкән авыз куышлыгында теле бәргәләнде, сүзләре өтек-төтек чыкты:

— Батя. Гафу ит мине... Мин... Казаннан китә алмыйм... Һич югы тагын... тагын ике көн...

Егетнең тавышы калтырый, күзләрендә яшь күренмәсә дә, бөтен җаны елаганы сизелә иде.

Савелий Кузьмичның иртәдән бирле күңелендә кайнаган шикләре утка май сипкәндәй дөрт итеп кабынды, төгәл бер фикер булып ялкынлана башлады: «Егет ялгыш юлга баскан. Җаһил адәмнәр кармагына капкан. Шуннан ычкына алмый. Йа хода! Үзең ярлыка!.. Газиземә ярдәм итү өчен җаным фида булсын!»

Шик-шөбһәсен тавышына чыгармаска, мөмкин кадәр ягымлы, дустанә булырга тырышып эндәште:

— И улым, улым! Атаң ярдәм итмәс идемени?! Нигә баштан ук барысын да сөйләмәдең? Миннән дә якын тагын кемең бар? Ник җанымны кыйныйсың, ник әйтмисең?..

Санька моң тулы, сагышлы һәм шул ук вакытта ниндидер аңлаешсыз үҗәтлек, тәвәккәллек чалымнары беленеп торган күзләрен атасына төбәп акрын гына сөйли башлады:

— Беләм, әти. Шуңа үтенеп сорыйм... Миңа Казанда калырга кирәк! Җанымда ни актарылганын белсәң, аңлар идең, төшенер идең... Мин бит юкка...

— Җитте сиңа,— дип бүлдерде тәкате беткән Савелий Кузьмич. Мин бит синнән ни булганын сорыйм. Әйт, кемнәр кулына төштең? Нинди юлда йөрисең син?..

Бүлмәдә тынлык урнашты. Йөрәкне изүче авыр тынлык.

— Әти... Мин бит гашыйк булдым...

Әйтерсең бөтен тәнен-җанын кысып, яндырып торган утлы кыршауны алып ташладылар, дәһшәте белән куркытып, рухын сытып бетергән шикләр өермәсе бөтерелеп очты, Савелий Кузьмич буылып-буылып көләргә тотынды, күзлә-

реннән атылып яшь чыкты. Әллә нинди шатлыклы да, шашкын да, сәер дә көлү иде ул. Атасының гайре табигый шашкынлыгы Санькага да күчте. Баштарак аның күз яше аша шаркылдавын сәерсенеп күзәткән егет үзе дә сыны белән бөгелеп төште, тыела алмыйча көләргә кереште.

— Кайгың шул гына идеме? — дип гөрелдәде Савелий Кузьмич көлүеннән тыела алмыйча.— Шуның өчен көннәртөннәр сугышып йөрергә кирәк идеме? Һай бизәгәннәр соң үзеңне!..

Улының мәхәббәт газабыннан көлүне килештермәсә дә, каяндыр күкрәк астыннан күтәрелгән дулкын аңа һич кенә тынычланырга ирек бирми иде. Ниһаять, ул үзен кулга алды, иплә кенә сораштырырга тотынды.

— Йә, кем инде ул бәхет кошы? Берәр сәүдәгәр кызымы?

Санька «Юк!» дигәнне белдереп баш чайкады.

— Һөнәрче, кәсепче кызымы?

Тагын баш чайкау.

— Әллә гаскәриләр нәселеннәнме?

— ...

Кинәт Савелий Кузьмичның йөзенә кара күләгә йөгерде.

— Алай-болай би, морза, карачы кызына гашыйк булмагансыңдыр ич. Аллам сакласын, үзеңә тиң түгел ярга күз төшерсәң... мәңге бәхеткә ирешмәссең! Аллам сакласын!..

Санька тагын җавапсыз калды.

Әтисенең иреннәре дерелди башлады, ул сораргамы-юкмы дигәндәй икеләнеп торгач, үзе уйлаган иң дәһшәтле, куркынычлы сорауны бирде:

— Соң, ходаем, әллә хан нәселеннән үкме? Башыңнан чыгарып ат! Казан ханнары туганлашса, тик асыл затлар — аксөякләр белән генә туганлаша.

Улының дәшмәвен ул ризалык билгесе дип аңлады булса кирәк, ике кулы белән башына ябышты, йөзенә борчулы, тәшвишле чалымнар чыкты.

— Их улым, улым! Үзеңә тиң түгел мәхәббәт сиңа кайгы-хәсрәттән башка берни дә алып килмәс. Соң түгел, оныт! Башыңнан чыгарып ат! Уйлама! Аллага гыйбадәттә йотыл. Башка чараң юк. Юкса... бетәсең!.. Хан исеме белән авыз чайкаган кеше якты дөньяда озак тормас.

Егет авыр сулап куйды һәм бар кичерешләрен бер авазга салып бетерергә теләгәндәй уфтанып җавап бирде:

— Мин аның кем кызы икәнен дә, кайда торганын да белмим. Бер нәрсәне генә төгәл беләм: ул фәрештәгә тиң

кеше. Аннан башка миңа якты тормыш юк. Ансыз тормыш миңа кирәкми...

— Кайда таныштыгыз? Ничек? Күрештегезме... Сөйләшмәдегезмени? Исемен дә белмисеңме?

Атасының бер-бер артлы ашыгып тезгән сорауларыннан югалып калган Санькага Гөлйөземне кайда, ничек күрүе, төнге очрашуы турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирүдән башка чара калмады.

Аның һәр сүзеннән үзенчә мәгънә чыгарырга тырышып, барысын-барысын күңеленнән үткәреп тыңлаган ата кеше түземсезләнеп бүлдерде:

— Аңлашып бетерә алмадыгызмыни соң?

— Юк! — диде Санька үкенүенә чыдый алмыйча.— Кичә төнлә аны минем кулымнан йолкып, урлап алып киттеләр...

— Кемнәр?.. Ничек?...

Күбрәк ишеткән, белгән саен Савелий Кузьмичның йөзе караңгыланганнан-караңгылана барды, Санька сөйләп бетергәч тә әле бик озак тавыш-тынсыз утырды, бармаклары нәрсәдер эзләп капшанды, сакал-мыекларын сыйпаштырып куйды. Күрәсең, ул ни әйтергә, моны нәрсәгә юрарга белми иде. Урыс кенәзлекләрен аркылыга-буйга гизгән, мөселман дәүләтләренең яшәү рәвешен һәм кануннарын ярыйсы гына белгән, һәркайсында озаклап сату иткән карт сәүдәгәр хәтерендә моңа охшаш вакыйгалар эзли, кайчандыр ишеткән хәлләрне исенә төшерергә тырыша иде.

— Урлаучылар ничек киенгән иде? Хәтерләп кала алмадыңмы? — диде ул ниһаять.— Сиңа, кызга бер-бер сүз әйттеләрме?

— Ю-у-ук! — дип баш чайкады Санька.— Киемнәрен аз гына төсмерләдем. Гаскәриләр булса кирәк. Тимер көбәдән икәнлекләрен абайлап калдым.

Савелий Кузьмичның йөзеннән сөенү шикелле яктылык узды, әмма бераздан куркынып Санькага текәлде.

— Бу юлы алла саклаган сине! — диде ул шомланып.— Бу кыз гади кыз түгел. Һөнәрче, сәүдәгәр, ирекле мәргәннәрнең-гаскәриләрнең балаларын болай сакламыйлар. Аңлыйсыңмы! Сине кыз каршында юк итәселәре генә килмәгән. Аны аяганнар. Юкса...— Аның тавышы торган саен куркынычрак, дәһшәтлерәк яңгырый башлады.— Алар сине танып, хәтерләп калган булырга тиеш. Алар гафу итми. Аң бул! Ялгызың чыгып китсәң, кайтып кермәвең дә бик ихтимал... Инде хәзер үк соң булуы мөмкин!

Санька әтисенең сүзләрен тыңлый, ишетә, әмма йөрәге

аларны кабул итми. Аның ул сөйләгән дәһшәткә ышанасы килми. Юк! Булмас! Гөлйөзем ханнар нәселеннән дә, карачылардан да түгел. Нәнкәләр кулында үскән нәзберек гөлләр андый кыю, батыр булмас. Колагында исә Гөлйөземнең ялварып, илереп, ярдәм сорап кычкырганы яңгырый:

— Ак канатым ми-не-е-ем!

Шушы тавыш искә төшүгә егетнең йөрәге читлеккә эләккән кош сыман бәргәләнә башлый, куллары йодрыкка төйнәлә, бөтен гәүдәсенә ниндидер үзе дә белмәгән көч-куәт тарала. Урлаучылар артыннан куып җитә алмавы, төн буе аһ орып, каңгырап йөрүе, Гөлйөземне тапмавы исенә төшүгә җаны парә-парә телгәләнә, үзен кая куярга белмичә ыңгыраша башлый. Ул бит аңа ярдәм итәргә, урлап качкан җаһилләр кулыннан коткарырга тиеш иде! Коткарырга тиеш!..

— Юк, эти! Мин аны тагын бер кат күрмичә китмим. Аның миннән башка ярдәмчесе юк! — дип тискәреләнеп үзенекен кабатлады ул.— Гөлйөзем карачылардан, би-морзалардан түгел. Йөрәгем сизә... Алардан булса да, мин аны күрергә тиеш.

— Белмим, белмим,— дип куйды Савелий Кузьмич.— Сине монда ни көтәдер... Ут белән шаярма.— Һәм кинәт кырысланып, усал итеп өстәде.— Сиңа — христиан кешегә — мөселманнар белән яр булу килешми. Анысын онытма! Ут белән су кушылмый.

Санька ачу белән сораганын сизми дә калды.

— Егет белән кыз арасында диннең ни катнашы бар? Алла яратмаска кушамы? Пәйгамбәрләреме?

— Аллага тел тидермә! — Савелий Кузьмич малаена кизәнгән җиреннән кинәт тукталып калды һәм, әле кайчан гына аның өчен җаны тетрәгәне исенә төшепме, тавышына ягымлылык чыгарырга ашыкты.— Җирдә кешеләрне алла түгел, аның вәкилләре — патшалар хөкем итә. Сафагәрәй хан — укымышлы, гадел хөкемдардыр дип беләм. Әмма ул да хан карачысы кызының христианга чыгуын яратмас. Алар безне кяфер дип йөри.

— Ә без аларны? Без аларны ничек атыйбыз?

Савелий Кузьмич диндар кеше түгел иде. Әмма улының маңгайга бәреп әйткәненә җавап бирми булдыра алмады. Аңа ничек тә ике яшь арасына салкынлык кертергә кирәк, Санька637 күңеленә иләслек саласы бар, ә моның өчен дин кануннары иң кулай нәрсә иде.

— Басурман дибез, неверныйлар дибез. Хагында да шулай ич,— диде ул.

Санька бераз уйланып утырды, әмма аның килешергә теләмәгәнлеге йөзенә чыккан, ул каршы төшәргәниндидер яңа дәлилләр, сүзләр эзли иде булса кирәк. Кинәт аның күзләре очкынланып китте.

— Кешеләрне кем яраткан? — дип ярып салды ул тиктомалдан.

— Кем булсын, алла,— дип җавап кайтарды Савелий Кузьмич.

— Барысын дамы?

— Барысын да.

— Үзе яраткан бәндәләрне алла яклый да, саклый да, ярлыкый да. Шулаймы?

— Әлбәттә, шулай,— диде сәүдәгәр тынычлана төшеп.— Аллаһы тәгаләнең рәхмәте бик киңдер. Кылган гөнаһларыңны, гаепләреңне танысаң, ярлыкар да, гафу да итәр.

— Димәк, мөселманнарны да алла яраткан. Ул аларны да яклый, саклый. Алар да хакның бәндәсе. Колларына бер-берсенә дошман булып яшәргә алла кушмый торгандыр. Димәк, без бертуганнар.

Улының сүзне сүзгә ялгап мондый нәтиҗә чыгаруын көтмәгән Савелий Кузьмич нәрсә әйтергә белми аптырады. Бер карасаң, аның сүзләрендә дөреслек бар кебек. Әмма мәхәббәт дип шашкан малайга юл куярга, сүздә җиңдереп, бала каршында абруеңны төшерергә ярамый. Ул тешләрен кысып, ачу белән каршы төште:

— Онытма, татарлар безнең дошманыбыз. Дошман туган була алмый.

— Бер алла бәндәләре дошман түгел. Бу — гөнаһ! — Санька ачыргаланып үзенекен расларга, хис иткәнен, уйлап тапканын белдереп калырга ашыга иде.— Дошман дисең, алайса нигә үзең дошман белән сәүдә итәсең? Димәк, син алардан башка яши алмыйсың. Һаман-һаман татарларга килеп егылганыңны белмиммени?! Ничә ачлыктан алар коткарды?.. Угличка да, Новгородка да батман-батман бодайны Казаннан ташыйсың бит... Әнә бу юлы да күпме төят тең. Ярдәмләшеп яшәгән мөселман белән христианның дошманлашуы гөнаһ! Моны алла кушмый. Мин беләм...

Карт сәүдәгәр улының дәлилләренә җавап таба алмады. Ул үзе дә кайчагында бу турыда уйлана, баш вата, әмма чиркәү әһелләренең буталчык аңлатмалары шулчаклы канына сеңгән ки, ул аларның берниндi очын таба алмый, бары тик шулай булырга тиеш дип инана, табына иде. Күз алдында гөнаһка баткан улын туктатыр өчен ул каты итеп кычкырып җибәрүдән башка чара тапмады.

— Җитте! Авызыңны үлчәп ач! Синең аркада җәһәннәм утында янасым килми.

Санька җавап биреп тормады, әмма атасына күзләрен тутырып карап, һәр сүзен кистереп әйтте:

— Батя, ә мин барыбер Казанда калам!

Савелий Кузьмичның башына күсәк белән ордылармыни, тагын тынсыз-өнсез калды. Улындагы кирелекне ул берничек тә аңлый алмый, әмма шунысын яхшы белә: моңа ничек тә чик куярга, мәхәббәт дип шашкан көчекне авызлыкларга кирәк иде.

Улы белән ризалашу төсмере чыгарып, ул килешкәндәй әйтеп куйды:

— Яхшы! Уйлашыйк. Карарбыз,— диде һәм сыкранып, күкрәгеӊ уа-уа ишеккә юнәлде.

Бераздан бернинди явызлык көтмәгән Санька янына өрлектәй өч көймәче килеп керде. Алар сүзсез-нисез генә егеткә якынлаштылар һәм эһ дигәнче аны бөтәрләп, кулаякларын бәйләп идәнгә ташладылар.

Күп тә үтмәде, кәрван-сарайдан Болакка таба җигүле ат чаптырып китеп барды. Берничә көймәче һәм Савелий Кузьмич утырган арбада торыпша белән капланган озынча капчыкны гына шәйләргә була иде.

Гәрәбәдәй Казан бодае, чынаяк савыт-саба, көбә, шам корычыннан* ясалган затлы корал, ефәк һәм батман-батман башка мал төягән зур көймә Болак суын ерып Казансуга юл алды. Ашыгычрак кузгалсалар да, сәүдәгәрләр канәгать иде. Алып килгән хәтле бар әйберләрен яхшы бәягә урнаштыра алдылар. Углич базарында дүрт күз белән көтелә торган яхшы тавар төяттеләр. Ярминкә уңды. Һәркемнең кәефе әйбәт иде. Бигрәк тә Иван-сәүдәгәр шат. Ул изүен җилбәгәй җибәргән, куе сары йон баскан күкрәген җилгә куеп, көймә борынында авыз эченнән генә нидер көйли-көйли алга текәлгән. Аның ашкынуын, ашыгуын кем дә аңламый. Хәер, ярминкәгә килүгә үк алтын белән генә эш иткән, булат кылыч, хәнҗәр, көбә, мылтык ише әйберләрне кул сугып кына тулаем алган бу малтабарны өнәп бетермиләр, аннан шикләнәләр, шул шикләнүләр, шөбһә сүзсез ихтирамга әйләнә кебек иде. Һәрхәлдә, үз эшен бетергән кешенең тизрәк кайтырга ашыгуы һәркемгә табигый тоела.

---

* *Шам корыч* — иң яхшы корыч. Димәшык корычы.

Савелий Кузьмич кына сүзсез. Аның җыерылган маңгаен, куе сакал-мыек арасында кысылган иреннәрен күпләр игътибарга алмады. Сәүдәгәрләр арасында башлык итеп танылган картның сүзгә артык һәвәс түгеллеген, үз дөньясына бикләнергә яратуын күпләр белә иде. Ыгы-зыгы, уңышлы сәүдә белән мәш килүче базаркәннәр шулай ук көймәдә бер кешенең җитмәвен дә сизми калдылар. Кузгалыр алдыннан гына йөк өстенә кертеп ташланган һәм торыпша белән капланган озынча капчыкка да беркем игътибар итмәде. Һәркемнең үз мәшәкате мәшәкать иде

Агым уңаена аккан көймә ишкәкчеләрнең бердәм талпынуыннан көч алып, кызулаганнан-кызулый, тизлеген арттыра бара. Төн җиткәнче Иделгә чыгарга, аның киң ярлары арасына сыенырга кирәк. Мал төягән көймәнең юлда, киңлектә булуы хәерле. Дөнья хәлен белеп булмый, мал тупланган җиргә юлбасар җыелмый калмас.

Берәүләрнең юл капчыгыннан пешкән тавык, йомырка, кыздырган балык, казанлылар гына ясый торган хуш исле казылык, яшел суган чыкты, икенчеләр озын муенлы шешәләрнең бөкесен ачты. Көймә төшемле эш башкарган хуш күңелле кешеләрнең бәйрәмен, шау-шуын Идел кочагына алып кереп китте.

Савелий Кузьмич бәйрәмгә кушылмады. Ул аяк-кулы бәйләнгән, авызы тастымал белән капланган Саньканы уйлый, аның өчен борчыла. Тыны бетмәсме, капчыкта уңайсыз түгелме?.. Һәр боерыгын сүзсез үтәячәк көймәчеләрнең улына артык зыян китермәскә тырышуларын белсә дә, җаны урынында түгел. Никадәр кире, үҗәт булмасын, барыбер үз каның, җаныңның бер кисәге ләбаса! Иншалла, акылына килер. Бу афәттән котылгач, үзе дә рәхмәт укыр әле, дип юана. Менә Казан биләмәләреннән чыгарбыз, ара ерагайган саен күңеле суыныр дип өметләнә. Анда инде егетне бәйдән ычкындырырга да мөмкин булыр Шашкын агымлы, мул сулы киң Идел уртасында беркая да бара алмас. Угличка кайтуга ук егеткә кыз ярәшергә, озак сузмыйча башлы-күзле итәргә кирәк. Әнә күршедәге Тимофейсәүдәгәрнең кызы пешкән җиләк кебек өлгереп килә. Аңа да ия тиз табылыр. Бер кашык су белән йотарлык шундый гүзәлне күрүгә егетеңнең дә күзе ачылыр. Казан вакыйгасы яшьлекнең бер җүләрлеге, дуамал кабынуы булып кына исендә калыр. Шулай гына була күрсен! Йа хода, ярдәмеңнән ташлама! Тизрәк, тизрәк Угличка! Туган йортка! Анда һәр агач, һәр таш, һәр чишмә ярдәм итәр, егеткә

айныткыч тәэсир ясар. Кода-кодагый булып, үз ишләрең белән аралашып, ярдәмләшеп яшәүгә ни җитә?!

Теше-тырнагы белән каршы торса да, өч әзмәвернең көченә буйсынырга мәҗбүр булган Санька, көймәчеләрнең усаллыгыннан бигрәк, атасының мәкеренә рәнҗеде. Ник аңламады ул мине?! Аңлата алмадыммы? Ләкин аңа сөйләшеп торырга ирек бирмәделәр, кулларын артка каерып бәйләделәр, аякларын сугымга әзерләнгән малныкыдай тышаууладылар, авызын каерып сөлге белән капладылар. Кайсысыдыр калын тавыш белән дәште:

— Арбада дулап тавыш чыгармасын тагы. Сыла берне!..

Калганын хәтерләми Санька. Ниндидер каты нәрсә башына килеп төште, күз алдында кызыллы-яшелле бөҗралар биешеп алды һәм... дөнья тынды.

Тәненең оюына чыдый алмый күзен ачканда бар дөнья караңгылыкка чумган иде. Аяк-кулларын кыймылдатып карады, әмма гәүдәсе аңа буйсынмады. Калын сүс аркан беләкләрне авырттырып кыра, аякларындагы тышау сыйрак итен кисеп кергән, бөтен тәне утлы энәләр кадалгандай яна иде. Ияген аска-өскә, уңга-сулга йөртеп тастымалдан котылу җаен карый башлады. Көймәчеләр артык нык тырышкан, калын киндер тукыма каты тарттырып бәйләнгән иде. Бит тиресе суелырдай хәлгә җитсә дә, ул акрын гына башын боргалавын белде. Менә тастымал бераз бушады, соңгы көчен җыеп кискен тартылуга муенга шуып төште, авызы иреккә чыкты. Беренче уе «Кабахәтләр, чишегез мине!» — дип кычкыру иде. Ләкин янында гына көлешкән, лыбыр-лыбыр сөйләшкән тавышларны ишетеп, телен тешләде. Туктале! Кайда соң мин? Кәрван-сарайдамы? Хәер, түгелдер. Әзмәверләрнең берсе «Арбада дуламасын!» дигән иде түгелме соң? Нинди арба? Мине кая алып баралар?..

Башыннан өермәләнеп узган сорауларга җавап табарга, кайдалыгын, нинди кешеләр арасында икәнлеген ачыкларга кирәк иде. Бәлки этисе әйткән куркыныч шушыдыр?.. Моның өчен шым гына тыңлап ятудан башка чара юк. Бәлки әле этисенең мәкеренә түгел, ә ул әйткән куркынычка юлыккандыр... Кем белә...

Санькаҗның зиһене, уе кыл кебек тартылды, тын да алмый тирә-яктагы тавышларны тыңларга кереште. Чү! Әнә кайдадыр аста су чупылдады, озак мыңгәреп ятудан

саңгыраулаган колакларына шыгырдау авазлары килеп керде.

Бәй, ишкәк тавышлары түгелме соң болар?! Әнә һәр ике яктан шыгырдап суга чумалар да, салмак талпынган канатлар кебек өскә күтәреләләр. Елга өстенә тамчылар коела.

Бишектә яткандай тирбәлүен абайлап алган Санька үзенең көймәдә икәнлеген, Идел уртасына җитеп дулкыннар өстендә чайкалуларын да аңлады. Димәк, аны, аяккулларын бәйләп, урлап алып китеп баралар. Аны бер якка, Гөлйөземне икенче якка! Гөлйөзем исенә төшүгә шытырдатып тешләрен кысты, йөрәге куырылып килде. Ул кайда хәзер? Аны нишләткәннәр? Нинди кабахәтләр кулына төште икән соң ул? Фәрештәмнең канатларын кем каерды?.. Ике күзеннән яшьләре агып төште. Ләкин ул аларны сөртә алмый, киндер капчык эчендәге яшь, чибәр, көчле егетнең иңсәләре генә калтырап-калтырап куя иде.

Күз яшьләре белән бергә чарасызлыктан интегү, рәнҗү, үпкә хисләре дә юылып төште бугай. Үз-үзен кулга алып, ихтыярын туплап ни эшләргә кирәклеген уйларга кереште. Иң элек, әлбәттә, аяк-кулларны чишәргә, бу капчыктан котылырга кирәк. Аннан соң күз күрер. Ләкин моны сиздерми эшләргә! Бер тапкыр үзен алдаган әтисенә дә ышанычы калмаган иде Саньканың. Ничек кенә булмасын, ул Казанга кайтырга, Гөлйөземне табарга, аны коткарырга тиеш!

Максаты ачык иде. Ул аңа көч бирде. Артык хәрәкәтләре белән игътибарны җәлеп итмәскә тырышып, аркасына каерылган кулларын кыймылдатырга кереште. Кайчан да булса барыбер чишелер бит инде алар. Әмма төен шулкадәр тыгыз итеп, чияләп бәйләнгән иде, күпме генә тырышмасын — бау бушамады. Аптыраудан, йөрәге әрнүдән бүтән чарасы калмаган Санька иреннәрен канаганчы тешләп, яткан урынында аунарга кереште. Чү! Кинәт аркасы ниндидер каты әйбергә килеп терәлде. Көчен җыеп шуңа омтылды һәм үзенең көймә кырыенда ятуын аңлап алды. Калын такталардан сумалалап, ныклап ясалган көймәнең кабыргалары эчке яктан берни белән дә капланмаган, алар тире эчендәге сөякләр сыман тырпаеп торалар иде. Саньканың куллары нәкъ әнә шул кабыргаларның берсе янында булып чыкты. Озак кармалана торгач, кабырга өстендәге ниндидер агач чөйне тапты һәм төенне шуңа эләктереп, салмак кына гәүдәсе белән алга тартылды. Ләкин капчык киндере комачаулый, киерелүгә үк төенне ычкындырып җибәрә иде. Ничә тапкыр бер үк хәрәкәтләрне кабатла-

гандыр, хәтерләми, ләкин инде булмый дип кул селтәргә җыенганда гына, бауның кинәт бушанып киткәнен сизеп алды. Озаклап бер җиргә ышкылудан капчык тишелгән һәм нечкә чөй кулдагы бау арасына, төенгә килеп кергән иде. Түземлеген, соңгы көчен җыеп тагын бер талпынуга, бау чишелде, егет арыган кулларын угалады, җиңел сулап куйды. Аякны чишү өчен инде берничә мизгел дә җитә!.. Озакка сузарга ярамый! Санька көймәдән ничек качып китәсен, Казанга ничек барып җитәргә икәнен дә белми, әмма Гөлйөземнең «Акканатым!» дип кычкырган авазы күңелендә кабатланган саен, үзенең нәрсәдер эшләргә, йөгерергә, көрәшергә, кирәк булса, тешләре-тырнаклары белән сугышырга, теләсә кем белән бугазга-бугаз килергә әзерлеген тоя. Тик моның өчен иң элек ирек, яңадан Казанга кайту гына кирәк.

Куллары бушау шул юлда беренче җиңү иде. Өметенә таба тәүге адымны ясаудан канатланган Санька аякларындагы бауга үрелде һәм якында гына кыштырдаган тавышлар ишетеп, тынсыз калды. Тирә-ягында кем бар икәнен белмәгән һәм тыпырчынуының кемнеңдер игътибарын җәлеп итү ихтималын аңлаудан бөтен тәне торараш булып катты. Иреккә чыгам дигәндә генә...

Аяк тавышлары якынайганнан-якынайды, авыр гәүдәле кемдер тук мышный-мышный килде дә туктап калды. Бераздан аның бодай капчыклары өстенә сузылып ятканы ишетелде.

— Әйдә, сузыл шушында,— диде ул артыннан ияргән икенче берәүгә.

Озакламый анысы да ятты булса кирәк, чакыру кабатланмады.

Саньканың түземе соң чиккә җиткән, кыл кебек тартылган бер халәттә ята иде. Җитмәсә, тамак төбе кыра, борынына тыгылган тузаннан төчкерәсе килә башлады. Ул ике куллап борынын кысты, корып, кытыршыланып калган тамак төбен төкерегә белән йомшартып, йөткерүдән сакланырга тырышты. Их, берярты гына чынаяк салкын су йотарга! Көймәгә бәрелеп чапылдаган дулкын тавышын ишетүгә күзләре ачытып куйды. Су янында сусыз ятудан да газаплы нәрсә бар микән!

Аның колаклары шылт иткән тавышны да әләктереп ала, шуннан үзенчә нәтиҗә ясый, кайда кем барлыгын гөманларга тырыша. Аның монда икәнлеген беләләрме болар, әллә очраклы килгән кешеләрме? Менә, ниһаять, күр-

шегә килеп яткан адәмнәрнең берсе гырлый ук башлады. Икенчесе ризасыз тавыш белән эндәште:

— Йокы симертергә өлгерерсең... Мондый табышлы сәүдәдән соң рәхәтләнеп бер типтермәгәч, нинди алыпсатар син?!

Аның әңгәмәдәшен мыскыллабрак, үзен зурга куеп сөйләшүеннән Санька аңлап алды. Иван-сәүдәгәр бит бу! Аны нишләптер яратып бетерми, сәбәбен үзе дә белми иде. Ләкин шунысын ачык тоя: Саньканың монда, торыпша астындагы капчык эчендә ятканын белсә, бөтен көймәгә шау-шу кубарачак, кешедән көләргә бер сәбәп табачак бу.

— Ә-ә... эй-е-е,— дип мыгырданды икенчесе йокы аралаш.

Шешәдән агач бөкенең шыгырдап чыгуы, калай чәркәләргә былкылдап сыекча акканы ишетелде. Эчемлек кабып куйдылар, тамак кырып ах-ух килештеләр. Саньканың авыз суларын китереп, казылык һәм яшел суган исе таралды.

— Син миңа тотын, югалмассың... Дөнья хәлен белеп, алдан күреп эш итүче бердәнбер купец мин,— дип мактанчык тавыш белән гөрелдәде Иван-сәүдәгәр.— Савелий Кузьмич ул иске кеше, эш йөртүе дә үзе кебек. Менә сора син аннан бүгенге көндә патша хәзрәтләренә нинди малның кайтуы кирәгрәк дип. Белми ул аны, белә дә алмый, белмәячәк тә... Шул Угличы белән, базар хәерчесе белән саташкан карт ул... Ә мин... Мәскәү белән эш итәм. Мәскәү... ул инде Мәскәү! Аннан акмаса да тама. Бүреләр сугышканда безнең кебек каргаларга ризык мулдан буласы... Шулай бит!..

Янындагы яшьрәк тавышлы кеше аны хупларга ашыкты, ярарга тырышып хихылдавына ялагайлану төсмере чыкты:

— Дөрес әйтәсең, Иван дәдәй! Картның көймәбашы булырына да күп калмаган инде. Комы коела...

Санька ачудан йодрыкларын төйнәде, бу тавыш иясенең авызына ямаудан нинди рәхәт татыячагын уйлап, тешләрен шыгырдатты. Шул мизгелдә борынына ургылып тузан керде, эчләре актарылып чыгардай булып, киерелеп төчкереп җибәрүен дә сизми калды. Бетте! Хәзер Иван-сәүдәгәр бу якка сикерәчәк.

Ул, гәүдәсен бөгәрләп, үзе янына килеп баскан кешегә тибеп җибәрергә әзерләнде. Ни булса да булыр! Башкача юл калмаган иде.

Эчемлектән җылынган Иван-сәүдәгәр көтмәгәндә шаркылдап көлеп җибәрде.

— Кичкә таба бераз җиләсләнде... Әнә, дөрес сүзгә

җавап юк. Ә син ашык-ма-а,— дип суздыул. Көймә башына нәкъ шундый кеше кирәк... Казан белән дус кеше. Сиздеңме, тамгачылар тамга акчасын Савелийдан ничек алдылар?

— Ю-у-ук!

— Шул-шул! Ә мин күрәм, беләм. Әшнәләр бит алар. Таварын юньләп тикшереп тә тормадылар. Берәүне дер селкетерләр иде. Ә моңа... Аның көймәсендә булгач, безгә дә караш шулайрак...

— Аңа түгелдер... Арыган чаклары иде,— дип каршы төшә башлаган сәүдәгәрне Иван тиз туктатты:

— Алдарсың Казан тамгачыларын!.. Җитте! Йә тагын төчкерә башларсың... Салыйк!

Тагын касәләр чәкелдәште. Иванның шапырынуыннан туя башлаган Санька түземсезләнеп аларның китүен көтә иде. Шул ук вакытта исерек сәүдәгәрнең тугарылып мактануы, акча, мал табу ысулларыннан уртаклашуы гыйбрәтле, егет барысын да хәтеренә сеңдерергә тырышты.

Чираттагы йотым Иванның телен тагын да чишә төште:

— Менә мин бу ярминкәдән дә, искечә әйтсәк, йөз бәлиш* мая туплап кайтып барам. Эчне тишми бит. Алтын бәлиш биш мыскал, көмеш бәлиш сигез дирһәм көмеш авырлыгы... Шуның чиреге тамгачылардан йомып калынган, өч чиреге патша хәзрәтләре казнасыннан...

— Ни-и-чек?

— Патша казнасы хисабына йөргән сәүдәгәр алтын тапмаса, башын салсын! Ха-ха-ха...

Җәелеп көлә башлаган Иван кинәт кенә туктап калды да күршесенә ысылдады:

— Әгәр бер-бер сүз чыгарсаң!.. Эчәгеңне актарып этләргә ташлармын. Аң бул! Идел төбендә синең ишеләр берәү генә түгел!..

— Аллам сакласын! Без синең белән бер җепкә бәйләнгән... Җаным фида... Белмим дә, ишеткәнем дә юк...

Иван канәгать тавыш белән кеткелдәп алды һәм тагын җәелеп сөйләргә кереште.

— Вот то-то!.. Дөньяның кая таба әйләнгәнен белсәң, патшага да ярарсың, аллага да... Үзеңне дә рәнҗетмәссең.— Ул тагын пышылдауга күчте.— Казан тәхетенә яңәдән Сафа Гәрәй утырды. Беләсең, ул Кырым-йорттагы Сәхип Гәрәйнең бертуган энесе. Гәрәйләр белән шаярырга ярамый. Алар ягында нинди көч торганын беләсең. Мәс-

---

* *Бәлиш* — акча берәмлеге.

кәүгә ярлык җибәргәннәр имеш. Патшаның Казан өстенә йөрмәвен таләп кылганнар. Басурман Сәхипнең сүзләрен җиткергәннәр. «Әгәр дә Казанга кул күтәрсәгез, без хәзер сезнең өстегезгә әүвәлге шикелле коры татар гаскәре белән генә бармабыз. Минем үземнең тупчыларымнан башка төрек солтанының йөз мең атлы гаскәре бар. Син уйлама ки, мин Мөхәммәт Гәрәй шикелле коры гаскәр белән генә барырмын дип, юк, хәзер минем көчем анықыннан күбрәк барачак. Казан җире минем йортым, Сафа Гәрәй хан минем борәдәрем». Шулай булгач, патша хәзрәтләренә бүгенге көндә ни кирәк? Табигый ки, корал кирәк. Мин төяткән йөкләрдә исә син атаң башы дип беләсеңме? Һа, юк! Корал ул. Иван ни эшләргә кирәген белә. Патшаның ни теләгәнен белә Иван... Әле тагын йөз алтын алмасаммы галиҗанәп кулыннан. Исемем Иван бул-л-мас-сын! Мин — аның йом-мыш-чыс-сы!.

Ул кикереп куйды, теле тотлыга башлады. Шешә төбендә эчемлек кими барган саен Иванның теле чишелә бара, мактанчыклыгы арта иде.

Хәрәкәтсез яткан Санькaның буыннары оеды, ул түземсезләнеп сәүдәгәрләрнең китүен, йә булмаса исереп йокыга талуларын көтә. Кайчан да булса бу исерек лыгырдауга чик куелырга тиеш бит инде! Ниһаять!.. Иван белән аның юлдашы тындылар, аларның бер-берсен уздырырга тырышкандай нечкәле-калынлы тавыш белән гырлаганнары гына ишетелә башлады. Җитте! Кузгалырга! Санька чалбар кесәсеннән пәкесен чыгарды һәм ялт иткәнче аяктагы тышауларын өзгәләп ташлады, саклык белән генә капчыкны кисәргә кереште.

Күк йөзендә йолдызлар калыккан. Тирә-як тып-тын. Караңгы. Шыплап мал төягән зур көймә җилкәннәрен төшереп Идел уртасында йокыга талган иде. Су төбенә ташланган тимер ыргакның арканы киерелеп тартылган, көймә янында бәргәләнүче дулкыннарның чайпалуы гына ишетелеп тора. Казаннан тизрәк китәргә һәм киң суга чыгарга ашыккан көймәчеләр дә, мал төятеп арыган сәүдәгәрләр дә тирән йокыда.

Әле моңарчы ни кыласын белмәгән Саньканың башында бер фикер оешып та өлгерде. Караңгылыкка ияләшкән күзләре яхшы күрә, кайда ни ятуын, кемнең кайда йоклавын да абайлап алды. Сакланып гына капчыктан чыкты, әтисен күреп күзләренә яшь тыгылса да, аның янына барырга кыймады. «Их, әти, әти, аңламадың. Бу эшкә мине үзең мәҗбүр итәсең,— дип уфтанып пышылдады.— Гаеп ит-

мә, ачуланма улыңны. Башкача булдыра алмыйм. Шулай кирәк, эти. Әле Казанга соңгы килүең түгел. Күрешербез, очрашырбыз. Кайчан да булса бер аңлашырбыз».

Күзләренә тыгылган яшьне сөртеп тә тормыйча, пычагын тотып Иван-сәүдәгәргә таба шуышты. Анысы исә капчыклар өстендә чалкан яткан, кулларын як-якка сузып җибәргән, ярымачык изүендә исә бүлтәеп күн янчык беленеп тора иде. Санька аз гына уйланып торды һәм янчык асылган бауны эзләп табып, үткен пычак белән аны сиздерми генә кисеп тә төшерде. Янчык авыр иде. Санька аны төйнәп муенына асты, тирә-юньгә тагын бер кат күз йөртеп чыкты һәм көймә кырыена шуышты. Башта капчыкны, аннары торыпшаны суга төшерде һәм этисеннән пышылдап гафу үтенгәч, үзе дә Идел кочагына кереп китте, тавыш чыгармаска тырышып, еракта күгелҗем-кара булып күренүче ярларга таба йөзеп китте.

Идел буенда туган, балачагыннан дулкыннарга колач салып үскән егеткә елга үзе ярдәм итә иде кебек. Ул тавыш-тын чыгармаска тырышып, акрын гына ишүен белде. Көймә шактый еракта калды. Менә инде су өстендә аның шәүләсе дә абайланмый. Баштарак бик якын тоелган каралҗым текә яр исә һаман үз урынында, әйтерсең Санька йөзми, бер урында тора. Казанның сул як ярда урнашканлыгын төгәл белгән егет, алга карап йөзде дә йөзде. Кайчан да булса барыбер ярга килеп чыгачак бит ул. Муенга эленгән авыр янчык аска тарта, итекләренә су тулды, алар төпкә сөйри башлады. Кулларындагы бау кырган җәрәхәтләре ачыта, җитмәсә, каяндыр килеп чыккан дулкын башыннан ук күмеп үтте. Егетнең авызына су тулды, тыны капланды. Япа-ялгыз төнге Идел өстендә калу шомландыра, аңлаешсыз курку хисе йөрәкне кыса. Арыган кулларны ял иттерим дип ишүдән туктауга ук гәүдә аска омтыла. Әйтерсең, анда, төптә, караңгы чоңгылларда утыручы җан ияләре Саньканы үз яннарына чакыралар, ихтыярын бәйләп, тылсым белән суырып алмакчы булалар. Егет тәмам арыды, гәүдәсе авырайганнан-авырайды. Башка чара юк иде, ул күкрәген тутырып сулу алды да дулкын астына чумды һәм юеш чолгаулардан тыгызланган итекләрен көч-хәл белән салып аткач, җиңеләеп тагын су өстенә калыкты. Күкрәгенә дымлы, сафландыргыч һава тулды. Соңгы көчен җыеп, яңадан йөзәргә керешге. Әмма көче кимегәннән-кими, акча янчыгы муенга бәйләнгән таш кебек аны аска сөйри иде. Юкса, әнә чыгып җитәргә дә күп калмады.

Куе агачлыклар белән капланган яр кул сузымында гына. Ләкин ул шулай тоела гынадыр. Җемдер аны үрти, ярны якын күрсәтеп алдый, ымсындырадыр.

Кылт итеп башыннан узган уйдан кул-аяклары хәрәкәтсез калды: «Хәрам мал мине төпкә сөйри. Шуның җәзасы бу! Кеше әйберенә кул суздым».

Кайдадыр бер якта су чапылдаганы ишетелде, тамчылар чәчрәгән кебек булды.

— Су иясе... Беттем! Аның белән очрашканчы хәрам акчадан котылырга кирәк!

Санька калтыранган хәлсез бармаклары белән муенындагы җепне өзәргә азаплана башлады, әмма суда тагын да тыгызланып калган калын җеп бирешми, ул агач кебек каткан иде. Аны бары пычак белән генә кисеп булачак. Кесәсенә тыгылды. Тар кесәдән пәкене чыгарырга азапланган арада тагын төпкә китте. Сөяк сап кулына эләккәндә инде ул шактый су йотып өлгергән иде. Атылып өскә чыкты, кабаланып, мәңге туймастай булып еш-еш сулады һәм пычакны кынынннан алырга тырыша башлады. Элекке вакытта чалкан ятуга бишектәге сабыйны тибрәткәндәй бәллүләтеп торган Идел аны күтәрергә теләми иде. Бөтерелчек чоңгылга туры килдеме — таш кебек төпкә китте. Агымнан котылырга теләп бәргәләнгән арада шома сапның кулыннан ычкынганын сизми дә калды. Чумган хәлдә бөтерелеп аккан су уңаена ыргылды һәм тагын өскә чыкты. Хәле беткән, ул соңгы чиккә җитеп тартыша, яшәү өчен теше-тырнагы белән көрәшергә омтыла иде. Әмма хәрам мал аны ычкындырырга теләми. Көчле агым белән берләшеп, алар Саньканың җанын даулыйлар, дәһшәтле тирәнлеккә суыралар иде. Егет янчыкка ике куллап ябышты, чияләнгән төенне тешләре белән чәйнәргә керешә. Шул мизгелдә су өермәсе аны бөтереп алып та китте. Күз аллары караңгыланды һәм... әллә нинди сәер балкышта соңгы тапкыр Гөлйөземне күрде. Кара чәчләрен иңсәләренә таратып салган кыз кочагын җәеп аңа каршы йөгерә, нәрсәдер әйтеп кычкыра, тик тавышы ишетелми иде. Саньканың йөрәген үкенеч уты чолгап алды, авызын ачып «Кәт мине, мин киләм» дип кычкырмакчы булды. Иреннәре аша саркылып су керде. Күз ачып йомган арада сурәт юкка чыкты, әллә кайдан гына әтисе, шелтәле карашы белән бәгырен телгәләп әнисе пәйда булды, сөекле абыйсы — бергә уйнап үскән иң кадерле дусты Васька йөгереп узды. Алар барысы да Саньканы каядыр чакыралар, кул изиләр иде. Агым ирегенә

бирелгән егетнең инде көрәшер ихтыяры, ташкынны җиңәр көче калмаган иде. Алтынлы янчыкны умырып тоткан килеш ул соңгы тапкыр талпынды да тынды. Дөнья дөм караңгы пәрдә белән капланды, яшелле-зәңгәрле утлы бөҗралар биеште дә... барысы да бетте.

КӨЙМӘДӘ

> Бер сәгать гадел кыйлмак яхшырак,
> Кем гыйбадәт алтмыш ел озаграк.
>
> *Мөхәммәдьяр.*
> *XVI йөз Казан шагыйре.*

Җәйге төн кыска. Арыган-талган тәнгә сихәт китерүче йокы ләззәте керфек очына кунарга да өлгерми, сызылып таң ата башлый. Әмма кичке ыгы-зыгы, качып киткәндәгедәй ашыгычлык белән дәррәү кузгалырга, юлга җыенырга мәҗбүр булган сәүдәгәрләр, көймәчеләр җәйрәп йоклый. Малтабарлык хиреслегеннән айный төшкән, алҗыган кешеләрне колак төбендә туптан атсаң да уятырлык түгел иде.

Идел өстен куе караңгылык пәрдәсе баскач кына башын мендәргә куйган Савелий Кузьмич бастырылып уянып китте.

— А-а-ха-а-а!..

Аның куркынган, карлыккан тавыш белән илереп кычкыруыннан көймәдәгеләр боргаланып куйды, кемнеңдер йокы аралаш дога укып мыгырданганы, кемнеңдер усал итеп сүгенгәне ишетелде.

Карт сәүдәгәрнең күкрәге, әйтерсең, биш батманлы капчык астында калгандай кысыла, сулыш ала алмый интегә иде. Гүяки, ниндидер албасты аның муеныннан буып алган да изә, сыта, аны көймә төбендәге такталарга сылап куярга тели иде. «Нәрсә соң бу? Нинди гөнаһ шомлыгы?.. Бер-бер чир зәхмәте ябыштымы?» Ул күкрәген уа-уа торып утырды һәм кичен газиз улы ягына күз дә салмавыннан имәнеп, бу авырту-сызлануның сәбәбенә төшенде. Бигрәкләр дә ачуын чыгарган иде шул Санька. Улы турындагы авыр уйлары, кичерешләре, бәйдән ычкынгандай кылануы төпчегенең хәленә керергә теләп тә, аны аңлый-төшенә алмавы, кара колдай аяк-кулын бәйләп салырга туры килүеннән туган бәргәләнү, чарасызлыктан гаҗизлектән туган җан газабы иде бу.

«Әйдә, каты кулның, атага буйсынуның ни икәнен бел-

сен! Талны яшь чагында бөгәләр. Хәзер бөкмәсәң, соңрак сындырырга туры килмәгәе»,— дип, үч итеп, аның янына юри бармаган, җәзасының катылыгын җанына үткәреп белгертергә, ачуының тирәнлеген сиздерергә теләгән иде. «О боже милостивый! Спаси и сохрани! Инде шәт төшенгәндер, сугымлык мал кебек бәйдә ятуның ачылыгын тойгандыр, суынгандыр. Җүләр булмаса аңлар! Дөнья кендегенең бер Казан кызына гына бәйләнмәгәнлеген дә төшенер, иншалла! Яшь чагында барыбыз да бер дуамалланып алабыз инде. Капчыктан чыгарырга кирәк. Озакламый кузгалырбыз, казанлылар мәмләкәте артта калыр». Авыр уйларыннан чайкала-чайкала ул бөгәрләнеп, бер-берсенә сыенып яткан көймәчеләргә басмаска тырышып, койрыкка, ашлык төялгән якка таба кузгалды.

Аның кузгалуын гына көтеп торгандай, көймәчеләр, сәүдәгәрләр кыймылдый башлады. Иртәнге салкынча һавадан бөрешеп калган малтабарлар җылыну өчен тиз-тиз хәрәкәтләнергә, үз-үзләренә суккаларга, авыз ачып киерелергә керештеләр.

Савелий Кузьмич уртадагы җилкән күчәренә менеп басты да кулын маңгаена куеп койрыкка текәлде. Көймә кырыена сузып салынган капчык юк, бодай көшеле өстендә ике кулын ике якка сузып җәйрәгән Иван-сәүдәгәр белән аңа сыенган яшь алыпсатар гына ята иде. Эче жу итеп китте. Әллә нинди куркыныч, шомлы сизенүдән теле аңкавына ябышып калды, күкрәгеннән ыңгырашуга охшаш сызлану авазы чыкты. Кибеп, корып калган авызында теле буйсынмый, әйтерен әйтә алмый изаланды. Ниһаять, күкрәгендә барлыкка килгән төер йотылды, дәһшәтле тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Сань-ка-а! Ул-ы-ым!

Үз-үзен белештермичә җан көче белән әйтелгән чакыру авазы Идел өстеннән ерак-еракларга, куе урман каплаган биек ярларга барып җитте, кайтаваз булып көймә өстендә бәргәләнде.

— Сань-ка-а-ау-у-у-лы-ым!

Иван-сәүдәгәр үзенә сыенган егетне читкә тибәреп торып утырды, сөякләре шатырдаганчы киерелеп иснәде һәм каты махмырдан айнып җитмәгән кешеләрчә алпан-тилпән көймә читенә килеп басты. Уйнаклап аккан талгын су өстенә күбекләндереп йөз санын язарга керешә, ярминкәнең төшемле үтүеннән кабат сөенеп, җанга-тәнгә рәхәт бирүче янчыгын сыйпарга куенына үрелде. Калтыранган кулы йонлач күкрәге буйлап аска шуышты, кесәләренә суккалады

һәм каударланып ике кулы белән дә үз-үзен капшарга тотынды. Бер мизгел эчендә махмыр зәхмәте онытылды, күзләрен кан басты һәм ул кыргыйларча үкереп, йоклап яткан иптәшенә сикерде.

— Анаңны... кабер такталарын актарып, җиде кат җир астыннан... Минем белән шаярыргамы?!.

Күз ачып йомганчы ул яшь сәүдәгәрне изүеннән һәм сыңар ботыннан умырып баш өстенә күтәрде.

— Әйт, кабахәт, янчык кайда? Алтын кайда? Бәрәм, суга тондырам...

Йокысыннан айнып җитмәгән егетнең күзләре шардай ачылды, куллары тотынып әйбер эзләп чапаланды, теле тотлыкты:

— Нин-нин-ди... ал-ал-тын?.. Нишлисең... Иван дәд-дәдәй...— дип мыгырданды ул.

— Эчәгеңне актарып балыкларга ташлыйм, эт җан! Әйт! Синнән башка беркем дә белми иде,— дип кабатлады Иван һәм корбанын болгый-болгый көймә читенә якынлашты.

— Әйт, әҗәлең килеп җитте. Юкса...

Яшь сәүдәгәр эшнең нидә икәнен аңлап алды булса кирәк, еламсырап такмакларга тотынды:

— Ипи чыраен күрмим... Мин түгел, Иван дәдәй! Мин түгел... Эзләп кара. Мин түгел... Алла шаһит...

Иванның ачуы басыла төштеме, ул егетне селтәнеп бодай көшеле өстенә бәрде, тешләре арасыннан ачулы зәһәр янау сүзләре сытылып чыкты:

— Кара аны... һәр бөрмәңне тикшерәм... Әгәр дә, эт җан, алдасаң... Чишен, кабахәт, кай җиреңә тыктың?..

Савелий Кузьмич килеп җиткәндә ул бөгәрләнеп яткан егетне ярсый-ярсый типкәләргә керешкән иде инде.

— Чү! Тукта! Тел белән аңлатып булмыймыни? — Карт сәүдәгәр үзенең кайгысын оныткандай, мөмкин кадәр сабырлык күрсәтеп эндәшергә тырышты, ике куллап Иванны кочаклап алды да читкә тартты.

— Тукта дим! Ни булды? Аңлатып сөйләш!..

— Анасын... алтынны урлаган. Ул гына белә иде,— дип ярсуын баса алмыйча гырылдады Иван.— Җибәр! Җанын чыгарам мин аның...

Савелий Кузьмич аны кулыннан ычкындырды һәм яшьләрчә җитезлек белән араларына сикерде.

— Акылыңа кил, Иван! Алган булса да көймәдән кача алмас. Бәлки, ул да түгелдер... Сабыр... Тикшерик. Аны үтереп кенә алтыннарың кире кайтырмы?..

Соңгы дәлиле тәэсир итте булса кирәк, Иван аларган күзләрен Савелий Кузьмичка текәп катып калды, йодрыгын йомарлап, ярсуына чыдый алмый тешләрен шыгырдатты.

— Тентибез... Барысын да рәттән тентибез. Энәсеннән җебенә үткәрәбез,— диде ул ачуына буылып.— Әгәр тапсаммы... Ул адәм ник туганына үкенсен!..

Көймә башлыгына казый вазифасын үз өстенә алырга туры килде.

— Йә, хәзер инде сабырлык белән генә уйлашыйк, - диде ул акрын гына. Салмаклыгы, басынкылыгы белән ул Иванның ачуын басарга, башкаларда ярсу уятмаска тырыша иде.— Нахак бәла тагудан да аяныч, үкенечле нәрсә юк. Үз өстеңә гөнаһ алма!

Шау-шуга, көймәне дер селкетеп сугышуга уянып өлгергән сәүдәгәрләр, көймәчеләр аларны уратып алган иде инде.

Аларның:

— Нәрсә булган?

— Кем урлаган? Кемнекен?

— Гомергә булмаган хәл,— дип үзара пышылдашканы ишетелде. Ярминкәдән соң була торган изрәткеч рәхәтлектән, бурычларын үтәгән кешеләрдәге канәгать тынычлыктан беркемнең дә чыгасы килми иде ахрысы.

— Һи, үзе төшереп калдыргандыр әле. Иванныкын алырсың, бар,— диде кемдер ризасыз тавыш белән.— Бәйләнергә сәбәп кенә эзләмиме?! Беләбез без...

Икенчесе аңа каршы төште:

— Ай-һай, Иван төшереп калдырамы? Кемнеңдер шакшы кулы уйнаган, иманым камил...

Артык сузарга, сәүдәгәрләрнең көймәчеләрдән, аларның исә малтабарлардан шикләнеп тавыш, җәнҗал кубаруына, бер-берсенә кул күтәрүгә юл куярга ярамый иде, Савелий Кузьмич үзенчә мондый очракта иң үтемле бердәнбер дөрес юлны сайлады.

— Йә, иң элек тикшерик. Бөтен кеше дә көймәдәме? — диде ул тирә-якта күтәрелә башлаган шау-шуны күмәрлек каты тавыш белән.— Саныйк! Әйдә, кереш, өлкән көймәче!

Утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге, куе кара сакаллы, әзмәвер гәүдәле ир авыз эченнән мыгырдый-мыгырдый, һәркемгә бармак төртеп санарга кереште:

— Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Әйләнә-тирәдәгеләрне санап бетергәч, ашыгып бодай көшеле өстенә, көймә кырыена күз төшереп алды, теле тотлыкты:

— Йоклап калганнар юкмы? Икәү җитми бит, Савелий Кузьмич,— диде ул. Аның йөзе агарып китте, маңгаена тир бәреп чыкты.

— Кемнәр юк?

Көймә башын уздырып, сәүдәгәрләрдән берәү мыскыллы тавыш белән сорап куйды:

— Ә үзеңне санадыңмы?!

Каушаудан үзен исәпкә кертергә оныткан көймәче ачу белән җиргә төкерде, күкрәгенә бармагын төртеп тагын кабатлады:

— Барыбер бер кеше җитми бит, Кузьмич!

Аның ялгышуын, үзенә төртеп «Бер кеше җитми» диюен көймәдәгеләр уенга борды, кычкырып көлеп җибәрделәр.

— Әйдә, тагын сана әле. Үзеңне бәлки бу юлы өч кешегә чыгарырсың...

— Ә нигә өч булмасын! Гәүдәсенә генә кара, синең белән мине кушсаң да бу хәтле ит чыкмас...

Көймәче ачу белән аларга карап кул селтәде.

— Үзегез санагыз, алайса.— Һәм Савелий Кузьмичка пышылдады.

— Санькaны чыгармаган идеңме? Капчык юк бит!..

Инде күптән кем юклыгын чамалаган сәүдәгәрнең тагын йөрәге авырта башлады, йөзе кәгазьдәй агарды, сулышы кысылды.

Егетне бәйләп алып кайтуда катнашкан һәм бу хакта кешегә ләм-мим сүз әйтмәскә кушылган көймәченең дә хәле шәптән түгел, ул үзен гаепле санап башын түбән игән һәм колларча буйсынучанлык белән карт сәүдәгәрнең әмерен, хөкемен көтә иде.

Аларның нәрсәдер пышылдашуын күреп алган Иван кинәт мәчедәй җитезлек белән Савелий Кузьмичка ыргылды.

— А-а-а! Әнчегеңне яшердеңме?! Әйт, кайда ул! Кайда?.. Ник дәшмисең? Ул урлап качкан. Ул... Алтын карагының атасы!..

Улын югалту газабына нахак яла ачысы кушылган карт сәүдәгәр түзә алмады, Иванның бугазыннан буып хырылдады:

— Җиттеме сиңа, юкмы?! Алтының белән буыл, тамагыңа тыгылсын! Тик телеңне генә тый!

Карттан мондый да җитезлек, беләгендә, батманлы гердәй йодрыгында мондый да көч-куәт яшеренгәнлеген көтмәгән Иванның башы бер якка салынып төште, бармаклары белән аның кулын кубарырга көчәнеп караса да, булдыра

алмагач, күгәрә башлаган иреннәре арасыннан ризалыгын чыгарды:

— Булды... җибәр... әйтмәм...

Кулын бушата төшсә дә әле һаман аны ычкындырмаган Савелий Кузьмич һәр сүзен кистереп, утыртма читәнгә сыер тизәге чәпәгәндәй өздереп-өздереп кабатлады:

— Алтының үзеңә кайтыр. Малайны тапсак та, тапмасак та! Тик дәшмә, җанымны кыйнама! Санькада дәхелең булмасын. Юкса!..

Гайрәте шактый ук шиңгән Иван-сәүдәгәр акланырга теләгәндәй сөйләнде:

— Миңа нәрсә... Кем алган, шул кайтарсын. Гаделлек өчен әйтүем... Сәүдәгәр бер-берсен алдый, талый башласа кемгә ярар. Мин риза, риза Савелий Кузьмич...

Картның тимер йозак булып каткан бармаклары акрын гына язылды. Иван муенын сыйпаштырып, башын боргалап алды һәм карт яныннан читкәрәк китеп, тагын үзенекен кычкырды:

— Белеп тор, Савелий Кузьмич! Алтыннарымны кайтармыйча барыбер тынмам... Белеп тор!..

Үртәлүе кыяфәтенә чыккан сәүдәгәр кул селтәде һәм ачы балан капкан кешедәй йөзен чытып. мәгънәсез әрне туктатырга ашыкты.

— Житте! Күпме иде алтының?! Әһле базар каршында әйтәм: барысы да үзеңә кайтыр... Тик борыныңа киртләп куй: Санька алмаган булса, гөнаһысы үзеңә... Җәһәннәм ялкынында куырылганда исеңә төшәр, еландай телләреңне чыгарып ялынырсың, соң булыр!

Иванның кашы астында яшел күзләре ялтырады.

— Төп-төгәл ике йөз бәлиш иде,— диде ул кистереп һәм әле һаман да сынын җыя алмыйча бодай өстендә бөгәрләнеп яткан яшь сәүдәгәргә ымлады.— Әнә, шаһитым бар. Ул белә иде. Әйт, шулай идеме?

Яшь сәүдәгәрнең канлы иреннәре көч-хәл белән кыймылдады:

— Шулай!.. Нәкъ ике йөз бәлиш иде...

— Әтә-тә-тә... Никадәр байлык,— дип тел чартлатты кемдер.— Ай-һай, шулкадәр мөлкәтне үзе белән йөртер микән?..

Гаепне Санька өстенә аударып хата эшләвен, малтабарлар арасында дәрәҗәсен, абруен какшатуын белсә дә, Савелий Кузьмич телен тешләде. Малаеның югалуы аның ихтыярын сындырган, рухын изгән; җаны бәргәләнә-кыйнала иде. «Ике йөз бәлиш коточкыч зур акча! Ул кадәр табыш

алу өчен билне шактый кысарга туры киләчәк! — Уйларының очына чыга алмады, кул селтәде. — Акчадамыни хикмәт! Баш исән булсын!.. Иң элек ничек тә Саньканы табарга кирәк. Аннан соң күз күрер!»

Дөресен әйткәндә, улының кеше малына кул сузарына ул ышанмый, аның туры сүзле, гадел, саф күңелле икәнлеген белә. Ташаяк ярминкәсендәге кирелеге, үҗәтлеге аңлашылмый, авырттырып җанын тырмый иде. Ә хәзер?!. Ахыры болай бетәчәген белсә, Казанда бер көн генә түгел, бер атна, бер айга калырга да ризалашыр иде. Их! Үткәнне кайтарып булмый шул!

...Көймә читенә кертеп ташланган капчыкта Санька ятканлыгын, аның төнлә капчыгы-ние белән юкка чыкканлыгын әле генә аңлап бетергән сәүдәгәрләр бер-берсен бүлдерә-бүлдерә гөман кылырга, бәхәсләшергә керештеләр. Аягы-кулы бәйле, шуның өстенә тыгыз тукымадан тегелгән киндер капчыктагы егетнең тавыш-тынсыз гаип булуы барысына да чишә алмаслык табышмак булып тоела, берсеннән-берсе гайре табигыйрәк фикерләрен әйтергә ашыгалар иде.

— Аягы-кулы бәйле кеше суга ничек төшсен?! Башыма сыймый. Аңлый алмыйм. Аллам сакласын, монда ниндидер явыз көчләрнең, елга иясенең кулы уйнамагае. — Картрак сәүдәгәрләрнең берсе чукынып, ашыга-ашыга дога сүзләрен мыгырдарга кереште. — Тизрәк кузгалырга кирәк! Каһәрле урын бу!..

— Ай-һай, капчыктагы егет ничек Иванның алтынына кул сузды икән?.. Ышанмыйм, — диде икенчесе башын чайкап. — Саньканың суга төшеп китүе хак булса да, алтынны алуы — нахак. Савелий Кузьмич үз өстенә күрәләтә ялган гаеп такты.

— Мин болайрак фикер йөртәм: яшь җан бит, хурлыгына түзә алмыйча бәргәләнгәндер, чыгарга итеп дулагандыр... Шулай бит!.. Дулаган гәүдә көймә читеннән суга ычкынмас дисеңме?

— Анысы шулайдыр да... Бәлки... Әмма Иванның алтыны кая киткән?! Менә монысы хикмәт, табышмак...

— Ышанасың икән, аның ач күзлеген кем белми. Саньканың юклыгын сизеп юри кыланмас дисеңме, — дип каршы пышылдады аңа яшьрәк сәүдәгәрләрдән берәү. — Алтын дигәндә, акча дигәндә газиз анасын сатып җибәрергә дә күп сорамас...

Телләре белән әйтмәсәләр дә, арада бер-береннән шикләнү, су ияләренең үченнән шомлану тойгысы уянып килә иде. Бу хәлнең озак дәвам итә алмаячагын белгән Савелий

Кузьмич кайгысын, газабын читкә куарга тырышты, көймә башы буларак дилбегәне ычкындырырга ярамый иде. «Һич югы, үле гәүдәсен булса да табарга кирәк. Угличка ни йөз белән кайтып күренермен?!» Аның күз алдына улының зифа буе, балаларча кабарынкылыгы да чыгып бетмәгән чиста чибәр йөзе килеп баса, очкынланып торган чаткылы зәңгәр күзләре пәйда була. Эчендәге ялкынны йотып, аһ оруын кешеләргә сиздермәскә тырыша. Аның яшьләрчә төз, таза бәдәне, әйтерсең, ун елга картайды, суырылып калды, маңгаендагы җыерчыклар тагын да тирәнәя төште. «Аһ, улым, улым! Нишләдең син? Нишләдең? Йа тәңрем, ни гөнаһларым өчен мондый җәза җибәрдең?» Тимер чапага тарттырылган көймә янында уйнаклап аккан суга карап ул яшьләрен сөртте һәм әмерен көткән көймәчеләргә борылды:

— Каекларны суга төшерегез! Гәүдәсен эзләп карыйк. Һич югы...

Улының үлеме белән ризалашырга теләмәгән ата кешенең тавышы киселде, күзенә тыгылган яшьләрен кул аркасы белән сөртеп, башлаганын әйтеп бетерерлек көч тапты:

— Тапмыйча кайтмыйбыз...

Көймәчеләр ашыгып каекларга ташланды. Карт сәүдәгәрнең сүзсез ыңгырашуын, әчтән сызуын күреп тору, яшь, чибәр егетнең хикмәтле югалуы аларны да газаплый, аны бәйләп ташлауда үзләрен дә гаепле тою исә бу әрнүне тагын да көчәйтә төшә иде. Нәрсә дә булса эшләргә кирәклеген аңлау аларга җиңеллек китерде булса кирәк, берничә мизгелдән көймәнең борынына һәм койрыгына каплап салынган җиңел каеклар шапылдап суга төште, аларга ишкәк, колга, озын ыргак тоткан таза ирләр сикерде. Елга агымы уңаена суны иңләп өч каек йөзеп китте.

Әле һаман тынычлана алмаган, ярсуын ничек басарга белмәгән Иван көймә койрыгында аларны озатып калды. Аның чыраена кара күләгә иңгән, иреннәре кысылган, яшькелт күзләре тирә-юньне ачу белән бораулый иде.

Кинәт миен кистереп узган көтелмәгән уйдан аның йөзе чалшаеп китте, кулларын болгап кычкырып җибәрде:

— Әй, туктагыз! Мине дә алыгыз! Бәлки ярдәмем тияр...

Каекларның берсе борылып көймәгә якынлашты, Иван ашыга-ашыга чукынып каек төбенә сикерде.

— Аллага тапшырдык! Минем күзләрем үткен! Бәлки табарбыз да әле. Нинди кайгы, нинди олы кайгы,— дип сөйләнде ул акланырга теләгәндәй.

Башында исә бөтенләй башка төрле уйлар чәбәләнә иде.

«Әгәр тапсак, алтыннарым Санькада булмаса... Яки анда булса?.. Ничек кенә борсаң да, ике чабата бер кием, икесе дә зыянга. Тапкан сурәттә йөз бәлиштән колак кагачаксың. Тапмау хәерлерәк... Тапмауның хакы — ике йөз бәлиш...»

Корылган хәйләсенең зирәклегеннән, фикеренең үткенлегеннән разый-канәгать булып ул кулларын угалады, иртәнге югалту ачысы онытылды, күңелендә өмет катыш сөенеч хисе бөреләнә башлады. Йөзенә кырыслык бирергә тырышып, кулын маңгаена куйды һәм игътибар белән тирәякны күзәтергә кереште. «Мәетне беренче булып күрергә, аның яныннан каекчыларны ничек тә читкәрәк юнәлтергә кирәк»,— дип уй корып куйды ул. Аннан соң тагын шөбһә басты. «Әгәр каекчылар күрсә?! Икесенә егермешәр бәлиштән телләренә йозак салып булырмы? Егерме бәлиш! Бу аңгыра сарыкларның төшенә дә кергән мал түгел! Шәт, ризалашырлар...»

Каеклар, бер-берсеннән яртышар чакрым ара калдырып, агым бәргән ярга таба юнәлде. Беренчесендә Савелий Кузьмичның кайгыдан сыгылган гәүдәсе шәйләнә.

— Йа алла! Газиз углымны, сөекле Александрымны, төпчегемне табарга ярдәм ит! Рәхмәтеңнән ташлама! Аны артык нык ратканга, сөйгәнгә бирдеңме миңа бу газапларны. Ник аның урынына мине алмадың? Яшисе дә яшисе, яшәүнең-тормышның асылын аңларга, кызыгын табарга да өлгермәгән үсмер чагы иде бит әле! Уллар-кызлар үстерәсе бар иде. Сөю-сөешү сәгадәтен дә татымаган көйгә нигә якты дөньялардан алып киттең аны? Инде мин нишлим? Канатым сынды, күз нурым бетте. Инде мин ничек яшим. Дәвамчым, варисым, тәнендә минем каным аккан газиз затны ник юк иттең, аллам?! Ни гөнаһларым өчен?

Савелий Кузьмичның иреннәре бертуктаусыз пышылдый да пышылдый, рәнҗүен, газабын күк ияләренә, бөек аллага, фәрештәләргә ирештерергә тели. Аңа ярдәм итәрлек затлар юк микәнни соң? Һич югы гәүдәсен кочаклап хушлашырга, сөекле улының газиз тәнен күз яшьләре белән юарга да насыйп итмәс микәнни?

Каеклардагы ирләрнең йөзләре кырыс, иреннәре кысылган, күзләре су өстендәге дулкыннарда. Агып килүче бер генә нәрсә дә аларның карашыннан читтә калмый. Әмма чал Иделнең кеше газапларында гаме юк, ул, ярларын тутырып, ерак-ераклардагы Хазар диңгезе белән кавышырга ашыккандай түбәнгә ургыла да ургыла. Кочагына алганны чоңгыллар кире чыгармый. Салмак тирбәлешеп, бер-берсен куышкан салкын дулкыннар астында нинди генә серләр,

нинди генә билгесез нәрсәләр юктыр! Болар кеше күзеннән яшерен, нәмәгълүм. «Их! Колач җитмәс кырпы* балыгы бул идең дә киң Идел төпкелләрен, караңгы чоңгылларын актарып чык идең. Салкын су төпләрендә мәңгегә ятып калырсың микәнни, газиз углым. Гафу ит мине, кичер, рәнҗеттем, хаксызга кул күтәрдем. Ичмасам, суккан җирләремнән үбеп, гаебемне йолар идем. Күз нурым минем, кадерлем, бәгырем! Бу дөньяларда синсез ничек торыйм?! Аңа булган шушы сөюемне күпсендеңме соң әллә, бөек аллам?!»

Башкалардан артта яр буйлатып килгән каекта аягүрә баручы Иван-сәүдәгәрнең йөрәге дерт итеп китте. Аның үткен күзләре Идел суын ярып кергән комташлы борын хасил иткән култыкның түрендә, тирә-ягын камыш баскан тымызык су өстендә соры бер нәрсә күреп алган иде. Агым уңаена төшүче каектан култыкны таллыклар каплаганын көтте дә ишкәкчеләргә эндәште:

— Егетләр, чак кына сабыр итегез әле. Теге култыкны карап килим. Кем белә...

Каек уртасында ишкәкләргә парлап утырган көймәчеләр борын артына уелып кергән култыкны күрми калганнар иде. Алар сүзсез риза булды. Каек ишкәкләрен салмак шапылдатып таллыкка якынлашты. Яр буена җитәр-җитмәс Иван суга сикерде һәм бил тиңентен төшеп тә китте. Аның карашы, үе култык эчендәге соргылт нәрсәдә иде, ул күн итек кунычыннан тулган пычрак ләмне сизмәгән дә кебек, лачтыр-лочтыр атлап куаклыкка кереп тә китте. Битенә бәрелгән ботакларны, кычыткан яндыруын ул тоймый, алай-болай ишкәкчеләр төшмәсен дип шикләнә һәм очып кына карап килә алмавына үртәлә иде.

Менә таллык артта калды. Илле адымнан да киң булмаган култык дигәне култык түгел, талгын гына агып ятучы җинсә, борынга санаганы — кечкенә утраучык икән лабаса. Иван эре адымнар белән сикереп атлый-атлый әле ерактан ук күзе төшкән соргылт нәрсәгә ыргылды. Килеп җитте дә күн итек очы белән тибеп карады, тирә-якка су чәчрәде, аягына эләгеп, суүсемнәргә уралып өлгергән киндер капчык килеп чыкты. Таныды Иван. Савелий Кузьмич ашлык төятә торган капчыкларның берсе иде бу. Әнә җөй кырында ак җеп белән салынган тамгасы да күренеп тора —

---

* *Кырпы* — белуга. Гаять дәрәҗәдә зур балык. Иделдә берничәшәр тонна авырлыктагыларының тотылуы мәгълүм.

«С.Қ». Иван иелеп аны җәеп карады һәм капчыкның нәкъ уртасыннан — бәйләгән җиреннән төбенәчә пычак белән урталай ярылганлыгын күреп алды. Ирен читенә мыскыллы елмаю чыкты: «Без уйлаганча ук мескен түгел бу Санька. Килештерә белгән...»

Капчыкны тиз генә бөтәрләп яңадан су төбенә ташлады һәм ярдан олы таш китереп, бастырып та куйды. «Табылуына караганда үле саналуы хәерлерәк»,— дип уйлап куйды ул һәм тиздән кулына керәчәк алтыннарны исенә төшереп, канәгать елмайды, ашыкмый гына каекка таба атлады.

— Йә нәрсә? — дип дүрт күз белән көтеп торган ишкәкчеләргә уфтанып кул селтәде.

— Ялгышканмын!.. Эт үләксәсе...

Каек тагын агым буйлап төшеп китте.

Кич якынлашты. Иртәдән бирле локма ризык капмаган әһле базар һәм көймәчеләр сүзсез. Берни таба алмаган каекчылар арып-талып әйләнеп кайтты. Артык эзләүнең мәгънәсез икәнлеген күпләр аңлаган, ләкин кинәт башына төшкән кайгыдан күз алдында картайган Савелий Кузьмичны аяп, нәрсә дә булса әйтергә кыймыйлар иде.

Ә карт сәүдәгәр тирә-якта ни барын, малтабарлар һәм көймәчеләрнең ризасызлыгын, әйтерсең, күрми, сизми. Аның үз уйлары. Кайгысы йөрәген кыса, үзе белән улын да алырга карар кылган сәгатькә ләгънәт укый, үзен тирги, ни-нәрсә кылырга белмичә җаны бәргәләнә. Чарасызлыктан кечерәеп, көчсезләнеп калган атаның әле өмет нуры сүнеп бетмәгән: йөрәгендә пыскый, алга чакыра, кире Казанга әйди.

Ул авыр сулап соңгы әмерне көткән көймәчеләргә, юлга берләшеп чыккан сәүдәгәрләргә күтәрелеп карады да, икеләнүен җиңеп, хисләрен чыгарды:

— Казанга кире кайтсак ничек булыр икән?! Күңелем сизенә, шунда булмагае... Батмаган ул... Юк! Ышанмыйм... Ышана алмыйм. Ул Казанда, йөрәгендә тәүгә мәхәббәт уты кабызган калада. Соңгы тапкыр талпынып карыйк. Улым, төпчегем бит!.. Ансыз ничек кайтыйм?!.

Сәүдәгәрләрнең йөзенә ризасызлык билгеләре чыкты. Сүзсез генә таптанып алдылар. Кемдер авыр сулап куйды, кемдер учына йөткерде. Барысы да башлап сүз әйтүчене көтәләр иде. Авыр тынлык урнашты.

Ниһаять, өлкәнрәк малтабарларның берсе тамак кырып куйды.

— Үлгән артыннан үлеп булмый, Савелий Кузьмич...

Нишлисең?.. Урыны җәннәттә булсын!.. Кайту ягына кузгалмыйкмы диюем. Вакыт сузып кына үлгәнне терелтеп булмас,— диде ул картның йөрәгенә җәрәхәт ясамаслык сүзләр эзләп, сабыр күренергә тырышып.

Шуны гына көтеп торгандай, башкалар шаулаша башлады:

— Шулай инде, Савелий Кузьмич, ни хәл итәсең. Безгә яшисе бит әле. Һәр көн күпме чыгым китерә, анысын беләсең...

— Углич базарына өлгерәсе бар. Базар таралгач кайтуның ни мәгънәсе?!

— Мине Мәскәүдә көтәләр. Вәгъдә — алтын. Сәүдәгәр вәгъдәсе ул! Пайтәхет белән эш иткәндә соңармавың хәерле...

Картның боларга каршы әйтерлек дәлиле юк, күңел төбендә пыскыган өмет утыннан гына ятлар йөрәгендә ялкын кабыза алмыйсың. Аларның исә һәр көне алтын, акча, мал! Мал дигәндә боларны җиңәрлек көч юктыр... Савелий Кузьмичның соңгы ышанычы сүнде, башын тотып, уфтанып аска иелде.

Кинәт аның күзләре очкынланды, элеккеге кискенлеге, тәвәккәллеге йөзенә чыкты, һәрберсенә туры карап әйтте:

— Чыгымыгызны үзем күтәрәм. Сүземнең ныклыгын беләсез. Кайтыйк Казанга, зинһарлап сорыйм. Кайтыйк сана!..

Сәүдәгәрләр янә сүзсез калды. Аларның һәркайсы эчтән генә үтәчәк көннәр исәбен саный, чыгымының тәгаен сумасын билгеләргә тырыша иде.

Көтмәгәндә Иван-сәүдәгәр телгә килде:

— Кысмырланмыйк, туганнар! Бәла агач башыннан йөрми. Хан каласыннан әйләнеп килгәннән генә бөлмәбез. Тәвәккәллик!.. Чыгымын да күтәргәч...

Берәү дә аннан мондый борылыш көтмәгән иде, ахрысы, сәерсенеп аңа текәлделәр.

— Ярый соң... Алай булгач, сузмыйк. Юл кешесенең юлда булуы яхшы,— дип беренче булып сүз башлаган сәүдәгәр бәхәскә йомгак ясады. Аңа каршы әйтүче табылмады.

Шуны гына көткәндәй, өлкән көймәче кычкырып әмер бирде:

— Җилкәннәрне күтәрергә-ә-ә! Юл — Казанга!

Кемдер көймә уртасындагы учакка ут элде, казан асты. Озакламый Идел киңлекләренә аш исләре таратып дәү көймә тулы тизлегенә алга омтылды.

Бодай өстенә җәелеп яткан Иванның исә үз уйлары.

Бердән, тәвәккәллеге, кирәк чакта ярдәм кулы сузуы белән ул Савелий Кузьмичның ышанычын казанса, икенчедән, аның яшерен максаты, Казанга кайтуның аңа гына аңлаешлы хикмәте дә бар иде.

Яшь егетнең мәхәббәт маҗараларыннан азмы-күпме хәбәрдар, күзәтүчән һәм итәк астыннан ут йөртергә остарган сәүдәгәр монда да үз файдасын онытмаган иде. «Мин әйтсәм дә, әйтмәсәм дә — барыбер Савелий Кузьмич күндергән булыр иде. Маңка малае өчен акчасын җәлләми. Бусы — бер.— Иван уйлана-уйлана бармакларын бөкли.— Икенчесе — Санька исән. Димәк ул Казанда. Аны Казанда иң беренче булып атасы түгел, мин очратырга тиеш. Күрергә дә әйтергә. «Сине эзлиләр, күзләренә чалынуга тышаулап яңадан Угличка озатачаклар. Бу юлы инде элеккечә саксызлык күрсәтмәсләр, җилкән колгасына богаулаячаклар. Атаңның ачуы кабарган чак». Боларны ишетүгә мәхәббәттән шашкан егетең шайтаннан җәяүләп качкандай юкка чыгачак, борынын да күрсәтмәячәк. Өченчесе — әгәр акчаны чыннан да ул алган булса, бугазлап кире кайтарамын, муенына буш янчык асып, мәетен кәрван-сарай ишегалдына кертеп атачакмын. О-хо-хо! Алтын ни генә эшләтми кешене. Йөз бәлиш янына тагын ике йөзне куш әле, Иванкаем! Шәпме?! Үзеңнеке дә кире кайта, яңасы да өстәлә. Алтын алтынны чакыра. Мондый сума белән Угличта сасып яту түгел, Мәскәүнең, бөек кенәз сараеның да ишеге киерелеп ачылыр. Түземлек, сабырлык, Иванкаем! Күзеңне киереп ач, колагыңны торгыз! Башкалардан күбрәк күр, күбрәк ишет! Бәхетең кул сузымында гына...»

Ул киерелеп иснәде һәм бер атуда ике, юк, өч куян алачагы, аларның да ниндиләре кулга төшәчәге күз алдына килүгә, йодрыгы белән бодай кешеләнә сугып алды, тәгам тулы табын янына утырырга әзерләнгән корсак колы кебек канәгатьлек хисенә чыдаша алмый кулларын угалады. «Алла кушып, барысы да мин дигәнчә булыр. Барысы да уйланылган, кире чигенер урын юк. Елгырлык, җитезлек бир, ходаем!»

* * *

Идел ярындагы тау башына укмашып утырган, Мәскәүгә буйсындырылып мөстәкыйльлеген югалткан элеккеге кенәзлек үзәгенә — инде елдан-ел сүнеп, бөлеп баручы Угличка Савелий Кузьмичка ияреп кара хәсрәт кайтты. Күтәрә, җиңә, үткәрә алмаслык кайгы, югалту ачысы...

Туган йортка якынлашкан саен хәсрәтле әрнү дә зурая, тирәнәя бара иде. «Прасковьяга ни дип әйтермен?! Сөекле улыбызның инде дөньяда юклыгын ничекләр аңлатырмын?!» Савелий Кузьмичның миен шул сорау бораулый. Ни эшләргә белми бәргәләнә. Бердән, башын тезләренә куеп елыйсы, йомшак кулларына маңгаен тигереп тынычланасы җефете янына ашыга, икенче яктан, мондый да олуг кайгы белән, ямьсез хәбәр белән кайтасы килми, аяныч күрешүне сузасы, арткарак чигерәсе килә иде. Әмма берни дә эшләр әмәл юк. Барыбер кайтасы, барыбер әйтәсе...

Савелий Кузьмич төяп кайткан малына да кул селтәде. Бушату, урнаштыру эшләрен көймәчеләргә йөкләп, көймәбашына амбар ачкычын тоттырды да салмак атлап текә ярдан күтәрелә башлады. Хезмәтчеләрен җибәртеп, ат чакыртырга да мөмкин иде, әлбәттә. Ләкин карт сәүдәгәрнең беркемне дә күрәсе килми, ялгыз калып барысын бәйнәбәйнә хәтереннән үткәрергә, сөекле Парашасын ничек тынычландырырга, нинди сүзләр табарга кирәклеген уйларга тели иде. Тик җылы сүзләр дә, югалтуны җиңеләйтер әмәл дә таба алмады. Ирексездән иреннәре кыймылдады, уфтанып:

— Их, Параша, Параша! Бала ата-анасыннан иртә үлмәсен икән ул! — дип куйды.

Унсигез еллап бер түшәкне уртак иткән Прасковья балаларына йомшак, ягымлы, кирәгенчә таләпчән һәм каты куллы, иренә игелекле һәм тугры хатын була белде. Тик.. аның аңлашылмый торган, ничә еллар уйланып та серен таба алмаган бер сәер ягы бар: ялгыз калды исә Прасковья күзен бер ноктага теки дә хәрәкәтсез кала... Тирә-ягында ни барын, ни кылынганын күрмәс, ишетмәс дәрәҗәгә җитә. Әйтерсең лә ул нәрсәнедер исенә төшерергә, кайчандыр үтә дә кадерле булган ниндидер хатирәләрне яңартырга тели. Савелий яшеренеп кенә күзәткәләп тә карады, хыянәттән, тугрылыксызлыктан шикләнгән күңел әллә нинди сурәтләр, фаразлар тудыра иде. Әмма Прасковья аларның берсенә дә сәбәп бирмәде. Тезләрен кочаклап утырыр да еракларга карап сүзсез калыр. Аннан соң ул акрын

гына чайкала башлый, иреннәре юка гына, кәгазь сыярлык кына булып ачыла да аннан ниндидер өн агыла башлый. Елау-сыктау да, җыр да түгел ул, ыңгырашуга охшаш бетмәс-төкәнмәс бер көй, бер моң. Тәүге тапкыр ишеткәндә Савелийның бала йоннары кабарды, бугазына төер тыгылды, тамагы кипте. Ул моның ни икәнен белми, әмма шушы көй, моң йөрәгеи кыса, тәнен эсселе-суыклы итә, тетрәндерә иде.

Прасковьяның нинди гаиләдән икәнен төгәл белми Савелий. Аның Углич якларында булмаганча чиста, гайре табигый ак тәне, биленә хәтле ишелеп төшкән алтынсу көлтәгә охшаш куе чәчләре, бу яклардагыча сусыл түгел, ә ниндидер җете куе зәңгәр күзләре әсир иткән иде яшь сәүдәгәрне. Йөзенең бу аклыгын башта үзенчә юрады Савелий: балачагын, үсмерлек чорын, яшьлеген калын таш диварлар арасында, Углич монастыреның тар тәрәзәле ярымкараңгы хөҗрәләрендә бикләнеп үткәргәнлегеннән күрде. Ирекка чыгуга, бу аклыкны көн яктысы юып алыр, битен җил, кояш ашар дип көтте. Алай булмады. Дөрес, Прасковья тагын да нәфисләнеп, матурланып китте, йөзенә исә чәчләренә тартым алтынсу төсмер генә иңде. Ул каралмый, тупасланмый торган затлардан иде, күрәсең...

Аңа өйләнүе дә әллә ничек сәер, көтмәгәнчә килеп чыккан иде. Күрәсең, барысын да язмыш үзенчә билгели, үзенчә оештыра торгандыр.

Мәрхүм атасы ихтыярына буйсынып өйләнгән беренче хатыны белән дә начар тормадылар анысы. Бер генә җитмәгән яклары, кешегә әйтмичә генә әрнетә торган уртак кайгылары булды: хатын балага узмый иде. Каударланып алыш-бирешкә, сәүдә эшенең четерекле дөньясына чумган Савелий башта моңа артык игътибар бирмәде. Булыр әле! Яшьбез, көчлебез, диде. Еллар узган саен шул үкенеч йөрәген ныграк кыса, кешедән кимлегеннән үртәлдерә башлады. Кәсептәшләренең аңа сиздермәскә тырышып көлүләре, «Кайсысы кысыр икән, хатынымы, үземе?» — дип сөйләнүләре исә ачык җәрәхәткә тоз сипкән кебек әрнеткеч тәэсир ясый иде. Әйе, көттереп, зарыктырып дөньяга килде Вася. Тик шатлыкка урап, сөенечкә төреп олы кайгы да алып килгән иде ул. Газапланып, интегеп бала табуга ай уздымы-юкмы, хатыны өзлегүдән мантый алмады, Васяны күкрәгенә кыскан хәлдә якты дөнья белән бәхилләште.

Әнә шул чакта Савелий Кузьмич өенә Прасковья аяк басты. Юк! Хатын булып түгел. Бала караучы, үксез Васяга нәнкә сыйфатында килде ул. Хәзер инде анык кына

хәтерләми дә, бер айлык бала тотып ялгыз калган атаның ул чактагы мазасы бар нәрсәне каплап киткән иде. Кәсептәшләреннән кем тәкъдим иткәндер, анысы да истә калмаган. Сәүдәгәр буларак бер генә нәрсәне хәтерли: «Арзан гына,— диделәр.— Менә дигән кол кызы. Нәсел-нәсәбе тәрбияле, асыл таифәдәндер»...

Дин сабагыннан ваз кичкән яшь монашка ул чакта Савелий өчен колачлап булгысыз авыр мәшәкатьтән коткаручы яшь бер фәрештәдәй тоелган иде. Чынлыгы да шулай. Кап-кара, башын-күзен каплап торган озын киемнәрен салып аткач, күз алдында чәчәк аткандай чибәрләнеп киткән басынкы холыклы, ягымлы Прасковья тора-бара сәүдәгәрнең бөтен дөньясын, җанын биләп алды. Аңа башка беркем дә кирәк түгел иде инде. Савелий Кузьмич хәзер дә аннан башка яшәүне күз алдына китерә алмый. Прасковья Васяга мәрхәмәтле ана, аңа тугрылыклы хатын, Санькага җан биргән кадерле бер зат иде. Үз баласы тугач, өлкән угылга кадер кимер дип шикләнгәне акланмады, Прасковья мәхәббәтен һәр ике балага тигез бүлә белде, теле һәм гамәле белән ни олысына, ни кечесенә аерымлау сиздермәде. Кеше мөгамәләсендә иң нечкә кимәлне дә тоемлау сәләтенә ия Савелий бары тик аның күзләрендә генә ниндидер бер нур балкуын сизеп яшәде. Ул нуры исә Санькага бакканда, аңа караганда гына кабынып ала иде. Гөнаһлы бәндә Савелий үзенә дә шундый нур кабынуын өмет итте. Әмма юкка! Соңыннан, газиз улыннан көнләшүен аңлап, тормышка ашмас хыялына кул селтәде. Тик, юк-юк та, шул нурны тансыклап, юксынып куя торган иде. Хәзер менә Прасковья янында аңлашырга, аңлатырга кирәк булачак. Йа хода, ярдәмеңнән ташлама!..

Җирдә ауный-ауный, Углич хатыннары шикелле чәчләрен йолкый-йолкый такмаклап елар дип көткән Савелий Кузьмич бер мәлгә хәтта аптырап калды. Прасковьяның күз карасы кинәт зурая башлады, бөтен зәңгәрлеген каплап, шомырт төсендәге зур төймәгә әйләнде, әмма авызыннан бер аваз чыкмады. Ул кулларын кушырып, лып итеп урындыкка утырды, бер ноктага текәлеп тораташтай катты да калды.

«Ник еламый? Кычкырсын, битәрләсен, сүксен, илереп бер аһ орсын иде ичмасам! — дип үрсәләнде Савелий Кузьмич.— Һич югы, идәнгә ятып аунасын иде...»

Ниһаять, көттереп, озак көттереп Прасковья телгә килде, хәлсез, әллә каян, баздан килгәндәй тоньк тавыш белән эндәште:

— Кайда? Газиз углым кайда?

— И-и-и анасы, әйттем бит инде... Үзем дә белмим бит ничек булганнарын. Идел дулкыннары серен чишми лаеа...— дип кабат уфтанды гаилә башлыгы, сүзләрен теш арасыннан чыгарып.— Үз җанымны да җәлләмәс идем дә...

Прасковья тагын телсез калды. Аның башына әллә нәрсә булды, ничәмә еллар искә төшерергә, күз алдына китерергә тырышкан сурәтләр оеша башлады. Әле ул аларның ни аңлатканын да, кемнең кем икәнен дә белми иде. Кинәт ике кулы белән дә башын тотып мендәргә ауды. Чигәне ике яктан кыскан авыртуга чыдый алмый, тешләрен кысып түзәргә, шул сызлауны куарга тырыша башлады. Күз алдына йөрәк парәсе — углы Санька килде, Иделнең салкын кочагыннан ычкынырга талпынып, ул: «Әни-и-ием!» —дип ялварып, ярдәм сорап кычкыра иде. Кинәт тагын күренешләр алышынды, Прасковьяның миен кисеп, яндырып икенче әрнеткеч тавыш яңгырап үтте:

– Әни-и-и-ем! Әне-кәч-чә-ә-ем!..

Ләкин бу тавыш Саньканыкы түгел. Тавышы да, сүзе дә аныкы түгел. Бөтенләй башка телдә, башка җирдә яңгыраган әрнүле ялвару иде бу. Тукта! Тукта! Ул илерү Прасковьяның үз эчендә, үз миендә бәргәләнә түгелме?! Нинди тел соң бу?! Нинди гаҗәеп якын аһәң, таныш та, таныш түгел дә тоелган сүзләр, бәгыреңне айкап чыккан газиз бер өн!

Идел өсте. Текә ярларны тутырып дулкынланган киң Идел кочагы. Җилкәннәрен киергән зур көймә... Көймә борынында кечкенә кызчыкны куенына сыендырган яшь бер хатын. Су өстеннән үсеп чыккан кыялар... Җилсез тарлавыкта шиңеп сүнгән җилкәннәр лыпырдавы... Каяндыр пәйда булган икенче бер көймә. Нindидер усал йөзләр. Сакал баскан, озын чәчле явыз адәмнәр... Пычак-хәнҗәрләр ялтыравы... Кан! Кан!.. Менә калын тырнаклы, йон баскан олы тупас кул аңа үрелә, әнисе кочагыннан йолкып ала. Нәни кызчык үз-үзен белештермичә ачыргаланып кычкыра.

— Әни-и-и-ем! Әне-кәч-чә-ә-ем!..

— Кызым! Кызымны бирегез! Кызымны!..

Тар кыялар арасыннан әзмәвер ирнең калын тавышы кайтаваз булып ишелеп төште:

— Ха-ха-ха! Кызың түгел, үзең кирәк безгә! Үзе-е-е-ең! Үзе-е-е-ең! Үзе-е-е-ең!..

Нәни кызчык кулларын сузып әнисенә омтыла, кычкыра, елый, ялвара. Кинәт аның гәүдәсе очып өскә күтәрелә, елга

юлбасарының бер селтәнүеннән ул котырып агучы күбекле дулкыннар арасына кереп югалачак. Шул мизгелдә икенче бер юлбасарның канлы кулы иптәшенең җилкәсеннән умырды, сары тешләре арасыннан зәһәрле ысылдау ишетелде:

— Кем баласы икәнен онытма! Көймәдәге бар мал бәһасына торырлык әнчек!.. Морза нәселе... Ха-ха-ха... Әҗерен кайтарасыбыз бар!

Тагын күренешләр алышынды. Елап арыган, үксүдән шешенеп беткән нәни кызчык өстенә кара киемле, тупас йөзле хатыннар иелешкән. Аңлаешсыз телдә нидер сөйләшәләр, баш чайкыйлар.

Авырту бер генә мизгелгә китеп торды. Һәм Прасковья инде ничә еллар үзен газаплаган сәер һәм газаплы соравына җавап тапты: ул — у л түгел икән ләбаса! Күкрәк астыннан бөрмәләнеп идәнгә хәтле сузылган киң, озын кызыл күлмәк эчендә Прасковья түгел, ә икенче бер кеше — кайчандыр Иделдә талап алынган нәни кызчык җаны, аның тәне. Теле дә аның башка икән ласа! Газиз углының Идел кочагында җан бирүе дөрес түгел. Түге-е-ел! Тү-ге-е-ел! Аның җаны әнисенең туган ягына ашкынган, шунда очкан!

— И-и газизем! — дип ыңгырашты Прасковья һәм илереп тагын ятакка ауды. Коточкыч авырту тимер кыршау булып ике чигәсен кысып алган иде.

Кинәт аңа өстендәге җете кызыл күлмәк ялкын булып тоела башлады. Идел өстендә ургылып ялкын уйный, аяусыз ут телләре җилкәннәрне ялмый, колгалар буйлап өскә, яшел әләмгә сикерә. Тизрәк, тизрәк бу уттан, ялкыннан котылырга кирәк! Ул сикереп торды, күлмәген йолкып ертырга, тарткаларга кереште. Әмма чыдамлы ефәк тыңлаусыз бармакларга бирешми иде.

— Ут! Ут! Янам!

Прасковья сикереп торды да ишегалдына йөгереп чыкты, кое янындагы улактан чиләкләп өстенә су коярга кереште. Ләкин ялкын кимемәде, ул киресенчә тагын да көчәя генә төште, тәненә сыланып, тагын да зәһәррәк яндыра, кыса, буа башлады.

Савелий Кузьмич хатынының хәлен аңламады. Аның чыгып йөгерүен үзенчә бәяләп юлына аркылы төшмәде. «Еласын, илерсен! Тынычлансын!» Аның күз карашы Василийда иде: «Бу дуамал тагын ни кыланыр?!»

Василийның исә йөрәге таштай каткан иде. Ул энесенең, җаныннан артык күргән, үзеннән ныграк яраткан Санькаының якты җир йөзендә юклыгына ышанмый. «Болай булуы

мөмкин түгел Бер елмаюы белән генә дә көн яктылыгын арттыручы, шат күңелле егет тормыштан болай китмәс!» Аның йөзенә кара йөгерде, күзләре пыялаланды, куллары йодрыкка төйнәлде.

Кинәт ул сикереп торып ишек яңагын төяргә кереште, ачу белән кысылган теш арасыннан мәгънәсез зәһәр сүзләр чыкты:

— Мин барыбер үч алачакмын. Аның үлеменә сәбәпчене җир астыннан эзләп табачакмын. Менә... күрерсез. Үч алачакмын. Үч! Үч! Үч! Казанга җитәрмен, табармын. Үч!

Аның гәүдәсе калтырана, гайрәт белән өзлексез имән борысны төйгән кулында кан күренде, бармаклары арасыннан тибеп чыкты, идәнгә тама башлады.

Кан!

Савелий Кузьмичның күз аллары караңгыланды, башы әйләнеп китте. «Тагын канмы?! Тагын үлемме?!»

— Җитте! Тукта! — дип җикерүен сизми дә калды.— Бүгеннән сиңа Казан юлы ябык! Мин исән чакта ике аягыңның берсен дә атламаячаксың. Аңладыңмы? Аңладыңмы, дим!..

Василий ничек тиз ярсып кабынса, шундый ук тизлек белән сүрелде дә. Күбрәк энесенә сыенып, аның фикере белән рәк яшәргә күнеккән, җитез һәм үзбаш уйлаучан Саньканың күләгәсенә әйләнә барган өлкән угыл атасына каршы сүз әйтергә базмады, йодрыгын тагын бер кат селтәде дә канлы кулы белән яшьләрен сөртә-сөртә ишеккә ташланды. Аның үзалдына киреләнеп әйткәне генә ишетелеп калды:

— Мин барыбер үч алачакмын!

Шушы ук мизгелдә карт сәүдәгәр үзенең дә моннан соң Казанга бара алмаячагын аңлап алды. Аяк тартса да, җан тартмас. Сәбәпсез ачуы, газизен аңлый алмавы, урынсыз кул күтәрүе, мәсхәрәләгәндәй бәйләп ташлатуы белән рәнҗеткән, һәлакәткә этәргән җирләрдә кабат-кабат газапланачагын, җанына тынгы таба алмаячагын, күңелендә мал кайгысы түгел, үкенеч һәм җан кайгысы булачагын да төшенгән иде ул.

ГӨЛЙӨЗЕМ

Аннан соң да гыйшкы һаман тәэсир кылды,
Гыйшкы аның көннән-көнгә артып торды,
Йокысыннан мәхрүм калды, йөзе сулды,—
Ашау-эчү кайгысын да белмәс имди.

Кол Гали. «Кыйссаи Йосыф».
XIII гасыр.

Арбага килеп төшүгә, янына сикереп, авызын көчле, кытыршы учы белән томаларга азапланучы егетнең күкрәгенә ике кулын терәп, Гөлйөзем җан ачуы белән кычкырып җибәрде:

— Җибәрегез, дим! Җибәр!.. Мин сезгә кол кызы түгел. Мин... Мин сезне... абыйга әйтәм!..

Сүзләрен әйтеп бетерүе булды, тавыш-тынсыз мышнашкан егетләрдән берсе кычкырып көлеп җибәрде, кулын бушата төште.

— Күптән шулай диләр аны, Гөлйөзем. Юкса, юлбасарлар тозагына эләккәндәй чапаланасың...

Таныш тавыштан, өстенә бозлы су сипкәндәй куырылып килде, тартылган кылдай киерелгән гәүдәсенең бердән хәле бетте, әрнү белән яшьләренә буылды:

— Сез... син... Ни хакыгыз бар? Мин аяклы мал түгел. Ни-и-ишлә-ә-дегез?.. Җибәрегез!

— Хурлыктан саклап калганга рәхмәт әйт,— дип ысылдады абыйсы Гөлйөземнең беләген кысып.— Күп кычкырсаң, төшеп ул егет аламаңны камчы белән ярырга да күп сорамам! Әнә арттан титаклый.

— Сез аны белмисез... Ник алама булсын. Нигә алай дисең?

Кыз рәнҗүеннән телсез калды, абыйсына каршы әйтер сүзләр таба алмыйча интекте.

– Акканатым,— дип үчекләүгә күчте абыйсы.— Кара канатың түгелме? Төн уртасында җиде ят белән кулгакул тотынып... Оятсыз... Әткәйгә ни йөз белән күренерсең?! Ул хакта уйладыңмы?

— Башкалар йөри бит әле...

— Син башкалар түгел. Син минем сеңел! Тагын килеп кенә карасын... Менә шушы кулларым белән изеп ташлаячакмын...

Гөлйөзем үзен үчекләүдән, җан ачысы белән ачыргаланып кычкырганын үртәүдән оялып яшьләренә тыгылды, учы белән битен каплап, утыргычка сеңде.

— Йә, җитте-җитте, Гөлкәй!.. Син акыллы кыз бит... Бо-

лай йөрергә ярамаганын беләсең. Бер ялгызыңа җыенда кем очрамас...— Абыйсы аны үгетләп юатырга, тынычландырырга кереште.— Ярәшелмәсә дә, күздә тотылган егетең бар. Болай килешми...

— Нинди егет,— дип ыңгырашты Гөлйөзем.— Ник минем өчен хәл итәсең?

Фәрит җиңелчә көлеп җавап бирде:

— Кызлар сиздерми инде ул... Аларныкы яшерен...

Моңа кадәр тавыш-тынсыз утырган Шәһит гаепле тавыш белән сүзгә кушыласы итте:

— Йә инде, Гөлйөзем. Баш ярылып күз чыкмаган, тынычлан. Юк икән, димәк, юк. Бигрәк тә әйбәт!

Абыйсының кырыслыгын, елау түгел, алдында җиргә ятып аунасаң да сүзеннән кире кайтмаячагын белгән Гөлйөзем язмышына буйсынырга мәҗбүр иде. Ләкин аның рухы сынмаган, күңеле буйсынмаган, йөрәге «Акканатым! Акканатым!» дип сулкылдый, СанькаНың барыбер аны табачагына ышана иде.

Кичке җыен, Александр атлы саф күңелле егет, фаҗигале өзелгән очрашуны, абыйсының мәкерле хәйләсен Гөлйөзем кат-кат исенә төшерә, чарасызлыгыннан иреннәрен тешли, бер күрергә зар булып Акканатны сагына иде.

Үзе дә аңламый кыз. Мондый сәер, татлы да, газаплы да, әрнүле һәм сагышлы да халәтне кичергәне, җанын кая куярга белмичә өзгәләнгәне юк иде әле аның.

Барысы да гади, гадәти иде. Ата-ана сүзеннән чыкмаган, өлкәннәргә күтәрелеп каршы сүз әйтә белмәгән кызның күңеле урман уртасында камыш баскан тымызык күлдәй тыныч иде. Бернинди җил-давыл аны айкамый, дулкынландырмый, тирә-яктагы йөзьяшәр имәннәр аның иминлеген, бөтенлеген саклый, чит-ят күзләрдән каплый иде кебек. Әллә каян килеп чыккан ак егет, әйтерсең, әнә шул күл өстендә өермә куптарды, җир асты чишмәләреннән дымга туенып яткан нәни генә көмеш күлнең астын-өскә китерде, мәңге тынычланмаслык итеп актарды да ташлады. Дулкыннары сикереп чыгарга җитешеп ярга ташлана, камышларның, талларның тамырын актара.

Башка ахирәтләре кебек үк үзен алда ни көткәнен дә анык белә иде Гөлйөзем. Кызлар гомере кыска — әти-әниләре, туган-тумачалары үз күргән берәр егеткә димләячәкләр, шартын китереп туен үткәрәчәкләр... Кыңгыраулы атлар, бизәкле паласлар... Кияү йортында телең балдай татлы булсын дип бал каптырырлар, холкына майдай йомшаклык те-

ләп майдан авыз иттерерләр, тыныч, бәхетле тормыш юрап мамык мендәргә бастырырлар... Кияү куенына керү — яшерен хыял, өмет, бәхет...

Сөйгән егетенә чыга алган кыздан да бәхетле кеше юктыр, ходаем. Элегрәк, нишләптер, бу турыда уйланмый иде Гөлйөзем. Гадәткә кергәнчә, йола кушканча, барысы да шәригатьчә булыр, ата-ана баласына яманлык теләмәс дип белә, шуңа ышанып яши иде. Хәләл җефетемә тугрылыклы яр булырмын, иптәш булырмын, тупырдатып балалар үстерермен дип хыяллана. Әмма күз алдында торганы, аһ, шуның яры булсамчы дип өметләнгәне юк иде.

Ак егетне күргәннән соң, көчле кулының кайнарлыгын, чаткылы зәңгәр күзләренең бәгыреңә үтеп керердәй тылсымын тойганнан соң, колакны назлаучы йомшак тавышын ишеткәннән соң — аның күңелендәге уйлары, хыяллары челпәрәмә килде. Күрәсең, буш хыяллар, нигезсез уйлар җиңел оныла. Үзенең шул егеттән башка яши алмаячагын да аңлады Гөлйөзем. Әйе, бәхете дә, бәхетсезлеге дә хәзер шул егет кулында.

Кайтыр ул, Гөлйөземне табар... Тапмый калмас! Аһ, ни үкенеч, сөйләшеп, серләшеп бетерә алмадылар! Эзләргә чыккан абыйсы белән Шәһит комачауламаса, таңга кадәр йөрерләр, аңлашырлар иде бит! Һич югы, кайчан киләсен генә дә белми калды...

Гөлйөземнең күзләренә яшь тыгыла. Санькаының арба артында тәгәрәп калуын, аның ләгънәт орып, нишләргә белмичә өзгәләнүен күз алдына китереп тагын яшенә буыла. Кемгә комачауладык соң без?! Абыйсына ачуы килә. Элек чибәр генә, акыллы гына тоелган Шәһитне күрә алмый, аңа нәфрәте арта. Ни хакы бар аның! Ни хакы бар иде?!

Читлеккә эләккән коштай бәргәләнде Гөлйөзем. Кулына ни тотса, шул төшеп китте, бүлмәсендә әрле-бирле йөренде дә йөренде. Башка бүлмәләрдән аерым итеп, йортның икенче катында кыек астына урнаштырылган, тар баскыч белән генә аш-су бүлмәсенә тоташтырылган хөҗрәсе кысан тоела башлады, аңа һава җитми кебек иде. Башка вакытта чигү чигеп, нинди дә булса кыйсса укып кызык таба, вакытның ничек үткәнен дә сизми кала торган кыз көнне үткәрә алмый изалана иде.

Тәрәзә каршына килеп басты да күзләрен офыкта каралҗымланып күренүче урманнарга текәп хәрәкәтсез калды.

Гөлйөземнәрнең өе тышкы шәһәрдә, кирмән коймаларыннан ерак түгел биек калкулыкта иде. Аның бүлмәсеннән

бер-берсенә сыенып утырган эреле-ваклы йортлар да, кала тышындагы бистәләр дә, урман-болыннар да уч төбендәгедәй күренә. Күршеләрендәге тимерче, чүлмәкче, бакырчы, тукучы ише урта кул җитенкелектә яшәүче һөнәрчеләрнең ихаталарында ни кылынганын, кемнең нинди аш пешергәненә хәтле күреп, белеп торырга мөмкин иде. Алар арасында исә Галиәкбар оста йорты тазалыгы, бөтенлеге белән дә, муллыгы һәм биеклеге белән дә аерылып торыр иде. Шулай булмый, атасы алтын-көмеш белән, асылташлар белән эш итүче. Ләкин боларның берсе дә яшь кызның күңеленә ямь, тормышына тәм бирми иде инде.

Әнә ерак болында яшь тайлар уйнаклый, зәңгәр күктән тургайлар җыры коела, шәһәр урамнарыннан кемнәрнеңдер яңгыратып көлгәне ишетелә... «Барысы да, җиһандагы бар җан ияләре дә бәхетле... һәммәсе дә тиңен, ярын тапкан. Мин генә ут йотып утырырга мәҗбүр»,— дип уйлап куйды ул һәм, баскыч шыгырдаганнан сискәнеп, тиз генә ятагына барып капланды. Яшьле күзләрен, калтырап-калтырап куючы иреннәрен беркемгә дә күрсәтәсе килми иде.

Авыр адымнар акрын гына ишеккә якынлашты. Менә басмалар шыгырдаудан туктады. Кемдер ишек янында тынып калды, авыр итеп сулады. Шул сулыш алуыннан аңлады: өлкән киңәшчесе, яраткан нәнәсе килгән. Ләкин барыбер урыныннан күтәрелмәде. Никадәр генә киң күңелле, мәрхәмәтле һәм сабыр булмасын, нәнә — нәнә инде, ул аның язмышын хәл итүгә берничек тә ярдәм итә алмый. Тагын бер кат күкрәгенә капланып елаудан гына ни файда?!

Шыгырдап ишек ачылды, кулыннан мәңге төшмәс дисбесен тотып, карт нәнә килеп керде, шөбһәле, тәшвишле тавыш белән дәште:

— Әллә йоклыйсыңмы, кызым?

Гөлйөзем җавап бирмәде.

Нәнә тамак кырып куйды һәм алай да җавап ала алмагач, Гөлйөземнең аркасыннан бәпләп, сөйләнә-сөйләнә үзенчә уятырга кереште:

— Тор инде, тор, йөрәк парәм. Кояш төшлектән авышып бара... Ә син һаман мендәрдән аерылмагансың. Бәхетеңне йоклап үткәрмә тагы...

— Нинди бәхет ул? И нәнәм...— дип сыкранды Гөлйөзем.— Беләсең ич инде...

Гөлйөземнең йөрәк серен уртаклашкан карт нәнә авыр сулап куйды:

— Кем белә, колыным!.. Баланың бәхете ата-ана кулында. Тыңлаучан булсаң, сүзләреннән чыкмасаң... саф ефәк-

тәй кызны рәнҗетмәсләр, юлына аркылы төшмәсләр, дип беләм. Ата-анага баладан да кадерле нәрсә юк. Алла боерса, күрешерсез дә, табышырсыз да әле... Егетеңне әйтәм, ул да атаң каршына ачык йөз, чиста күңел белән килә белер. Казан ярминкәсенә йөрердәй адәм төшеп калганнардан булмас...

Карт нәнәнең акрын гына, иплә п кенә әйткәннәреннән Гөлйөземгә әллә ничек җиңел булып китте, йөрәген кысып торган авырту акрынлап юкка чыга башлады кебек. Торып утырды да нәнәсенә ялварды:

— И нәнәм... сөйлә, тагын сөйлә... Синнән башка кемнән киңәш көтим? Күземне ач бу четерекле дөньяга!

— Ярый, ярый... Артыгын кыйналма, җәрәхәтеңә тоз сипмә. Фәрит абыеңны да аңларга тырыш, синең өчен дип, синең намусың өчен дип үрсәләнгәндер. Сөенеп торырга кирәк, «яклаучым, саклаучым бар», диеп...

Абыйсының исемен ишетүгә, Гөлйөзем тагын куырылып килде, йөзенә төксе кыяфәт чыкты.

Нәнә ялгышрак ычкындыруын аңлады булса кирәк, тиз генә сүзне икенчегә борды:

— Әйтергә онытып торам икән лә... Әтиеңнең йомышчысы килде. Кичекмәстән, хәзер үк сине чакырган.— Аның тавышында тәшвишле төсмерләр куерды, йөзенә борчылу галәмәте чыкты. Галиәкбар оста, гадәттә, хатын-кыз эшенә тыкшынмый. Аның үз дөньясы, ереле-ваклы, бетмәс-төкәнмәс үз мәшәкатьләре бар.

Балаларга, йортка, аш-суга кагылышлы һәрнәрсәне Гөлйөземнең әнисе хәл итә. Йортта шундый кагыйдә иде. Ә инде Галиәкбар останың йомышчы җибәртүе, Гөлйөземне остаханәгә атап чакыртуы гадәттән тыш хәл иде. Никадәр генә тыныч күренергә тырышмасын, нәнә үзенең борчылуын барыбер яшерә алмады.

Гөлйөземгә килсәк, ул әтисе янына остаханәгә йөрергә ярата иде. Галиәкбар оста көннең күп вакытын ихата түрендәге бер катлы зур таш йортта үткәрә. Монда тылсымлы, сихерле, үзенчәлекле икенче бер дөнья. Монда ут һәм су, таш һәм алтын патшалыгы. Әтисе исә әнә шул буйсынмас көчләрне җиңеп, игә китереп, асыл бизәкләр, асыл сурәтләр тудыручы гали бер зат булып тоела Гөлйөземгә.

Кечкенә чагында иртән торуга ук остаханәгә йөгерер иде. Кечкенә сандалда чүкеп күбәләк канатыдай юка көмеш яфракчыклар ясаучы, ереле-ваклы ниндидер таш кисәкләрен эретеп балдак-йөзекләр коючы әтисе бер тылсым иясе иде. Остаханәдәге абыйлар Гөлйөземгә бакырдан коеп нә-

ни балдаклар, беләзек, күкрәкчә кебек нәрсәләр ясап бирделәр. Шуларны тагып, һәр бармагына берәр балдак киеп, кул чабып, көйли-көйли тыпырдаган нәни кызчыкны өлкән алтынчылар да, өйрәнчек егетләр дә мыек астыннан елмаеп күзәтә, һәрберсе нинди дә булса бүләк бирергә генә торыр иде. Үсә төшкәч исә әтисе кырысланды. Көннәрнең берендә әйтте:

— Балам, син инде хәзер җиткән кыз булып киләсең. Һаман-һаман ут, корым арасында, егет-җилән, ир-ат тирәсендә йөрү килешмәс. Остаханәгә керүеңә асла рөхсәтем юк,— диде.

Сабыр холыклы ата аны өйрәнчеклеккә килгән чая егетләр күзеннәнерактарак тотуны хәерлерәк санаган иде.

Монысын, әлбәттә, Гөлйөзем белми һәм үз вакытында әле әтисенә үпкәләп, кинә саклап та йөргән иде. Һәм менә кинәт кенә атап чакыру, йомышчы җибәртеп дәшү. Бу юкка гына булмас! Гөлйөземнең йөрәге дерт итеп китте: Александр атлы чибәр егет килмәгәнме икән?! Таш ярып чыккан, елгалар, урманнар кичеп ярминкәгә килеп җиткән батыр егет атасы янына юлны тапса гаҗәпме?!

Гөлйөзем иңнәренә ефәк япмасын гына элде дә ике басманы бер итеп аска төште, пешекчеләрне гаҗәпкә калдырып ишегалдындагы ташлардан сикерә-сикерә остаханәгә элдертте. «Менә-менә хәзер нәрсәдер булырга тиеш. Мине күрмичә Александр барыбер Казаннан китмәс. Китәргә тиеш түгел. Йөрәгем шулай сизенә. Аның урынында булсам, мин дә китмәс идем!»

— Йа ходаем! Бәхетен-тәүфыйгын бир! Бигрәкләр дә чибәр, акыллы, сылу кыз ласа. Инде үзенә тиң егеткә насыйп итсен! Мәхәббәт белән кавышуларга ни җитә!..— Карт нәнә теләкләрен әйтеп дога кылды һәм үзенең кире кайтмас яшьлеген уйлый-уйлый яшьле күзләрен сөртеп, мендәргә чүгәләде.

Галиәкбар останың хыял-өметләре зурдан иде. Шәҗәрә очы Казан һәм Болгар мәмләкәтенең иң оста алтынчыларына барып тоташкан, аларның һөнәр серләрен саклап килгән зәргәрнең эше күзгә күренеп алга бара, һәр көн аңа бәрәкәт, мал китерә, байлыгын ишәйтә иде. Казан патшалыгының иң оста алтынчысы дигән исем күпне белергә, һәр гамәлеңнең алдын-артын уйлап эш итәргә, күпне бирергә мәҗбүр итә. Шуның белән бергә, әҗере дә шактый сизелерлек иде.

Тышкы шәһәрдәге йорт-ихатасы мулдан, остаханәсе киң

вә иркен булуга карамастан, ничек тә эчке шәһәрдән йорт алу исәбе бар иде Галиәкбарның. Ул беләː анда күчү Казанның иң күренекле затлары арасына керү, кайда да сүзең үтү дигәнне дә аңлата. Хәер, аларына хәзер дә зарланырлык түгел. Әмма тагын да яхшыракка, әйбәтрәккә омтылу кеше дигән затның табигатеннән килә торгандыр.

Эш шуңа таба бара иде дә инде.

Көннәрдән беркөнне остаханә ишеген сарай чапкыннары какты. Гади йомышчылардан гына да түгел. Олуг башын кече итеп Галиәкбар катына Җангали ханның ышанычлысы, казнабашының ярдәмчесе үзе килгән иде. Мәмләкәттә акча сугуга күзәтчелек итүче, алтын-көмеш, асылташ эше хәзинә сакчысының үзенә сәлам бирүен яхшыга, бик яхшыга юрады алтынчы оста. Иелеп сәламен алды, остаханә түрендәге йомшак күн мендәр түшәлгән урынга күрсәтте, горурлыгын югалтмыйча гына тәмле сүзләр тезде:

— Рәхим ит, и бөек хакимнәрнең бере! Без фәкыйрегезнең караңгы хөҗрәсенә нур алып кердең... Алла рәхмәтеннән ташламасын! Мәрхәмәтеңне һәм әмереңне көтәм...

Казнабашының ярдәмчесе ияреп кергән тән сакчыларына башы белән ишарә ясады, тегеләре ашыгып алгы якка чыгып китте. Бары тик шуннан соң гына ул өстәлләрдә таралып яткан алтын-көмеш беләзек, йөзек кеби нәрсәләрне, аерым үтенеч белән ясалып ятучы асыл касәләрне күздән кичерде һәм канәгать калды булса кирәк, тамак кырып куйды, йөзенә елмаюга охшаш чалым кунды.

Галиәкбар әле һаман аның ни йомыш, нинди әмер белән килүен аңлый алмый интегә иде. Салымнарын казнага вакытында озатып бара, сату-алуда кемгә дә булса хилафлык китергәне, нәфесенә юл куйганы юк. Тынлыкны бозу өчен тагын үзе эндәште:

— Галиҗәнаб казнабашы! Җаның ни тели? Хезмәтчеләргә әйтим, чәй китерсеннәрме, шербәтме?..

Вазифасын бер башка югары күтәреп атаганны казнабашы ярдәмчесе сизмәмешкә салышты һәм үзалдына елмаеп куйды: «Әйе, бу алтынчы беркатлы түгел. Мәмләкәтнең иң оста зәргәре* исемен күтәрүе генә җитмәгән, телгә оста, кирәген әйтер өчен кесәгә керә торганнардан имәстер». Галиәкбар абзый үзе дә сизмәстән аның иң яшерен хыялын чын итеп әйтеп ташлаган иде.

Казначы кулы белән кагып «Мәшәкатьләнмә!» дигәнне

---

* *Зәргәр* — алтын-көмеш белән эш итүче. Ювелир.

аңлатты да ишекле-түрле йөренә-йөренә акрын гына сөйли башлады:

— Сарай әһле сәбәпсез йөрмәс... Аңлагансыңдыр, беләсеңдер... Йомышымның җитдилеген искәртеп куймакчымын. Әмерне сарайга чакыртып та бирергә мөмкин иде. Үтә җаваплы, олы эш тапшырмакчыбыз. Аны әйткәнче бер шартым бар: синең ни эшләгәнеңне, сарайдан нинди йомыш алуыңны ни диван әһелләреннән, ни хезмәтчеләреңнән һичберкем белергә тиеш түгел. Авызың йозакта буласы... Син шуңа разыймы?

Галиәкбар абзый ике кулын күкрәгенә кушырып баш иде:

— Тыңлыйм һәм буйсынам, галиҗәнаб казнабашы! Сарай сүзе безгә канундыр... Әйткәнегездән чыкмам!

Казна йомышчысы бер мәлгә тынып калды, аның үткен күзләре алтынчының эчендә, күңелендәгесен белергә теләгәндәй Галиәкбарны бораулый иде.

Ниһаять, ул тагын телгә килде, тавышында тантаналы, кисәтүле аһәң чыңлый башлады:

— Бу — сарай йомышы гына түгел... Казан патшалыгының хөкемдары, олуг хан Җангали галиҗәнабларының шәхсән әмерен алып килдем мин сиңа, кем... Галиәкбар оста. Тыңла да күңелеңә сеңдер! Телдән кергән телдән чыкмасын! Килештекме?

— Килештек, галиҗәнаб!

— Алайсаң, тыңла! — Казнабашы ярдәмчесе өсте көмеш тәңкәләр белән бизәлгән, һәр төге уттай янып торган асыл кеш тиресеннән тегелгән кыйммәтле, затлы бүреген арткарак этеп куйды, хәлләсен ычкындырып җилләнеп алды. Алтын эретергә әзерләнгән Галиәкбарның остаханәсендә мич ягулы, эссе, бөркү иде. — Мөмкин кадәр тиз арада син, Галиәкбар оста, җиһандагы теләсә кайсы хөкемдарга һәдия кылсаң да йөз кызартмаслык алтын аяк, ягъни зур касә, маңгаена патшалык мөһере басылган затлар гына кулланырлык зәргәри савыт әзерләргә тиешсең. Аның кемгә тәгаенләнүен чамалыйсың булыр, Җангали хан Мәскәү хөкемдарларының ачуына түгел, рәхмәтенә мохтаҗ. Аң бул! Кылган эшең белән син аңа кулыңнан килгән ярдәмне күрсәткән булып чыгасың. Синең осталыгыңа таянып, олуг хан сиңа, Галиәкбар оста, мәрхәмәтен күрсәтә. Акласаң рәхмәтенә, игелегенә тиенерсең, булдыра алмасаң, нәфрәте-ачуы озак йөрмәс!..

— Алтынны казнадан китерерләрме? Ул кадәр малны табуым бик шикле, галиҗәнаб казнабашы... Фараз итүем-

чә, шактый мал, асылташ кирәк булачак.— Галиәкбар остаың тамагы карлыгып китте, тапшырылган эшнең яшеренлеге, дәрәҗәсе аны каушаткан, бер мәлгә ихтыярын йомшарткан иде.— Алтын җамаякка алтын мыскаллап түгел, батманлап китәсе...

Казначының йөзеннән ризасызлык галәмәте йөгереп узды, күзләре кысылды.

— Казна белән дә, сарай белән дә бернинди бәйләнешең юк. Булырга да тиеш түгел. Оныттыңмы, яшерен йомыш, яшерен эш! Сарай алтынчылары эшли алмас иде дип беләсеңме? — Аның тавышына мыскыллау төсмере чыкты.— Галиәкбар останың бер савытлык алтыны юкмы?

Алтынчы сүзсез калды. Тәхет иясе йөкләгән эш артык чыгымлы булырга охшый. Әмма ул үзен сүз белән, вәгъдә белән бәйләп өлгергән иде инде. Ризалыгын биргәндәй, янә тамак кырып кына куя алды.

— Борчылма, алтыны да, асылташлары да кире үзеңә кайтыр. Ханлык хәзинәсеннән тияреңне алырсың. Хезмәтеңә түләү дә мулдан буласы. Шартын беләсең, ул — телсезлек! Ярты гына кәлимә сүз чыгарсаң да җәзасы артыңнан куа килер... Аңладыңмы? — Казнабашы ярдәмчесенең сүзләрендә тимер чыңы яңгырый башлады.— Бүгеннән эшкә тотын! Никадәр тизрәк тотсаң, шулкадәр хәерлерәк... Әзер булгач, хәбәрен җиткерерсең. Тик белеп тор, сарайга барып йөрү юк!

Галиәкбарның иңсә җыеруын күреп, ул кесәсеннән бакыр тәңкә чыгарды. Күптән түгел генә акча сугу остаханәсеннән чыккан тәңкә шома, алтындай ялтырый иде. Оста аның акча түгеллеген, гадәттә сан язылысы ягында ниндидер тамга барлыгын гына шәйләп өлгерде.

— Әзер булгач, шушы тәңкәне тоттырып йомышчыңны җибәрерсең... Мин барын да аңлармын. Тәңкәне туп-туры миңа бирәсе, миңа кайтарасы. Мин барын да үзем аңлармын. Ләкин сүз белән, тел белән берни дә әйтәсе түгел. Язу турында инде әйтеп тә тормыйм.

Көтмәгәндә килеп кергән казнабашы ярдәмчесе алтынчы останы тәшвишле уйлар өермәсендә калдырып ашыгычлык белән чыгып та китте.

Бөтен осталыгын, зиһенен эшкә җикте Галиәкбар оста. Йокысы качты. Затлы, кыйммәтле савытның рәвешен күз алдына китерү өчен генә дә атна-ун көн вакыт узды. Күңелен иң үртәгәне, үрсәләндергәне ашыгычлык булды. Җитмәсә ул моңа кадәр мәгълүм бер генә зиннәтне дә кабатламаска, аларга охшамаска тиеш иде бит. Ата-бабалары-

ның моңарчы сер итеп саклаган алымнарын, кайчандыр алар ясаган кыйммәтле әйберләрне хәтереннән үткәрде һәм, ниһаять, тапты. Ике ягына дугаланып, сыртларын кабартып ябышкан аждаһа рәвешендәге тоткалы, өскә таба киңәеп килгән зур авызлы чүлмәк төслерәк бер савыт иде ул. Як-ягындагы бизәкләренә асылташлар беркетте, нигезенә вак асылташлар сибеп чыкты. Чүлмәк гаҗәеп дәрәҗәдә матур, сокландыргыч иде. Бүлмәсенә бикләнеп ул аны кат-кат карады, ут яктысында әйләндергәләп бизәкләренең урнашуын кат-кат тикшерде. Өйрәнчекләренә, кәсептәшләренә, хатынына күрсәтеп, аларның хуплау, соклану сүзләрен ишетәсе килсә дә, тыелып калырга мәҗбүр булды. Галиәкбар останың үз гомерендә ясаган иң гүзәл, иң затлы, иң кадерле һәм кыйммәтле нәрсәсе кеше-кара күзенә чалынмыйча гына кайсыдыр хөкемдарның хәзинәсендә урын алырга тиеш иде.

Соңгы тапкыр тикшерде дә сандыгына бикләде. Җангали ханның йомышын тиешенчә, сөйләшенгәнчә, килешенгәнчә үтәү генә аны шөбһәле уйларыннан, бөлүдән коткарып калачак. Монысын ул үтә дә яхшы аңлый иде.

Ләкин... алай булып чыкмады шул!

Галиәкбар оста әле һаман аңына килеп җитә алмый. Бер көн эчендә бөлде дә калды. Хезмәтчеләргә түләргә акчасы, эшен дәвам итәргә алтын-көмеше юк! Барысы да бетте, барысы да пыран-заран килде. Өстендә фәрештәләр канат кагынган, муллыгы, җитенкелеге ташып торган өйдән бәрәкәт китте, хәерчелекнең аяусыз кара күләгәсе кунды. Барысына да шул алтын савыт сәбәпче. «Аһ! Никләр генә ризалык бирдем, никләр генә ярлык сорамадым?!» — дип уфтанды Галиәкбар оста. Әмма инде киткәнне, югалганны берничек тә кайтарып булмый иде. Дәһшәте, кодрәте Кырымнан Мәскәүгәчә таралган олуг хан белән дәгъвалашып кара!

Барысы да көтмәгәнчә сәер һәм бик тиз килеп чыкты. Барысы да куркынычлы, саташулы төштәге сыман.

Казнабашы ярдәмчесенең ышанычлылары зур алтын касәне алып киткәндә әйттеләр:

— Иртәгә ястү намазыннан соң йомышчың казнабашы ярдәмчесенең ишеген шакысын. Теләгәнен алыр, — диделәр.

Үзенә нинди олы йомыш йөкләнгәнлеген белмәгән өйрәнчек егет исә ике кулын селтәп кайтып керде. Керде дә куркынган кешедәй як-ягына каранып, пышылдап сөйләргә кереште. Аның күзләре зур булып ачылган, үзе еш-еш сулый, бер урында басып тора алмыйча таптана иде.

— И алтынчы-остазым! Шәһәр имеш-мимеш белән тулы. Чат саен гаскәриләр. Җангали хан галиҗәнаблары шәһит киткән имеш. Тәхеткә яңадан гайрәтле Сафагәрәй хан кайткан, ди...

— Болары соңыннан, болары соңыннан,— дип бүлдерде Галиәкбар.— Әйт, казнабашы ярдәмчесен күрдеңме?

— Юк! Капкалары бикле иде. Күпме шакысам да ачмадылар. Анда да гаскәриләр... Озак йөрергә шикләндем...

Галиәкбарның тез астына китереп суктылармыни, бердән хәле китте, йөрәген тотып урындыкка чүкте. Әллә нинди куркыныч сизенүдән күз аллары караңгыланды.

Йомышчы егет җыеп кайткан хәбәр исә дөрескә чыкты. Җангалинең кайдалыгын сөрәнчеләр кычкырып йөрмәде. Аның белән бергә ышанычлысы, казнабашы ярдәмчесе дә гаип булган иде. Үз хисабыңа Җангалигә асылташлар белән бизәп алтын касә ясаганыңны инде хәзер берничек тә раслап булмаячак. Шаһитләр да, раслаучы язу-ярлык та юк. Барысы да сер иде, яшерен иде. Хәер, булса да, аларны тотып казый янына, каты куллы булса да гаделлеге белән даны чыккан Сафагәрәй хан катына килү олы мәгънәсезлек дип бәяләнер иде. Алай гына булса әле...

Галиәкбар оста башын ике кулы белән учлап тирән уйга чумды. Остаханәдәге бүлмәсендә бикләнеп көн утырды, төн утырды, әмма котылыр, байлыгын кайтарыр чара тапмады. Бер генә юл бар — ул да булса, баш иеп рибачыларга* ялыну... Рибачыга бурычка баткан кеше тиз генә котыла алмас. Тик башка чара калмаган, бүтән юл юк иде.

Көннәр уза торды, Галиәкбар оста рибачыларга барасы көнне һаман-һаман чигереп килде. Ләкин кайчан да булса барыбер аларга баш иярга кирәклеген, мәҗбүр булачагын ул инде күптән аңлаган иде.

Углы Фәритнең хәбәре исә Галиәкбар останың күзләрен ачты, котылгысыз караңгылыктан чыгу юлын күрсәтте. Аның тотылмаган ефәктәй хәзинәсе бар ич әле! Мал-мөлкәтле, шан-шәүкәтле нәсел белән туганлашу гына аны хәзер бу афәттән коткара алачак. Гөлйөзем! Гөлйөзем! Бар өмет синдә. Син генә нәселебезне бөлгенлектән, хурлыктан тартып чыгара аласың. И тәңрем, мәрхәмәтеңнән ташлама!

---

* *Рибачы* — арттырып түләү шарты белән акча, мал биреп торучы. Ростовщик.

Алгы якта ишекнең шартлап ябылганы, өйрәнчек егетләрнең бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләшкәне ишетелде:

— Һи, Гөлйөземнең нурлы йөзен күрер көннәр дә бар икән... Бик сирәкләдең әле... Сагындырып кына йөри беләсең дә инде.

Телләренә салынган шәкертләренең сөйләнүен тыңлыйтыңлый, ата кеше кызын каршыларга әзерләнде. Исәбе — уйлаганын сиздерми генә кылын тартып карау, күңелендә тоткан бер-бер егет бармы-юкмы икәнлеген тикшерү иде. Хәерле сәгатьтә!

— Йә, кызым! Сөйләп җибәр, хәлләрең ничек? Эш тә эш... Күптән утырып сөйләшкәнебез дә юк икән,— дип бик ерактан башлады ул. Кулына көмеш җептән пәрәвезләп үргән беләзекне алды, кысага утыртылган ташның ныклыгын тикшергән шикелле тоткалап карады да, кызгылт-шәмәхә нурдан күзе чагылгандай, керфекләрен кысып, кызына төбәлде.— Йә, көтәм...

— Ни хәлләр дип...— Әтисенең юкка гына, тиктомалдан гына чакырмаганын сиземләгән Гөлйөзем кирәкле сүзләр таба алмый интекте.— Ни турында сөйлим соң, эти?! И беләсеңме, әле мин бер калфак чиктем, остазым-ханым да, башка кызлар да аһ итте. Күчереп алдылар. Нигә ул бизәкне бездән яшердең, диләр. Аның ничек килеп чыкканын мин үзем дә сизми калдым бит... Шундый да матур булды... Күрсәтермен әле, яме, әтием.

Кызының сызылып киткән кашларына, шомырт кара күзләренә, иңнәренә төшкән калын толымнарына яратып, сокланып карап торды Галиәкбар оста.

Улы сөйләгәннәргә әллә ни исе китмәгән иде аның. Җыенда кыз-кыркын, егет-җиләннең очрашуы, уен-көлке, җыр-бию дигәндәй, бер бездән генә калмаган. Бөтен яме шунда ич. Уйнар чаклары, дип фикер йөрткән иде. Әмма кызның пешкән җиләктәй өлгергәнлеген, чибәрлеген яңача күргәч, бәяләгәч, күңеленә хафа керде. «Фәрит дөрес уйлый. Аллам сакласын, мондый чибәргә күз салучылар, нәфес сузучылар аз булмас. Әхләмделиллаһи шөкер, нәселдә яман ат чыгаручылар булмады анысы. Шулай да кисәтеп кую зыян итмәс...» Әмма аның уйлаганы, көткәне бөтенләй башка нәрсә иде: «Кем белән булган? Безгә тиң нәселме? Бөлгенлектән коткара алырлык даирәдәнме?» Әгәр андыйлардан булмаса, кызга иреге белән, җыеннар, уеннар белән хушлашырга туры киләчәк. Иплэп кенә сорашуында булды.

— Ярар, ярар, кызым... Җыен ничек үтте?

Гөлйөземнең битенә куе кызыллык йөгерде. Әтисенең

юктан гына сорашмавын күптән сизенгән кызның йөрәге дерт итеп куйды. Ничек итеп атаң хәтле атаңа сөйләмәк кирәк! Әни сораса бер хәл иде...

Әтисенең тавышында кырыслык, катылык чалымнары пәйда булды:

— Кемнәр белән чыктыгыз, кайда йөрдегез, дим. Нигә дәшмисең? Нәселебезгә тап төшермәячәгеңне беләм анысы, әмма да ләкин, кара аны... Сүзем бер булыр...

— Әти, мин бала түгел ич инде. Үземнең нишләгәнемне беләм ләбаса...

— Шуңа күрә сорыйм да. Бала булсаң, сорап та тормас идем. Йә, көтәм...

— Мин... мин...— Кызның теле тотлыга башлады, ни әйтергә белмичә, толымын бармагына уорарга кереште. Сораганын сөйләтмичә туктамаячагын, каты куллы булса да, гаделлеген, үзен яратканын һәм кичерәчәген белсә дә, йөрәк серен ата белән уртаклашу җаваплылыгыннан шикләнә, икеләнә иде. Гөлйөзем кинәт үзендә көч тойды, каушавы, икеләнүе бетте. Санька белән очрашуы, җыенда йөрүләре, абыйсының урлап качуы хакында сөйләде дә ташлады.

Галиәкбар абзый тәрәзәгә карап шактый озак уйланып утырды, беләзекне бер алды, бер куйды, тик торганда өстәлдәге кораллрны җыештыра башлады. Башындагы уйлары чуалды: «Дөрес, урыс белән туганлашкан кешеләр дә бар анысы. Әнә, сәүдә бистәсендәгеләр татар кызлары өчен җан атып тора. Араларында Мәскәү, Новгород, дала белән эш йөртүчеләре дә байтак. Мал-мөлкәтле адәмнәр... Бу кем? Бер талпынуда баерга, алдау-йолдау белән мал җыярга килгән хөсетле бәндәләрдән түгелме?» Ул яхшы белә: урыслар Казан кызларына никадәр генә кызыкмасын, горурлыгын җуймаган хөр казанлылар урыс кавеменә әйләнеп капланырга тормый. Мал өчен генә, бер көнлек иминлек өчен генә ата-баба йоласыннан баш тартыргамы?! Әгәренки ыштансыз бер урыс баласы булып чыкса?!

Галиәкбар останың көмеш карасы йоккан бармаклары өстәл тактасында биеште, нәрсәнедер сорарга җөрьәт итмәгәндәй, икеләнеп әйтте:

— Ул егетне кайсы яктан дисең инде?

— Угличтан ул, әти... Ярминкәгә бодай төятергә килгәннәр... Көймә белән...

— Аны... яратасыңмы димме?

Гөлйөземнең бите алсуланды, җәядәй киерелгән озын керфекләре тибрәнеп күзен каплады.

— Әйе, әти...

— Бер-бер хезмәтчеме, сәүдәгәр баласымы соң?

— Ул кадәресен мин белмим инде аның... Әтисен сәүдәгәр дип әйтте шикелле. Без бит ул турыда юньләп сөйләшмәдек тә.

— Әтисенең исемен дә белмисеңме? Алар бит үз исемнәренә атасы исемен дә кушып сөйләшергә ярата.

— Юк инде, юк, әти...

Галиәкбар абзый хәтереннән Углич сәүдәгәрләрен барларга, таныш-белешләрен үткәрергә кереште. Алтын-көмеш белән эш итүчеләрне исенә төшерергә тырышты. Әмма зәргәр буларак үзе ярминкәләргә артык еш чыгып йөрмәгәнгәме, бодай төятүчеләрдән кемне дә белми икән. Авыр сулап куйды. Ата-баба һөнәренә тугрылык саклаган Галиәкбар абзый бары тик алтын-көмеш белән эш итүчеләрне генә чын сәүдәгәр, чын мал иясе дип белә иде. «Күрәсең, бу егеткә юлны бикләргә туры килер. Гөлйөзем мәсьәләсендә дә ялгышырга ярамый. Соңгы өмет, соңгы ышаныч. Гөлйөзем бары тик саф алтынга ия малтабар нәселенә генә яр булачак. Үзенең киләчәге дә, безнең бүгенгебез дә аның кулында. Йа алла, мәрхәмәтеңнән ташлама!» Күңеленнән шундый карар чыгарса да, Галиәкбар абзый әле һаман икеләнә иде. Бер яктан, кызын рәнҗетәсе килми, әгәр бай нәселдән булса, урыс кавеме белән туганлашырга да күп сорап тормас иде. Икенче яктан, ата-баба йоласы бар, билгесезлек бар. Урыс бабасы дигән яманат күтәрүе дә рәхәт булмас. Хәер, анысына төкерер дә иде. Хөкемдарлар әнә илне, мәмләкәтне ныгыту өчен кем белән генә туганлашмыйлар да, кемне генә кәләшлеккә алмыйлар. Кичәге дошманнары түр башында утырыр. Барысына да үзенә төшенергә, белешергә кирәк иде. Ә хәзергә хөкем бер булыр. Кызына туп-туры карап әйтте:

— Кяфер белән очрашуыңа риза-бәхил түгелмен. Моннан ары минем рөхсәттән башка калага чыгу юк! Балачагың үтте...

Кызының агарып калган йөзе, бармакларының ефәк япманы урап, бөтереп тотуы, мөлдерәмә күзләре күп нәрсә сөйли иде. Әмма ата кеше хөкемен үзгәртмәде. «Ярминкәгә килерләр дә китәрләр. Бусы да озак тормас. Югалыр да онытылыр. Яшь кыз күңелендәге вәсвәсә дә озакка бармас. Су өстендә көймә эзе тиз җуела. Иншалла, бу да шулай булыр...»

Мендәр юпь-юеш. Гөлйөзем тыела алмый. Яшьләре ирексездән агалар да агалар. «Кяфер — бик начар, имансыз,

хөсетле бер бәндәдер. Ак канатлы, эчкерсез, очкынланып торган зәңгәр күзле чиста егет ничек кяфер булсын!»

Онытылып, кайгысына буылып күпме яткандыр, кинәт башына килгән уйдан сикереп торды, күзләрен сөртте. Ишегалдына чыгып җиз комгандагы чишмә суы белән битен чылатты. Хәрәкәтләре җитезләнде, томан элпәсе каплаган күзләренә нур кайтты.

«Әйе, көчсез бәндә булып мендәр чылатып ятудан мәгънә юк! Кулыннан сөйгәнен йолкып алып китүгә Александр да битараф калмагандыр. Ул да җан тетрәткеч аерылышудан соң Казанны җиңел генә ташлап китмәс. Китмәгәндер... Ут йотып аны эзлидер, көтәдер, юллыйдыр... Китмәгәндер ул... Ирекле сәүдәгәр баласы бирешмәс! Ничек тә җаен табар. Көчле бит ул! Үткен, җитез егет ләбаса!»

Абыйсының бүлмәсенә керде, ишек өстендәге чөйгә карап, кинәт туктап калды. Абыйсының очлы башлы, затлы бүреге эленеп тора иде. Әһә! Менә монысы Фәритнең бәйрәмнәрдә кия торган чалбары, ак күлмәге. Якасындагы, җиңендәге бизәкләрен Гөлйөзем үзе чигеп биргән иде. Тагын нәрсә? Тышта салкынчарак. Өскә кимичә дә ярамас. Гөлйөзем ашыга-кабалана күлмәген салып атты, гадәтләнмәгән киемнәрне үлчәргә кереште. Барысы да нәкъ аңа атап теккән диярсең. Буйга абыйсы белән бер чамадарак кызга аның киемнәре үтә дә килешеп, гәүдәсенә ятып тора иде. Җилкәсе киңрәк киңлеген... Хәер, анысын гына кем карый аның...

Ул биленә каеш салды, өстенә җиңе терсәк буена гына җитәрлек итеп калдырылган, абыйсының буен тагын да зифа, озын итеп күрсәтә торган билле җиләнен киде. Озаклап юанырга вакыт аз. Йөгереп килеп чөйдәге бүрекне алды һәм озын толымнарын баш түбәсенә чорнап, аны очлы бүрек белән бастырып та куйды. Тәрәзәдә чалынган шәүләсенә сокланып карап алды. Кара син аны. Нәкъ яшүсмер егет! Танып карасыннар инде хәзер, бар!..

Аякта үкчәле читек, башта затлы бүрек. Морза баласымыни! Ләкин әле барыбер нәрсәдер җитми иде кебек. Аксөякләргә хас сыйфатларны хәтереннән үткәрергә керешкән кыз аңлап та алды: хәнҗәре юк лабаса! Ул — затлылык, ирлек, егетлек, хөрлек билгесе. Көмеш кынына канатлы аждаһа сурәте уелган сөяк саплы кечкенә хәнҗәрне дә тагып җибәргәч, Гөлйөзем үзен тиешле сурәткә керде исәпләп, канәгать елмаеп куйды. Әйдә, хәзер танып карасыннар инде! Сәйранга чыккан яшь угланда кемнең ни катнашы бар?!.

Өйдән чыгып киткәндә бик тиз генә хәл иткән кыз таныш түгел мохитта бөтенләй аптырап калды. Болактан Казан-суга хәтле халык мыжлаган җирдә танышыңны түгел, үзеңне югалтырлык иде. Урыс сәүдәгәрләрен күрде, әмма: «Сез Угличтан түгелме?» — дип сорарга батырчылыгы җитмәде. «Кемне эзлисең?!» — диярләр. Кыз бала: «Александр кирәк!» — дисенме?! Ояты ни тора. Гөлйөзем үзенең ирләр киемендә икәнен исенә төшереп, чак кына көлеп җибәрмәде. Егет егет кешене сораса, оятмы?! Аягына көч керде, арыганлыгы онытылды. Иңнәрендә канатлар үстемени, тагын дәртләнеп, менә-менә очратачагына өметләнеп базар әйләнүен дәвам итте.

Күрәсең, иптәшенме, дустынмы югалтканнар, аймыл булышканнар бер ул гына түгел. Әнә озын гәүдәле, ярсу кыяфәтле бер адәм үтеп киткән һәр егетнең күзенә керердәй булып карап кала. Эзләгәне ул булмый, ахрысы, ачуланып, теш арасыннан чертләтеп җиргә төкерә дә, тагын озын кулларын болгап китеп бара. Бер сәер ягын да абайлап өлгерде Гөлйөзем. Куе кара сакаллы, калын кашлы, күрер күзгә яшь тоелса да, картларча бөкрәя төшеп атлаган бу алла бәндәсе кемнәндер кача, шикләнә иде шикелле. Юка чикмән якасын бастырып куйган, башын бормаска тырышып, тирә-якны йалт-йолт күзәтә, кабалана иде кебек. Аның яныннан тизрәк үтеп китәргә ашыккан Гөлйөзем урыс киемендәге бу кешенең салкын карашын үзендә тоеп, сискәнеп китте. Калын каш астындагы яшел күзләр, әйтерсең, аны чишендереп капшый, үзәгенә үтәрдәй булып текәлгән иде. Юеш, салкын бакага кагылгандый тәне чирканып куйды. «И ходаем, дөрес юлда йөрми ахрысы бу алла бәндәсе»,— дип укынып, тизрәк читкә китү ягын карады.

Әмма озакламый яшел күзле адәмне дә, базарга ник килүен дә оныта язды. Ташаяктан кала капкасына сузылган юл ягыннан ишетелгән яшерен дәрт, моң катыш өметләнү, талпыну сизелеп торган авазлар аны үзенә тартты, аяклары үзеннән-үзе шул якка атлады. Якынайган саен тылсымлы аһәң көчәя, уен коралларының бер-берсен уздырырга тырышкандай сыкрап ыңгырашканы, көмеш чың таратып бәргәләнгәне ачыграк тоемлана; оста көйчеләр кулында кыллар елый, җырлый, үкси иде. Менә җыручының йомшак күкрәк авазы да колагына килеп керде. Бәрхеттәй йомшак, ефәктәй шома, тау бәллүредәй чиста яңгыраш колакны иркәли, йөрәкне рәхәтлектә изрәп талпынырга мәҗбүр итә, моңы белән сыкрата, дәрте белән алга, каядыр ерак офыктагы киңлекләргә чакыра иде.

Үз-үзен белештермичә кешеләрне терсәге белән аралап алга үткән кыз каршында ачылган күренештән телсез кала язды. Бохра ясап уратып алган халык арасында, яшел мәйданда, нибарысы бер кеше — нәкышлап чиккән ак күлмәктән, куе зәңгәр төстәге чалбар балакларын саурый читек кунычына тыккан җыйнак кына гәүдәле япь-яшь егет, озын чәчле, ак йөзле ялгыз көйче утыра иде.

«Ничек берьюлы шулкадәр күп аваз чыгара соң бу?» — дип уйлап куярга өлгермәде, серен аңлап, рәхәтләнеп елмаеп та җибәрде.

Хәйләкәр көйче барысын да шулкадәр оста җайлаган иде ки, ничәмә-ничә мәмләкәтләрне кичкән елгыр базаркәннәр гаҗәпләнеп тел шартлаталар, шаккатып бот чабалар иде.

— Билләһи, валлаһи, мондаен оста көйчене күргәнем юк иде...

— Тавышы да тавышы... Чичәннәрнең чичәне бу егет!..

— Афәрин! Мең яшә, акыллым! Дәрт-дәрман өстәдең.

— Казанның атаклы көйчеләре нәселеннән ул,— диде кемдер, аны белгәне белән горурланып, танышлыгы белән мактанырга теләгәндәй тамак кырып.

Хуплау сүзләре бер дә юкка түгел, көйче, чыннан да, бер тылсым иясе булып тоела, көе, моңы, җыры, хәтта ки сөлектәй зифа сынын егетләрчә тотуы, карашындагы яшерен горурлыгы белән дә тыңлаучыларны әсир итә, көй хөкеменә буйсындыра иде.

Гөлйөзем аның тапкырлыгына, осталыгына, исемнәрен дә белеп бетермәгән уен коралларының саф авазларына сокланды. Әнә бит ничек җаен тапкан, берүзе дистә көйчене алыштыра. Егет муенына тал чыбыгыннан бөгеп бохра кигән, аңа беркетелгән дүрт-биш курай сыбызгысы иреннәренә терәлеп үк диярлек тора. Беләгенә каеш белән төрле зурлыктагы шөлдерләр, көмеш кыңгыраучыклар таккан, читек башында юка җиз түгәрәкләр беркетелгән нindidер җайланма. Аягын хәрәкәтләндерүгә алар бер-берсенә бәреләләр дә нечкә чың тудыралар. Кулында ялтыравык бизәкле, күз явын алырлык итеп шомартылган думбыра... Егет үзе исә шакмаклап ясалган зур давылбаз* өстенә кунаклаган. Әйтерсең, тәхеттәге шаһзадә!

Менә ул кара мыек астыннан ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды да күзләрен бер ноктага төбәп талпынып куйды.

---

* *Давылбаз* — барабанның бер төре.

Шөлдерләр, кыңгыраучыклар чыңлады, җиңелчә аяк сикертүгә буйсынып, җиз түгәрәкләр чылтырады, озын бармаклары иркәләгәндәй йомшак кына кылларга кагылды. Иреннәре курайның әле берсенә, әле икенчесенә өрә, күчеш саен аларның тавышы үзгәрә, йә калынная, йә нечкерә, тойгыларга яңа төсмер биреп сызлана иде. Егетнең хәрәкәтләре кызулаган саен уен кораллары да дәртлерәк тавышлар чыгара, йөрәк тибешен лепелдәп сулкылдаудан алып бәргәләнгән кошчык хәленә китерә, талпындыра, канатландыра иде. Кинәт кенә ул читек үкчәләре белән ике яклап давылбазга китереп бәрде, киереп тарттырылган үгез тиресеннән калын, куе авазлар чыкты. Әйтерсең, туптан аттылар. Гөрселдәүгә охшаш бу ярсулы аһәң көйне бозмый, киресенчә аны тагын да көчәйтә, дәртен ташыта иде.

Гөлйөзем карады да катты. Ул моннан китә алмый, сихерләнгәндәй көйчене күзәтә, тылсымлы авазлар дулкынында тирбәлә, күңелендә үзе дә аңламаган шашкын хисләр баш күтәрә. Көй ләззәте бөтен тамырлар буйлап тарала, аяк бармакларына хәтле чемердәп куярга мәҗбүр итә иде. Күңелендә җыелган, Александр атлы егеткә әйтәсе килгән, әлегә әйтелмәгән барлык хисләре, тойгылары шушы көйдә чагыла, канатлана иде кебек.

Көй бетте. Әсәрләнгән тыңлаучылар шактый озак тын да алмыйча басып тордылар. Аннан соң, әйтерсең, көтмәгәндә давыл купты, мәйдан өстәндә тойгыларын тыя алмаган йөзләгән кешеләрнең хисләнеп кычкыруыннан өермә күтәрелдеме, егет каршындагы ачыклыкка алтын, көмеш тәңкәләр ява башлады.

— Һай, егет, рәхмәт яусын! Җаныма дәва бирдең!

— Мең яшә! Мең яшә!..

Ә көйче боларны, әйтерсең, күрми дә, сизми дә. Йөзендәге бер генә чалымы да үзгәрмәде. Тыйнаклыгы, үзен тотышындагы басынкылыгы аны тагын күкләргә күтәреп мактарга, рәхмәтләр яудырырга мәҗбүр итә иде.

Ул халыкны тынычландырырга теләп кулын күтәрде. Әгәр: «Җиргә егылыгыз»,— дип әйтсә, сүзсез аның ихтыярына буйсыначак халык төркеме тынсыз калды. Тагын курайлар телгә килде, кыллар тартылып дерелдәде. Егетнең иреннәне арасыннан нииндидер таныш түгел, яңа, озын көйнең моңнары агыла башлады.

И кабер, ачыл, тиз ачыл, сөйгәнемне мин күрим,
Мин керим аның янына, мин бу дөньяны сөймим.
Гүр караңгы, гүр кысынкы, гүр юеш сиңа, бәләм,
Мин туйдым якты дөньядан, мин синең янга килэм.

Гөлйөземнең күзләренә яшь тыгылды: йөрәге актарылуга чыдый алмыйча иренен тешләде, йодрыкларын кысты. «И бәгърем, синең дә шундый кайгыларың бармыни соң? Нинди җаһиллар сиңа шундаен яра ясады?! Ничек итеп якты җир йөзләрендә тормак кирәк»... Буе белән сыгылып төшкән кыз үзе дә сизми бер-бер артлы шул сүзләрне кабатлый иде. Тирә-ягында тагын кемнәрнеңдер сиздермәскә тырышып мышкылдаганы, хисләрен тыя алмыйча тирән итеп «Аһ!» дип куюлары ишетелә башлады. Күрәсең, дөнья тигез генә түгел. Җаннарын ачып карасаң, кемнең дә йөрәгендә ярасы, үзе генә белгән җәрәхәте, тешләрен кысып, иреннәрен чәйнәп онытырга теләгән, ләкин онытылмый, бетми, сүнми торган кайгысы, хәсрәте бар.

Җыр Санькаларны-Александрны, базарга ни өчен килүен исенә төшерде. Җырдан, моңнан исергән Гөлйөземнең көйчене тагын, тагын, тагын тыңлыйсы килсә дә, үзен мәйданны ташлап китәргә мәҗбүр итте. Сөйгәнең өчен, аның белән бергә булу өчен елау-сыктау гына җитми, көрәшә, үз дигәнеңә ирешә белергә дә кирәк икән әле. Сөйгәне янына хәтта кабергә керергә риза егет турындагы җыр юкка чыгарылмагандыр. Ярыннан аерылган — якты дөньядан туйган... Ә Гөлйөзем үз дигәненә ирешәчәк. Белеп тор, газиз әткәем, аңла мине, кадерле әнкәем, аяк чалма миңа, туган абыем!

Җырчыдан ерагайган саен кыз күңелендә хәлиткеч адымны ясау теләге кискенләшә. Сузарга ярамый.

Урыс сәүдәгәрләре, гадәттә, Болак буенда туктый торган иде. Ялгышмаса, Санька да шулай дигән иде кебек.

Яр өстендә бер-берсеннән берничә терсәк ара гына калдырып салынган лапаслар янында, чыннан да, лыбыр-лыбыр урыс телендә сөйләшәләр иде. Боларның кайсылары Угличтан икән соң? Гөлйөзем тәвәккәлләде, борыны белән ярга терәлгән көймә читендә авыз эченнән нидер көйләп утырган калын сакаллы берәүгә эндәште:

— Абзый кеше, әйтегез әле, зинһар, сез Угличтан түгелме?

— Юк, энекәш. Ялгышмасам, алар күптән кузгалды бугай инде. Юкка эзлисең,— дип кул селтәде көймәче агай битараф кыяфәт белән.

Шулчак Гөлйөзем каршында җир астыннан үсеп чыккандай яшел күзле, калын кашлы баягы адәм пәйда булды. Ул кызның үзәгенә үтәрдәй иттереп, сеңдереп карап алды да ярарга тырышкандай төче тавыш белән сүз кушты:

Без идек Угличтан, ачуланмасаң... Кем кирәк иде

димме, нәрсә кирәк иде дип әйтимме?.. Баш өсте. Әмереңне тыңлыйм, и-и яшь шаһзадә...

Ялагай кылануын яратмады, тавышының төчелеге ошамады, Гөлйөзем җавап бирергә ашыкмады. Башыннан йөз төрле уй чагылып үтте. Бүген инде икенче тапкыр юлына каршы төшкән бу кешенең нindidер мәкере, хәйләсе бар сыман тоела иде. Ләкин, күрәсең, башка чара юктыр. Очраган бер кешедән «Сез Угличтан түгелме?» — дип кычкырып, сорашып йөреп булмый ласа. Бәлки юкка шикләнәдер. Тәҗрибәсез, әле мыек та типмәгән яшь егетне шаяртырга маташуыдыр. Базарда ни булмас! Әнә ич, үзе әйтеп тора, «Мин Угличтан»,— ди. Чит-ят кавем кешеләренең гадәтйолаларын каян белеп бетерәсең!..

Гөлйөземнең башка чарасы юк иде, гозерен чыгармый булдыра алмады.

— Миңа... Александр... кирәк иде,— диде ул ихтыярын җыеп.— Аны күрәсе бар иде...

Чикмән якасын утыртып куйган яшел күз ялт-йолт якягына каранып алды да Гөлйөземгә якыная төшеп пышылдауга күчте:

— Кайсы Александр икән соң? — дип сузды ул нindidер уеның очына чыгарга, хәтерләргә тырышкан кеше шикелле.— Бездә Александрлар күп...

— Сәүдәгәр баласы... Яшь егет... Казанда бодай төятергә тиешләр иде.

— Ә-ә... аны әйтәсең икән...— Яшел күзленең тавышына кайгы тәсмере чыкты, гәүдәсе тагын да бөкрәя төште.— Ай, энекәш, олы кайгыга дучар булдык бит әле... Иделдә батып үлде бит ул... Сизми дә калдык. Юкса...

Ул тагын нидер сөйли, Гөлйөземнең күзенә керердәй булып хәбәрнең аңа ничек тәэсир иткәнен күзәтә иде.

Кызның күз аллары караңгыланып китте, авызын учы белән каплады. Күзләре зур булып ачылды.

— Ялгышмыйсыңмы, абый... Ул озын, сары чәчле, зәңгәр күзле...

— Беләм, беләм,— дип бүлдерде кара чикмән иясе.— Уналтысы яңа гына тулган җиләктәй егет иде. Ничек ялгышыйм... Үле гәүдәсен судан үз кулларым белән тартып чыгардым...

— Булмас, булырга тиеш түгел, ялгышасың,— дип пышылдады Гөлйөземнең иреннәре. Ул үзенең ни сөйләгәнен, ни эшләгәнен белми, аяныч, әрнүле хәбәр бөтен миен ялкын белән чорнаган, күз алдында утлы боҗралар биешә иде.

Хәбәрнең яшь егетне яшен суккандай миңгерәтүен ку-

реп торган Иван-сәүдәгәр — кара чикмән иясе нәкъ ул иде — кызларга охшаган бу чибәр яшь егет белән Александр арасында ниндидер бәйләнеш барлыгын инде күптән аңлаган, серне чиштерерлек әмәлләр, ысуллар эзли иде.

Кинәт ул корбанына ташланган елан тизлеге белән Гөлйөземнең колагыннан эләктереп алды да күз ачып йомганчы ике лапас арасындагы бушлыкка тартып кертте. Усал итеп, зәһәр ысылдап сорады:

— Ә хәзер инде дөресен әйт! Аны нигә эзлисең?

Хәлнең мондый борылыш аласын бөтенләй көтмәгән Гөлйөзем югалып калды, тимер җәмки булып кыскан көчле бармаклардан котылырга теләп башын боргалады. Әмма яшел күз көчле, кысканнан-кыса, ычкындыру уенда да юк иде.

— Әйт тизрәк! Тизрәк, тизрәк! — Тагын усал пышылдады ул. — Юкса...

Күзләренә яшь тула башлаган, ялварып еларга җыенган кыз бала кинәт үзенең ирләр киемендә икәнен, егет икәнен исенә төшерде. Әйтерсең, абыйсының киемнәре көч бирде, ихтыярына ирләрчә катылык өстәде. Яшен тизлеге белән ул хәнҗәрен тартып чыгарды да дошманының корсагына терәде, тавышына бөтен ачуын, рәнҗүен салып, усаллык белән кычкырды:

— Селкенмә! Казан егетләре белән сөйләшәсең!

Озын, каты бармаклар колакны ычкындырды, гаҗәпләнүдән яшел күзнең керфекләре челт-челт йомылды, ияге аска салынып төште.

— С-си-ин... с-и-и-н, — дип мыгырданып куйды ул гәүдәсен туры тотарга тырышып. Күз кырые белән очлы хәнҗәрнең кояш нурында ялтыравын күреп өлгергән Иван бер мизгелгә югалып калды.

Ә кызга шул гына кирәк иде дә. Кайчандыр сабан туенда чин ягыннан килгән көрәшчеләрнең кул сугышын караганы, батырлардан берсенең сынын җыя алмыйча сыгылып төшкәне күз алдына килде. Аны-моны уйлаганчы, аягы хәрәкәткә килде, дошманының корсак астына китереп тәтипте. Кара чикмән иясе әллә нинди ямьсез тавыш белән илереп урталай сынды, кычкырып уаланырга кереште.

Гөлйөзем исә лапас арасыннан атылып чыкты да, артыннан бер өер эт кугандай, шәһәргә таба томырылды.

Бетте! Барысы да юкка чыкты!.. Александр атлы фәрештә егет татлы төш булып томанга уралып югалды. Күңелдә бушлык, йөрәктә әллә нинди җирәнгеч хәлсезлек. Дөньяның яме, яшәүнең тәме калмады.

Гөлйөзем сүнде, күз алдында сула, сүрелә башлады. Бер мәгънәсезгә йорт буенча кая сугылырга белмичә йөри-йөри дә бүлмәсенә кереп бикләнә, яшьләренә буыла. Хәзер аңа беркем дә, дөньядагы бер кеше дә ярдәм итә алмый.

«Аһ, көйче егет! Никләргә генә сине күрдем, моңлы җырыңны ишеттем икән! Әллә соң ул моң, ул яшьсез елау, сыкрау минем күрәчәгемне сиздергәнме?! Каберенең кайда икәнен генә дә белмим бит, ичмасам!» — дип өзгәләнә Гөлйөзем. Иреннәре арасыннан яңа ишеткән моңлы, җан тетрәткеч хәсрәтле көй агыла.

И кабер, ачыл, тиз ачыл, сөйгәнемне мин күрим,
Мин керим аның янына, мин бу дөньяны сөймим.
Гүр караңгы, күр кысынкы, гүр юеш сиңа, беләм,
Мин туйдым якты дөньядан, мин синең янга киләм.

«Әллә суларга ташланыргамы соң!.. Минем җаным да аныкы белән Идел дулкыннары арасында очрашыр, күбәләккә әйләнеп, бергә талпыныр иде!»

Кайгылы хәбәр белән бергә зәргәр Галиәкбар абзыйлар өенә тагын бер хәсрәт керде.

Бер көн эчендә бар мөлкәтеннән колак кагуын, бөлүен якыннарыннан яшерә алган, эчтән генә янган, эчтән генә сызган Галиәкбар оста язмышның бу сынавын күтәрә алмады. Кызының күз алдында сулуында үзен дә гаепле санаган атаның чәчләренә чал кунды, күзенең нуры сүнде. «Шулкадәр дә ярату буламы икәнни соң, и раббым!» Алтын кайгысы, мал кайгысы артка чигенде. Әгәренки терелеп кайта калса, Гөлйөземне ул үз кулы белән шул егет кулына тапшырыр хәлгә җитте. Ләкин соң инде. Үткәнне кайтарып булмый.

Әни кеше үзенчә юатырга тырышты, иркәләп, назлап сөйләштерергә, кайгысын куарга җай эзләде:

— Кызым, балам, күз нурым! Ул кадәр өзгәләнмә сана, бетермә сана үзеңне... Дөнья бер бүген белән бетми. Узсын вакыт... Шуннан да олы дәва юк. Күңелеңә ошаган егетне тагын очратырсың. Барысы да онытылыр... Кем булса да, каршы килмәбез. Үз теләгәнеңә чыгарсың...

— И-и-и әни! Миңа беркем дә кирәкми инде... Теләсә нишләтегез!..

Гүр караңгы, гүр кысынкы, гүр юеш сиңа, беләм,
Мин туйдым якты дөньядан, мин синең янга киләм...

Кыз авызыннан ишеткән җырдан энисенең тәне эсселесуыклы булып китте.

— Йа хода! Үзең сакла, акылына гына зыян килә күрмәсен!

КАЧКЫНЛЫКТА

Дус итеп серең сөйләмә —
таңда дошман булмасын;
Дошман дип хәтерен калдырма —
таңда дустың булмасын.

Татар халык мәкале.

— Мин кайда?..

Үзенең тавышын танымады Санька. Йөрәге калтырый, бөтен буыннарында җирәнгеч хәлсезлек. Әйтерсең ул үзендә тау-ташларны актарырлык егәр тойган яшь егет түгел, ниндидер бер сыек бөҗәк, әкәм-төкәм.

— Ашыкма, улым, ашыкма! — диде кемдер. — Ятып тор. Аллага шөкер, гомерең бар икән әле. Кулымда җан бирәсең дип котым очкан иде.

Санька күзләрен ачып җибәрде һәм өстенә иелгән ак сакаллы, бөтен битен, маңгаен тирән җыерчыклар буразналаган таныш түгел картны күреп, күзләрен йомды.

— Кем бу? Мин кайда? Кем белән сөйләшәм?..

Кинәт үзенең көймәдән качуы, озак-озак ярга таба йөзүе һәм су төбенә китү газаплары, үлем белән тартышуы исенә төште. «Димәк, мин теге дөньяда! Алайса бу карт кем? Ул да минем шикелле Идел төбендә әҗәлен тапкан алла бәндәсеме? Әллә су иясе шул үземе?! Алай булса, ни өчен «Гомерең бар икән әле» дип сөенә?»

Ул күзләрен ачарга курка, төрле хәшәрәтләрнең муенына, битенә, кул-аякларына сарыласын, канын суыра башлауларын көтеп чиркана иде. Тирә-якта тынлык. Һәр сүүсем артыннан кан баскан пыяла күзләр аны күзәтәдер, бер кыймылдауга салкын тәнле хәшәрәтләр өерләре белән аңа ташланырлар, бер-берсен изә-сыта чолгап алырлар...

Тагын кемнең дә булса тавыш бирүен көтеп бик озак ятты Санька. Инде телсез, хәрәкәтсез яту газабы түзә алмаслык авыртуга әйләнеп, башын, гәүдәсен кыса башлагач, шикләнеп кенә, сиздермәскә тырышып керфекләрен ярым ачып дөньяга күз салды. Бака ефәге томалаган, төрле хәшәрәтләр мыжлаган караңгы чоңгылда түгел, ә Иделнең текә яры астында, ат башыдай зур, шома чуерташлар өстенә җәелгән печәндә ята икән ләбаса. Су иясенең чәчләре урынында зәһәр еланнар мыжгымый. Кыска гына калдырылган чал чәчле, мөлаем карт икән ул.

— Мин кайда соң? Монда ничек килеп эләктем? — диде ул, ниһаять, зиһенен җыя төшеп.

— Борчылма! Син имин-аман җирдә,— диде карт әүвәлгечә тыныч тавыш белән.— Шөкер, изге рухлар ярдәменнән ташламаган. Күземне ачтылар, үзеңне коткарырлык көч бирделәр. Бигрәкләр дә шомлы җиргә эләккәнсең. Суның котырып аккан урыны. Көймә-каекларны да әйләндереп кенә сала ул...

Санька ашыгып, каударланып муенына тотынды. Аска сөйрәгән хәрам мал урынындамы? Шул гына батырды, төпкә сөйрәде ич. Каһәр төшкән алтын!..

Аның хәрәкәтләрен, сискәнеп нидер эзләвен күзәтеп торган карт сүрән генә елмайды.

— Курыкма, улым! Юлбасар түгелмен. Кеше малына кызыкмыйм. Тамагым тук, өстем бөтен. Шөкер, Идел анысын да, монысын да мулдан бирә...

Оятыннан бугазына төер килеп тыгылган Санька каршы бер сүз дә әйтмәде, икенче якка борылып ятты һәм тагын онытылды. Хәлсезлек үзенекен итте, күзләре йомылды. Картның тыныч, ягымлы тавышыннан бөтен җанына рәхәт бер иңрәү сыман талгынлык иңгән иде, тирән йокыга талганын сизми дә калды.

Менә Идел өстендә сары табак булып кояш күтәрелде, бөтен тирә-як кош-корт сайравына күмелде. Чикерткә кычкыра, бал кортлары, шөпшәләрнең чәчәктән-чәчәккә күчеп выжылдаганы ишетелә. Күк йөзе чалт аяз. Ник бер болыт әсәре булсын! Санька куе үләнлектә, чуар келәм булып җир җиләге, ак чәчәк баскан аланлыкта ята имеш. Матурлыктан, киңлектән хәйран калган, телен әйләндереп бер сүз дә әйтә алмый. Чу! Әнә алан башыннан кочагын җәеп аңа каршы бер кыз йөгерә түгелме соң?! Гөлйөзем ич ул! Тизрәк, тизрәк аңа каршы чыгарга, көмеш тавышын ишетергә, серле моң тулы күзләренә багарга! Кулга-кул тотынып чәчәкле алан буйлап барырга да барырга иде. Аның бәхете күңеленә сыеша алмый, оча-талпына, бөтен гәүдәсе каядыр ашыгып канатлана иде.

Санька сикереп торырга теләде, әмма җирдән кубарыла алмады, гәүдәсе тораташтай каткан, бармакларын селкетерлек тә хәле юк. Ә Гөлйөзем аны чакыра, кулларын сузып ялвара, нидер ымлый, күрсәтә иде. Егет, тешләрен кысып, бар көченә алга ыргылды һәм кинәт җирдән аерылуын сизеп алды. Күз алдындагы алан кинәт юкка чыкты. Ул сәерсенеп як-ягына каранды һәм үзен яр буендагы ташлар өстендә күреп ыңгырашып куйды.

Әлеге саташу төш түгел! Гөлйөзем аны көтә ич... Аның коткаруын, кара төндә карчыга булып очып кунган залим

адәмнар кулыннан йолып алуын көтә. Тизрәк, тизрәк яңадан Казанга! Гөлйөземне коткарырга! Ашыгырга, бик тә ашыгырга кирәк!.. Юкса, соң булуы мөмкин...

Ни кылырга белмәгән Санька үрсәләнеп картны эзләде. Изге күңелле бу кеше ярдәм итми калмас, юл күрсәтер, ни эшләргә кирәген өйрәтер. Буш итмәс аны Санька. Күн янчыгындагы йөз бәлишнең йөзе дә кызганыч түгел!.. Кая гына киткән соң бу карт?! Артында яфрак кыштырдаганнан сискәнеп борылып карады. Куаклар арасындагы тар сукмактан коткаручысы чыгып килә иде. Кулындагы ятьмәдә беләк буе җәен, өч кызылканат, берничә түбәнавыз чапалана.

— Бәхетең бар икән,— дип елмайды ул.— Табышлы көн булды бу! Беренче ауга... сине эләктергән идем, икенчесенә күр, никадәр байлык.

Картның йөзе җыерчыклы, кояшта янган, каралган булса да, күзләре яшь, очкынланып балкый иде. Аңа җавап итеп елмаюын Санька сизми дә калды.

— Рәхмәт инде сиңа, бабакай! Гомерем буе изгелегеңне онытмам. Тик монда озак кала алмыйм, миңа мөмкин кадәр тизрәк Казанга кайтырга кирәк...

— Кайтырсың... Боерган булса... Шулай да мин сиңа ашыкмаска киңәш итәр идем.

Аның сүзләрендә сабырлык һәм әйтелеп бетмәгән мәгънә тоеп, Санька ашыгып муенына үрелде. Ике куллап көч белән тартуга бау өзелеп тә чыкты.

— Менә, бабакай, минем бүтән нәрсәм юк. Изгелегең өчен шушыларны ал да... юл күрсәт! Кая барыйм?

Карт, өстенә сикерергә әзерләнгән зәһәр еланны күргәндәй, Саньканың ачык изүенә текәлде, күзләренә курку, нәфрәт чыкты. Кинәт ике кулын да алга сузып ямьсез, карлыккан тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Кит! Кит! Күземнән югал, кяфер! — Һәм үз-үзен белештермичә артка тайчанды. Аягы шома ташка эләгеп, буе белән чалкан барып төште.

Әле яңа гына үзенә елмайган, ашыкмаска киңәш иткән картның нәрсәдән шул хәтле куркуын аңламаган Санька муенына үрелде һәм анда тагын хәерсез янчыкны табып, телен тешләде. Кулында исә... ефәк җепкә тагылган саллы көмеш тәре тирбәлә иде. Егет аны ачу белән җиргә бәрде һәм карт янына тезләнде. Балыкчының күзләре йомылган, ул тавыш-тынсыз калган иде. Калтыранган куллары белән картның башын күтәрде, аны йомшакка, үзе яткан җиргә илтеп салмакчы иде. Баш астындагы ташта кызыл тап

күреп, йөрәге жу итеп китте. Карт җайсыз егылган да очлы ташка эләккән, күрәсең. Җәрәхәтеннән кан саркый иде.

Менә ул акрын гына күзләрен ачты, бернәрсә аңламыйча Санькага карап торды һәм тагын керфекләре йомылды.

— Бабакай!.. Ни булды сиңа? Нишлим? Ничекләр генә ярдәм итим,— дип өзгәләнде Санька.— Нидән курыктың син?

Ул аның нәрсәдән куркуын аңлый алмый интегә. Христианга да, яһүдигә дә, мәҗүсигә дә бердәй тигез караучы казанлы тәредән генә шул хәтле өрекмәс бит инде.

Карт телсез иде.

Саньканың бөтен гәүдәсе куырылып килде, йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып бәргәләнә башлады.

Гөлйөзем янына талпынган җанының кыйналуына түзә алмыйча, ачу белән үзенең күкрәгенә сукты. Ләкин никадәр генә ашкынса да, карт балыкчыны ул болай гына калдырып китә алмый иде. Нәрсәдер эшләргә, нидер кылырга кирәк. Ярдәм көтәр кеше юк. Ул яр буйлап йөгереп урап килде, картның шалашын, йә булмаса торган куышын табарга иде бит. Ерак та түгел комташны киртләп баскычланып күтәрелгән сукмакны күреп алды һәм алга ыргылды.

Яр өстендәге куе агачлык арасындагы аланда сыңар тәрәзәсе Идел ягына караган, түбәсен камыш белән япкан кечкенә генә өй тора иде. Санька кабаланып шунда чапты, җиңел сулап куйды. Менә ярдәмгә кешеләр чакырыр, картны кертеп салырлар, урнаштырырлар. Аннан соң... Казанга!..

Өй тирәсендә тынлык. Ишегалдындагы учак күптән сүнгән. Таганга асылган җиз казан буш. Тирә-якта кара күмергә әйләнгән кисәү агачлары гына аунап ята. Шылт иткән аваз да юк. Санька тамак кырып куйды һәм ул-бу ишетелмәгәч кыюланып ишекне шакыды. Җавап бирүче булмады. Тагын шакыды һәм ишекне ачып җибәрде. Түр башындагы мич, аңа терәп салыган сәке, чүлмәк савыт-саба, берничә тәбәнәк урындык һәм балык тоту, ау кирәк-яракларыннан башка өйдә бернәрсә дә юк иде. Аңлап алды: картның йорты булырга тиеш бу! Һәрхәлдә, монда картны беләләрдер.

Йөгереп яр астына төште һәм картны күтәреп алып менде, сәкегә җайлап салып, өстенә каплады. Тагын нишләргә икән дигәндәй як-ягына каранды. Аста калган балыклар искә төште, тагын шунда йөгерде. Аларны күтәреп менгәч кенә Идел өстенә күз салды.

Елга уртасында ялгыз көймә чайкала. Савелий Кузьмич көймәсе. Аның җилкәннәре төшерелгән. Артка тагылган өч

каекның өчесе дә юкка чыккан. Көймә ишкәкләрен салмак кына шапылдатып Казанга таба төшеп бара. Әнә көймә борынында берәү күренде, ул кулларын маңгаена куеп Идел өстен күзли, көймәдәге башка кешеләр дә сузылып-сузылып тирә-якны күзәтәләр. Яр буена табарак, бер-берсеннән чирек чакрымнар ара калдырып, өч каек килә. Алдагысында Савелий Кузьмичның тузгыган чәчле башын, бер төн эчендә сыгылып төшкән баһадир гәүдәсен дә абайлап була. Менә ул каек төбендәге капчыктан түгәрәк ипи алды һәм, нәрсәдер укынып, аны агым уртасына йөздереп җибәрде.

Санькaның йөрәге жу итеп китте. Аны эзлиләр түгелме соң?! Карт балыкчы менә нәрсәгә ишарәләгән икән. Түгәрәк икмәк кеше баткан җирдә туктап әйләнә башларга тиеш. Әгәр бу ырым чын булса, икмәк Санькага таба йөзәчәк. Бетмәгән ризыгың сине эзләп табасы...

Егет тавыш-тынсыз гына куаклар арасына чумды. Күзләренә тыгылган яшьне йодрыгы белән сөртә-сөртә куелыкка атлады, иреннәре бертуктаусыз пышылдады да пышылдады:

— Әтием, бәгърем, кичер мине! Нинди утларга салуымны беләм... Тик нишлим?.. Нишлим... Ни кылыйм? Гөлйөземне күрмәсәм, миңа якты дөньяның мәгънәсе юк! Аңлата алмадым, әйтеп бирә белмәдемме соң?.. Кичер... Әнкәйне сакла! Ә мин... кайтырмын. Кайтырмын!

Ни эшләргә белмәгән Санька тагын яр буена чыкты, тагын куаклар арасына качты, көймә Идел борылышында күздән югалганчы җанында икеләнү хисе бәргәләнде. Дөрес эшләдемме?! Яңадан Угличка нинди йөз белән кайтып күренермен!!! Җилкән колгалары борылыштагы калкулык артына күмелүгә эчендә ниндидер бер җеп өзелгәндәй булды, җаны тынычлап калды, күңеле урынына утырды. Икеләнү хисе, әйтерсең, шул колгаларга уралып еракка, Идел киңлекләренә кереп юкка чыкты.

Санька ашыкмый гына коры-сары җыйды, ишегалдындагы учакка ут элде һәм җәенне чистартып, кисәкләргә турап, казанга салды. Кичтән бирле бер кабым ризык кермәгәнлеге үзен шактый сиздерә башлаган иде инде. Сукмак читләреннән эзләп әрекмән яфрагы табып алды. Карт балыкчының ярасына ябарга кирәк булыр. Бәрелгән җиргә әнисе шундый яфрак яба торган иде.

Карт әле һаман күзен ачмаган. Егет аның маңгаен тотып карады. Ут яна. Күрәсең, Саньканы коткарганда үзе дә суга чумган. Бөтен тәне кызыша. Һушына килсә дә,

аны мондый хәлдә ташлап калдыру турында уйларга да ярамый иде.

Шулпа быгырдап кайнап чыкты. Санька белә: балык шулпасына юа, кузгалак, балтырган ише нәрсәләр килешә. Аларны эзләп тапты, мич аралыгындагы тәпәннән тоз килеп чыкты. Пешкән балык исе, шулпа исе, төрле үләннәрнең хуш исе борынын кытыклый башлады, авызга су җыелды. Ул ашыкмый гына ашны җамаякларга бүлде. Их, бер генә кисәк икмәк булсачы! Хәер, шулпа болай да ашап туйгысыз. Җәен ите ап-ак булып, кисәкләргә таралып тора. Ачык һавада мәмрәп пешкән балык теләсә нинди талымчан кешенең дә нәфесен кузгатырлык иде.

Ашны карт янына китереп куйды һәм аны уятырга теләп маңгаена учын салды. Аның тиз генә тормаячагын белсә дә, инәлеп кабатлады:

— Бабакай! Тор инде, уян! Ач күзеңне... Әнә балык та пеште. Бабакай дим...

Балыкчы карт күзләрен ачты, танымыйча Санькага карап торгач, куллары белән аны куган хәрәкәт ясарга кереште. Учларын читкә каратып селтәнүе «Күземнән югал, кит» дигәнне аңлата иде булса кирәк. Санька аңлый алмый интегә: нигә куа ул? Санька аңа нинди зыян китергән? Шундый ук куркыныч затмыни соң ул? Бәлки теге каһәр суккан янчык шулай тәэсир итәдер. Ул озак уйлап тормыйча, мич кырыендагы почмактан үткен пычак алды һәм шартлатып янчыкны кисеп төшерде, аны кая куярга белмичә аптыранып торгач, ишек катындагы ау кораллары арасына ыргытты. Ятсын шунда. Кемгә дә булса бәлки файдасы тияр әле!

Карт янә күзләрен ачты. Шуны гына көтеп утырган егет, кашыкка аш алып, аны картның иреннәре янына китерде.

— Бабакай, аша инде!..

Әллә ялваруы тәэсир итте, әллә карт чыннан да бик ачыккан иде, бу юлы каршы килмәде, егет кулыннан ризык алды. Аның битләре алланып китте, күзләренә нур кайтты. Сәер итеп, текәлеп Санькага, аның изүенә, күлмәк якасындагы бизәкләргә карап торды. Әмма аңа мөнәсәбәтен үзгәртмәде. Аның йөзеннән ризалык та, канәгатьсезлек тә, курку да, шикләнү дә абайланмый. Ул тулысы белән үз эченә бикләнгән, аңа гына мәгълүм нindидер бүтән бер дөньяда яши сыман иде.

Санька картның урын-җирен рәтләде, башындагы әрекмән яфрагын алыштырды да ятарга ишарәләде. Үзе сөй-

ләшмәгән кеше белән ул да ирексездән ым-ишарә аша аралаша башлаган иде. Карт сүзсез генә урынына ятты. Ул һаман нидер уйлый, нәрсәгәдер борчыла кебек. Егет аңа комачауламас өчен тышка чыкты да чирәмгә сузылды. Мәңге бетмәстәй тоелган көнне ничек тә уздырырга кирәк иде. Тизрәк бабай гына терелсен дә...

Төнге урман уртасында учак дөрли. Ялкын телләре берберсе белән узышып күккә үрлиләр. Коры агач шартлап-шартлап куя. Учак янында ике шәүлә тирбәлә. Салмак кына сөйләшәләр.

— Бабакай, сиңа мин гомерем буе рәхмәт укырмын Үлгән идем ич инде. Син мине кабердән тартып алдың...

— Анысы шулай,— дип көрсенә карт тавыш.— Бу хакта бүтән сөйләмә. Җыясы ризыгың калган булгандыр... Әҗәлеңне кайтардың инде...

— Юк, юк, бабай! — Яшь тавыш каударланып, бүлдерүләреннән курыккандай кабаланып сөйли.— Мин үземдәге бөтен алтынны сиңа калдырам! Кешеләр арасына, калага кайтырсың. Картлыгың балда-майда үтәр...

— Юкны сөйләмә! Миңа алтын кирәкми. Бөтен явызлыкның, мәкернең башы шунда. Аңа ягылып җанымны пычратасым килми. Булган хәтлесе дә бик җиткән! Алтыннарың үзеңә дә кирәгер әле. Яшь кешесең. Күрәчәгең алда...

— Бабакай! Мин бит чын күңелдән... Ярдәм итәргә теләп... Әтием хәлле кешеләрдән... Аннан гына безгә зыян килми.

— Ярый... Әйтеп бетерим инде алайсаң. Баштарак мин сине угры-фәлән түгелме дип шикләнгән идем. Ушкуйниклар азынды... Шуларның берәрсе түгелме дидем. Хәзер белдем, сиңа алтын мәкере, явызлыгы йокмаган. Күңелең чиста. Тик кара төндә ничек Иделгә төшүеңне белмим. Анысы миңа караңгы... һәрхәлдә үз ирегең белән түгелдер...

— Их, бабай, белсәң иде эчемдә нинди утлар дөрләгәнен! Үзем монда, җаным Казанда минем. Кошлар булып очып китәр идем...

Карт тавыш әкрен генә кеткелдәп куйды:

— Яшь чакта барыбыз да шундый... Барыбыз да канатланып очар идек...

Учак дөрли. Ялкын телләре яңа салынган һәр ботакны кочаклап алалар да сары төскә манчып ялый башлыйлар. Бераздан агачның сөякләре күренә, кара тут булып бәгыре ачыла. Агач ут белән кушыла. Аларның кушылуыннан җылылык, эсселек, якты нур чәчри, тирә-якка очкыннар сибелә.

Учак туемсыз. Аның нәфесе туктауны белми. Соңгы сулышынача ул агач сорый, ялкынын үрләтерлек бер ботак кисәге ялварып ысылдый, бәргәләнә.

Учак янында балыкчы карт белән Санька. Ялкын шәүләсе картның йөзендә бии. Егет аңа карап үз уйларына чумган. Балыкчының аны башта чоңгылдан коткаруы, аннан соң өрәк күргәндәй куркып үз яныннан тибәрүе, соңра тагын аңа мәрхәмәтенең сәбәбен аңлый алмый интегә. Бөтенесе нибары ике көн эчендә давыллы өермәдәй уйнап үткән шомлы вакыйгаларда ниндидер аңлаешсыз эзлеклелек бар кебек. Мәрхәмәт һәм нәфрәт, дуслык һәм дошманлык, үз итү һәм читкә тибәрү... Алар шулай бер-берсенә бәйләнеп, үрелеп киләләрме соң әллә?

Мәхәббәте хакына ут-суларга керергә әзер егет ашкыну белән сабырлык арасында, ук булып очу теләге һәм Идел буенда яту мәҗбүрлеге арасында гаҗиз. Учактагы утны ул үзенә тиңли. Йөрәгендә шундый ук ялкын дөрли ләбаса.

Ашыкмый гына гәп йомгагын сүтәләр. Егетнең тышкы сабырлыгында дуамал ашкыну чалымнары, картның сабырлыгында күпне күргән кеше зирәклеге...

Аның үз туксаны туксан.

— Сабыр ит! Сабыр иткән морадына җиткән. Бу хәлеңдә син әлегә Казанга кайта алмыйсың. Иманым камил, анда күренүгә ук бәйләп Угличка озатачаклар. Әтиең сүзе үтә торган, каты куллы адәмнәрдән күренә. Үҗәтлектә синнән кайтыш булмас. Сөйләвеңнән чыгып фикер йөртәм: үзе китсә дә дусларына әйтеп калдырыр. Белеп тор, сине көтәләр... Синең батып үлүеңә ышангандыр дип беләсеңме? Тагын бер генә соравым бар: алтыннарыңны әтиең үзе биргән идеме?

Санькaның битенә гөлт итеп ут кабынгандай булды. Йөзенең кызыллыгын сиздермәс өчен учактан читкәрәк китеп утырды. Телендә исә тагын шул ук сүзләр кабатланды:

— Нишлим соң? Нишлим, бабакай? Анда Гөлйөзем... Хәлен беләсең ич...

— Белгәнгә күрә әйтәм дә,— дип, соравын җавапсыз калдырганны сизмәгәнгә салышып дәште карт балыкчы.— Гөлйөземеңне әйтәм, кол-чуралардан булырга охшамаган. Ирекле кеше кызына Казанда кем дә кул күтәрмәс. Беләм! Күңелем шулай сизә, кызыңа берни дә булмас. Очрашырсыз, алла насыйп итсә, кавышырсыз да бәлки. Тик, әйтеп куям, ай-һай авыр, күтәреп булгысыз авыр эшкә алынган-

сың. Ә хәзергә түз! Ата-анаңа да хәбәр җибәрерсең. Вакыты җиткәч, сине Казанга озату җаен үзем табармын...

Балыкчы карт сүзен әйтеп бетермәде, нәрсәдер исенә төшкән, ашыгыч эше бар кеше сыман ашыгып йортка кереп китте. Озак та үтмәде, кулына ике терсәк озынлыгы кипкән курай тотып килеп чыкты, нидер вәгъдә иткән кебек өметләндереп әйтте:

— Хәзер мин сиңа гыйбрәтле бер кыйсса сөйлим. Аңларсың...

Үткен пычак белән курайның бер очын кыеклап кисеп төшерде, ике бармак ара калдырып тишек уйды, тагын бераз ара калдырып яңа тишекләр ясады. Уйчан карап, тамак кыргалап алгач, курайны иреннәре арасына куеп өрә башлады. Кипкән камылдан, гап-гади үлән сабагыннан моңарчы ишетмәгән, урман-даланың үзе кебек үк серле, тылсымлы, моңлы көй агыла башлады. Саньканың бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Әйтерсең лә аны алыштырып куйдылар, җанын тырнап торган уйлары каядыр очты, күңелендә өмет, ышаныч ныгый башлады кебек. Ул аның нинди өмет, нинди ышаныч икәнен дә белми, тик курайдан агылган көйдән тамырларына көч кергәнен, ашыгып бәргәләнгән җанына сабырлык иңгәнен, сынган рухы яңарганын гына тоя.

Карт күзләрен йомды. Ярым ачык иреннәреннән шул көйгә сузылган, гыжлауга охшаш авазлар яңгырады. Саньканың мондый әйтешне гомерендә беренче кат ишетүе. Читят булса да, халәте рухиясенең бөтен нечкәлеген бары тик шушы көй, шушы өзгәләнү, газаплы моң гына аңлатып бирә аладыр, моннан башка бар көйләр дә, җырулар да мәгънәсез кычкыру, шаяру гына булып каладыр сыман.

Зөләйха әйтте: «Инде кил син яныма,
Рәхим итеп, бу камчыңны бир кулыма,
Гашыйк булсам, ул күрсәтер моны сиңа —
Күрсәтмәсә, дәгъвам ялган булыр имди».

Йосыф, килеп, аңа үз камчысын сонды,
Хатын камчыга орды да кире бирде,
Камчыга ут кабынганын Йосыф күрде,—
Камчы янып, Йосыф кулын пешрер имди.

Тугры Йосыф ул камчыны атып бәрде,
Зөләйханың гашыйклыгын ачык белде,
Һич калмады шиге, тугрылыгын күрде,—
Гаҗәпләнеп ат тезгенен тартыр имди.

Зөләйхә әйтте «Күрдеңме, аңладыңмы,
Камчыга ут кабуга син таң калдыңмы?
Кулыңны пешергәнгә түзалмадыңмы? —
Ул ут мине кырык ел көйдерә имди!»

Тылсымлы моң дөньясында сихерләнеп озак утырдылар. Тынлыкны балыкчы карт бүлде:

— Менә шулай,— диде ул озак көйләүдән арыган тавыш белән.— Дөньяда адәм балалары бер-берсе өчен яратыла. Ялгыз кеше — ярты кеше. Бербөтен булыр өчен әнә шул үзеңә билгеләнеп дөньяга килгән затны таба, аның өчен көрәшә белергә дә кирәк. Мин сиңа сокланам, аны табарыңа ышанам. Бәхетеңне китереп бирмәсләр, егеткәем. Син шушы хакыйкатьне, үзеңә тиң затны белүең белән дә бәхетле кешесең...

Санька моң дөньясыннан айный алмаган иде әле. Картның үзенә атап әйтелгән сүзләренең мәгънәсе соң гына барып җитте. Сораганын сизми дә калды.

— Бабакай, ә синең андый затың... ярың бар идеме?

Карт балыкчы сискәнеп китте. Бик озак бер ноктага текәлеп утыргач кына, авыр сулап, уфтанып җавап бирде:

— Бар иде, улым, бар иде...

— Ә кайда соң ул?

— Моннан ун-унбиш еллар булыр... Без яу чаптык. Гаскәри идем... Без яуда чакта урыс дошманнар килеп авылны туздырган. Минем... Зәйнәбемне дә харап иткәннәр... Язмышын белмим. Балаларымны да кылычтан үткәргәннәр.

Балыкчының күзенә яшь тыгылды, ул Санькага күтәрелеп карамый йортка кереп китте.

Авыр тынлыктан икесе дә котыла алмадылар. Соң гына йокларга яттылар. Ике арадагы элекке җылылыкка бәс сарды кебек.

Өченче көн дигәндә Иделдә Углич көймәсе күренде. Уңайга искән җилдән җилкәннәрен киергән көймә кызулаганнан-кызулый агымның бар икәнен дә сизмичә югарыга үрли иде.

Санька аны яр башындагы калын имән артына качып күзәтеп калды. Күңелендә тагын нәрсәдер өзелде, күңеле тулды. Тик ул хәзер берни дә эшли алмый иде инде. Язмышы аны башка якларга чакыра, үзенең ярын чит-ят кавемнән эзләргә әйди иде.

— Менә хәзер Казанга кайтсаң да ярар,—диде аның көймәне озатып калуын күргән ялгыз балыкчы.— Моннан

ярты көнлек юлда саклаубашы* бар. Аннан ике көнгә бер пайтәхеткә алмаш җайдаклар чаба. Мин аларга балык илткәлим. Бу юлы үзем бармам. Йомышымны син юллар-сың. Үзеңә дә уңай булыр. Шикләнмә, тоткавыл Шәһитне сора. Ярдәм итми калмас. Яшь булса да, акыллы, төпле егет. Ордым-бәрдем түгел.

Санькаың биштәренә балыкның яңа тотылганын да, кипкәнен дә тутырды карт, чүлмәк белән уылдык тыкты, берничә көлчә салды.

— Юлда үзеңә дә җитәр, саклаубаштагыларга да...

Хушлашу, аерылышу авыр, икесенә дә моңсу иде. Зәйнәбенең, балаларының һәлакәтен сөйләгәннән соң үз эченә бикләнеп калган картның ничек тә күңелен күтәрәсе, аңа юаткыч сүзләр әйтәсе килә иде. Хәтерендә күпме казынмасын, Санька андый зур югалтудан юатырлык сүзләр таба алмады. Гаскәриләр нәселеннән булмаса да, ничектер үзен дә гаепле шикеллерәк хис итә, «урыс дошманнар кылычтан үткәргән» дигән сүзләр аның бәгыренә дә пычак булып кадалган иде.

Кинәт башына бер фикер килде.

— Бабакай, Казанга бергәләп кайтыйк! Бергә-бергә көн күрербез әле,— диде ул дәртләнеп, уеның гадилегенә һәм картка ярдәм итәргә мөмкинлек чыгуга куанып.

— Юк инде, улым! Мин кешеләрдән биздем. Алар арасында кызык түгел миңа...

Саньканың нәүмиз караган күзләреннән карашын читкә алды һәм:

— Бер тиенең дә кирәкми,— дип өстәп куйды.

— Нигә, бабакай? Мин бит чын күңелемнән әйтәм...

— Үпкәләмә! Дошман кавеменнән ярдәм ала алмыйм.

Саньканың яңагына чаптылармыни, бите кызарып чыкты, еш-еш сулый башлады.

— Мин бит сиңа дошман түгел,— дип кычкырып җибәрде ул ачыргаланып.— Алайса, ник миңа ярдәм иттең?! Нигә кире суга төртеп төшермәдең?

— Әйе, син дошман түгел,— диде карт сабыр гына.— Ялгыз башың син дошман түгел... Ялгыз бүре ат көтүенә һөҗүм итми. Ә өере белән килсә... Өернең үз кануннары бар. Динегез шулай кушамы, патшагызмы? Белмим...— Моңсу гына Санькага карап торды һәм елмаеп, яратып

---

* *Саклаубашы* — гаскәр сакта тора торган җир. Хәзерге пост мәгънәсендә.

өстәп куйды.— Сине үземнең малаема охшатам. Ул да шушындый чибәр егет булыр иде... Йә, ярый. Юл кешесенең юлда булуы яхшы.

Карт кулларын кушырып дога укыды һәм кай тарафка ничек барасын аңлаткач, тагын бер киңәш бирде.

— Син сәүдәгәр баласы. Казанда бик авырга килсә, соңгы чиктә Әҗемгә барып егыл. Балыкчы бабайдан килдем диген. Үзе аңлар. Кулыннан килгән ярдәмен кызганмас. Малтабар булса да, әүлия кеше. Урыс бистәсенә борыныңны тыкма. Атаңның сер сыйдырыр кешеләре байтактыр... Угличка хәбәр итү җаен тапмый калмаслар.

Санька аягына чабаталар киде, аркасына биштәр асты. Казанда ни көтәсен анык белмәсә дә, күңеле күккә омтылган сабан тургаедай ашкынып җырлый, бер көйгә талпына: алда Казан, анда Гөлйөзем! Алда нурлы кала, алда мәхәббәт сурәте!

Картка карап кул болгады да җиңел адымнар белән чикләвек куаклары арасындагы тар сукмактан атлап китте. Һәр адымы аны көтелмәгән маҗараларга илтә, үзеннән ярдәм көткән кыз белән кавышу мизгелләрен якынайта. «Эх, канатланып очарга иде дә ук җитмәс биеклектән лачын кебек ташланып, кызны күтәреп алырга иде! Очарга иде бергә-бергә офыктан-офыкка... Канатлар талганчы, йөрәкләр бер булып тибә башлаганчы... Күрсеннәр иде Казанда да, Угличта да...»

Гөлйөземнең «Ак-ка-а-на-а-тым!» дип, ярдәм көтеп, ачыргаланып кычкырганы исенә төште. Ничә көн әрәмгә үтте, ничә көн газаплы көтү белән узды. Кулына эләккән беренче таякны сөңге итеп алга сузды һәм дошманнарын күз алдына китереп, аларга кадарга, баш аша чөеп ыргытырга кереште.

— Менә сезгә! Монысы Гөлйөзем өчен... аның күз яшьләре өчен... Саф күңелле кызның күңеленә пычрак кулларыгыз белән кагылган өчен! Рәнҗү-каргышлар өчен!..

Санька күзгә күренмәс дошманнарын кырды, изде, таптап, сытып үтте. Алар барысы да юл кырыена егылып, шәфкать сорап, ялварып ятып калдылар. Егет күңеле аяу белмәде, рәхимсез бәндәләргә рәхимсезлек белән кадап, алга омтылды.

«Их! Булсын иде шушында Вася! Бергә-бергә никадәр җайлы-уңайлы булыр, теләсә нинди ишекләрдән бәреп керерләр, теләсә кемне чөеп кенә ыргытырлар иде!» Санька Гөлйөземнән кала үзе өчен иң кадерле затны — ике яшькә өлкәнрәк агасын исенә төшерде. Угличта Вася барында аңа

беркем дә бармак белән кагылырга да җөрьәт итми иде. Энесен җанынннан газиз күргән абый кеше аның яклаучысы, саклаучысы, кырыс һәм гадел остазы да иде бит! Әллә нинди бер ачыну белән Санька хәзер үзенә нәкъ менә агасы җитмәгәнлеген, таяныр кешесе булмаганлыгын аңлады. Алда билгесезлек! Өметсезлек... Тагын нинди куркыныч хәлләргә юлыгырга туры килмәс әле... Ялгызлыктан да авыр нәрсә юктыр! Хәтереннән бер-бер артлы Вася белән үткән рәхәт күңелле мизгелләр узды.

Күптән, бик күптән булган иде бу. Ә хәтердә барысы да бүген генә булган кебек. Санька белән Вася Идел буенда, сап-сары комлы култык ярында яталар. Вася чалкан төшкән дә күктән агылучы ап-ак болытларга карап хыяллана:

— Их, Санька! Менә үсеп җитәрбез, ак җилкән киергән көймәләрдә ерак илләргә сәяхәткә чыгарбыз. Явыз юлбасарлар, усал баскыннар очрар. Без синең белән кулга сөңге-кылыч тотып көймәнең иң очына басарбыз да берәм-берәм аларны су төпкеленә озатырбыз. Син баһадир, мин пәһлуан. Безнең көймәне ерактан ук танып, юлбасарлар шыр җибәреп кача торган булыр... Мал төяп, ефәк, җофар төяп илләр гизәрбез, әкияти җирләр күрербез, диңгезләргә чыгарбыз... Шулай бит, ә?..

— Ыһы-ы,— дип баш селкеде Санька.

— Моның өчен көчле булырга, чыныгырга кирәк, энекәш! Ә син әле йөзә дә белмисең. Суда балыктай, җирдә йөгерек аргамактай җитез булыйм дисәң, чынык! Кулларың тимер, бәдәнең баганадай булсын! Шулаймы?..

— Ыһы-ы-ы...

— Нәрсә син ыһы да ыһы... Әйдәле, йөзәргә өйрәтим үзеңне.

Иренеп, иркәләнеп, җылы кояш нурларына изрәп яткан Саньканы ул бер кулы белән генә тартып торгызды, җитәкләп Иделгә сөйрәде. Сизми да калды, Вася аны кочаклап баш очына күтәрде һәм текә ярдан каралып күренгән тыгыз, саллы дулкыннар арасына атып та бәрде. Таш кебек төпкә китте Саня. Иреннәрен чытырдатып кысты, күзләрен йомды, аякларының каты җиргә бәрелүен сизүгә, этенеп өскә ыргылды. Куллары белән чапаланырга кереште. Бөке кебек атылып чыкты һәм җан ачысы белән:

— Вас-ся! — дип кычкырып җибәрде.

Агасы ярдәмгә ашыкмады, кулларын салмак кына салып күрсәтте, киңәш биреп кычкырды:

— Чапаланма! Салмак кына... салмак... Кулларың бе-

лән эшлә! Иш! Тавык түгел бит син! Менә болай... Ярга таба, ярга таба дим!..

Яңадан төпкә китә башлаган Санька абыйсы күрсәткән хәрәкәтләрне кабатларга мәҗбүр булды һәм сәер гаҗәпләнү белән үзенең су өстенә килеп чыгуын абайлады. Ул ишкән саен су аны өскә этәрә, батмас өчен җан-фәрман тырышкан малай кабат-кабат шул хәрәкәтләрне ясарга мәҗбүр иде.

— Йөзәм бит, йөзәм,— дип шатланып шәрран яруын сизми дә калды.— Йөзәм бит!..

Гәүдәсенең дулкыннар өстендә йомычкадай уйнаганын сизгән саен аның күңеле күтәрелә, тагын-тагын йөзәсе, колач җәеп Идел уртасына ыргыласы килә иде.

— Китте! Бу якка иш! — Агасының тавышында сөенү, гаҗәпләнү һәм куркыну тоеп, Санька юри Идел уртасына борылды. Бераздан яр буенда чулт иткән тавыш ишетелде. Вася ашыга-ашыга аңа таба йөзеп килә иде

Кыен чакта һәрвакыт шулай: абыйсы ярдәм кулы сузды, куркыныч упкынга этәреп тә, аны кирәгендә тартып ала белде. Менә бүген дә Санькага киңәшче, ярдәмче, иптәш һәм дус — агасы җитми иде.

Уйланып бара-бара шактый юл үтелгән. Бөдрә каеннар белән аралашкан наратлыкны үтеп, киң аланга килеп чыгуга, кемнеңдер кычкыруын ишетеп туктап калды.

— Саня-а-а! Санька дим, улым!..

Аланга ашыгып-кабаланып балыкчы карт килеп керде. Ул еш-еш сулый, аркасына тир бәреп чыккан, һәрвакыт пөхтә, җыйнак сакалы таралып, аңа ниндидер таныш түгел төсмер биргән иде.

— Ни булды, бабакай? Нигә ашыгасың?

Саньканың соравын карт балыкчы җавапсыз калдырды. Каударланып изүенә тыгылды һәм калтыранган бармаклары белән күн янчыкны тартып чыгарды, аны ачулы кыяфәт белән Санькага сузды.

— Мә, ал! Миңа синең алтыннарың кирәкми...

— Соң, бабай...— Санька каршы әйтерлек сүзләр таба алмады, гасабиланып, тагын үзенекен кабатлады.— Миңа да кирәкми бит ул! Ал инде, бабакай... Минем сиңа игелек эшлисем килгән иде...

— Изгелекне хәрамлашып эшләмиләр.— Картның йөзенә кырыслык чыкты, һәр сүзен кистереп әйтте:

— Синең яшиселәрең алда әле. Кирәге чыгар. Чыкмый икән, мохтаҗларга өләшерсең...

Саньканың күзләренә яшь тыгылды. Ау кораллары ара-

сына ташлап калдырган һәм тагын үзенә кире кайткан бу янчык аның кулларын яндыра сыман иде.

— Ярар, алайса,— дип мыгырданды ул һәм янчыкны алып биштәренә яшерде.

Сүрән генә хушлаштылар. Үзенә карата мәрхәмәтле дә, кырыс та була белгән, яктырып аталарча сөйгән һәм кинәт читкә этәргән картны Санька аңлый алмый иде. Табышмак булып калган балыкчы аның күңелендә аңлаешсыз хисләр өермәсен кузгатты.

— Шулайдыр... Изге эшне хәрамлашудан башламыйлар. Әллә соң чыгарып атаргамы ул каһәр суккан янчыкны!

Биштәренә үрелгән куллары тагын туктап калды. «Юк! Ярамас! Урманда аунаганчы, мохтаҗлар, ятимнәр кулына керсен. Картның киңәше дә шундый лабаса!» Бу уйдан җаны тынычланып калды. Әнә, кояш инде төшлеккә күтәрелеп килә. Ашыгырга кирәк. Бәлки әле алмаш җайдаклар Казанга бүген үк чабар. Алар белән Санька да канатланып очар, бәхетенә якынлашыр.

БИЛГЕСЕЗ КӨНДӘШЛӘР

Казан каласы таш кала,
Күп калага баш кала...

Халык җыры

Балта осталары төшкә кадәр ялга туктамый эшләде. Казан ашыгырга кушкан. Каты куллы Сафагәрәй ханның үз авызыннан чыккан фәрман көне-сәгате белән Иделнең өске агымындагы ерак Саклаубашка да килеп җиткән иде.

Саклаубашы дигәнебез Казан мәмләкәтенең төньяк-көнбатыш чикләрендә гаскәриләр саклый торган соңгы кизләү иде. Моннан ары кеше аягы басмаган калын урманнар башлана. Аларның иясе юк диярлек. Анда-санда сибелгән чирмеш авылларында халык аз. Җир җитәрлек. Казан дәүләте казнасына хәлләреннән килгәнчә ясак түләп, тыныч кына яшәп яткан мари кабиләләре гомер бакый татарга тартылды, дус булды, Казанга сыенды. Алар үзләрен Казан иле кешеләре саный. Киң күңелле, тиз ышанучан һәм садә холыклы бу кабиләләргә яннарында кораллы, көчле гаскәр тупланган олуг кала, ныклы кирмән кирәк. Казан исә алар өчен һәнүз шул вазифаны үтәп килде: баскын-

нардан саклаучы калкан да булды, дошман явы узынса, сыеныр урын да биреп килде.

Сафагәрәйне урман кешеләре шикләндерми, алар артында күтәрелеп килүче тәртипсез, сугышчан, дуамал башка кабиләләр — Мәскәүгә тез чүктереп сындырылган урыс кенәзлекләре борчый. Саклаубашы аларның хәрәкәтен чамалау өчен куелган иде.

Кояш нәкъ баш очына күтәрелеп, күләгәләр аяк астына кереп югалгач кына Шәһит осталарга туктарга ишарәләде. Соңгы бүрәнәләрне каезлап, киртләр һәм ырмау салып килгән балтачылар теләр-теләмәс кенә эшләреннән аерылды. Ул аларга киекне куып җиткән ау этенә туктарга кушкан боерык шикелле тоелды. Шулай да яшь бинең ишарәсен санга сукмауны яхшысынмадылар. Гаскәр башы итеп җибәрелгән егетнең холкын белмиләр, әмма тоткан җиреннән сындыручан кырыс Мәмәт би углы икәнлеген ишеткәннәр, аннан бераз гына шикләнәләр иде.

Ашчылар табак-савыт шалтыраткан арада акрын гына гәп куерды:

— Җилле чыкты бу. Элеккесеннән егерме терсәкләп биегрәк булыр, ахры,— диде арадан берсе.

— Үлчәнгән, чамаланган инде... һәр карышы кәгазьгә төшерелгән. Аны фараз итеп утырасы юк,— дип белдеклелеген күрсәтте икенчесе.

— Дөрес чамалаганнар. Өстәге мәйданчыктан бөтен дөнья уч төбендәгедәй күренә...

— Монда озакка сузып, сырт кыздырып ятудан файда чыкмас... Тизрәк бетерик тә... Әле калада күпме эш көтә. Башланган да ташланган, дигәндәй...

— Борчылма... Башланган эш — беткән эш, дигән бабайлар. Алар белми сөйләмәс.

Бер читтәрәк утырган укчы-мәргәннәр осталар сүзенә катышмады. Күрәсең, һәркайсының үз уе бар иде.

Ашчылар табак тутырып ит китерде, казаннан агач җамаякларга шулпа чумырды. Учак янындагы бүрәнәләргә түгәрәк ясап утырдылар. Барысы да тынып калды. Гадәт буенча, дәрәҗә буенча беренче сүзне ил агасы булырдай картлар әйтергә тиеш иде. Әмма өлкәннәрдән берәү дә тел кыймылдатмады, алар гаскәр башы, димәк, аларга да баш итеп тәгаенләнгән Мәмәт би оланның рөхсәтен, аның ишарәсен көттеләр. Кырыс морза нәселе монда да үзенекен итми калмас, аксөяк баласы үзеннән узып эндәшкәнне яратмас дип кыенсыналар иде, күрәсең.

Шәһит шунда гына үзеннән нәрсә көткәнлекләрен аң-

лап алды, ирексездән кызарынып куйды. Уйларына бире леп, йола гадәтен үтәми калган икән ләбаса.

— Алты көн ач булсаң да, ата гадәтен җуйма. Йәгез. аштан олы булып булмас, утырышыйк,— диде ул, ниһаять һәм балтачылар арасында иң өлкән картка туп-туры карап әйтте.— И ага, арабызда хөрмәткә лаек аксакал синдер... Табын башы булып, тәгам җыюны ил-көнгә иминлек, бәхет теләүдән башласаң иде.

Карт оста озак көттермәде, бисмилласын укып, кирәкле сүзләрне вәкарь белән әйтеп, табактагы итне ботарларга кереште.

Шәһит тә тезләрен чәнчеп уртак табын янына чүгәләде. Аның ни кыласын, кемгә нинди мөнәсәбәт күрсәтәсен каш астыннан гына күзәтеп утырган, табыннан аерылып үзенә аерым тәгам китертер дип көткән осталар җиңел сулап куйды: Мәмәт би олан үзен зурга куймый, һаваланмый, гади балтачылар белән дә, укчы-мәргәннәр белән дә тиң күреп сөйләшә, аралаша белә иде. Яшь морзага эчтән генә бәхет-тәүфикъ теләделәр. Тышкы кабыгы гына түгел, егетнең әхлагы-тәртибе дә шактый ук чибәр икән.

Ниһаять, түбә такталарына соңгы кадак кагылды. Җирдән кеше буе чамасы биеклектә чыгып торган борынгы таш нигезгә бурап күтәрелгән манара, биегәйгән саен нечкәреп, ярымайлы очы белән күккә барып тоташты кебек. Һәрхәлдә, астан караганда шулай күренә, тотып тормасаң, баш киемең төшеп китәрлек иде.

Осталар ашыкмый гына җиргә төште, балта, чүкеч, кадак ише нәрсәләр тутырган әрҗәне куеп, өсләренә ябышкан йомычка, пычкы чүбен каккаладылар, сүзсез генә Шәһиттән мактау сүзе көттеләр. Аларның үз эшләреннән канәгатьлеге йөзләренә чыккан иде. Күзәтү манарасы, чыннан да, ныклы, тотрыклы, шуның өстенә матур һәм күрекле дә иде. Шомартылган, шыңгырдап торган сап-сары нарат буралар берсе өстенә берсе шулкадәр төгәл һәм ипле ятты, алар тоташкан урынга кыеклап ябылган түбә такталары шул хәтле килешле иде, Шәһит ирексездән телен шартлатып куйды һәм корылманы бәбәй итәкле күлмәк кигән зифа кызга охшатып, үзалдына елмайды. Әллә нишләп күз алдына Гөлйөзем килде. Әйтерсең, тирә-якка сагыз исе чиста агач исе таратып утырган яңа манара Гөлйөземне сынландыра иде. Елмаюын тыя алмыйча, алан читенә таба атлады һәм еракт ан шактый озак сокланып карап торды.

күңелен рәхәт бер тойгы биләп алды: Сафагәрәй ханның боерыгы вакытында үтәлде.

Осталар аны көтәләр иде. Шәһит биленә аскан күн букчадан бер янчык тәңкә тартып чыгарды һәм авырлыгын чамалагандай учында биетеп алгач, карт остага эндәште:

— Ил агалары! Олуг йомышны авыриксынмый, тиз, кирәгенчә эшли белдегез. Сафагәрәй хан галиҗәнабларының шәхсән рәхмәтенә лаексыз дип беләм,— дип, янчыкны сузды.— Хәләл өлешегезгә карап, тиярәнчә бүлешерсез...

Осталар бер-берсенә карап алды. «Юк! Бу Мәмәт би угланы олыны олы, кечене кече итә белә торган затлардан икән. Аллаһы тәгалә гамәлләрен уң кылсын!» Аларның күзләреннән шундый фикерне укып булыр иде.

Шәһит озак юанмады, бил каешын рәтләп куйды да манарага ашыкты. Баштарак текә баскычтан йөгерә-чаба атласа да, биеклек үзенекен итте, соңгы арааларны үткәндә аяк буыннары шактый йомшаган иде инде.

Иң өстәге мәйданчыкка менде дә тирә-яктагы матурлыктан, тел белән әйтеп, каләм белән язып бетергесез гүзәллектән телсез калды. Әнә, ерак-еракта бормаланып аккан киң Идел, елга аръягындагы куе кара урманнар... Әле тау-тау булып калкып, әле төшеп югалган яшел киңлекләр!.. Шушы мизгелдә Шәһит үзен лачынга охшатып куйды. Алар, әнә ич, болытлар белән ярыша-ярыша зәңгәр күктә тавышсыз гына йөзәләр. Күккә караганда ул үзен дә шул болытларга каршы очкандай, талпынып йөзгәндәй хис итте.

Кулын маңгаена куеп кояш чыгыш ягына борылды һәм яңа матурлыктан тагын йөрәге ашкынды, бөтен барлыгын шатлык, сөенеч хисе биләп алды. Күз күреме ераклыкта нәкъ җеп сузып турылагандай бер сызыкта шундый ук биек манаралар тезелеп киткән иде. Аларның ерактагыларын коралланмаган күз белән аерып та булмый. Ләкин Шәһит белә, алар калкулыктан калкулыкка сикерә-сикерә шулай ил үзәгенә — пайтәхеткә кадәр җитәләр. Боларның ни-нәрсә икәнен кара халык белми. Белмәүләре әйбәт. Дәүләтнең бөтен кешегә таратырга ярамаган үз серләре була. Аларны никадәр азрак даирә белсә, шулкадәр яхшырак.

Шәһит юл букчасыннан ерактан күрсәтүче көпшә алды да күзләренә куеп, манараларны санарга керешә. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау... Хәтта коралланган күз белән дә инде җиденче манараны аеру мөмкин түгел иде. Анысы ерактa, бик ерактa... Казан юлы өстендә. Озакламый аларын да корып бетерерләр, биектәге мәйданчык-

ларга күзәтчеләр менеп утырыр һәм... дәүләтнең ерак чикләрендә ни эшләнеп ятуы көне-сәгате белән хан сараендагы күзәтче бигә мәгълүм булыр. Дөрес, хәбәрләрнең ничек тапшырылуын якынча белсә дә, Шәһит күзәтчеләрнең сәер хәрәкәтләренең мәгънәсен аңламый иде. Аларны башкалардан аерып, яшерен әзерлиләр. Серне чишкән күзәтче — хаин! Аны дар агачы көтә. Мондый куркыныч серне белгәннән белмәгәнең хәерле. Шәһит тагын үзалдына елмаеп куйды. Аның бүген кәефе күтәренке, теләсә нәрсәгә елмаерга, шаярырга, шаяртырга әзер иде. Эш тәмам! Иртәгә алмаш киләсе... Аннан Казанга. Анда барысы да аңлашылыр, хәл ителәр. Гөлйөзем генә үз сүзен әйтсен!.. Шәһит аның уңай җавап бирәсенә өметләнә, ышана иде. Моңарчы Шәһит Мәмәт углы Мәмәт бигә каршы төшүче, кире җавап бирүче юк иде. Төнге маҗара исә бер аңлашылмаучылык кына...

Шунда Шәһитнең язмышын багып карыйсы килеп китте. Кесәсеннән тәңкәнең зуррагын аралап алды да икеләнеп туктап калды. Бер ягына «Котлы булсын яңа пул»* дип язылган, икенче ягына киереп тарттырылган җәягә куелган ук сурәте төшерелгән, әле күптән түгел генә сугылган зур көмеш тәңкә иде ул. Аны әйләндергәләп торды, әгәр тәңкә кирәгенчә төшмәсә дигән уйдан арынырга теләгәндәй, башын чайкап һәм үзенең шикчел адәмгә әйләнә башлавына көлемсерәп, чөеп тә җибәрде. «Тамгалы ягы өскә чыкса — Гөлйөзем риза, язулы ягы белән төшсә — шикләрем рас килер!» Манара түбәсе астында зырылдап әйләнгән акчага карап шуларны уйлап өлгерде. Тәңкә зыңлап килеп төште дә түр почмакка тәгәрәде һәм... бөтенләй көтмәгәнчә, идән ярыгына кысылып, басып калды.

Тәңкә чөюнең уен гына икәнен белсә дә, Шәһит үзе өчен начар фал күрде. Йөзе җыерылды, ирен читләре белән елмаеп куйды. Каһәр суккан бу акча аңа буйсынмыйча, ни әйтергә тели икән соң? Язмышың башкалар ихтыярында, алар хөкеменә буйсынырга мәҗбүрсең димәкчеме?! А-а... юк! Юк инде! Мәргән** буларак Бөек ханга, диванга баш орсам да, мәхәббәттә, көн көрешемдә мин ирекле! Ничек телим, шулай хәл итәрмен дә...

Тик күңелендәге икеләнү, шик барыбер кимемәде. Ул

---

* *Пул* — акча. Казан ханлыгында акчага шундый теләк язу гадәте булган.

** *Мәргән* — гомерен гаскәрилеккә багышлаган кеше. Хәзерге әдәби телдә бу сүз төз атучы, снайпер мәгънәсендә кулланыла.

тәңкәне ярыктан алып тагын чөеп җибәрде. Язмышны, гадәттә, өч тапкыр сынйлар. Көмеш тәңкә чыңлап идәнгә төште, бер урында зырлап әйләнде һәм ничек ятарга белмәгәндәй алпан-тилпән килеп торгач, лапылдап ауды. Ашыгып идәнгә чүгәләгән Шәһит алдында аны үртәгәндәй «Котлы булсын яңа пул» дигән сүзләр ярылып ята иде.

Тәңкә аңа киләчәген әйтергә теләми. Һәрхәлдә, ул теләгәнне күрсәтми иде. Шәһит акчаны кесәсенә яшерде. Өченче тапкыр сынап карау теләге сүрелгән иде инде

Шул чак балта осталары, укчыларның астан карап торулары исенә төште. Гаскәр башының бала-чага шикелле акча чөеп уйнавын алар нәрсәгә юрар?! Битенә куе кызыллык йөгерде һәм ул «Таптың вакытын, хөрмәтле Шәһит би»,— дип, үз-үзен мыскыллый-мыскыллый аска төбәлде. Бәхетенә, андагылар һәркайсы үз эше белән мәшгуль иде.

Осталар манара янәшәсендә к… әреләчәк йортның беренче ниргәләрен салып ята, гаскәриләр исә учак янында... Кайсы кылычын чарлый, кайсысы ат дирбияләрен җайлаштыра. Аланның аргы башында тышаулап җибәрелгән чаптарлар утлап йөри. Гадәти күренештән Шәһитнең күңеле тынычланды, әле яңа гына сабый балаларча шөбһәләнүен онытып, яңадан хыялга бирелде. Озакламый бөтен каралтылар төзелеп бетәр, осталарның кайсысы Казанга, кайсысы үз авылына, каласына юл тотар. Монда исә күзәтчеләр һәм укчылар гына калыр. Җәй буе аларны саклап, айга бер алыштырып торырлар... Кыш көне бөтен тирә-як ап-ак карга күмелер. Адашкан аучылар, төн ягыннан кайтучы сәүдәгәрләр, кирәксә, йортка кереп кунак булыр, хәл җыяр... Табигать йокыга талган кебек, кыш көне дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр сүлпәнләнә, ызгыш-тарткалаш бетә, Казан-йортка тәмгысын сузучылар да кышын юлга чыкмый... Зәһәр кышның үз кануннары...

Шәһит җиргә төшәргә әзерләнде һәм очар кошлар биек легеннән тагын бер кат әйләнә-тирәгә күз салды. Аның бу матурлыктан, хозурлыктан аерыласы килми иде. Әнә, Идел ягыннан, бер-берсе белән узышкандай, каурый болытлар агыла. Каралҗымланып торган калын урманнар өстендә җил уйный, агач башлары талпына...

— Шәһри Казан җиһан гөшә! — дип куйды Шәһит кинәт кенә хискә бирелеп. Аның шушы матурлык, шушы киңлек, хөрлек, соклану, ярату хакында җыр чыгарасы, күкрәк тутырып, дөньяны яңгыратып җырлыйсы килә башлады. Кайчан гына «Тапканнар кара урман уртасына саклаубаш куярга?! Кайсы зирәгенең башы җиткән»,— дип эчтән сук-

ранганы исенә төште. Юк! Манара нәкъ кирәк җирдә икән. Әнә ич, Иделе дә, сәүдә кәрваннары салган олы юл да, төн ягына илтүче сукмаклар да аерымачык күренеп тора. Манараны исә куе ябалдашлар томалый, аны чит-ятлар күзеннән яшереп тора. Әйе, барысы да уйланган, җиренә җиткереп әзерләнгән иде.

Кинәт аның игътибарын бер көтү саескан җәлеп итте. Кошлар, әйтерсең, кемнедер озатып килә, каен башлары өстендә чыркылдашып агачтан агачка куналар. Әнә, астарак куак ботаклары да селкенде түгелме? Озак та үтми Идел ягыннан бормаланып-бормаланып сузылган тар юлда аркасына биштәр аскан сыңар җәяүле күренде. Көпшәсен күзләренә куеп карады: үзе белән бер яшьләр чамасы егет. Юллардан, авыллардан читтәге урманда нишләп йөри бу? Нинди максат, нинди кайгы, ни йомыш куа бу мәхлукны?! Әллә бер-бер яшерен мәсләген үтәп йөрүче шымчы-фәләнме?

Шәһит баскычка ташланды.

— Тукта! Кем килә?

Ике яктагы ике куак артыннан каршына чыгып баскан коралллы кешеләрне күреп, юлаучы егет бер генә мизгелгә каушап калды, әмма артка чигенмәде.

Сакчылар сөңгеләрен аның күкрәгенә төбәп сорауны кабатлады:

— Син кем? Кайдан киләсең, кая юл тотасың?

Коралллыларның шаяртмавын төшенде булса кирәк, егетнең йөзеннән елмаю качты, кулын күкрәгенә куеп баш иде:

— Мин Казанга юл тотучы мөсафирмын... Сезгә балыкчы карттан сәлам алып килдем,— диде.

Таныш исемне ишеткән сакчылар сөңгеләрен төшерсәләр дә, ышанып җитмәделәр булса кирәк, тагын сорау бирделәр:

— Нишләп үзе килмәде? Аны каян беләсең?

Юлаучы җиңел сулап куйды һәм ашыгып тезәргә керешге:

— А-а... сөйләргә озак аны... Ул мине үлемнән коткарды... Идел төбеннән тартып чыгарды...

Сакчылар бер-берсенә карашып алдылар һәм кул ишарәсе белән егетне туктатып, алан уртасына, Шәһит би янына әйдәделәр.

Киң аланга, тирә-яктагы кешеләргә күз йөгертеп өлгергән Санька (юлаучы дигәнебез нәкъ ул иде) инде күптән мондагыларның башлыгын тәгаенләп алган иде. Өс-

башы, затлы кораллары белән дә, кыяфәтендәге бәйсезлек, буй-сынындагы төзлек белән дә иптәшләреннән аерылып торган яшь егет аңа беренче күрүдә үк кай ягы беләндер ошады, аның үзенә зыян салмасына ышанды. Мондый ачык карашлы, бәйсез кешеләр, гадәттә, үчле булмый, кирәксез золымга бармый.

Аркасындагы биштәрне ычкындырды да егет каршына куйды, иелеп баш иде, кулын күкрәгенә куеп, тагын сакчыларга әйткәнне кабатлады:

— И мөхтәрәм гаскәрбашы... Сезләргә балыкчы карттан сәлам күндерәм, аның әманәтен тапшырам,— диде.— Мин сезнең хөкемегездәмен. Әмерегезне көтәм,— дип тә өстәде.

— Сәламеңне кабул кылдык, кем... мөсафир! Күчтәнәчең өчен рәхмәтен алла кабул кылсын. Үзең кемсең, кая барасың? Олы юллардан читтә, адәм аягы басмаган якларга нинди җилләр ташлады? — дип сорады яшь морза аны баштанаяк күздән кичереп.

Кием-салымына карап фикер йөрткәндә дөньяның бер фәкыйре тоелса да, Шәһит юлаучының йөзендә, сүз сөрешендә аксөякләргә хас чалымнар тоеп алды. Хәер, теткәләнеп беткән өс-башы да кайчандыр шактый затлы, кыйммәтле малдан тегелгәнлеген кычкырып тора иде. Ул сөальләренә җавап көтеп егетнең күзләренә туп-туры карады: аларда яшерену-посу, икейөзлелек күренмиме? Әмма җете куе төстәге зәңгәр күзләрдә ул яшьләрчә турылык һәм гади кызыксынудан, дусларча елмаюдан башканы тапмады кебек. «Хәерле булсын! Бу да алла бәндәсе. Башына төшмәсә, ул да киндер капчык асып ялгызы юлга чыкмас иде»,— дип уйлап куйды.

Мөсафир ашыкмый гына сөйли башлады:

— Сөйләсәң бик озакка китәр, хөрмәтле гаскәрбашы... Үзем мин Казан ярминкәсенә килгән бер урыс сәүдәгәренең улы идем... Иделдә батып үлгән идем... Күрәсең, җыясы ризыкларым бетмәгәндер, караңгы чоңгылдан мине балыкчы карт тартып чыгарды, ул миңа яңадан җан өрде. Инде теләгем кире Казанга кайту. Бәлки, мәрхәмәт күрсәтеп, мине дә юл уңаеннан үзегез белән алмассызмы дип өмет итәм... Миңа Казанга кайтырга кирәк! Бик кирәк!..

Аның җавабыннан Шәһит тулаем разый калды, әмма сизенде: бу егет беренче карашка садә күренсә дә, артык беркатлы түгел, нәрсәнедер әйтеп бетерми, йөрәгендә ниндидер сере, беренче очраган кешегә үк тотып селкергә ярамаган ниндидер яшерен уе бар кебек иде. Шулай да

шикләнгәнен йөзенә чыгармаска тырышты, тагын сорау бирде:

— Атыңны кем дип белик?

— Исемем Александр. Сәүдәгәрләр токымыннан...

— Анысын ишеттек,— дип бүлдерде Шәһит.— Казанда ни йомышың бар? Нинди кайгы сине янә пайтәхеткә куа? Югалткан малыңны эзлисеңме, аерылган юлдашларыңнымы?

Юлаучының керфекләре сизелер-сизелмәс дерелдәп куйды, битенә балаларча алсулык йөгерде.

— Юк, хөрмәтле гаскәрбашы, мине мал кайгысы йөртми, җан газабы куа,— диде ул, ниһаять, үзе өчен нәрсәнедер хәл иткәндәй кискенлек белән.— Казанда минем мәгъшукам, сөйгән ярым калды. Аның янына ашыгам, аны күрергә тилмерәм...

Шәһит эчтән генә көлемсерәп куйды. Ләйләсен эзләгән Мәҗнүн шикелле каршылыкларны, киртәләрне үтеп һаман сөйгәне янына ашкынуын хуплап баш селкеде, ирексездән үзен аның белән чагыштырып карады. Хөрмәткә, ихтирамга лаек егет икән бит бу. Теле исә башканы әйтте:

— Сөйләгәнеңне хуп күрдек! Осталар янында чатырда урын табылыр. Кыенсынмасаң, башыңнан кичкәннәрне әле бәян итәрсең, мәрхәмәтле тыңлаучың булырбыз,— диде. Аның мәхәббәт кыйссасы ишетәсе, егетнең ничек шушы хәлләргә төшүен беләсе килеп китте.

Әмма сүзне дәвам иттерә алмадылар. Казан ягындагы сукмакта ат тояклары дөпелдәде, сакчылар бердән ук-җаягә тотынды, өч-дүрт мәргән тышауланган атлар янына йөгерде. Шәһит морза да тәхеттәгечә җайлап утырган бүкәненнән сикереп торды һәм ашыгып сукмак ягына китеп барды. Аланда тынлык урнашты.

Күп тә үтмәде, агачлар арасыннан томырылып ялгыз җайдак килеп керде, тезгенен кинәт тартып атны арт аякларына чүктерде һәм Шәһит каршына атасының йомышчысы сикереп төште. Гелән-гелән асылзадәләр арасында буталып, бәкләр, морзалар итагатенең йола-гадәтләрен үзләштереп бетергән чая егет бөтен шартын китереп сәлам бирде:

— Олуг морзадан кечек морзага ашыгыч хат китердем, кабул кылып алсаңчы, Шәһит би,— дип аланны яңгыратты.

Аның кыланышында атасының гадәтләрен таныды Шәһит һәм, ирексездән, көлеп җибәрде. Бары тик аның атасы гына әнә шулай теләсә кая бәреп кереп үзенекен ярып салырга мөмкин. Баһадир гәүдәле әтисе тыштан аюдай ту-

пас күренсә дә, нечкә, саф күңелле кеше, ул сабый баладай куана, шатлана белә, читләр кайгысын үзенекедәй авыр кичерә, ярдәм кулын сузарга тырыша. Ә инде ачуы чыкса, аннан мәрхәмәт көтмә. Аяк атлаган саен җир тетрәп калгандай булыр, тынычланганчы үзенә урын таба алмый бәргәләнер. Шундый кеше ул!

Әтисен искә төшереп Шәһит үзе дә шундый ук көр тавыш белән кычкырып җавап бирде:

— Булдыргансың, рәхмәт сиңа, углан! Хатыңны бир дә ял ит. Әй, ашчылар! Мәмәт би йомышчысына тәгам китерегез!..

Үзе исә бераз читкәрәк китеп көпшәләп төрелгән кәгазьнең башындагы мөһерне ватты да таныш кулдан язылган йөгерек юлларга текәлде. Шулкадәр ашыгырлык нәрсә бар икән! Борчакны артык тиз куырырга яратучы әтисе тагын нинди шөгыль, нинди йомыш уйлап тапкан?!

«Алмаш килүгә күзеңне дүрт итеп Казанга чабасыңны беләм мин.— Беренче юллардан ук әтисен таныды Шәһит. Менә шулай кереш сүзсез-нисез бары тик ул гына яза ала.— Карт атаңны санга сукмаска чамалыйсың. Ашыкма! Әле минем йодрыгым нык, көчем җитәрлек, сине генә бөгәр чамам бар... Әмерем шундый: хатны алуга туры өйгә, Казандагысына түгел, төп утарга — Мәмәт би утарына чабасың. Җир ярылса да, күк ишелсә дә кайтасың. Сүзем шул. Шунсыз миннән мәрхәмәт көтмә».

Хатның ахырында, күрәсең, миһербаны уянган, ваграк хәрефләр белән өстәп куйган иде: «Күптин күп, чуктин чук сәламнәр күндереп, әтиең Мәмәт Сәүбан углы Мәмәт би».

Тизрәк кайтырга кирәклеген аңласа да, Шәһит хаттан моның сәбәбен сиздерүче бүтән бернәрсә дә таба алмады. Бу исә аның корган уй-фикерләрен, тизрәк Казанга элэгү өметен челпәрәмә китерә иде. Дуамал чагына юлыксаң, үзсүзле Мәмәт бидән тиз генә котылырмын димә... Укчылар арасында теленә салынган йомышчыны дәште.

— Дөресен әйт әле, утарда ни бар? Бер-бер хәл сизмәдеңме? Әти нигә шулай ут өерттереп чакыра икән?!

Йомышчының күзләре генә елтырады. Кирәкмәс чакта теленә шайтан төкергәндәй кыланучы үткен егет иңсәләрен җыерды. Карт морзаның аны ни өчен шулкадәр якын итүен, үз күрүен хәзер генә аңлап алды Шәһит. Моннан кирәкмәс сүзне келәшчә белән каерып та ала алмассың.

Шулай да, яшь морзаның гозерен аяк астына салмады, аз гына җеп очын чыгарды йомышчы:

— Тәгәл белмим,— диде.— Якыннары белән Дәүран би килеп төште. Сиңа йомышлары бардырмы...

Аның хәйләкәр кысылган күзләреннән аңлады Шәһит, белә, белә бу таш ярып чыккан углан. Әмма әйтми. Әйтмәячәк тә... Атасының холкын үзләштергән йомышчы кирәк чакта тимер йозакка әйләнә белә иде шул.

Кич буе баш ватты Шәһит, әмма борчылырлык сәбәп күрмәде. Мөгаен, атасы мәмләкәтнең көньяк вилаятеннән — Нугай дәругасыннан килгән дусты Дәүран би хөрмәтенә мәҗлес җыя. Кайтып күренмичә ярамас. Карт морза мондый мәсьәләләрдә бик чәүчәләк, нәзбереклек саклый һәм йола бозуны һич кенә дә күтәрә алмый.

* * *

Атларны тыймадылар. Алмаш соңлабрак килгәнлектән, төш алдыннан гына юлга чыккан гаскәр төркеме һич югы ястү алдыннан Мәмәт би утарына җитәргә чамалый иде. Шәһит шулай хәл итте. Үзе шикелле үк яшь мәргәннәрне аерып Казанга җибәрүне яхшысынмады, барысын да атасы утарына чакырды. Иш янына куш сыя дигәндәй, табын янында ун-унбиш егеткә генә урын табылыр... Аш-суны мулдан әзерлиләр Мәмәт би утарында. Икенче ягын да күздә тотты Шәһит: чиру хәтле дус-ишләре белән кайтып төшсә, Казанга чыгып китү дә җиңелрәк булыр сыман иде. Һәрхәлдә, хан хезмәтендәге угылга ата кеше артык таләпчәнлек күрсәтмәс, йола кушканны үтәүгә үз иркендә калдырыр...

Чаптырып барган ат өстендә киңәеп сөйләшү, гәпләшү мөмкин түгел иде. Барысы да үз уйларына бирелде. Сәүдәгәр углы, мәгъшукасын юллап килүче Александрны берничә мәртәбә исенә төшерсә дә, Шәһит аның кыйссасын тыңларга вакыт таба алмады. Үз хәле хәл иде.

Санька исә мажарасын төпченмәүләренә, йөрәгендә сулкылдаган ачык ярага кагылмауларына, сорау биреп бимазаламауларына шат. Ышанып юлга алдылармы, алдылар; ашкынган, канатланып очардай Казаныңа якынаясыңмы — якынаясың! Тагын ни кирәк?! Дөрес, аның үзенең дә гаскәр башы, кай ягы беләндер йогышлы, мәхәббәтле Шәһит би белән сөйләшәсе, аның янәшәсендә буласы килеп куя. Ләкин бу аның ихтыярында түгел. Син — аның мәрхәмәтенә мохтаҗ юлдаш, ирексездән килеп эләккән бер сукбай. Башкасына өмет итмә! Хәер... аның кирәге дә юктыр... Ка-

занда Санькаңы әле чишеп бетергесез яңа мажаралар, ерып чыккысыз башка мәшәкатьләр көтәдер... Кем белә? Барысы да алла кулында, бернәрсә дә анык кына билгеле түгел. Һәрхәлдә шуны ачык тоя: теләгәненә, алдына куйган олуг максудына ирешми торып Санька Казаннан кит мәячәк. Юл бер генә — йә җиңәсең, йә бетәсең... Ә бетәсе, олы юлда тузан булып каласы килми. Димәк, эзләргә, табарга, көрәшергә һәм җиңәргә кирәк!

Кинәт Шәһит бинең ак чаптары тирә-якны яңгыратып кешнәп җибәрде. Туып-үскән ихата якынлыгын тойган айгырның: «Уяныгыз, кайтып җитәбез»,— сөрән салуы иде бу. Бертуктаусыз чаптырудан арыган һәм адымнарны акрынайтуга изри башлаган укчыларның бердән йокысы качты. Алда уйнаклаган атның җанлануы башка чапкырларга да тәэсир итте, иярләренең тезген кагуын да көтмәстән, җай гына юыртырга керештеләр.

Урман авызыннан чыккан атлылар тау астындагы иңкүлектә җәйрәп яткан зур утарны, аннан арырак сибелгән эреле-ваклы йортларны күреп бер мизгелгә туктап калдылар. Кайберләренең Мәмәт би утарын әле беренче күрүе иде һәм алар сокликуларын яшерә алмадылар, баш чайкап, тел шартлатып куйдылар.

Мәмәт би утары, чыннан да, бик матур җирдә иде. Ике яклап тау кочагына сыенган иңкүлек дигәнебез тигез дала булып офыкка кадәр сузыла, анда исә күгелҗемләнеп торучы куе урманнарга тоташа. Күз күреме иңләгән һәр якта иген басулары, куе, сусыл үләнле болынлыклар, Алып батыр сибеп калдырган көзге кыйпылчыкларыдай ялтырап ятучы күлләр... Болар күңелдә иркенлек, киңлек тойгысы, шушы матурлыкны колачлау теләге уяталар иде.

Би утары иңкүлекнең кап уртасында, яшел диңгез эчендәге утрау шикелле калкып тора. Калын бүрәнәләрдән биек койма аңа кирмән төсе бирә; ихата эчендәге олуг таш йорт, аның тирәсендә, шулай ук бизәкләп салынган башка өйләр, биек манаралы мәчет, ныклы каралты-кура — Мәмәт бинең дөнья көтү тәмен белеп яшәүчеләрдән икәнлеген күрсәтә иде. Шуның өстенә, бу кечкенә кирмәнчек һәрьяклап тирән, киң ур белән чолгап алынган, ур үзе күлгә тоташып, су белән тутырылган иде. Биек һәм калын капка алдында урны артык киң булмаган агач күпер сикереп үтә һәм ул, гадәттә, төннәрен икегә аерылып, капкага таба күтәртеп куела иде.

Шәһит тезгенен бушатты. Шуны гына көтеп торган ай-

гыр сөзәк юлдан аска ыргылды, башка җайдаклар һайһулап аңа иярде.

Капкадан керүгә Шәһитнең күзенә ташланганы — ихатадагы атлар, затлы арбаларның күплеге булды. Атасы, күрәсең, олыдан кубарылып нидер майтарып ята.

Тау башындагы атлыларны инде күптән шәйләп өлгергән хезмәтчеләр, кол-чуралар, кыз-кыркын ишегалдына сибелде. Кемдер атларның тезгененә ябышты, кемдер Шәһитнең кулыннан букчасын, кылыч-калканын алырга әзерләнде. Кыскасы, яшь морза кайткач була торган гадәти ыгы-зыгы башланды.

Шәһит аттан сикереп төште дә: «Төкле аягың белән, Шәһит би! Аман гына йөреп кайттыңмы? Көтәбез, Мәмәт углан, күптән көтәбез»,— дип сөйләнүче хезмәтчеләргә игътибар итмәстән, юл тузанын да кагып тормыйча өйгә атлады. Бер-ике адым атларга өлгермәде, борылып әмер бирде:

— Дусларымны карагыз! Урнаштырыгыз! Аларны минем кебек үк кабул күрегез,— диде һәм, арадан өлкәнрәген чакырып, колагына пышылдады.— Арабызда урыс углан Александр бардыр. Юньрәк кием хәстәрләрсең... Атам каршында оятка калырлык булмасын!..

Кунак бүлмәсендә кеше күп түгел. Күрәсең, төшке аштан соң хатын-кыз таифәсе таянып алырга иткән. Тынгысыз атасы янында Дәүран бидән кала Шәһиткә таныш түгел, киемнәренә караганда, аксөяк зат булырга тиешле тагын өчме-дүртме ир-ат утыра иде. Алар кызып-кызып нәрсә хакындадыр бәхәсләшәләр идеме, мәзәк сөйлиләр идеме, һәрхәлдә, этисенең гөбедән чыккандай калын тавышы барсыныкын да күмеп, каплап китә иде. Ишек тавышына ярты сүздә бүленделәр. Кунакларның уңайсыз тынлыкка чумуыннан Шәһит сиземләде, сүз аның турында барган! Шулай булмаса, тып итеп килеп кергән Шәһиткә игътибар итүче дә, борылып караучы да булмас иде.

Мәмәт би табындашларына күз йөртеп алды да, тавышын бөереннән чыгарып, улына ымлады:

— Бердәнбер варисым, дәвамчым Шәһит Мәмәт углы Мәмәт би булыр,— диде.

Аның бу ымында горурлык та, аз гына масаю һәм мактанырга теләү дә бар иде шикелле. Янәсе, күрегез, нинди баһадир улым бар!

Шушыларны тоемлап өлгергән Шәһит үртәлде, атасының масаюыннан оялды, әмма моны кунаклар алдында сиздерергә ярамый иде, горурлыгын җиңеп, барысына берьюлы сәлам бирде:

— Исән-аман килеп җиттегезме, ил агалары! Юл авыр булмадымы? Йорт-җирегез, гаиләгез, бала-чагаларыгыз иминме? Ил-көн тынычмы?

— Шөкер, аллага шөкер, олан! Дөньяларыбыз имин, ил-көн тыныч,— диештеләр кунаклар беравыздан. Күзләре исә Шәһитне капшый иде әле.

Угланның үзләрен олылап «ил агалары» дип эндәшүе, борынгы йолача тутырып исәнләшүе аларның күңеленә хуш килде, бер-берсенә карап елмаештылар, баш селкеделәр. Бары тик шуннан соң гына Шәһит атасына эндәште:

— Хатыңны алдым, и газиз атам. Кичер, юл киеменнән катыңа бәреп керергә ашыгыч чакыруың сәбәп булды. Әмереңне көтәм...

Мәмәт би кул гына селтәде. Берни дә булмагандай гади генә әйтте:

— Бар! Әзерлән! Ярты сәгатьтән бөркетләреңне күрсәтерсең! — Табындашларыннан сорады.— Шәһит угланның мәргәннәрен карыйбызмы? Сыныйбызмы?

Аңа, күрәсең, Шәһитнең иптәшләре белән кайтуын хәбәр итеп өлгергәннәр иде инде.

Ярты гомерен иярдә үткәргән Дәүран би һәм башка кунаклар канәгать елмаешты:

— Мондый бөркетләрне дә карамасаң... Карыйк, багыйк, сыныйк. Казан-йорт язмышын шулар кулына бирәсе... Кылычлары үткенме, сыннары төзме, бәдәннәре ныкмы, гайрәтләре җитәрлекме?!

Ишегалдында мәргәннәр тезелде. Аларның байтагы Мәмәт би утарында Шәһит белән бергә аунап, тирә-яктагы урман-болыннарны бергә айкап үскән егетләр иде. Калганнары исә төркемгә Казанда гына кушылды һәм алар кыюлыгы, гайрәте бөтен дәүләткә танылган карт морза каршына басуларына горурлык хисләре кичерде. «Ясавыл булырга хыялланмаган мәргән — мәргән түгел». Карт морзаның канатлы сүзләре һәммәсенә дә мәгълүм иде.

Мәмәт би, аның артыннан Дәүран би, алардан бераз калышып башка кунаклар саф алдыннан үтте. Атасы риза калды, күрәсең, тамак кыргалап куйды, әмма сүз әйтмәде. Юлдан соң юынган, чистарынган, кием-салымнарын тәртипкә китереп баскан егетләр, чыннан да, матур иде, көч-гайрәтләре сизелеп тора иде. Аларның сөңге очларында кояш чагылды, калканнары бер-берсенә бәрелеп зыңгылдады.

Шулчак карт морза гаскәриләрдән бер адым читкәрәк

баскан мөсафир егетне күреп алды. Кхы, кхы, дип ютәлләгән сыман итте, китә башлаган җиреннән кинәт әйләнеп килде, нәрсәнедер хәтерләргә теләгәндәй, ят егетне күзләре бораулады. Кунаклар белән гәпләшкән арада да Мәмәт би мөсафирга карап-карап ала иде әле.

Шәһит чит-ят егеткә аерым игътибарны сизде, әмма аның кем икәнлеген аңлатырга җае чыкмый калды. Өсбашын хезмәтче биргән киемнәргә алыштырып өлгергән мөсафирны мәргән дип уйлады, коралсызлыгына гаҗәпләнде, күрәсең, дип үзенчә нәтиҗә чыгарды Шәһит.

— Мәргән егетләр! Төз атуда көч сынашасы килгәннәр бире килсен! Җиңүчегә көмеш саплы булат хәнҗәр,— дип кычкырды морзалардан берсе.

Сафлардан таралган егетләр ук-җәяләрен тотып ашыгаашыга аның янына җыелдылар.

Мәмәт би Шәһитне үз янына чакырып алды.

— Менә инде синең белән сөйләшер чак та җитте,— диде ул улына сынап карагандай текәлеп.— Әйдә, йортка, бүлмәгә узыйк.— Олуг сүз бар сиңа, улым...

Атасы сүзне еракан башлады.

Киң җиңле озын хөлләсенең изүен ычкындырып җибәрде дә тәхет хезмәтен үтәгән аркалы урындыкка утырып, Шәһиткә янындагы тәбәнәк урынга күрсәтте.

— Утыр! Сүз күп булыр. Аяк өстендә сөйләшә торган түгел.

Шәһит шомлы хәбәр ишетергә әзерләнде, башыннан берьюлы әллә ничә гөман йөгереп узды: «Дәуран бигә дала баскыннары яу чапканмы? Аңа ярдәм кирәкме? Әллә юкса, атасы бер-бер яры чирү җибәрмәкчеме? Әллә соң ерак илләргә сәяхәткә юлламакчымы? Мәргәнлектән алып, ерак гарәп илләренә хаҗга чыгарырга җыенамы?» Кәефе кырылган, җаны бәргәләнгән чакларда әтисе еш кына «Хаҗ кылырга иде! Зәмзәм сулары белән юынып, изге җирләрдә дөньялык гөнаһларыннан ваз кичәр вакыт җитте»,— дип сөйләнергә ярата. Аннан монысын да көтәргә мөмкин. Шәригать кануннары үзең өчен кем дә булса башканы җибәрү ихтималын кире какмый. Әмма Шәһитнең Казаннан беркая да китәсе килми иде һәм ул атасына да катгыян шуны белдерергә җыенды.

— Без җылкы ыруы, борынгы, бик борынгы нәсел,— дип тамак кырып, горурлангандай әйтеп куйды Мәмәт би.— Ерак бабаларың дошманга тез чүкмәде, авызы тулы кан булса да, дошманы каршында төкермәде. Якыннарына

мәрхәмәтле, игелекле булды, ярлыларны, хәерче-саилчеләрне, гарип-горабаны рәнҗетмәде, авызыннан өзеп, мохтаҗларга өлеш чыгарып яшәде. Нәфесен сузган җаһил адәмнәрнең кулын кыскарта белде, кешенекен алмаган кебек, үзенекен чит-ятларга талатмады... Менә шул, улым! Боларын беләсең булыр...

Шәһит сүзсез генә башын иде. Кереш сүзнең тизрәк бетүен, атасының сузмый-тартмый төп мәсьәләгә күчүен көтә иде ул. Тик бу хакта кычкырып әйтергә теле бармады, түземен, сабырын җыеп тыңларга әзерләнде. Ишетәчәген ишетеп бетермичә, атасының ихтыярын белмичә, газиз әнкәсен күрмичә һәм фатихасын алмыйча ул барыбер утардан чыгып китә алмаячак. Һәр сәгатен, мизгелен бөртекләп санаган вакыт дигәнең аңа буйсынмый иде шул. Атасы исә сузачак, тартачак ул вакыт дигән нәрсәне!

Мәмәт би Шәһитнең кыбырсынганын әллә күрде, әллә күрмәмешкә салышты, башлагандагы вәкарен саклап, ашыкмыйча гына сөйли бирде:

— Болары белән син мактанырга хаклы.— Һәм кинәт, тавышын күтәрә төшеп, кычкырып сорады.— Ә син үзең шул нәсел мактанычын ишәйтү, көчәйтү өчен нәрсә эшләдең? Бармы бер-бер кылган гамәлең? Беләм!.. Әле син яшь, күрәчәгең дә, кылачагың да алда... Алла боерса, изге Казан-йортта Мәмәтләр исеменә тап төшермичә, пычратмыйча көн күрерсең дип ышанам.

Бик азга гына бүлмәдә тынлык урнашты. Шәһит хәтта тышта очынып-очынып сайраучы тургай тавышларын да ишеткән кебек булды, ук атуда көч сынашучы яшьтәшләренең күңелле шау-шуы колагына килеп керде.

— Шулай, улым,— диде Мәмәт би уч төбе белән урындык тоткасына суккалап.— Без сине шул юлга кертергә карар кылдык. Шөкер! Инде балигъ егетсең. Киләчәгең, нәсел-нәсәбең хакында уйланыр вакыт җитте. Кыскасы, улым, без сине иҗабы кабул кылырга... ягъни, ярәштерергә чакырдык.

Шәһитнең йөзе бер агарды, бер кызарды, күз алдын әллә нинди кара пәрдә томалап алды.

— Мин... мин... әле өйләнергә... теләмим,— диде ул, ниһаять, теленә беренче килгән сүзләрне әүшәләп.— Мин үзем... Мин... ни...

— Әйе, син... син үзең өйләнәчәксең,— дип бүлдерде карт морза.— Синең өчен мин өйләнә алмыйм лабаса!

Шушы мизгелдә язмышы хәл ителәчәгенең бөтен кат-

гыйлыгын, билгесезлек дәһшәтен аңлап алган Шәһит кыюлыгын, батырлыгын җыеп әйтте дә салды:

— Минем сөйгәнем бар, үз дигәнем, үзем тапкан ярым бар,— диде.

Бу юлы инде Мәмәт бинең йөзе караңгыланды.

— Бардыр, ышанам! Әмма безнең чигенер юлыбыз юк,— диде ул авыр сулап. Әйтерсең аның үзен көчләп өйләндерергә җыеналар иде.

Кызыксынуы җиңде булса кирәк, бераз тынлыктан соң, күзендә җылылык чаткысы кабынды, төз гәүдәсен алга ия төшеп, пышылдап эндәште:

— Анысы кем инде, сер булмаса? Кемне таптың икән?! Нинди нәселдән? Нинди ырудан ул синең башыңны әйләндергән гүзәл җан иясе?

— Ул... ул... алтынчылар... зәргәрләр нәселеннән. Мин... аның белән сүз куештым... Вәгъдәләштек инде... Казандагы иң маһир зәргәр Галиәкбар оста кызы,— диде Шәһит. Шушы сүзләре белән ул атасының күңелен йомшартырмын, морза вәгъдәсенең кадерен белгән аксөяк үз улының ант бозуына юл куймас дип өметләнә иде.

— Ыһы, ыһы,— дип куйды атасы.— Беләм, беләм ул нәселне. Безнең кадәр үк булмаса да... тирәннән, ерактан килүче ырудан. Казаяклар алар... Казаяк ыруыннан.

Шәһитнең эченә җылы йөгерде, һәр сүзен йотардай булып атасына текәлде.

Карт морза башын чайкап куйды һәм кулындагы тамгалы йөзекне әйләндергәләп утыргач, кистереп әйтте:

— Юк, улым! Тамырларыңда аксөякләр каны ага. Син бары тик аксөякләргә генә өйләнә аласың!..

Шәһит үзен тыя алмады, ярсып, үртәлеп кычкырып җибәрүен сизми дә калды.

— Алайса мин гомеремдә дә өйләнмим. Миңа кирәкми! Берни дә кирәкми. Өйләнмим.

Мәмәт би сүзеннән кире кайта торган кеше түгел иде. Ул углының тынычланганын үзенә хас булмаган сабырлык белән көтеп торды.

— Сабыр! Сабыр, улым! Без — җылкы, ягъни ат. Сөйгәнең исә — казаяк ыруыннан, ягъни кош нәселеннән. Аларның тамгасы — каз. Әйе, ат казның матурлыгына, җиңеллегенә, зифалыгына сокланыр... Үзенең дә шулай җиңел талпынасы, зәңгәр күкләрдә болытлар белән ярыша-ярыша очасы килер... Әмма ат казга өйләнә аламы? Уйла, улым! Мин йодрык төеп тә тыя алган булыр идем... Иллә үзеңнең аңлавыңны, гади зәргәр — һөнәрче кызының аксөяк,

асылзат, мәргән нәселенә тиң түгеллеген төшенүеңне телим. Бел, аксөяк югарырак булган саен бу мәсьәләдә тагын да югарырак очарга тиеш. Чөнки син үзен түгел, нәселең өчен уйларга, аның киләчәге хакында фикер йөртергә тиеш! Һәр адымың шулай! Һәр гамәлең күз алдында. Бүген каралар белән туганлашкан адәм иртәгә биләр арасында бер башка түбән төште дигән сүз. Хаким затлар сугыш башлый, меңнәрне яуга куа ала, кол-чураларның язмышы аның кулында... Аның бер авырлыгы бар — хаким зат үзе теләгәнгә өйләнә, үзе күзләгәнгә кияүгә чыга алмый. Әдәп, әхлак бар. Безнең үз кануннарыбыз. Тамырында Алмыш хан* якыннарының каны аккан затның ул канны сыекларга хакы юк! Аңладыңмы?

Аның маңгае җыерылды, йөзе кырысланды, мыек чылгыен шактый озак бөтереп утырды. Ниһаять, авыр сулап куйды һәм улын ныграк ышандыру өчен, икеләнгәнен, күңелендә булса да, чыгарып түгәргә ашыкмаган фикерләрен әйтергә кирәк тапты:

— Шәригать кушканча ярәштерәбез. Дәүран би җылкы ыруының иң затлы, бай адәмнәреннән... Кызын бер кашык су белән йотарлык диләр. Ике көчле тармак кушылганнан без дә, алар да отар...— Ул тамак кырып алды да улына каш астыннан карап әйтеп бетерде.— Каләме шәриф икене, өчне, хәтта дүртне алуны да фарыз саный. Аннан соң үзең карарсың... Күз күрер... Ләкин, кабатлап әйтәм, беренчесе Дәүран би кызы булыр. Асылзат булыр! Сүзем шул! Бүтән әйтмәм. Кабат сорама да, уйлама да!..

Нинди генә гаярь, үткен, чая булмасын, шәҗәрә намусын күз карасыдай саклап яшәгән гаиләдә тәрбия алган егет ул кануннарга буйсынырга кирәклеген, моның мәҗбүрилеген төшенә иде. Тик, барлы-юклы ике дистә елга да тулмаган гомерендә аның теләгенә ирешми калганы булмады. Асыл егетнең, бердән, бүтән көндәше, тиңдәше юк; икенчедән, атасы хакына күпләр аның сүзен аяк астына салмауны хәерлерәк күрә; өченчедән, кызларныкыдай озын керфекле, янып торган кара күзле, мәнле егет ирләрчә чибәрлеге белән дә йомышы төшкәннәрне әсир итә, тәвәккәллеге белән буйсындыра иде.

Пайтәхеттә вә һәм дә мәмләкәтнең башка шәһәр-калаларында яшәүче, биләмәләреннән чыкмыйча көн күрүче биләр, морзалар тормышыннан да мәгълүматлы Шәһит

---

* *Алмыш хан* — Борынгы Болгар ханы. Ислам динен кабул итүче.

моның шулай икәнлеген белә, күреп тора иде. Әмма егетлеген югалтмаган, дөньяда үз тиңең, бәхетең, мәхәббәтең бүленмәс һәм бердәнбер дип күз алдына китергән егет этисе белән килешә алмады, ачуына буылды:

— Мин... Мин нәсел айгыры түгел...

Мәмәт морза сынын тота алмыйча бөгелеп төште, кысынкы күз кабаклары арасыннан сытылып яшь бөртекләре чыкты. Ак сөлге белән битен, күзләрен сөртә-сөртә тагын нидер әйтергә теләгән иде дә, көлүен тыя алмыйча кул селтәде. Ниһаять, басыла төште, урындыкка кырын ятып. ңа гына күргәндәй, Шәһиткә тагын бер кат текәлеп карады да сер сорагандай пышылдап эндәште:

— Бәгъзе угыллар корсак асларына йон үсмәс борын кыз-кыркынның итәк астына борын төртә... Ә син... син... башлы-күзле итәм дигәндә... Хафага салма.— Кинәт ул җитдиләнеп китте.— Яшерми әйт, углым, әллә хатын-кыз таифәсенең исен сизмисеңме? Борының ис сизмиме әллә диюем...

Шәһитнең бите бер агарды, бер кызарды. Этисеннән мондый сүзне, ачыктан-ачык ирләрчә сөйләшүне көтмәгән иде. Гарьләнергә дә, үртәлергә дә белмәде, сүз таба алмый интекте. Ниһаять, этисенең үртәлерлек нәрсә әйтмәвен аңлар дәрәҗәгә җитте, нигә хафалануын төшенде, тотлыга-тотлыга җавап бирде:

— Аны... анысын мин... мин үзем беләм, эти. Булачак җефетемне мин үзем табарга, үзем сайларга телим... Аңа гына хакым бардыр ич...

Әле генә көлүеннән буылган Мәмәт бинең йөзендәге хушлык кискен кырыслык белән алышынды.

— Мин әйттем! Нәселебез канунын боза алмыйсың! Әйе, әлегә синең хакың юк! Кемне димлибез, шуны аласың. Алачаксың! — Ул йодрыгын өстәлгә куйды һәм кинәт йомшап, килешкәнсыман тагын дәвам итте.— Әнә, мин үлгәч карарсың... Анда барысы да синең кулда буласы

Шәһит эндәшмәде. Гөлйөземнең арбада бәргәләнүе күз алдына килде, җылы сулышы колагына килеп бәрелгәндәй булды, бәдәненә тиеп киткән кайнар тәненнән әллә нинди аңлаешсыз бер рәхәтлек саркыганын янә тойгандай хис итте.

Мәмәт би исә сөйләде дә сөйләде.

— Шигемне алдың, анысына рәхмәт, Шәһит морза!

Этисенең шулай рәсми итеп, читләтеп эндәшә торган гадәте бар. Андый чакта каршы төшү мәгънәсез. Үзенекен барыбер әйтәчек, күңелендәгене чыгарып бетермичә

туктамаячак. «Шәһит морза» дип эндәшү ул аны җиткән егет, балигъ зат, олы кеше итеп тану билгесе. Әйтерсең, ике мәмләкәтнең илчесе сөйләшә. Мондый чакта эчеңдәгесен тышка чыгармау хәерле. Илчеләр хисләрен яшерә белергә тиеш. Алар ил, дәүләт файдасы хакына шәхси мәнфәгатьләреннән баш тарта. Бу — асылзатларга, аксөякләргә генә хас шәкел. Әтисе, әнә шулай, сиздерми генә улын ачыктан-ачык, хисләргә бирелмичә сөйләшергә, аңлашырга чакыра иде. Шәһит моны аңлады, телен тешләргә мәҗбүр булды. Рәсми эндәшү аның күңеленә богау салды, ялыктыргыч булса да, кирәкле, кире каккысыз сүзләрне тыңларга әзерләде.

— Әйе! Син — нәсел айгыры,— диде Мәмәт би кистереп.— Син — минем бердәнбер улым, дәвамчым. Туталарың, сеңелләрең исәпкә керми Минем нәселне син генә дәвам иттерә аласың. Орлыгы синдә. Белеп тор, мин нәселемнең теләсә нинди канга кушылып сыеклануын теләмим. Пычрануын теләмим. Моңа кадәр Мәмәтләр нәселе илгәкөнгә тап төшермәде. Кол-чуралар да җиде бабасын белә. Белергә тиеш! Син — Шәһит Мәмәт углы Мәмәт би! Унҗиде буын бабаңны белсәң дә сиңа аз! Берсе дә йөзеңә кызыллык китермәс. Аларның җаннары сине күзәтә. Дөньялыкта кылганыңа ахирәттә җавап бирәсең, алар каршына басасың бар!

Картның тавышы карлыкты, әллә кайчангы, еракта, бик еракта калган үткәннәрне уйлап булса кирәк, карашын тәрәзәдән күренеп торучы урманнарга төбәп уйга калды.

Шәһит кыймшанырга да базмады. Мондый чакта карт морзаны бимазаларга, уеннан аерырга ярамый иде.

— Чын нәсел айгыры кадерле, үтә кадерле мал,— дип дәвам итте Мәмәт би.— Нәсел айгыры булмаса, җылкы көтүенә ни бәһа! Беләсең булыр... Үзең әйткәнгә күрә сөйлим — затлы, гайрәтле, каны чиста нәсел айгыры көтүдә, бөтен биләмәдә бер генә була. Андый малга, андый тулпарга белекле адәмнәр бер көтү җылкысын да җәлләмәс. Әй-йе... Әйбәт чагыштырдың... Телең, зиһенең үткен. Инде тагын бер чагыштырып кара, уйлап бак: ат белән ишәк кушылганнан ни туа? Качыр туа. Качыр дигән мәхлугыбыз инде ат та, ишәк тә түгел... Ул мескен нәсел калдыра алмый. Кан бутаганны табигать шулай җәзалый, аның асыл сыйфатларын юк итә, тамырын корыта. Тамыр корыту гөнаһ, олы гөнаһ. Адәм баласы җиргә бәхет өчен яратыла, нәсел калдыру, тупырдатып балалар сәю өчен яратыла... Нәселне бозарга, болгатырга, туздырырга ярамый. Үзеңнән соң якты

җир йөзендә нәселсез, затсыз, теләсә кем тотып җиксә дә, менеп атланса да карышусыз качыр калдырырга җыенмыйсыңдыр... Менә шул ул, улым, нәсел дигәнең!

Сиздем: син «нәсел айгыры» дип кимсетергә, хурлап әйтергә теләдең. Чынлыкта исә, нәсел айгыры булуың белән, тамырларыңда Мәмәт би каны агуы белән горурланырга тиешсең. Шул канны дәвам иттерергә хакың барга сөенергә тиешсең.

Безнең нәселне бетерергә, туздырырга, юкка чыгарырга, оябызның көлен күккә очырырга теләүчеләр аз булмады. Шәҗәрәбезне өйрәндең, беләсең. Әмма тагын кабатлыйм. Кабатлау зыян түгел, белмәү зыян. Таркау, сибелгән ырулар бер булып олуг дәүләт — шанлы Казан-йорт төзелгәнче, көчле дәүләт булып оешканчыниләр булуы да сиңа мәгълүм. Йә, әйт, кайсы бабаң җир йөзеннән үз үлеме белән китте? Кайсысы түшәгендә җан бирде?

Шәһит дәшмәде. Мәмәт бинең сораулары кемгәдер төбәлгән сөаль түгел, бәлки, сүз куәтен арттыру өчен үзенә атап эндәшү иде.

Бүлмә тып-тын калды.

Мәмәт би муллыкта, таза, җитенкелекле тормышта яшәргә яратса да, артык зиннәтләрне, затлы купшылыкны сөйми иде. Шунлыктан, хатын-кыз, бала-чага бүлмәләреннән аермалы буларак, аның үзенә атап килгән кунакларны, дәрәҗәле йомышчыларны кабул итү, эче пошкан чакларда кереп бикләнү өчен хезмәт иткән бу олы бүлмә бөтенләй буш диярлек. Тәхеткә охшатып ясалган, алтынлап бизәлгән зур йомшак урындык, почмаклары җиз белән тотылган, калайланган берничә сандык, дивардагы келәмгә аркылы-торкылы эленгән булат кылычлар, дәү калкан һәм түр башындагы китап киштәләреннән башка монда күзгә чалынырлык артык бернәрсә дә юк иде. Ләкин Шәһит белә: картның иң изге, иң кадерле саналган нәрсәләре шушында саклана. Ул имән сандыкларда ниләр юктыр да, нинди генә серләр сакланмыйдыр... Шулай да, этисенең иң кадерләп, саклап тотканы — китаплар. Аларның һәркайсын ул аерым капта — алтын яисә көмеш җепләр белән чигелгән тышлыкта тота. Гомеренең күп өлешен яу кырларында, ауда һәм пайтәхетнең диван мәҗлесләрендә үткәргән карт морза язма сүзнең, гыйлемнең, үткен тәгъбирнең, зиһен йөгереклегенең бәһасын дөнья малыннан күпкә өстен куя иде. Шәһит шушыларны тагын бер кат күздән кичерергә өлгерде.

Тынлык авыр томан булып идәнгә җәелде, суырылып

тәрәзә төпләренә күтәрелде, тын алырга да кыймый утырган Шәһитнең йөрәге янына үрмәләде, чигәләрен кыса башлады. Ата кешене бүлдерергә ярамый.

Менә, ниһаять, Мәмәт би тәхетеннән торды да салмак адымнар белән түр башына — китап киштәләренә таба атлады. Идән сайгаклары шыгырдап куйды. Кайчандыр кызык өчен, көчен сынау өчен генә азау ярган гайрәтле аю җанварына яланкул каршы чыккан пәһлуан атасын танымады Шәһит. Аның туры, төз сыны, әйтерсең, сыгылган, аркасы бөкрәя төшкән, хәрәкәтләрендәге сыгылмалылык, җиңеллек юкка чыккан иде. Атасының инде шактый картайганлыгын беренче тапкыр тойды Шәһит. Кызгану хисе йөрәгенә сарылды, ихтыярын бәйләп куйды. «Еллар үзенекен итә... Көч-куәтенә тирә-якта тиңнәр юк кешене дә җир әнә ничек үзенә тарта, бөгә икән»,— дип уйлап куйды егет. Әтисенә ниндидер җылы сүзләр, юату хисләрен белдерәсе килеп китте. Ләкин бу мөмкин түгел эш. Хөр табигатьле, горур һәм азмы-күпме тәкәбберлектән дә мәхрүм булмаган атасы аларны күтәрә алмас, рәнҗер һәм картаюына, көчен югалтуына ишарәләү дип аңлар иде. Вакыт-вакыт теләсә нинди дуамаллыкка әзер Мәмәт би үзенә карата нинди дә булса кызгану хисен, яисә тörттерүне кабул итә белми иде.

Аның уйларын сизгәндәй, Мәмәт би кинәт тураеп басты, киштәдәге төргәкләрнең берсен алып, аны бер сугуда үгез ега торган көчле кулы белән сыйпаштырып торды һәм кискен хәрәкәт ясап борынгы кәгазьне сүтеп җибәрде. Күзләрендә яшьләрчә нур кабынды, гәүдәсенә элеккеге төзлек, җиңеллек кайтты кебек.

— Менә, кара, Шәһит Мәмәт углы Мәмәт би! Синең тамырларың көчле, алар ерактан, бик ерактан килә,— диде ул тантаналы тавыш белән.— Кил, тагын бер кара, тагын бер кат алар каршында ант эч! Бүген без шушы гали затларның соңгы күзәнәкләре, соңгы буыннары...

Кинәт аның тавышы утырды, әйтерсең, тамак төбен нидер кыра иде. Карлыккан, үзгәргән тавыш Шәһит көткәнчә, элеккечә түгел иде, сүзләре дә башкача яңгырады:

— Йә, кил, углым,— диде ул баягы күтәренкелеген онытып.— Хәзер мин сиңа нәселебезнең тарихын сөйлим. Сиңа катылыгымның сәбәбен дә үзең төшенерсең... Төшенерсең, аңларсың дип беләм.

Шәһитнең күз алдында балачактан таныш сәер сурәт ачылды. Нечкә генә тамырдан чыккан күп тармаклы, күе ябалдашлы агачны хәтерләткән рәсем төрлесе-төрле якка

сузылган нечкә сызыклардан һәм нәни яфракчыклардан тора иде. Һәр яфракчыкка яшел кара белән Шәһиткә таныш булмаган исемнәр язылган: Мәмәт, Күчем, Якуш, Латыйф, Сәүбан, тагын Мәмәт... тагын Сәүбан... Сызыклар бер-берсе белән кисешмичә, әмма асыл тамырда бергә тоташып оя-оя булып үреләләр, таралалар иде.

— Безнең нәсел агачы шушы булыр,— диде Мәмәт би шәҗәрә тамырына күрсәтеп.— Монысы олуг бабабыз Мәмәт. Борынгы Болгардан... Күрекле, көчле ырудан. Без барыбыз да аңа барып тоташабыз. Җылкы ыруының мин белгән башы шуннан килә. Шәҗәрәнең борынгырагы да булган, диләр. Анысы гарасатта юкка чыккан, янып көл булган...

Мәмәт би көрсенеп куйды.

— Ни аяныч, күпме тырышсак та без аны инде кире таба да, яңарта да алмыйбыз. Хәтер кеше белән бергә үлә. Үлмәсен дисәң, кәгазьгә теркәп калдырырга кирәк. Инде ябалдашның очына кара... Күрәсең, агач корый бара. Җылкы ыруының асыл затлары бетүгә юл тота. Син шуны телисеңме?!

Чыннан да, куе ябалдаш өскә таба тарая-тарая килә дә нәзек кенә чыбык очындагы яшел яфракчык белән тәмамлана иде. Аның эченә язылганны да Шәһит укып өлгерде: атасының кулы белән каты итеп «Шәһит Мәмәт углы Мәмәт би» дип язылган иде. Үзен шушы агачның бер яфракчыгы итеп тойган Шәһиткә әллә нәрсә булды, күңеле тулды, башы әйләнеп китте сыман. Әйтерсең, менә шушы мизгелдә тамырларында аккан каны — ерак гасырлардан килүче бабаларының авазы тавыш бирде. Алар чакыралар, өндиләр, үтенәләр, таләп итәләр: «Нәселебезне сакла! Нәселебезне сакла! Син бетсәң, без дә бетәбез!..» — диләр сыман иде.

Үзен борчый, газаплый башлаган сорауны бирергә иң уңайлы вакыт иде, Шәһит түзмәде, тынлыкны бозды. Хәер, «углым» дип эндәшеп, ата кеше аңа сөйләргә рөхсәт биргән иде инде.

— Әтием!.. Бер нәрсәне беләсем килә... Шәҗәрәбез куе, күп тармаклы... Нишләп соң минем... безнең... туганнарыбыз аз?

Мәмәт би гомердә булмаганны кыланды: улын иңнәреннән кочаклап үзенә таба тартты да тирән сулап куйды:

— Әй, углым... Күптән, бик күптән көтә идем мин бу сорауны,— диде.— Белеп тор: дошманнарыбыз күп булды, аяусыз булды.— Һәм ул шәҗәрә тармакларына төртеп күр-

сәтә-күрсәтә сөйләргә кереште.— Менә бусы Батый хан Болгарга яу чапкан елларда бетте, кырылды. Ил-йортны саклап башларын салдылар. Монысын Василий Темный башкисәрләре харап итте. Сөйләп кенә бетерерлекме... Ызгыш-талашларда күпмесенең гомере киселде. Аяныч... тормыш дигәнең без дигәнчә генә бармый. Җир йөзендә бердәнбер безнең тармак торып калды. Менә күрәсеңме? — Мәмәт би очлаеп сузылган нечкә ботакка күрсәтте.— Монысы бабаң Сәүбан, аннан соң инде мин калдым, миннән соң берьялгызың син каласы... Ә мин синең ялгыз булуыңны теләми идем. Теләмәдем... Нишлим? Аллаһы тәгаләнең каһәренә дучар булдыкмы, башка сәбәпме... белмим. Әүвәл дөньялыкта мине апа-ялгызлыкка хөкем итте... Инде сиңа да шуны теләмим. Сүзем бер — нәселең ишле булсын, өеңдә бала-чага тупырдап торсын!..

Мәмәт би унлап кыз-кыркын арасында бердәнбер булып дөньяга килгән улын өзелеп ярата, аны күз карасыдай сакларга тырыша иде. Ул — аның өмете, киләчәге, нәсел-нәсәпнең, олуг Мәмәт токымының соңгы ышанычы иде. Киләчәк белән аны — Мәмәт Сәүбан углы Мәмәтне — бары шушы углан, борынгы бабаларының асыл сыйфатларын җыйган, терекөмештәй җитез, пәһлуандай көчле һәм кызларча чибәр Шәһит углан гына тоташтыра ала. Бар мал-мөлкәт, Мәмәтләр нәселенең шанлы исеме аңа каласы. Ләкин никадәр генә яратмасын, кадерләмәсен, карт морза аларны, ул хисләрне угланга сиздерүне кирәк тапмады. Ир бала кырыслыкта, каты кулны тоеп, иркәләнми, назланмый чын баһадир булып, мөстәкыйль булып үссен. Аның кагыйдәсе шундый иде. Бәлки, артык кырыслыгы белән улын үзеннән читкәрәк тә этәргәндер... Ләкин... Шәһиткә андый-мондый куркыныч янаса, дошманны ул теше-тырнагы белән ботарлап атарга әзер иде. Үзе тоеп йөрде, күреп, белеп торды: углы да аңа шундый ук кырыс мәхәббәт белән җавап бирә иде. Кечкенәдән атасыннан яклау эзләмәде, аңа салынмады, утардагы малай-шалай белән бәрелешеп, авызборынын канга батырып кайтса кайтты, әмма атасына зарланмады. Аның үзбаш яшәргә, һәр нәрсәне хәл итәргә үзе алынуын күрү ата күңеленә әйтеп бетергесез олы шифа бирә иде. Шуңа да ул балалык, үсмерлек һәм егет чакларында да Шәһиткә бар нәрсәдә ирек куйды, аның горурлыгына, көченә, үзен тота белүенә ышанды. Бәхетенә, барысы да ул көткәнчә барды: малай өметнеаклады. Тик менә бүген, хәзер тәртәгә тибәргә азаплануы бердән сөендерсә, икенче яктан, ата ихтыярына буйсынмыйча үзбаш кыланыр-

га маташуы көендерә иде. Барысы өчен үзе җавап бирергә күнеккән мәгъруp җан буйсынмаса?! Хәер... Мәмәт би улын бөгә, әйткәненә күндерә алуына ышана иде. Ул бүген олы, гаять тә олы һәм тирән төшенчәләр белән эш итә!

Менә хәзер дә, шушы мизгелдә дә Мәмәтнең улын тагын бер кат кочып сөясе, аркасыннан кагып булса да иркәлисе килә иде. Әллә нинди тыелгысыз, тәкатьне бетерә торган сәер хис иде бу. Әмма карт морза кулларына ирек бирмәде, акрын гына сөйләвен белде. Инде иң соңгы, иң үтемле сүзне әйтәсе калды.

— Мин дә ялгыз түгел идем,— диде көрсенеп Мәмәт би.— Атамның йорты киң, билек бакчалары чәчәктә, яшәвебез рәхәт иде. Газиз әнкәмнең кочагы җылы, атамның кулы кырыс булса да, йомшак иде. Барысы да бер көндә бетте, пыран-заран килде. Шушы утарда ялгызым утырдым да калдым.

— Әбием, бабам... Аларның гомере шулай аяныч киселдемени? — диде Шәһит атасының тын калуыннан файдаланып. Ул дәһшәтле көннәр хакында аның ишеткәне бар, әмма яшьлек иләслеге белән элегрәк артык әһәмият бирми иде. Хәзер исә, атасы кинәт ачылып киткәндә, бу сәер тарихны бөртекләбрәк, җентекләбрәк ишетәсе килү теләге уянды. Кырыс морзаның улы белән инде шактый күптән шулай ачылып, тирәнгә кереп сөйләшкәне юк иде.

Әтисе үкенечле, аянычлы көннәрне искә төшереп булса кирәк, тирән сулап куйды, башын учына терәп бераз утырды да акрын гына сөйли башлады. Маңгае җыерылды, күзләрендә яшерен ут кабынды.

— Мин ышанам... Әйе, кайдадыр бәлки... Минем сеңлем яшидер...— диде ул капылт кына.— Тик белмим, төгәл әйтә алмыйм. Бәлки синең дә ир туганнарың, ягъни туганнан туган абый-энекәшләрең бардыр... Юллап, эзләтеп карадым, очына чыга алмадым. Идел дулкыннары серен саклый белә. Ләкин сизенәм, тоям, күңел төбендә үлмәгән өметем бар... Исәндер шикелле ул. Аңлата гына алмыйм...

Шәһитнең күзләре зур булып ачылды. Әле генә: «Мин ялгыз, япа-ялгыз»,— дип утырган атасы моңарчы бөтенләй ишетмәгән, сәер сүзләр сөйләп ята иде.

— Ничек? Кем ул? Кайда? — дип сорау арты сорау ташлаганын сизми дә калды.

— Анысын мин үзем дә белмим. Бабаң, ягъни Сәүбан морза дәүләт йомышын үтәп ерактагы Бәлҗәмәнгә — Кырым-йорт белән Казан-йорт чикләрендәге ялгыз кирмәнгә киткән җиреннән әйләнеп кайтмады. Анысын беләсең... Кем

кулыннан үтүе, кайсы дошманының үч алуы билгесез. Урыны җәннәттә булсын! Ул кайтмагач, әбиең — Суфия бикә кечкенә сеңлемне алып, укчылар төяп көймәдә Бәлҗәмәнгә юлга чыга. Үгетлиләр, ушкуйниклар — урыс юлбасарлары азган чак, сабыр ит, диләр. Тыңламый. Әҗәле тартканмы... Бабаңны, минем әтиемне бик яраткан, диләр. Үлүенә, һәлагенә ышанмаган... Нишлисең?.. Күрәчәгең гүргә кертер, ди бит.

Бер-ике атнадан укчыларның берсе кайтып егылды. Яраланып суга егылган да ярга чыгып күзәтеп яткан. Ул сөйләде. Әбиеңне тураклап суга атканнар. Бик каты сугышкан ул. Ә нәни кызчыкны, сеңлемне, сиңа туган апа буласы кешене алып киткәннәр. Хак булса, аның өчен Сәүбан морзаның ярты байлыгын каерасылар имеш. Шулай сөйләнгәннәр... Әмма юлбасар сүзенә ышанып буламы?! Барысы да шулай югалды, таралды, бетте. Ушкуйниклардан чапкын да, йомышчы да килмәде. Мин аны гомер буе көтеп яшәдем. Көт-тем... Калганын беләсең...

— Ул канечкечләр шулай җәзасыз калдымыни? Казан-йорт хәтле Казан-йорт Сәүбан морзаның үчен алмадымы?— диде Шәһит ярсуына чыдый алмыйча. Канлы куллардагы нәни кызчыкны, кылыч тотып дошманына ташланган Суфия бикәне ул үз күзләре белән күргәндәй булды. Ирексездән бармаклары йодрыкка төйнәлде, күзләрендә үч чаткысы кабынды.

— Үчне алдылар анысы... Бише белән кайтардылар,— диде Мәмәт би.— Казан-йортның иң асыл ирләре яуга китте. Ушкуйникларның ояларын туздырып, мәңге онытмаслык иттереп кайттылар. Явызлыкларын кан белән юдырдылар... Тик ни файда?! Сәүбан морзаны да, Суфия бикәне дә кире кайтарып булмый иде инде. Сеңлем әле сабый гына, миңа нибары унөч яшь иде... Менә шул, улым.

Ә шулай да күңелем нидер сизенә... Бүген менә тагын искә төште. Ул бала исән калгандыр... Балалары бардыр, нәсел үрчетеп ятадыр... Бәлки урыс-улак арасындадыр. Бәлки... Тик инде алар Мәмәт би нәселе булмас, борынгы җылкы ыруының шәҗәрәсендә аларга урын табылмас.— Мәмәт би тагын бер көрсенеп куйды, күзен йомып уйланып утырды-утырды да, йөрәгенә тотынып, акрын гына әйтеп бетерде.— Нигәдер күңелем урынында түгел. Йөрәгем уйный. Тиктомалдан әллә кайчангы вакыйгалар, югалган сеңлем искә төште. Хәерлегә булсын!..

* * *

Тузанлы юлдан бер төркем атлылар чаба. Алда буйсынга бер чамадарак ике яшь егет килә. Ләкин бу тышкы охшашлык кына. Якынрак килеп караган кеше аларның берсенең күзләрендә чаткылы очкыннар күрер иде, икенчесенекендә кайгы, моң, хәсрәт күләгәсен абайламый калмас иде.

Ике егет дигәнебез — Шәһит белән Санька иде.

Шактый озак сүзсез генә бардылар. Ниһаять, Шәһит тынлыктан, телсезлектән, күңелен актарган хисләрдән котылырга теләде булса кирәк, атын тыя төште һәм куршесенә эндәште:

— Йә, Александр, Саклаубашта биргән вәгъдәңне үтә: сөйлә, ичмасам, башыңнан кичкәннәрне!..

Дәүран би кызы белән ярәштерелгән яшь морзаның күз яшьле, мажаралы, газаплы һәм әрнеткеч мәхәббәт кыйссасы ишетәсе килә иде.

КОЛ ШӘРИФ

«Җәнаби үзенең тарихында болай дип яза: «Ул (Сафагәрәй) ханнарның олыларыннан, усалракларыннан иде. Аның заманында патшалык бакчалары рәхәт, ә мәмләкәте төзек иде».

Шиһабетдин Мәрҗани.
«Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар»дан.

Сафагәрәй тагын Казанга кайтты. Казанлылар чакырып кайтарды. Пайтәхеткә каты куллы, гадел һәм зиһенле хан кирәк иде.

Морзалар, биләр, карачылар, дәүләт хакимлегенә торган саен күбрәк йогынты ясый башлаган сәүдә әһелләре — малтабарларның ыгы-зыгысына, сарайдагы талаш, кычкырышка чик куярга, хакимлекнең каты бер кулда тупланырга тиешлегенә басым ясаган ханның төшерелеп, хурлыклы рәвештә Кырымга кайтып китүенә өч ел вакыт узган. Өч мәртәбә язлар килгән, кышлар үткән. Нәүруз саен бөек аллаһы тәгалә кодрәтенә сыгынып, аннан Казан җиренә иминлек, бәхет һәм муллык, татулык сорап, ялварып чалынган корбаннарның нәтиҗәсе булмады, мәмләкәткә нә иминлек, нә муллык килмәде; карачыларның һәркайсы үз ягын

каера башлады, биләр арасында астыртын көндәшлек тамырланды. Үз мәнфәгатьләрен генә уйлаган кайберәүләр алдап-йолдап та, ачыктан-ачык та Мәскәү ягына каеруны гөнаһка санамый, моның өчен кырыкмаса-кырык сылтау таба, аклану юлларын эзли иде.

Соңгы елларда урыс кенәзлекләренең бер-бер артлы мөстәкыйльлеген югалтуы, кайсының күршесенә хөсетлектән, кайсысының зәгыйфьлектән, күпләренең канга батырылып, корал тотардай ирләренең кылычтан үткәрелеп Мәскәүгә баш ияргә мәҗбүр ителүе, Казан җирләре чигендә генә уртак бөек кенәзгә буйсынган көчле мәмләкәт оешып килүен, аның нәфесе көннән-көн артуын аксөякләр аңлап бетерми. Күзләрен байлык артыннан куу томаны каплаган, зиһеннәрен комсызлык, нәфес чире баскан, колакларын алтын чыңы томалаган. Дөрес, Мәскәү белән сәүдә итү — табышлы, төшемле эш, әмма дә ләкин малтабарлык кына изге ханлыкның ныклыгын, бердәмлеген какшатырга тиеш түгел ләбаса.

Хуп, Сафагәрәйне тәхеттән төшердек. Ләкин ул китү генә казанлыларга берәр отыш бирдеме соң?! Юк! Бирмәде генә түгел, дәүләтнең сәясәтенә зыян китерде, күп нәрсәдә мөмкинлекләрен чикләде. Борынгылар юкка гына «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» дип әйтмәгәндер. Казан һәм Кырым тәхетендә нәсел җепләре бер шәҗәрәгә тоташкан асыл затлар утырганда һәр ике ханлык бертуган булып яшәде, бер бөеклекнең, галилекнең ике канатына әверелде. Сафагәрәйнең Казан тәхетеннән төшерелүе аркасында кырымлылар белән мөнәсәбәткә салкынлык иңде, Кара диңгезгә юнәлгән сәүдә юлларына чирәм үсә башлады. Шуны гына көтеп торган, бөтен сәясәтләрен, хәйләкәр осталыкларын Казан белән Кырымны дошманлаштыруга юнәлткән мәскәүлеләр тагын отты, казанлыларга юл ябылган базарларда урыс малтабарларының кәрваннары шаулады.

Аллага шөкер, инде моны биләр, морзалар гына түгел, кара халык та аңлады. Диван* әһелләре ялгышларын төшенеп, кире Сафагәрәйгә бил бөгәргә, тәхеткә кайтуын гозерләргә мәҗбүр булдылар.

Кол Шәриф авыр сулап куйды: «Хәерлегә булсын! Сәясәттә барысы да ак-пакъ булмый күрәсең...»

---

* *Диван* — хан сараенда биләр, морзалар, карачыларның киңәшләшү мәҗлесе, идарәче, киңәшче орган.

«944 сәнәнең* язында күзен Мәскәү ягына аларткан, мәмләкәт ихтыярын урысларга саткан Җангали хан бәкләр кулыннан шәһит китте. Нәфесенә хуҗа була белмәгән, гали затлар тәхетенә утырса да, галилектән, дәүләт мәнфәгатеннән бихәбәр Җангали кара гүргә керде. Урыны җәннәттә булсын дия алмыйм. Барысы да бөек тәңребез иркендә. Барыбыз да аның коллары. Казан тәхетенә яңадан Сафагәрәй хан утырды.

Аллаһы тәгалә куәт вә мәдәт бирсен!»

Кол Шәриф каурый каләмен көмеш кара савытына батырды да күзләрен бер ноктага текәп уйга калды, авыз эченнән генә дога укып битен сыпыргач, янәдән иртәдән бирле тынгы бирмәгән уйларын, чуалган зиһен җебен сүтәргә кереште. «Әйе, ни генә дисәң дә, Сафагәрәйнең тәхеткә кайтуы олы җиңү, елъязмалар бизәге булырлык бөек вакыйга. Һичшиксез ул Казан-йорт тарихына язылып калырга тиеш. Кырым-йорт белән бертуганлык мәмләкәтнең сулышын киңәйтеп җибәрер, көч-куәтебезне арттырыр. Казан, Кырым, Әстерхан хөкемдарларының туганлыгы даладан Каф тауларынача, Себергәчә мәгълүм, ул бәхәссез. Туганнарга каршы урыс та, башка бүтән бер кавем дә күтәрелергә кыймас. Хәер, хәзер урыстан башка бүтән бер ыру да, кабилә-кавем дә бу йортларның нык икәнен белә, патшалык бакчаларына борын тыгарга базмый инде»

Кол Шәрифне куандырганы шул — тәхетне ныгытуда аның өлеше аз булмады. Алтын-көмеш чыңыннан колаклары томаланган малтабарларның күңеленә барып җитәрлек, зиһеннәрен уятырлык сүзләр табарга, күзләрен ачарлык дәлилләрне үтемле итеп күрсәтә дә белергә кирәк иде бит. Иншалла, ахыры хәерле булсын, Казан халкы аның сүзенә битараф түгел, әйткәне бер колактан кереп икенчесеннән чыкмый, биләр-морзаларның аңында да, гади халык күңелендә дә урын таба.

Әле ир уртасы яшенә җитмәсә дә инде галимнәрдән дә нәкыйбел-әшраф** дип танылган галиҗәнаб мелла Шә-

---

* Һиҗри белән 944 ел — милади буенча 1535 ел. Алга таба, укучыларгы аңлаешлырак булсын өчен, еллар исәбе хәзерге календарь — милади буенча бирелә.

Сафагәрәй хан 1521 елда Казан ханы була, 1532 елда төшерелеп Кырымга китә һәм 1535 елда кайтып, тагын унбер ел хан була. Ул еллар Казан ханлыгының иң көчле, чәчәк аткан чоры.

** *Нәкыйбел-әшраф* — бөекләрнең житәкчесе

рифкол сигез манаралы җәмигъ мәчетнең беренче имам-хатибы, гыйлемле вә белекле, белкевар* дигән югары исемгә лаек затлардан да беренчесе иде. Аксөяк угланнарга вә дәхи гади халыктан чыгып, тырышлыгы, зирәклеге белән башкалардан аерылып торучы, гыйлемлек эстәүче яшь егетләргә сабак укыту белән бергә, ул мәмләкәтнең иң кадерле, иң асыл хәзинәсенә ия кеше. Чөй язуы белән чуарланган таш такталарны да, ерак Рум галимнәренең серләрен теркәгән, бозау тиресеннән тегелгән калын китапларны да, уйгур, чин һәм гарәп хәрефләре белән сәйләндәй тезелгән йөзләрчә битле елъязмаларны, күтәрә алмаслык алып китапларны да табарга була аның хәзинәсендә. Алар арасында да иң кадерлесе — борынгы бабаларыбызның шәҗәрәсе — ерак-ерак гасырлар төпкәленнән килгән изге язмалар саклана монда.

Кол Шәрифнең инде күп еллар элек үзенә кагыйдә иткән бер гадәте бар: ил-көндә чуалышлар, хөкемдарлар арасында сәбәпсез ызгышлар кузгалса, яисә күңелендә шомшөбһә уянса — китапханәнең аскы катындагы хөҗрәгә керерп бикләнә, калын китапларның дәверләр кичүдән тоныкланган көмеш каптырмаларын ычкындыра да борчыган сорауларына, күңелен бимазалаган шикләргә җавап эзли.

— И борынгы төрки бабаларыбыз! Киңәш бирегез, ни кылыйм? Мәмләкәтнең авыр көннәрендә котылу юлын каян эзлим?

— Аһ, болгар бабаларыбыз! Тарих кабатланмый калмас. Мондый чакларда сез ни кылыр идегез? Киләксез ызгышларга ничек чик куярга?! Зиһеннәре томаланган хөкемдарларның күзләрен ничек ачарга?!

— Әйтегезче, чин, рум, Мисыр һәм уйгурның белекле адәмнәре, сезнең тарихта моңа охшаш хәлләр булдымы? Булса, чыгу юлын ничек таптыгыз? Ахыры ни белән бетте? Киләчәк буыннарга кисәтү-киңәшләрегезне кайларда язып калдырдыгыз, нинди сүзләргә, тылсымга тиң гыйбарәләргә төреп яздыгыз?

Китаплар белән шулай сөйләшә Кол Шәриф. Алар — аның өчен җан ияләре, авазсыз, тавышсыз киңәшчеләре. Бары тик телләрен генә аңлый белергә кирәк.

— Йа ходаем, изге язмаларның мәгънәсен аңларлык тел ачкычлары бир!

---

* *Белкевар* — Казан ханлыгында һәм Бөек Болгар дәүләтендә югары дәрәҗәдәге мәктәп-мәдрәсәләрдә сабак бирүче иң белемле укытучы, остаз. Хәзерге төшенчәләр буенча академик дияргә мөмкин

Имам-хатиб авыр уйларын куарга теләгәндәй башын чайкап алды, имән бармаклары белән чигәләрен уыштыргач, тамак кырып тавыш бирде:

— Кайсыгыз бар анда, керсәгезче!..

Белкеварның үзен бүлдергәнне яратмаганлыгын белгән һәм шунлыктан бүлмә ишеге янында сакта торгандай кизүлек иткән китапханә хадиме тышкы яктан салмак кына тавыш бирде, шыгырдап калын ишек ачылды.

— Нәрсә кирәк иде, имам-хатиб әфәнде? Әмереңне көтәм...

Кол Шәриф шәкертенең ярату һәм ихтирам тулы күзләренә, боерык көтеп алга таба иелә төшкән яшь сынына карап, шактый озак сүзсез торды да фикер җебенең очын яңа гына тапкандай кистереп әйтте:

— Мин астагы хөҗрәдә булырмын. Кем килсә дә кертмәгез. Мин — юк!

Килеш-килбәтендә олылык, зирәк ирләр олпатлыгы чагылган остазының һәр сүзенә тавышсыз баш ияргә күнеккән хадим бу юлы тынлыкны бозды:

— Сарайдан килсәләр дәме? Галиҗәнаб Сафагәрәй хан хәзрәтләре...

Хадим әйтеп бетерә алмады, имам-хатибның куе кара кашлары астындагы зәңгәр күзләрендә ризасызлык чагылып үтте, киң ак маңгаенда бер генә мизгелгә җыерчыклар хасил булды, кул ишарәсе белән егетнең сүзләрен бүлдерде.

— Диваннан килсәләр дә,— диде ул сабыр гына.— Пәйгамбәрләр белән сөйләшкәндә комачаулаганны сөймим.

Кинәт аның карашындагы таркаулык әчке нур белән алышынды, салмак хәрәкәтләренә кискенлек, нәрсәнедер хәл иткән һәм аны үтәргә ашыгучы кешеләрдәгечә омтылучан җитезлек иңде. Ул яшьләрчә җиңеллек белән урыныннан күтәрелде, бер төргәк чиста кәгазь, кара савыты алды, каурый каләмен өстәлнең бер читенә шудырды, ашыгып-ашыгып өстенә яшел чапанын киде, кара кәләпүше өстеннән ак чалмасын чорнады.

— Аска ике көнлек шәм төшерерсең,— диде ул карлыгып киткән тавыш белән.— Өйдәгеләргә хәбәр ит: имам-хатиб хөҗрәгә бикләнде... Борчылмасыннар!..

Китаплар, кулъязмалар, дистәләрчә таш такталарны кулыннан үткәрсә дә, яшь хадим әле аларның күбесен аңлап бетерми, мең-мең еллык белем, тәҗрибә тупланган, борынгыларның бүгенгеләргә җиткерәселәре язып калдырылган ул акыл хәзинәсенең кыйммәтен тулы дәрәҗәсендә күз

алдына китерә алмый иде. Еш кына уйга кала: борынгының бүгенгегә нинди бәйләнеше бар, үткән — беткән дип тә фикер йөртеп карый, әмма остазының гыйлемлеге, күп нәрсәне алдан күрә белүчәнлеге — язмаларда нindидер гали затларның, пәйгамбәрләрнең күрәзәлеге язылганлыгына шик калдырмый иде. Шулай булмаса, Казан өчен иң афәтле көннәрдә Кол Шәриф алтын-көмеш, асылташлар, кыйммәтле, зиннәтле маллар сакланган хәзинәне түгел, нәкъ менә китапханәне, шушы борынгы язмаларның саклануы өчен җанын кызганмыйча утка ташланмас иде. Шулай булмаса, олуг хан хәзрәтләре, диван әһелләре киңәшкә иң элек Кол Шәрифне, белекле кешеләрне чакырмаслар иде.

Китапны белеп, сайлап кына җыя Кол Шәриф.

«Язу-сызу, китап — ул хәтер. Теге яки бу халыкны юк итим дигән илбасар, залим хөкемдар иң элек аның китабын, язуын бетерер, яндырыр, көлгә әйләндерер. Хәтерсез кеше — хайван мисалында,— дип өйрәтә аларны белкевар.— Хайван ни эшләткәнгә дә риза. Муенына бау тагып сатарга алып барганда да, бәйләп суярга салганда да. Чәйнәренә ризыгы, күшәренә чүбеге булса — аңа шул җиткән. Сез — адәм затыннан. Хайван хәленә төшәсегез килмәсә, укыгыз, белем җыегыз. Белем алу — әнә белән кое казудыр. Аның башка юлы юк. Адәми зат дигән исемгә тырышып, күз нурыңны коеп кына ирешеп була. Анадан ике аяклы, ике куллы булып туу гына җитми. Әнә, маймыллар да ике куллы, ике аяклы, әмма кеше түгел. Кеше үзенең кеше икәнен белгәндә, шул исемне аклар өчен яшәгәндә генә кеше»,— ди остаз. Аны калада «китап җене кагылган» дип тә сөйлиләр. Бәлки шулайдыр да. Кем белә. Бар байлыгын, тапкан-казанганын китапка түгәргә шул җен мәҗбүр итмиме икән әле?! Әнә ич, ярты Казан белә: моңарчы таныш булмаган нindидер борынгы язмага тап булса, үзенекен дә, хан казнасы байлыгын да кызганмас, шул китапны кулына төшермичә тынычланмас. Ташаяк ярминкәсенә йөрүче карт сәүдәгәрләр Казандагы акыл иясенең бу гадәтен беләләр һәм ел саен нинди дә булса иске китап, язма, йә булмаса чөй язулы таш такта алып килмичә калмыйлар иде. Әнә шулай бөртекләп, кадерләп, әнә күзеннән үткәреп тупланган акыл хәзинәсе саклана монда.

Яшь хадим үзенең кайчан да булса ул яшерен серләргә ия булачагын, борынгы акыл ияләре фикерләре, киңәш-тәгъбирләре белән танышачагын күз алдына китереп, канәгать елмаеп куйды. «Йа хода, моның өчен никадәр сабырлык, түземлек, дөнья ваклыкларыннан өстен була белү

сәләте, тырышлык, үҗәтлек кирәк! Зиһенеңне чупләмичә саф тота белү аны олуг затлар туплаган тәҗрибә өчен ачу дигән сүздер»...

Уйларына бирелеп ул Кол Шәрифнең ишарәсен дә сизми калган икән. Колагына сүзләре килеп керде.

— Йә, аллага тапшырып, тәвәккәллик, улым! Менә бу кулъязмаларны, әсбапларны алып төшәргә ярдәм итәрсең,— диде ул яраткан шәкертләреннән саналучы хадимгә борылып.— Кабатлап әйтәм, яу-фәлән килә калса гына хәбәр итәрсез... Башкасына ризалыгым юк.

Шәкерт дивар куышлыгыннан махсус коелган озынча калын шәмнәр алды, ут элде һәм остазы күрсәткән төргәкләрне култыгына кыстырып ишеккә таба атлады. Тар аралыктан үтеп аска төшүче баскычларга борылдылар. Ишекне ачуга борынга мәгарәләрдә була торган тынчу һава түгел, ә талгын җылылык бәрелде. Моның сәбәбен дә белә иде шәкерт. «Китап — нәзберек әйбер, ул саклаганны, кадерләгәнне ярата»,— дип өйрәтә Кол Шәриф. Шунлыктан, хәтта җәй көннәрендә дә китап саклау йортының миче ягулы. Шома таштан тигезләп салынган калын диварларда дым әсәре сизелми, киштәләрдә калын-калын төргәкләр, икешәр-өчәр кирпеч зурлыгындагы китаплар, таш такталар, тагын әллә никадәр таныш түгел хәрефләр белән чуарланган, вакытлар үтүдән яшелләнә башлаган бакыр такталар...

Уртадагы аралыкта киң имән өстәл, аның янында тәбәнәк урындык. Өстәлдә өч башын өч якка сузган аждаһа сурәтендәге шәмдәл, очлап куелган каз каурыйлары...

Шәкерт аждаһа башындагы шәмнәргә ут элде, төргәкләрен өстәлгә таратып салды һәм уң як диварда, кеше буе биеклегендә уелган төнлекне ачып җибәрде. Хөҗрәгә елга исе, болын исе катыш салкынча һава ургылды. Егет яңа әмер көтеп остазына текәлде.

Кол Шәриф, күрәсең, инде уйлары белән бөтенләй башка дөньяга, гыйлем, фән дәрьясына кереп беткән иде, ул шәкерт егетнең сораулы карашына да, аның сүзсез катып калуына да игътибар итмичә, алдындагы язмаларга үрелде. Үзенең һәнүз бирелә икәнлеген белдереп, егет тамак кырып куйды.

— Рәхмәт сиңа, углым! Чыгарга мөмкин,— диде имамхатиб башын күтәрмичә генә.— Тагын шәмнәр төшерергә онытмассың...

Китәргә җыенып борылган шәкерт кинәт тагын туктап калды һәм нидер әйтергә теләгәндәй Кол Шәрифкә карады.

Әмма остазы аны күрмәде. Бөтен гаме, игътибары, дикъкате китапта иде инде. Аны бүлдерергә, комачауларга ярамаганлыгын тәгаен белгән егет шыпырт адымнар белән ишеккә таба юнәлде. Колак төбендә күк күкрәсә дә белкеварны инде китаптан аеру мөмкин түгел иде.

«Вакытында әйтә белмәдем. Ничек кенә онытып җибәрдем соң,— дип үкенүле уйларына бирелде ул.— Юкса, иртәнге якта кәефе әйбәт, күңеле күтәренке иде бит. Кеше гозерен гозерли белмәдем. Гөнаһы үземә буласы».

Әллә нишләп ярдәм итәсе килгән иде аның таныш түгел егеткә. Ялварып, ярдәм эзләгәндәй үзенә төбәлгән җете зәңгәр күзләрне исенә төшерде. Әйтерсең, алар аны шелтәли, рәнҗи кебек тоелып китте.

Әле иртә иде, Казан мәчетләре өстендә мөэмин-мөселманны намазга чакырган азан тавышлары да тынып өлгермәгән иде. Кизү тору сәбәпле иртәнге доганы китапханәдә генә уку хокукы бирелгән егет, намазлыгын җәеп, дөнья ваклыкларыннан ваз кичәргә әзерләнеп кенә йөри иде, тимер капканың кинәт шакылдавыннан сискәнеп китте. Вакытлы-вакытсыз кем йөри! Олысы-кечесе ил-көн мәшәкатен читкә ташлап, җанын, бөтен барлыгын хак тәгалә рухына багышлаган чакта бимазалаучы юктан гына шакымыйдыр. Шуларны уйлый-уйлый капка янына йөгерде. Тимердән чүкеп ясалган чәчәкләр белән бизәүле капка янында сары чәчле, озын гәүдәле, шактый таушалган сәләмә киемле егет басып тора иде.

«Вакытсыз борчып йөрмәгез! Беркем дә юк»,— дип тиз генә келәне төшермәкче иде дә, ирексездән аның кием-салымын күздән кичерде. Таушалган, тузган булса да затлы тукымадан тегелгәнлеге әллә каян күренеп тора. Гәүдә тотышы, буй-сынының төзлеге, ачык-якты карашы аның гади халыктан түгел, аксөякләр таифәсеннән икәнлеген белгертә, егетнең юкка йөрмәвен ишарәли иде кебек. Ләкин шәкерт аларны күзеннән үткәрсә дә, җанына якын алмаган иде, китапханәгә кемнәр генә килмәс.

Соңгы мизгелдә күзләре очрашты. Мөлдерәмә тулы җете зәңгәр күзләр аның һичкичекмәстән нәрсәдер хәл итәргә тиешлеген дә, чарасыз икәнлеген дә, соңгы өмете шушы йортта икәнен дә кычкырып тора иде кебек. Ул кемнедер эзләп китапханә йорты баскычына текәлде һәм аягын атлараталмас сорау бирде.

— Зинһар, кертегезче! Миңа Кол Шәриф хәзрәтләре кирәк иде...

Татарча сөйләшсә дә, ят шивә вәкиле икәнлеген, зур

гозере барлыгын аңлаган шәкерт аңа кырт кистереп тискәре җавап бирергә кыймады. Кол Шәрифнең шәкертләре төрле яктан. Кырым белән Әстерханнан гына түгел, тау илләреннән дә, Себер белән даладан да җитәрлек. Шөкер! Инде тагын кайсыдыр бер яктан, әйтик, урыслардан килүләре гаҗәпме! Шулай булмыйча! Хисапмы, әл-җәбрмы*, күк йөзе һәм йолдызлар гыйлемеме, рум яисә славян телләреме — барысы да сабакка Кол Шәрифкә килә. Хәер, ул гынамы?! Җәмигъ мәчет мәдрәсәсенең башка мөдәррис-остазлары да укымышлы, гали затлар.

Шәкерт шуларны уйлап өлгерде һәм таныш түгел егеткә, хәленә керергә тырышып, җавап кайтарды:

– Хәзрәт юк шул әле... Өйлә намазы алдыннан гына киләчәк. Килсә дә кабул итмәстер, вакыты тыгыз чак. Бигайбә.

Никадәр генә битараф күренергә тырышмасын, кызыксынуы җиңде — яшьтәшенең ни йомыш белән йөрүен сорамыйча кала алмады.

— Минем үз йомышым... шәхси эш,— дип җавап кайтарды нәүмизләнеп калган егет.

Аның Кол Шәрифне туры китерә алмавыннан гаҗизләнүе шулкадәр ачык сизелде ки, егетнең күз алдында кечерәеп, бөрешеп калгандай аһ дип коймага сөялүен күреп, шәкерт аны ышандырырга, өметләндерергә ашыкты:

— Мин әйтеп карармын... Бәлки хозурына чакырыр. Килерсең,— диде ул мөсафирның күзләренә туры карап.— Чит мәмләкәт кешеләрен борып җибәргәне юк.

Мөсафир егет уфтанып куйды һәм хушлашып та тормастан борылып китеп барды. Кизү аның алга бөкрәя төшеп, теләр-теләмәс атлаган гәүдәсенә, иртәнге җилдә чәбәләнеп җилфердәгән озын сары чәчләренә озак карап торды. «Күрәсең, олы кайгысы, башкалар белән уртаклашырга ярамаган хәсрәте бардыр. Юкса, таң тишегеннән Кол Шәриф хәтле Кол Шәриф катына гозер белән килмәс иде»,— дип уйлап куйды ул. Артыннан куып җитәсе, сорашасы белешәсе килеп китте. Әмма ул бик теләсә дә китапханә йортын ташлап китә алмый. «Әйдә, тагын килер әле, әйттем ич»,— дип үзен тынычландырырга ашыкты. Ләкин, ничек кенә булмасын, таныш түгел мөсафирның чарасызлыгы, өметсез нәүмизлеге җанына ярылып кергән иде, ярдәм итәсе, булышасы килү теләге уянганын сизми дә калды.

* *Әл-җәбр* — алгебра (гарәпчә).

Хәер, бу хисләр ничек тиз барлыкка килгән булса, шундый ук тизлек белән онытылдылар да. Мәчеттән кайткан шәриктәшләре шаярыша-көлешә егетне уратып алдылар, аннан соң өйләгә кадәр барысы да эшкә ябышты: китап күчерүче — хәттат осталыгын өйрәнүчеләрнең имтиханы якынлаша, китапны иң матур күчереп язган, бизәкләгән һәм шәрехләгән шәкерткә мөгаллим-хәлфә исеме биреләсе — барысы да эчтән генә шул дәрәҗәгә өметләнә һәм һәркайсы иптәшләреннән яшерергә тырышып бизәк эзли, вакытын шул шөгыльгә багышлый иде.

Безнең шәкертебез дә инде берничә еллар элек башлаган хезмәтенең соңгы битләрен язарга өметләнеп, буш вакыт табылуга сөенә-сөенә хөҗрәсенә ашыкты.

— Ай-һай, Мөхәммәдьяр, бигрәк тырышасың. Кизү көнне дә ял итмисең. Хәлфәлекне ычкындырасың килми, ахрысы,— дип иптәшләреннән кемдер көлеп тә калды. Әмма егет аларга игътибар итмәде. Күңелендә бик матур сурәт — лалә чәчәкләреннән таҗ рәвешендә хәрефләр тезү уе туган иде. Каурыен яшел карага манып, ак кәгазь битенә нәни генә яфракчыклар төшерергә кереште. «Менә озакламый китап әзер булыр, йокысыз төннәрнең таҗы шикелле иттереп, аска «Тәммат-тәмам» дигән сүзләр язылыр, аскарак төшереп «Шәһре Казанда тугыз йөз дә кырык икенче сәнәдә башланып, кырык дүртенче сәнәдә тәгәлләнде, алла колы ятим Мөхәммәдьярның күз нурлары түгелде» дип өстәп куярга онытмас. Инде тәгәлләнеп килүче шушы хезмәт, иҗат газаплары иртәнге очрашуны онытырырга мәҗбүр иткән дә иде инде.

* * *

Тышкы дөньядан калын таш диварлар белән аерылган җир асты хөҗрәсендә тынлык. Урам шау-шуы, атлыларның һай-һулап чаптырып үтүе дә, дистәләрчә кырык тартмачыларның малларын мактап кычкырышуы да, яшь-җилкенчәкнең ваемсыз уен-көлкесе дә ишетелми. Шылт иткән тавыш та юк. Бары тик бакыр аждаһа башларындагы шәмнәр генә ара-тирә чертләп куя.

Куе тынлыкта Кол Шәриф борынгы бабаларыбызның рухлары белән сөйләшә, аларның күңеленә ачкыч эзли, киләчәкне бага. Авыр, ай-һай авыр, мәшәкатьле, газаплы эш ул.

Кол Шәриф киштәләрнең иң өстәгесеннән такта белән тышланган берничә китап алды һәм өстәл янында җайлап

урнашкач, аны ачаргамы-юкмы дигәндәй уйга калды. Читтән карап торган кеше аны йоңыга талган дип фараз итәр иде. Ләкин Кол Шәриф йоклаңый, йоклый алмый. Дөньяны борчулы уйлар басты. Алар тынгылык бирми, көнен дә, төнен дә миен бораулый, ике чигәсен авырттырып кыса, диван әһелләреннән, бөтен ханлыкның акыл ияләреннән ала алмаган җавапны каян табарга кирәклеген эзләп бәргәләнергә мәҗбүр итә.

Бабаларыбызның сыеныр, туеныр урыны — газиз җиребезне, ил-көнебезне, аллаһы тәгалә рәхмәте илә Мәхәммәт галәйһиссәламгә согынган илдәшләребезне ни көтә?! Киләчәкне, еллар гарасаты артынданиләр торганлыгын аңлау сәләте адәми затларның бик сирәкләренә генә бирелә. Моны яхшы белә имам-хатиб. Төп шартын да тәгаенлый. Анысы — үткәннәрне өйрәнү, танып белү, кемлегеңне төшенү. Әле дә хәтерендә: яшүсмер егет чаклары иде. Казанның атаклы мәдрәсәсе — хан сараена турыдан-туры буйсынган гали уку йортында шәкертлек узган көннәр. Йөзьяшәр имам-хатиб мөдәррис Каюм ага нишләптер Шәрифне якын итә, башкалардан аралап үз хозурына чакыра торган иде. Киңәшләре диван әһелләре, галиҗәнаб хан хәзрәтләре тарафыннан да олуг изгелеккә саналган мәртәбәле затның үзенә аерым игътибары егетне баштарак бераз сәерсендерә, шәриктәшләреннән читләштерә иде. Ул моның сәбәпләрен белми, эчтән генә горурлана, үзен башкалардан өстенрәк куеп сөйләшә торган булып китте.

Каюм ага сынап йөргән икән. Көннәрдән беркөнне янә хозурына китертте. Ак сакалын бармаклары белән аралап, шактый озак күзләренә карап торды, карашы бәгыреңә үтәрдәй дәрәҗәдә үткен, аннан дулкын-дулкын каты, кырыс, буйсындыргыч нур бөркелә кебек иде. Егет җир ярылса җир тишегенә кереп китәрдәй булып кызарды. Каюм ага, әйтерсең, аның миенә үтеп кергән һәм берәмтекләп-берәмтекләп аның бөтен фикерләрен, һәрбер күзәнәген капшый иде. Тамырларында әллә нинди талгын агым хасил булды, ихтыяры сынды. Ул үзен мәгънәсез буш бер кешегә генә түгел, хәтта суы агызылган балчык кувшинга тиңли башлады.

Остазы ачуланмады, күтәрелеп бәрелмәде, әмма сүзләре бәгыреңне телгәләрлек кискен иде.

— Шәрикләреңнән үзеңне өстен куеп масаюдан күзеңне кан, йөрәгеңне май басар, рухың тупасланыр. Әлегә күңелләрегез язу язылмаган ак кәгазьдер. Аңа ни-нәрсә теркәлү хәлфә-мөгаллимнәрдән генә тормый. Аң бул: ма-

сайган җанга гыйлем иңми, керсә дә сеңми, сеңсә дә файда бирми...

Тораташтай каткан Шәриф керфек селкетергә дә базмый, күзләре ирексездән остазына төбәлгән. Ул ни кылырга да белми, ихтыярсыз хәлдә түземсезләнеп аның тагын нинди авырттыргыч яралар ясаячагын көтә иде.

Каюм ага чәмчәләп чигелгән күн мендәре өстендә җайлабрак утырды, тавышы йомшый төште, ияге белән ымлап шәкертен каршындагы утыргычка чакырды.

— Инде тыңла,— дип дәвам итте ул.— Күп сынадым, холык-фигылеңне өйрәндем, гакылың сәламәт, рухың таза икәнен белдем. Әйткәннәремне мыегыңа чорна да калганнарын күңел дәфтәреңә теркә.— Аның тавышында тантаналы аһәң сизелә башлады.— Әйе, мәңгелеккә теркә! Бу дөньяда мин дә күп тормам, тапшырып каласыларымны сиңа җиткерергә насыйп булгандыр, күрәсең... Бәлки, иртәрәктер дә... Ләкин ни кыласың, гомер озынлыгы безнең кулда түгел. Варисның һәммәсен дә белүе шарт...

Остаз сөйли дә сөйли, тәфсилләп аңлата, төшендерә...

«Каюм ага, нигә алай дисең, мең яшә, шәкертләреңнең яратуы, сөюе, ихтирамы яшәтсен сине. Синсез нишләрбез»,— дип эндәшмәкче булды, әмма теле аңа буйсынмый, башында чагылган уй, яшен тизлеге белән, каядыр артка чигенеп тә өлгергән иде инде. Ул үзен чишмә улагына куелган кувшин кебегрәк хис итә башлады, аккан су йотылып аңа керә, тамчысы да читкә түгелмичә, тулганчы шунда торырга, сакланырга тиеш иде кебек. Бу аның ихтыярыннан тыш эшләнә, тула барган саен тамырларында талгын рәхәтлек, миендә сафлык арта бара.

Изгеләрдән булгандыр Каюм ага. Шул сөйләшүдән атна-ун көн үттеме-юкмы, Казан халкы кан-яшь түгеп имамхатибның җеназасын озатты. Урыны җәннәттә булсын!

Әйе, бик озак, бик күп, бик тәфсилләп сөйләгән, төшендергән, дөньяның бихисап үзлекләренә күзен ачкан иде Каюм ага. Хәтер дәфтәрендә аларны актара башласаң, тәүлек түгел атналар да җитмәс... Кол Шәрифне мәгарәгә истәлекләргә бирелү теләге түгел, ә соңгы бер серне аңларга тырышу, киләчәккә күз салырга омтылу китерде.

— Тарих — тәгәрмәч ул,— дигән иде остаз ага.— Күпме генә әйләнмәсен, тәгәрмәч җиргә кат-кат бер үк төше белән баса. Мисал өчен, әйтик, тәгәрмәч тугымын түгәрәкләп бөгәләр. Телисеңме-теләмисеңме, тоташтырган җирдә җөй кала. Яма-ямама, никадәр шомартып тигезләмә, җөй — җөй инде ул. Тарихта да шулай. Аның тәгәрмәчендәге

җөйнең еллар агымында кай җиргә басасын төшенгән адәм киләчәкне дә алдан күрә белер. Бу — сирәкләргә генә бирелә торган зирәклек, илаһи хасият. Дөнья, галәм түгәрәге — охшашлыгы булса да, арба тәгәрмәче түгел. Күңел сизгерлеге, гакыл сафлыгы, гыйлем вә зирәклек, тирә-юнеңдәге вакыйгаларда тарихи эзлеклелекне танып белү зарур. Андый затларга хак тәгалә пәйгамбәрлек хасияте бирер диелә каләме-шәрифтә.

Эшемне ахырына кадәр җиткерергә язмаган икән,— дип уфтанды ул.— Шул җөйнең кайдалыгын гакылым колачлый алмады. Сиземлим, еллар-гасырлар-дәверләр агышында, чорлар алышынуда бер-бер гарасат, өстебезгә афәт якынлашуын тоемлыйм, әмма дә ләкин тәгаен генә әйтә алмыйм. Ул нә булыр — табигать казасымы, аллаһы тәгалә җибәргән җәзамы, кыргый кабилә-ыруларның көчәеп, үрчеп, саранча өередәй бер диңгездән икенчесенәчә бар терәклекне ачка тилмертеп, гөлбакчаларны туздырып, коры сөяккә калдырып яу белән үтүеме — әйтә алмыйм. Бәлкем, язмыш сиңа мәрхәмәтлерәк булыр.

...Кол Шәриф дөнья ваклыкларыннан ваз кичеп шуларны аңларга, Каюм ага гакылы колачлый алмаган дөнья әйләнешенең агышына кереп карарга тели. Хәерле сәгатьтә! Борынгы гакыл ияләреннән калган, саргайган китап битләрендәге гыйбарәләрне, кинаяләп, читләтеп әйтелгән акыл хәзинәсенең тылсымына төшенергә тырышып утыра-утыра ул вакыт узганын да, көнне төн, төнне көн алыштырганын да тоймады. Шәм артыннан шәм алышынды. Кинәт аның күз алды яктырып китте, әйтерсең лә башын кысып торган тимер кыршауны алып ташладылар, арыш басуы өстендә уйнаган аҗагандай булып алдында төрле төсләр биеште һәм... ул галәм чиксезлегенә читтән баккан бер илаһи зат шикелле кеше акылы колачлый алмаслык киңлекне күз алдына китерде, камаштыргыч яктылыкка чыдый алмый керфекләрен йомды. Ләкин бу төсләр уены, аклык тышкы дөньяда түгел, аның үзендә, миендә чагыла, көчле давылдан соң кире ярга ятучы дулкыннар каплаган офык ачылгандай, күз карашы, акыл карашының җиһанны иңләве кебегрәк сәер бер халәт иде.

Уйларының очына чыкты түгелме соң?! Каюм ага хәтле Каюм ага хәзрәтләре төшенмәгән сер аңа чишелдеме?

Кол Шәриф ашыгып, каударланып урыныннан күтәрелде һәм авыр сандыкларның берсен ачып, борынгы дисбе — аркылысы ике илле чамасы зурлыктагы бакыр түгәрәкне кулына алды. Яссы табага охшаш дисбенең уртасына канат-

ларын җәйгән сәмруг кош сурәте, аның әйләнәсендәге кече түгәрәккә җиде пәйгамбәр, аннан соңындагы зур түгәрәккә исә янә унике илаһи затның рәсеме төшерелгән иде. Сурәтләр үзләре тагын ярым ялпак түгәрәк эченә урнаштырылып, аларның әйләнәсен билгеләүче сызыклар сәмруг кош янындагы түгәрәк белән тоташа һәм ишелгән бау җепселләре, шикелле бер-берсенә үреләә, әмма беркайда да өзелмичә тоташ бербөтен хасил итә иде. Сурәтләрдән соң бөтен дисбенең каймасы буенча хәрефләр тезелеп киткән. Бу — борынгы, бик борынгы, затлы, кыйммәтле әйбер. Аның Казан китап йортына кайчан, ничек килеп эләккәнлеген, кыйммәтенең нәрсәдә икәнлеген, сурәт вә язуларның ни-нәрсә аңлатканлыгын беркем дә белми. Әмма кайчандыр китап саклаучылардан калган гадәт буенча аны үтә кадерләргә кирәклеген беләләр, буыннан-буынга вәсыять әйтеп, мирас итеп тапшыралар иде.

Гарәп теленең барлык шивәләрен, төрки ыруларның һәммәсен биш бармагыдай белгән, рум вә славян кабиләләренең телен дә чит итмәгән, кояш батыш ягындагы халыклар теленнән дә мәгълүматлы Кол Шәриф бу хәреф-тамгаларның мәгънәсен аңлый алмады. Бернинди ара калдырмыйча тоташтан үрелгән хәрефләрне кай җиреннән укый башласаң да йә яңа мәгънә төсмере, йә аңлаешсыз сүзтезмә килеп чыга кебек иде. Ләкин белкевар сорауларына җавапның нәкъ менә шушы дисбедә, дөнья тәгәрмәчен сынландыручы тылсымлы әйбердә икәнлеген чамалый. Китаплар шуңа ишарәли, ничек икәнлеген күрсәтмәгән хәлдә, дисбе белән эш итәргә киңәш бирә. Бәлки, әлеге китапларны язучылар үзләре дә инде ул серне югалткан булгандыр, төгәл һәм анык киңәш бирә алмаулары шуның дәлилеме әллә?! Ничек кенә булмасын, дисбедә теләсә кем күзеннән, аңыннан яшерелгән мәгънә ята. Юкса, буыннан-буынга тапшырылмас, күз карасыдай сакланмас та иде.

Үзе дә аңламаган теләккә буйсынып, Кол Шәриф мәгарә түрендә читләр күзеннән яшереп эшләнгән ишек янына килеп басты. Аның барлыгын белмәгән кеше монда һичнинди ярык-фәлән күрмәс, ишек бөтен дивар шикелле үк калын ташлардан ясалган һәм мәгарәнең бер ягын тәшкил итә иде. Ул дивардан чыгыбрак торган кечкенә ташка таянды да көч белән этә башлады. Эчтә нәрсәнеңдер гөрелдәгәне, шыгырдап шуышканы ишетелде һәм диварның бер өлеше артка чигенеп, кеше сыярлык ярык хасил булды, шәмнән сирпелгән сүрән яктылыкта кое сыман караңгы бушлык, өскә күтәрелгән таш басмалар күренде. Кол Шә-

риф дисбене тотып ярыктан эчкә атлады, күптән кеше аягы басмаган ташлар буйлап манара эченнән күтәрелә башлады.

Төн уртасы. Күзгә төртсәң берни күренмәслек караңгы иде. Күк гөмбәзендә меңнәрчә йолдызлар җемелди. Казан йоклый. Ник бер эт өрсен дә адашкан җәяүленең тавышы ишетелсен. Каланың иң югары ноктасына күтәрелгән Кол Шәриф үле тынлыктан, күңелдә шом уятучы дәһшәтле маһурлыктан калтыранып куйды. Әйтерсең, җир йөзендә барча җан иясе үлеп беткән, күк белән җир арасындагы бушлыкта бары тик бер тере җан — ул гына калган. Күзләрен күккә төбәп ул Тимер казык йолдызын эзләргә керешкте. Күк гөмбәзенең нәкъ уртасында, баш очында гына салкын нурлар чәчеп җемелдәгән йолдызны тапкач, җиңел сулап куйды һәм дисбене итәге белән сөртеп, аны манара дивары өстенә куйды, кулындагы шәмне якынрак китереп, хәрефләрнең серен белергә теләгәндәй тагын аларга текәлде. Озак, бик озак карап торды Кол Шәриф. Һәм эчке бер сизенүгә буйсынып дисбене акрын гына кояш чыгышыннан кояш батышына таба әйләндерергә керешүен дә сизми калды. Шунда әллә нәрсә булды, Тимер казык йолдызыннан төшкән нурлар чагылдымы, әллә талгын исеп куйган җилдән шәм ялкыны тибрәлдеме — дисбе өслеге әкрен генә яктырып куйды. Янәдән дисбене шул хәленә кайтарды — яктыру кабатланды гына түгел, ә томан эчендәге шикелле генә күренгән сурәтләр ачыклана төште, алар җанлангандай күз алдында төрле төсләргә керә башладылар.

Кол Шәриф тирә-юньдәге бер нәрсәне күрмәс хәлгә килде, бөтен барлыгы, игътибары, акылы шушы сәер яктырышка юнәлде, миен томалаган томан таралып, күзе яңадан ачылгандай булды.

Борынгыларның дөньяны танып-белү серләрен туплаган дисбе, исемнәре, кемлекләре нәмәгълүм акыл ияләренең сере, ниһаять, аңа да аңлашыла башлады. Юк, бу газаплы уку, тырышу түгел, урман сукмагыннан киң аланга килеп чыккандагыдай күз күременең киңәюе, акылның галәм белән бер сулышта йөзүе шикеллерәк, сәер дә, аңлаешсыз да бер халәт иде. Гүяки кемдер аңа салмак тавыш белән пышылдый да пышылдый, аяк астында җәйрәп яткан җир йөзенең, анда яшәүче, көн күрүче кавемнәрнең үткәнен, язмышын тасвирлый иде. Тик бу тавыш читтән, йә булмаса күк гөмбәзеннән килми, аның үзенең эчендә, үз миендә яңгырый иде. Хәзергә алар әле өзек-өзек, ерткаланып актарылучы болыт йомарламнары кебек агалар да агалар,

аларны тоташтырыр, бер-беренә ялгап гали манзара тудырыр өчен белем вә тәҗрибә кирәк.

«Җир йөзендә барысы да кабатлана,— дип пышылдады тавыш. Аны Каюм аганыкына охшатып, Кол Шәриф сискәнеп китте.— Галәм чиксез бер түгәрәктер, әйләнгән саен яңа чор туадыр. Әмма аң бул, ул һәрчак яңа сыйфатта, яңа халәттә кабатлана. Белеп тор, асылы, сәбәпләре бердер. Бу дөньяда бар нәрсә дә бүленәдер, бүленгәне янә бүленәдер, анысы янә бүленәдер... Шулай чиксез дәвам итәргә мөмкин... Сезгә, көн ваклыкларыннан, ачлык һәм үлем тырнагыннан качарга тырышып, тамак ялына гына яшәгән адәмнәргә бик азы, меңнәрдән меңнәренең бер микъдары гына мәгълүмдер. Ә галәм бөек бер тоташлык. Аның үз кануннары, үз агышы, үз әйләнеше бар. Сез әлегә бары тик елларны гына беләсез, аның өч йөз алтмыш көннән, унике айдан торганлыгын, айларның утыз көнгә тиңлеген тәгаенлыйсыз*. Елларны гасырларга берләштереп, үзегез өчен иң зур сан — йөзне саныйсыз. Кеше гомере бер мизгел. Үлемсез затлар әйтер: галәмнең бер әйләнеше өч йөз алтмыш елга тиң. Үз чиратында ул да унике фасылдан торадыр. Ләкин болар да чик түгел, галәм әйләнешенең сезнең акыл колачлый алмас тагын үз фасыллары бар. Кешелек дөньясының үсешен әйләнеш тарихын белгәннәр генә төшенер, азмы-күпме күзаллау сәләтенә ия булыр, яшәеш һәм һәлакәтнең галәм әйләнеше фасылларына бәйлелеген аңлау дәрәҗәсенә күтәрелер».

Кол Шәриф баш миендә яңгыраган бу тавышны йотылып тыңлый, һәр сүзен, һәр өтерен сеңдереп калырга тырыша.

— Ул фасылларның башы кайда? Каян чыгып исәпләргә?

Бу сорауны да ул теле белән әйтми, уйлары гүяки, турыдан-туры тавыш иясенә барып ирешә һәм шулай ук тавыш ярдәменнән башка гына җавабын да ала иде.

— Анысы әһәмиятле түгел,— диде тавыш.— Сез елларны үзегезчә исәплисез, аннан ни аерма. Җүмәдиял ахирә** барыбер яңадан җүмәдиял ахирәгә барып тоташа. Иң мөһиме — фасылларның кабатлану эзлеклелеген белү. Бусы — күп нәрсәгә ачкыч.

— Кешелек тарихы гарасатлар, афәтләр, һәлакәтләр-

---

* Борынгы мөселман календаре елларны, айларны шулай исәпләгән.

** *Җүмәдиял ахирә* — мөселман календарендә ай исеме.

дән тора. Алар да шул фасылларга бәйлеме, бәйле булса — безне алда ни көтә? Котылар чара бармы? Ни кылыйк? Гөнаһларыбыз өчен җәза шулмы?!

— Гөнаһны да, җәзаны да кеше үзе уйлап чыгарган. Табигатеңә хас булмаганны кылмасаң, гөнаһысы да юктыр. Тик моны аңлау өчен гаять күп, сезнең төшенчәләр белән әйтәм, гаять тә күп еллар агышы кирәк. Анысы — киләчәгегез. Ә нәрсә көткәнен мин әйтә алмыйм, киләчәгегезне сез үзегез корасыз. Бүгенгегез, үткәнегез белән аңа нигез саласыз. Котылу юлын да үзегез табарга тиеш. Мин ачкычын бирдем. Кисәтә генә алам: галәм фасылларының билгеле бер агышында адәм балаларына курку иңә, затсызлык, кансызлык арта, алар үз табигатенә, хасиятенә тәңгәл булмаган эшләргә бата. Сез аны гөнаһ дисез. Шуннан сакланыгыз.

Кол Шәрифнең күз алдында берсеннән-берсе дәһшәтле, тәнеңдә кан агышын туктатырлык тетрәндергеч сурәтләр пәйда була башлады. Әйтерсең, бөтен кешелек тарихы канлы сугышлардан, җан кыюдан, үтерү-көчләүләрдән тора. Офыктан-офыкка утлы өермәләр котырып узды, авыллар, калалар өстендә дәһшәтле ялкын күтәрелде. Дисбенең һәр әйләнеше саен бу гарасатлар кимемени генә түгел, тагын да коточкычрак, канлырак була бара иде. Тарих һәм кан! Кан! Кан! Кан! Җир йөзендә бу газапларны, адәм баласының бер-берсен суешын туктатырлык, күзен ачарлык көч юк микәнни соң?!

Дисбе салмак кына әйләнә дә әйләнә. Менә һуннарның утлы ташкыннары юлындагы бар нәрсәне яндырып, изеп, сытып, канга батырып узды. Хәрабәләр өстендә бөек һун дәүләтенең әләмнәре җилфердәде. Телләрдә бер сүз — Аттила! Аттила!

Тагын бер әйләнеш. Галәм фасылы мизгелләрен санаучы өч йөз дә алтмыш ел. Һуннар дәүләтенең таланган, күмергә, көлгә әйләнгән гөлбакчаларында хазарлар каганлыгы хакимияте. Җир өчен, мал-мөлкәт өчен, байлык өчен, үзен алланың җирдәге вәкиле дип игълан иткән комсыз затларның мин-минлеген котырту, аның колагын ялагай тәгъбирләр белән иркәләү хокукы өчен үзара ызгыш-талаш, якыннарыңның аркасына кадалган хыянәтчел хәнҗәр...

Дисбе әйләнеше инде Кол Шәрифкә таныш чорларга якынлаша. Офыкта гайрәтле Чыңгыз хан яулары, күз ачып йомганчы дистә чакрымнарны уктай очып узучы тыелгысыз атлылар ташкыны. Болгар, Биләр, Сувар — бөек бабаларыбыз корган кальгалар янында ут уйный, кеше язмышлары

канлы өермәгә уралып тузан бөртегенә әйләнә, күккә каргыш, нәләт ургыла.

Кол Шәриф тетрәнеп дисбе әйләнешен күзәтә, аны туктатасы, бу дәһшәттән, җирәндергеч канлы суешлардан, колагында яңгыраган елаш-каргышлардан арынасы, ял итәсе килә. Әмма бу аның ихтыярында түгел, җаны-тәне тартышса да, тарихи дөреслекне, кешелек дөньясы үткән чынбарлыкны каплап та, бизәп тә, юкка чыгарып та, үзең теләгәнчә яңабаштан язып та булмый. Тешеңне кысып түз, йөрәгеңне учыңа кыс! Түз! Түз! Түз! Болар барысы да синең, синең бабаларың, бабаларыңның бабаларының бабалары үткән юл. Кеше гомере бер мизгел. Бу гарасатларда исә галәм әйләнеше фасылларының мизгелләре.

Сурәтләргә, ниһаять, серен ачкан тылсымлы язмаларга икеләнү, тетрәнү, аяныч үкенү һәм өмет, ышаныч белән текәлгән Кол Шәрифнең бүгенге көнгә, киләчәккә күз саласы килә Киләчәк пәрдәсенең бер читен генә күтәреп алга караш ташлыйсы иде... Шул ук вакытта күңелен шом баса кирәкме? Нигә җаныңны кыйнарга! Әгәр вакыйгалар көт кәнчә, күз алдына китергәнчә, өметләнгәнчә булмаса?! Аһ, ни аяныч! Ул чакта яшәү мәгънәсе каламы соң?! Күрәсең, алдагы көнеңдә ни-нәрсә булачагыннан, үзеңне ни көтәчәгеннән хәбәрсезлек — яшәүнең асыл кануныдыр! Әгәренки белсәк, ул коточкыч афәтләрне көтеп тормас идек, ризалашмас идек. Күпме кеше муенына элмәк салыр, Иделнең караңгы чоңгылларында яшәү белән хушлашыр иде. Котылгысызлыктан чыгу, киләчәгеңнән, күрәчәгеңнән качу юлы бармы? Әгәр булса, ул котылгысызлык дип аталыр идеме?!

Ил агасының миендә мең-мең сорау бәргәләнә. Ә дисбе туктамый. Менә-менә галәм әйләнешенең яңа фасылы башланачак. Ул безгә нинди канлы афәтләр белән яный. Әллә кан коюдан, үчлектән, хөсетлектән, хыянәттән туйган адәм балаларын тыныч, имин еллар көтәме?!

Кинәт Кол Шәрифнең йөзе агарып китте, сул кулы белән күкрәгенә ябышты. Томан эченнән шәйләнгән сурәтләрдә канлы байраклар айкала, сөңге очына котырган эт башларын чөйгән атлылар чабыша, таш урынына адәм башлары түшәлгән юлдан карчыгадай үткен карашлы, кыяфәтенә усаллык, шик, курку һәм бер үк вакытта нәфрәт белән кискен кыюлык сеңгән яңа хөкемдар күтәрелеп килә иде.

Белде, күзләрен кан-яшь томаласа да, Кол Шәриф афәтнең кайсы яктан янавын күрде. Сизенүе юкка түгел икән!.

Йөрәгендәге әрнүгә, авыртуга чыдый алмый ул аркасы белән манара диварына сөялде, авызын ачып еш-еш сулый башлады. Аңа һава җитми, төн кочагына сураеп сузылган биек манарада гына түгел, бөтен галәмдә кысанлык, тарлык... Күк гөмбәзе кечерәеп, тараеп кысылганнан-кысыла, менә ул инде манара очына терәлде, берничә мизгел узар да колач җитмәс таш кирпечләрне сытып изәр, дәһшәтле авырлык астында сөякләр шыгырдар, таш уалып комга әйләнер, тимерләр сытылып коймак булыр.

Кол Шәрифнең дисбене изеп, сытып манара башыннан чүплеккә тондырасы, йә булмаса ажгырып торган бакыр мичәнә ыргытасы, юк итәсе, тузанга әйләндереп, аны җиде юл чатында җилләргә очырасы килә башлады. Ләкин шул ук вакытта ул дисбенең бер гаебе юклыгын да, аның бары тик көзгедәгедәй дөньялыктагы кануннарны, аларның бер әзлеклелектәге агышын гына чагылдыруын да белә иде. Күпме вакыт үткәнен абайламады, күңелендәге шом өмет белән алышынды. Алда ни көткәненнән хәбәрдарлык моңа юл куймау өчен көрәшкә, тешең-тырнагың белән аңа каршы торырга чакыра түгелме соң?! Юкса, дисбенең тылсымы үткәнеңнең генә түгел, киләчәкнең дә пәрдәсен ачмас иде. Илаһи затлар кисәтә. Аны, Кол Шәрифне, Идел буеннан Кырымгача, Себергәчә сүзе үткән ил агасын кисәтә, күрсәтә, аңа өмет баглый. Шулайдыр!

Акылы, күңеле тынычлана төшеп, яңадан күз салганда дисбе тагын да ераграк киләчәккә төбәлгән әйләнешенә кереп килә иде инде. Имам-хатибның чәчләре үрә торды: киләчәк кешеләре бүгенгеләрдән мәрхәмәтсезрәк, явызлык, хөсетлек, усаллык һәм ерткычлыкта күз алдына да китереп булмаслык яңа ысуллар уйлап чыгарганнар, ахрысы. Томан эчендәге күренешләрдә ут, ялкын, үлем сибүче үзйөрешле тимер манаралар, очып үткән саен янартаулар актарылгандай җир өстен кара төтенгә күмеп тетрәтүче тимер кошлар... Агулы ачы җилләр сызгыра, чәнечкеле тимер чыбык белән чорнап алынган җәйрап ятучы карлы далалар, зәмһәрир суыгында ярым ялангач ирләр, хатын-кызлар, балалар... Бер сынык икмәккә тилмереп аһ оручы, ләгънәт-каргыш яудыручы шыр сөяккә калган адәм уллары... Көтмәгәндә тигез җирдә атылган янартаулар... Тоташ-тоташ шәһәрләрнең парга әйләнеп күккә ыргылуы... Афәт! Гарасат!

Артыгын карарга көче, түземе җитмәде, Кол Шәриф дисбене тартып алды да күкрәге белән каплады. Иреннәре

бертуктаусыз «Юк, юк! Җитәр! Боларны белгәннән белмәгәнең мең артык»,— дип пышылдады.

Аның кискен хәрәкәтеннән туган җилдән шәм сүнде, тирә-як куе караңгылыкка чумды. Ул капшанып баскычка таба атлый башлаган җиреннән тагын туктап калды һәм кискен бер карарга килеп, дисбене янә диварга куйды. Теләсә ни бәрабәренә явыз хөкемдарның кем буласын, кемнән сакланырга кирәклеген беләсе килә иде аның.

Дисбедә сурәтләр яңармады. Ул, әйтерсең, гап-гади бер бакыр табага әверелгән иде. Кол Шәриф озак көтте, алай да, болай да әйләндереп карады, әмма әле күптән түгел генә сихри балкышка чумган тәлинкәдән хәтта кыштырдаган аваз да чыкмады.

Күк гөмбәзенең куе каралыгы сыек шәмәхә төс белән алышына башлады, җемелдәшкән бихисап йолдызлар бер-бер артлы эреп юкка чыкты.

«Күзеңә генә күренгәндер. Ышанма! Гап-гади бакыр тәлинкә ни әйтсен. Болар хыялыңда туган сурәтләр генә иде»,— дип пышылдады эчке бер тавыш. Шунда ук аңа икенчесе каршы төште: «Киләчәкне генә түгел, үткәнне дә болай ачык күзаллау өчен пәйгамбәр сизгерлеге, зиһен, кайчандыр җир йөзендә яшәгән йөзләрчә-йөзләрчә кавемнәрнең туплаган гыйлеме кирәк. Ә син аларны моңарчы колачлый ала идеңме? Ышан! Борынгылар гап-гади тәлинкәне күз карасыдай кадерләп сакларга васыять әйтмәс иде, бер-бер хасиятен тапмасалар буыннан-буынга тапшырмаслар иде. Һичшиксез, дисбенең акылга сыймас нindидер тылсымы бар. Пәйгамбәрләрдән калган, моңарчы асылын аңларлык кеше табылмаганга гына сандык төбендә яткан хәзинә түгелме ул?!»

Онытылып китеп, Кол Шәриф бармагын дисбе уртасына куйганын да, аны әүвәлгечә әйләндерә башлаганын да сизми калган иде. Кинәт тәлинкә каймасындагы хәрефләр бер-бер артлы җемелдәп алды. «Йай, уау, дал*...» Хәтереннән бөтен телләрне, шиваләрне үткәрде, әмма мондый сүз яисә исемнең ни-нәрсә аңлатуын тәгаенләрлек, аларның серен чишәргә юл күрсәтерлек төсмер тапмады. Нәрсәгә ишарәли бу дисбе? Нәрсә ул И У Д? Әллә И В Дмы? Әллә башкача бер-бер хикмәте бармы?

Бармагын алмаган көйгә әйләндерүен дәвам итте, дисбе

---

* *Йай, уау, дал* — гарәп әлифбасында И, В, Д авазларын белдерүче хәрефләр.

читендәге хәрефләрдән тагын өчесе — йай, уау, дал җемелдәп алды. «Ике әйләнештә дә бер үк тамгалар!.. Галәм фасылларының икесендә дә «йай, уау, дал»дан сакланыргамы? Нәрсәне аңлаталар соң бу каһәр суккан билгеләр?» Үзенең тылсымлы дисбегә каһәрләү әйтүен абайлап имәнгән Кол Шәриф тиз-тиз генә кабатларга ашыкты:

— Әстәгыфирулла тәүбә... Әйттем исә кайттым. Тәүбә, тәүбә, тәүбә!

...Таш диварларда шәм ялкыны шәүләсе. Сулыш җиленнән тибрәнгән ялкын телләре әллә нинди хыялый сурәтләр тудырып талпыналар, тагын туктап калалар, тагын биешәләр. Кол Шәриф утырган җирендә салмак чайкала-чайкала уйга чумган. Авыр кичерешләрнең, билгесезлек пәрдәсен күтәреп алга — киләчәккә күз салырга теләүнең газаплы мизгелләре сәгатьләргә тоташа, сәгатьләр көнгә җыела, ә борчыган, бәгырен актарып ташлаган сорауларга җавап юк.

Йай, уау, дал!..

Яисә «Дал, уау, йай»мы?

Әллә «Уау, йай, дал»мы?

Өч хәрефтән ничә төрле нисбәт ясап була, аларны ничә тәртиптә тезәргә мөмкин? Кайсысы дөреслеккә туры килә?!

Ни өчен дисбедә канлы хөкемдар үзе күренмәде соң әле? Башка сурәтләрдә тоташ яу, кан, ут иде, Аттила һәм Чыңгыз шәхесләре гәүдәләнде. Кем соң бу И, В, Д? Хәреф тамгаларын авазга әйләндерүгә ул сискәнеп китте, өстенә салкын су сипкәндәй сикереп торды. Ниндидер эчке сизенү белән ул дөрес юлга керүен чамалап алган иде. Тукта! Тукта! Ашыкма! Хәрефләр әле туачак хөкемдарның исеменә ишарәли түгелме?! Афәт, гарасат, ил-көнне канга батырачак куркынычның кай яктан янавын инде күптән абайлаган Кол Шәриф бары тик хөкемдарның нинди нәселдән киләчәген генә белергә тели, шуңа баш вата иде.

Уйларын кайдан башлаган булса, янә шул урынга кайтып төште. Киләчәкне белү өчен бүгенгене, чынбарлыкны төшенергә, көчләр һәм сәяси халәтне биш бармагыңдай белергә кирәк. Канлы хакимиятләр барысы да сәясәттән, кемнеңдер тыелгысыз нәфесеннән башлана. Ә хәзергә дөнья хәле борчылырлык түгел, көчләр нисбәте бер чама, Казанның ныгып, мал вә гайрәт туплап нык утырган чагы. Аллага шөкер, тәхеттә Сафагәрәй хан! Иншалла, низаг-бәхәскә чик куелыр, мәмләкәт бакчалары имин һәм бәрәкәтле булыр. Дөрес, Сафагәрәй Кырым-йортның Дәүләт-Гәрәйләр нәселеннән. Бер хәрефе аңа да туры килә кебек... Лә-

кин, Кол Шәрифнең белә-белгәннән, тарих төпкеленнән өйрәнгәненнән Казанның дөнья хакимлегенә омтылганы юк иде.

Ничек кенә тырышмасын, Кол Шәриф Дәүләт-Гәрәйләр һәм яңа хан нәселеннән өч шартка да, ягъни өч хәрефкә дә туры килерлек кешеләр таба алмады. Бәлки әле ул тумаган, ана карынында гынадыр?!. Ләкин, туган һәм туасы варислар арасында, Кырым, Казан, Әстерхан ханлыкларында, Нугай урдасында атасы яисә бабасының исеме «В» хәрефенә башланганы юк иде. Солтан Төркиясен, Бөек Литва кенәзлеген хәтереннән үткәрде... Әмма Казан мәмләкәтенә азмы-күпме кагылышы булган бу дәүләтләрдә дә өч шартны үтәрлек хакимнәр, шаһзадәләр юк иде.

Кол Шәрифнең көчәеп, үсеп килүче Мәскәү кенәзлеге хакында уйлыйсы килми, «Кирәксезгә лыгырдаган шайтан чакырыр» дигән тәгъбирне истә тотып, уйларына күләгә төшерүче фикерләрне куарга тели. Ир җенесендәге һәр икенче адәмнең Иван икәнлеген белгәнгә күрә, мондый мөмкинлекне якын да китерәсе килми иде. Әмма, ничек кенә булмасын, дөнья сәясәтеннән, ханнар, кенәзләр, корольләр, патшалар-хөкемдарлар тормышы җәһәтеннән, ул мәмләкәтләрдәге сарай ызгышларыннан хәбәрдар гыйлем иясе күрәзәлегенең Мәскәү елгасы сазлыклары арасында күтәрелеп килүче яңа дәүләткә юнәлүен сизми түгел иде, әлбәттә.

Данила кенәз нәселеннән, Иваннар токымыннан янаган дәһшәтле куркынычны булдырмау хакына, әгәренки юравы юш килсә, юлындагы бөтен-бөтен халыкларны, үтеп кермәслек кальгаларны яндырып, канга батырып узачак затның мәкеренә, усаллыгына, чик белмәс җаһиллегенә, явызлыгына киртә куярлык көчләр табарга кирәк иде.

«Йа алла! Сабырлык, түземлек бир! Белгәнеңне, сизенгәнеңне теш арасына кысып чыдарлык көч бир! Кара төннәргә уралып галәм фасыллары үтәр дә китәр, якты көннәр туар. Этләргә каласы Казан* алардан арыныр, бетмәс, чорлар томаныннан яктырып, ялтырап яңадан күтәрелер, койрыклы йолдыз шикелле эзсез янып югалмас, галәм

---

* Казан шәһәре салыну тарихына караган риваятьтән өзек.

«Еланнарны кырып бетергәч, шәһәр төзи башлаганнар. Хан мәчет төзергә кушкан. Ул эшчеләргә әйткән: «Нигез салганда, сезнең яныгызга кем беренче булып килсә, җиргә шуны терелэй күмегез».

Төзүчеләр янына хан малае килгән. Алар аны терелэй күмәргә батырчылык итмәгәннәр, аның урынына эт күмгәннәр. Бу турыда белгәч, хан: «Димәк, минем шәһәрем этләргә эләгер»,— дигән.

әйләнешенең яңа фасылында көлдән үсеп чыгар. Чөнки кальга астына эт салынса, мәчет астына тегермән ташы* салынган. Этләр үләр дә бетәр, таш калыр, Амин!»

Кол Шәриф догасын тәмамлап битен сыпырып куйды һәм ләйакыл кеше шикелле чайкала-чайкала ишеккә таба атлады. Үткәннәргә һәм киләчәккә күз салырга теләү, миенең һәр күзәнәгеннән эшкә җигеп тәүлекләр буе үзе дә аңламаган нииндидер сәер халәттә үткән гомер эзсез калмаган, хәлсезлектән аның аяклары сыгыла, гәүдәсенә, әйтерсең, гасырлар авырлыгы иңгән иде. «Мәдрәсәдән чыгуга беренче очраган кеше урыс кавеменнән булса, юраганым юш килер»,— дип уйлап куйды ул һәм аруын, ачыгуын, җеп өзәр хәле дә калмаганлыгын онытып, урамга атлады.

Бер-ике адым узарга да өлгермәде, каршысына ертылып беткән сәләмә киемле, озын чәчле яшь егет килеп чыкты. Бер сүз әйтеп тормастан, тез астына китереп суккандай бөгелеп төште, ике кулын аңа сузып ялварырга кереште:

— О Кол Шәриф хәзрәтләре, изге имам-хатиб! Читкә тибәрмә! Зинһар, тыңла... Бары тик син генә ярдәм итә аласың...

---

* Тарихи язмалар һәм риваятьләргә караганда, Җәмигъ мәчете төзелгәндә нигезенә тегермән ташы салып калдырылган. Тегермән ташы — муллык, тыныч, имин тормыш теләү символы.

МӨСЕЛМАНМЫ СӘН?

Синең вилаятьләреңдә булган мөселманнарны тоттырып, аркаларыннан каеш чыгарып, минем динемә кер дип, сөкәнҗәләр итеп, каләме шәриф вә мәсҗед-мәдрәсәләрне ябып мондый олуг гөнаһ иттегез.

Кырым ханы Сәламәтгәрәйнең урыс патшасына җибәргән ярлыгыннан. 1554—1556 еллар.

Соң чиккәчә җитеп арыган, сеңерләре* кылдай тартылган Кол Шәриф капкадан чыгуга ук кеше очратуына хәтта сөенеп тә куйды һәм кызыксынуын сиздермәскә тырышып сорау бирде:

— Син кем? Кем баласы? Мөселманмы сән?

— О изге имам хатиб! Мин Углич сәүдәгәре Савелийның төпчек углы булырмын. Исемем Александр... Миңа синең ярдәмең кирәк. Зинһар, үтенечемә колак сал, гозерләп сорыйм...

— Хуп, монысын ишеттек, углым. Ашыкма... Тәфсилләп, аңлатып сөйлә. Мин ни белән хәлеңә керә алам?

— Миңа мөселманлыкка чыгарга кирәк.

— Ай-һай,— дип, елмаеп баш чайкады Кол Шәриф.— Шулай тиз генәме? Мондаен да авыр йомыш белән килгәнсеңдер дип көтмәгән идем. Урамда аяк өсте генә сөйләшә торган сүз түгел. Әйдә, хөҗрәгә үтик. Тыңлап карыйк...

Кол Шәрифкә ияреп Санька мөселманнарның изге йорты — мәсҗед-мәдрәсә вә китапханәне бер итеп, бер түбә астына туплаган олуг ташпулатның ишеген атлап керде. Ак мәрмәрдән түшәлгән чиста идәннәренә басканда гөмбәз түшәмнәр астында аяк тавышларының кайтаваз булып тонык яңгыравына, бүлмәләрнең зурлыгына, биеклегенә игътибар итте, бөтен буыннарыннан әллә нинди, үзе дә аңламаган, сискәнүгә охшаш бер хис тибрәлеп узды. Шушы мизгелдә үзенең кире кайтарып булгысыз, гаять җаваплы һәм хәлиткеч адым ясаганын аңлаудан ул үзе дә бер йомарлам сеңергә әйләнгән иде.

Кол Шәриф бүлмә түрендәге биек аркалы йомшак урындыкка барып утырды, кул изәп янына Александрны чакырды, каршында урын күрсәтте.

— Йә, тыңлыйм, углым. Барысын да бәйнә-бәйнә сөйлә!..

* *Сеңер* — нерв мәгънәсендә (борынгы төрки сүзе).

Белкеварның әле һаман да зиһене таркау, төнге манарада кичергәннәрен кабат-кабат миеннән үткәрә, аларны билгеле бер тәртипкә салып аңларга, яшерен серләргә төшенергә тырыша иде. Дисбе никадәр генә ачык күрсәтмәсен, аның әле һаман ышанып җитәсе килми, җәннәттәй патшалык бакчаларының көлгә әйләнәчәген күз алдына китерә алмый иде. «Булмас! Булырга тиеш түгел! Теш-тырнагың белән юл куймау чарасын эзләргә кирәк. Башка әмәл юк'»

Дөресен әйтергә кирәк, урыс кавемендәге егетнең каршына килеп егылуында үзенчәлекле фал күрде Кол Шәриф. Бу үзе үк тагын бер кат афәтнең кай яктан янаганына ишарә сыман тоелды. Менә шуңа күрә дә аны тыңларга, бөтен-бөтен нечкәлекләре белән егетнең эч серләренә төшенергә теләде дә.

— Йә, тыңлыйм, углым,— дип кабатлады ул арган тавыш белән.— Ни өчен сиңа мөселманлыкка күчәргә кирәк?

— Мин гашыйк булдым, имам-хатиб...

— Шул гынамы? Мөселманлыкның монда ни катнашы бар?

— Мәгъшукам мөселман затыннан... Казан кызы, имам-хатиб. Мөселманлыкка чыкмасам, мин аны ике колагымны күрмәгәндәй, гомергә дә күрә алмаячакмын. Атааналары шулай диде.

Кол Шәриф егетнең үзенә ышанып, кискен һәм ашыгып сөйләвенә мыек астыннан гына елмаеп куйды: «Их яшьлек, яшьлек! Ул чакта барысы да ничек җиңел тоела!» һәм мәхәббәт кыйссасын тыңларга әзерләнде. Бөтен нечкәлеген вә асыл сәбәпләрен белмичә хәл итә торган мәсьәлә түгел иде бу.

И киң күңелле укучым, шуны да белеп тор: без тасвирлап яткан бу заманнарда Казан дәүләтендә адәм баласы хөсетлекне белми иде, күзгә карап астан пычак белән кисү юк иде Хәйлә, мәкер вә астыртынлык бик сирәк затларның гына коралы булып, алар иң бозык, фасикъ адәмнәр исәпләнер, кылганнарының язык икәнлеген күпләр белеп торыр, вә һәм дә алардан котылу чарасын күрер иде. Хәтта ки олуг мәмләкәтләрнең хөкемдарлары кайсы да булса патшалыкка сугыш ачарга җыенса, алдан чапкыннарын җибәреп: «Өстеңә фәлән меңлек яу иләкиләм»,— диеп, хәбәр җиткерер иде.

Гомер дигән көймәгә утырып бәхре җиһанга* сәяхәткә чыккан мәгъшук каһарманыбыз — күңеле керләнмәгән, олуг диңгезнең су асты агымнарын вә җаһәләтен әлегә белмәгән бүз углан Александр Кол Шәриф хәзрәткә үзенең башыннан кичкәннәрне, барча серләрен нәкъ Казанча түкми-чәчми сөйләде дә бирде.

— Әйе, үтә дә четерекле хәлдә икәнсең,— дип куйды Кол Шәриф Саньканы тыңлап бетергәч.— Әмма сөалем бар: Казан каласында укымышлы кешеләр, мәсҗедләр бихисап. Нилектән нәкъ менә минем янга киләсе иттең?

— Мин булдым инде, күпләр янында булдым... Тик берсе дә хәер-фатихасын бирмәде... Синең яныңа барырга киңәш иттеләр. Мәмләкәттә мондый эшкә тик Кол Шәриф хәзрәтләре генә рөхсәт бирә ала, диделәр.

— Бәлки, хак әйткәннәрдер... Ләкин син мөселманлыкның нәрсә икәнен ачык беләсеңме, күз алдына китерәсеңме соң?

— Хрәстиян дине кебектер инде,— дип куйды беркатлы гына итеп Санька.

— Ай-һай, җиңел уйлыйсың, углым... Җир йөзендәге бар кавемнәрне яраткан, юктан бар иткән Аллаһы тәгалә бер булса да, аңа табыну, инану, үзеңне рәхимле һәм мәрхәмәтле, шәфкать иясе Бөек Алланың җирдәге бәндәсе һәм илчесе итеп тою, шуңа ышанып яшәү бөтенләй башка нәрсә. Мөселманлык дөньялыкта тәнне җаннан аерып карамый. Тән белән җан берлеге — исламның беренче һәм иң төп кануннарыннан. Иманы саф кешенең тәне дә чиста, пакь булырга тиеш, углым. Көнгә биш намаз фарыз, һәр намаз алдыннан тәнеңне сафландыру фарыз. Гакылың, холкыңфигылең дә... тәнең дә, гаурәтең дә чиста булсын... Син боларны кабул кыласыңмы, гакылың колачлый аламы? Уйла...

— Кабул кылам, имам-хатиб... Аңлармын... Тик хәерфатихагызны гына бирегез.

— Ашыккан ашка пешкән, диләр бездә. Сабыр ит, иң әүвәл тыңлап бетер. Өлкәннәр сүзен бүлдерми колак салырга өйрәнү дә ислам кануннарының берседер.— Кол Шәриф үзе дә белми, нигәдер күңелендә бу егеткә ярдәм итәсе килү теләге уянды. Шул ук вакытта аның ашыгуына, нишләргә белми үрсәләнүенә аз гына үртәлә дә кебек. Уйхисләре капма-каршы ике якка бөреләнде. Егетнең каудар-

---

* *Бәхре җиһан* — тормыш диңгезе мәгънәсендә. *Бәхр* — океан дигән сүз.

ланып, ашыгып, ашкынып сөйләнүе, мәхәббәте хакына бөтен нәрсәдән ваз кичәргә әзерлеге сокландыра һәм әллә нишләп бераз шикләндерә дә иде. Җете кызыл тиз уңа, диләр түгелме? — Мөселманлыкка күчү җиңел генә эшләнми,— дип дәвам итте ул.— Син инде тормышыңның бер өлешен яшәгән, балигъ булган, үзең өчен үзең җавап бирер кеше. Ә адәм баласы берьюлы өч халәттә яши: үткәнендә, бүгенгесендә, киләчәгендә. Үткәнеңне хәтерләү-белү, бүгенгесен намусыңа, вөҗүдеңә, калебеңә хилафлык китермичә үтү фарыз. Киләчәгең шулардан укмашыр. Әмма шунысын да бел: телисеңме-теләмисеңме, үткәнең инде киләчәгеңә юл сабып куйган. Беркем дә узган гомерен, кылган гамәлен сызып ташлый алмый. Ә син, күрәм, бер селтәнү белән үткәнеңнән баш тартырга җыенасын. Тормышыңны яңа сыйфатта башлый алуыңа ышанычың бармы? Ныкмы? Үкенмәссеңме?

— Юк, имам-хатиб, үкенмәм... Мин бик озак уйландым, газаплы төннәр кичердем. Шунысын анык беләм: Гөлйөземнән башка миңа тормыш юк. Ул булмаса, яшәүнең мәгънәсе калмый. Үземә кул салыйммыни соң инде?! Башка чарам юк...

— Яхшы... Хуп... Мин сиңа мөселманлыкка күчәргә фатиха бирдем ди. Син шәкертләр янына утырып ислам догаларын өйрәнергә, аның кануннарының, шәригатьнең серләренә төшенергә, сабак укырга ризамы? Шунсыз мөселман була алмый.

— Риза, мең риза, изге Кол Шәриф!

Хәзрәтнең тавышына тимер чыңы керде, егетнең күзенә туп-туры карап, кырыс итеп сорады:

— Әй син урыс углы урыс, мөселманлыкка күчеп якыннарыңа, ата-анаңа, кавемеңә хыянәт кылганыңны беләсең ме?

Саньканың битеннән куе кызыллык, җете зәңгәр күзләреннән кара күләгә йөгереп узды. Ләкин бик азга гына. Кызыллык кәгазь аклыгы белән алышынды, күзләрендә тәвәккәллек очкыннары биеште.

— Беләм,— дип пышылдады ул.— Әмма, кабатлап әйтәм, Гөлйөзем хакына мин хәтта тормышымнан ваз кичәргә дә әзермен. Соңрак, ата-аналарым мине аңлар, кичерерләр дип беләм...

— Анысы шулай... Ата-ана бәлки гафу итәр дә,— дип үзалдына әйткәндәй пышылдап куйды Кол Шәриф.— Тагын бер сөалемә җавап бир. Синең бу адымыңны мәгъшукаң

беләме? Аның ризалыгын алдыңмы? Ул ни ди? Соңыннан үкенмәссеңме?

— Юк, юк! Изге имам-хатиб, ул беләм... Риза... Башка чарабыз юк. Бердәнбер өметебез шушы.— Һәм Санька, киселгән агачтай, Кол Шәриф каршына ауды; калтыранган кулларына таянып, аның итеген үбәргә шуыша башлады, бертуктаусыз сөйләнде дә сөйләнде, ачы яшьләре идәнгә тамды.

— Зинһар! И изге имам-хатиб! Зинһарлап сорыйм. Бәхетебезне кисмә... Мәңгегә бурычлы булырмын... Акчам күп минем!..

— Мөселманлыкны сатып алмыйлар,— диде кырыс тавыш.— Тор! Егет кешегә — җирдә аунау түбәнлек. Горур затлар гына тиң күреп сөйләшергә лаек. Мотлак мондый гамәлеңне килештермим.

Санька үзенә чыгарыласы хөкемне көтеп таштай катып калды. Хәзер, менә шушы мизгелдә аның язмышы хәл ителә. Йә барысын да кисеп, өзеп, өметне тамыры белән йолкып аталар, йә җир фәрештәсенә тиң затка дәгъва кылырлык хокук бирәләр. Һәммәсе дә шушы олпат һәм изге кеше кулында.

Кол Шәриф кулындагы дисбе төймәләрен тарта-тарта тирән уйга чумды. Аның тагын зиһене чуалды, галәм агышының серләренә күз салган изге бер көндә вак мәшәкатьләр белән чуаласы, олуг фикерләреннән аерыласы килми иде. Икенче яктан күңелен шик корты кимерә: беренче очраган кеше урыс кавеменнән булса, юраганым юш килер, дигән иде. Ә хәзер үзе үк шул кешене мөселманга әйләндерергә фатиха бирергә җыена түгелме соң? Моның күрәзәлеккә бер-бер зыян-зәүраты булмасмы?

Санька үзен онытты лар дип уйлады, күрәсең, сак кына тамак кырып куйды. Кол Шәриф исә тирән сулап егеткә янә тагын бер сорау бирде:

— Мөселманлыкка чыккач, сөннәткә утыртылырга тиешлегеңне беләсеңме?

Санька тагын бурлаттай кызарынды, ләкин үзен бик тиз кулга алды һәм ашыгып җавап кайтарды:

— Беләм, изге имам-хатиб... Беләм һәм ризамын.

— Балигъ булганнарны, ягъни җиткән егетләрне сөннәткә утырту гаять авыр... Гомерлек хастага әйләнүең бар... Шуңа да ризамы?

— Риза, риза, имам-хатиб. Мин беркемне дә гаепләмәячәкмен. Тәңрем ни язган булса, шуңа күнәрмен...

Християн динендәгеләрне мөселманлыкка күндерүдән

тыелып яшәгән, моны дин әһелләренең барчасына канун итеп дөндергән Кол Шәриф бу егеткә ташлама ясарга карар бирде. Ике мәгъшук җанның Ләйлә илә Мәҗнүн мисалындагы газапларын ул йөрәгеннән үткәргән, аларга ничек тә изгелек кылырга тели иде. «Гозерләп килгән алла бәндәсенә күрсәткән бер изгелек, кайчан дә булса уны белән үзеңә кайтыр»,— диләр акыл ияләре. Бәлкем бу егетнең кылган догалары да җирдә асылынып калмас, күккә барып ирешер... Барысы да бер Аллаһ кулында!» һәм ул алдындагы намазлыкка ишарәләде.

Санька кечкенә келәмгә тезләнеп басты да муенындагы тәрене йолкып алды, аны бер читкә атмакчы иде, Кол Шәрифнең шелтәле карашын күреп, тиз генә кесәсенә тыкты һәм башын иеп хәрәкәтсез калды. Бу аның «Мин синең ихтыярыңда, имам-хатиб!» дигәнен аңлата, тулысынча аңа буйсынуын белгертә иде.

Кол Шәриф исә аның баш өстенә яшел сәхтиян тышлы коръән — каләме шәрифне куеп тантаналы тавыш белән акрын гына көйләп изге дога сүзләрен укырга кереште:

— Бисмил-ләһир-рахманир-рахим. Әл-хәмдү-лил-ләһи раббил галәмин. Әр-рахманир-рахим. Малики йәүмид-дин. Ийәкә нәгъбүдү вә ийәкә нәстәгыйн. Иһдинас-сиратал-мүстәкыйм. Сиратәл-ләзинә әнгамтә галәйһим, гайрил мәгъдуби галәйһим-вәләддалина.

Мәрхәмәтле, рәхимле Аллаһ исеме берлән... Моннан кире синең атың Сәет булыр... Сәет Сәлим улы. Аңладыңмы, хәтереңә сеңдердеңме, улым?!

— Әйе, имам-хатиб. Мин Сәет Сәлим улы, мөселман өммәтендәге затмын... Бөек Аллаһының җирдәге бәндәсе...

— Яхшы!.. Инде бергәләп гыйбадәт кылыйк. Минем арттан кабатлап барырсың... И мәрхәмәтле, рәхимле Аллаһ...

Сәет Кол Шәриф хәзрәт артыннан тылсымлы сүзләрне кабатларга кереште:

— Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, сиңа гына ярдәм сорап сыенабыз. Безне туры юлга күндер. Адашкан һәм ачуыңны казанганнар юлыннан түгел, изгелегеңә лаек кешеләр юлыннан атлап...

Гыйбадәтне тәмамлап битләрен сыпырып куйдылар. Кол Шәриф егеткә торырга ишарәләде һәм гаять авыр бер эш башкарган кешедәй җиңел сулап үгет-нәсихәт, вәгазь сүзләрен тезәргә кереште:

— Мин кулымнан килгәнне эшләдем, Сәет Сәлим улы. Инде калганнары барысы да үз ихтыярыңда... Хак мөселман буласыңмы, әллә хрәстиян да, мөселман да булмыйча,

урталыктагы бер имансыз затка әйләнәсеңме. Барысы да, барысы да үзеңә тапшырыла. Әмма мин сиңа ышанам, улым. Шуңа тәвәккәлләдем дә... Аллаһы тәгалә мәгъшукаң белән кушылырга, бер-берегезне сөеп, кадерегезне белеп яшәргә ярдәм итсен. Мәхәббәтеңнең кайнарлыгын, йөрәгеңнең тугрылыгын, сафлыгын аңладым дип беләм. Җефетеңә гадел, тугры һәм хәләл ир бул, җәмәгатең исә сине аңлап, зурлап тормыш кичерүче хатын булсын! Амин! — Кол Шәриф догасын укып бетерде һәм алдындагы кәгазь кисәгенә нәрсәдер язарга тотынды. Кауры каләмен читкә куеп, язганына өстәлдәге кечкенә көмеш савыттан вак ком сипте, аны өреп төшереп, ягъни караны киптереп Сәеткә сузды. — Монда мин гыйльме тыйб* әһелләренә бер-ике кәлимә сүз юлладым. Теләгеңә каршы килмәсләр... Уйлаганыңны озакка сузмый гамәлгә ашыру фарыз. Йә, тәвәккәллә, улым!

Казан каласында мәхәллә саен аерым табиб булып, алар сырхауларны җәмәгать акчасына тотылучы хастаханәләрдә дә, өйләрендә дә карыйлар, кирәксә, хастаханәгә салып та дәвалыйлар икән. Аларның күбесе табиб кына түгел, гыйльме симия вә гыйльме кимиядән** дә хәбәрдәр, фәннәрнең башка тармакларыннан да шактый мәгълүматлы, белемле адәмнәр икән. Боларны Сәетнең инде Углычта чакта ук ишеткәне бар, галим-голәмә арасында гына түгел, сәүдәгәрләр таифәсендә дә Казан акыл ияләренең абруе шактый югары куеп сөйләнелә иде.

Үзенә кирәкле хастаханәне Сәет бик тиз тапты. Гөлйөземне эзләп, аны бер күрергә зар-интизар булып, зарыгып Казан урамнарын айкап йөрү әрәм үтмәгән, ул үрмәкүч пәрәвезе җепселләре шикелле тармакланып, чәбәләнеп беткән күпсанлы тыкрык вә урамнарның кайсы кая илтүен, кайда ни-нәрсә барлыгын шактый ук яхшы абайлый башлаган икән.

Имче табиб бик кырыслардан иде булса кирәк. Ул Сәетнең гозерен тыңлап бетерер-бетермәс йөзен чытып куйды һәм кире кайтарып сорамаслык итеп кыска гына җавап та кайтарды:

— Юкка йөрисең, улым... Берни белән дә ярдәм итә алмыйм. Без балигъ адәмнәрне сөннәткә утыртмыйбыз. Нәкъ ун елга соңлагансың...

---

* *Гыйльме тыйб* — медицина гыйлеме.

** *Гыйльме симия вә гыйльме кимия* — борынгы фән исемнәре

Сәет үзенең олуг ялгыш җибәрүен шунда гына аңлап алды. Кол Шәриф хәзрәтләре дә нәкъ шулай дигән иде ич. Һәм тизрәк хатасын төзәтергә ашыкты:

— Мин Кол Шәриф хәзрәтләренең мәктүбен алып килдем. Аның фатихасы белән...

Галим-голәмә арасында абруе чиксез олуг затның исемен ишетүгә, табибның йөзендәге кырыслыкны кул белән сыпырып аттылармыни, ул түбәнчелек белән баш иде, йөзенә елмаю, канәгатьлек һәм басынкы итагать билгесе кунды.

— Нигә башта ук әйтмәдең аны,— дип шелтәләп куйды ул.— Мәктүпне күрсәтүдән башларга кирәк иде...

Сәет кадерле язу кисәген табибка сузды да аның хөкемен көтеп тын калды. Хәзер менә тагын аның тормышында мөһим бер үзгәреш булачак, аны Углич белән, туганнары, ата-анасы һәм гомумән үз кавеме белән тоташтырып торучы тагын бер кыл өзеләчәк. Артка юл юк!

Аның бу уйларын сизгәндәй, табиб хатны укып бетерде дә Сәетнең күзләренә туп-туры текәлеп карады һәм барысын да хәл иткән кешеләрчә кистереп сорады:

— Соңыннан үкенмәссеңме?

— Юк, табиб әфәнде, үкенмәм... Никадәр тизрәк хәл итсәк, минем өчен шулкадәр яхшырак. Мин барысын да, барысын да уйладым инде.

— Хуп! Анысы үз иркеңдә. Әмма хәлиткәч адым ясаганчы мин тагын бер кат уйлап карарга киңәш итәр идем. Безнең казанлылар; «Җиде кат үлчә, бер кат кис»,— дип әйтергә ярата. Бу сиңа ефәк билбауның очын кисеп ташлау гына түгел,— дип көлемсерәп куйды табиб.— Җан җире белән эш итәсе...— Аның әле һаман Сәетне уеннан кире кайтарасы килгәне сизелә, шуңадыр ахры, төртмәлерәк итеп сөйләргә тели иде кебек.

— Юк, табиб әфәнде, уемнан кире кайтмыйм. Җиде генә түгел, мең кат үлчәдем инде. Синең катка да үз ихтыярым, үз теләгем белән килдем. Мин — мөселман затыннан, хак дингә үзем теләп күчүчеләрдән. Атым Сәет, атам Сәлим булыр. Мин бар нәрсәмнең хак мөселманнарча булуын телим. Зинһар, сузмыйк... Әҗереннән тормам.

— Ай-һай, энем, борчакны тиз куырмакчысың... Яхшы! Мин сине сынап бактым. Инде сынауны үттем дип исәплә! Калганы — безнең карамакта. Мин әйткәндә ятарсың, мин әйткәндә торырсың... Ризамы?

— Берсүзсез ризамын! Ни әйтсәң, шул булыр, табиб әфәнде... Мин әзер!

Табибның ни өчен алай әйткәнлеген, аның нәрсәне күздә тотканлыгын Сәет өч көннән соң гына төшенер. Әлегә ул үзенең тәнен вә җанын тулаем шушы имче табиб кулына бөтенләе белән тапшырганлыгын аңлап бетерми иде.

Имче табиб исә ашыкмый гына урыныннан күтәрелде дә Сәетне үз артыннан ияреәргә чакырды, кулы белән күрше бүлмә ишегенә күрсәтте:

— Хәерле сәгатьтә...

Тар тәрәзәләрдән төшкән сүрән яктылыкка күзләре ияләшкәч, Сәет диварның буеннан-буена сузылган өстәлләрдә, әллә-ничәшәр катлы киштәләрдә эреле-вакллы төрле шешәләр, кувшиннар, йодрык хәтледән алып икешәр чиләк сыешлыга кадәр балчык чүлмәкләр күреп хәйран вә вәйран калды. Имән өрлекләрдәге кадакларга бәйләм-бәйләм төрле үләннәр, яфраклар, чәчәкләр, себерке итеп бәйләнгән юкә, имән вә каен ботаклары, тагын ул танып бетермәгән әллә нинди башка үсемлекләр, киптерелгән тамырлар асылган иде. Төрле зурлыктагы җамаякларда нәмәгълүм җимешләр, он хәленә китереп тарттырылган, төелгән үлән вагы, чәчәк бөреләре иде. Иң куркытканы — почмактагы адәм сөякләре булды. Ул, тәне-ите булмаса да, бөтен буена торып баскан һәм Сәеткә карап тешләрен ыржайта сыман тоелып китте. «Сихерче өненә эләктем, ахры»,— дип уйлап куярга өлгерде ул. Кайчандыр ишеткән куркыныч әкиятләрдәге мәкерле, усал сихерчеләр, тылсымчылар исенә төште, тәне чымырдап куйды. Ләкин чигенергә соң иде инде. Хәер, ул биредә үзенә начар гамәл кылынмасына чын күңелдән ышана, Кол Шәриф хәзрәтнең аңа карата игелегенә иманы камил иде. Андый затлар күрә торып кешене явыз сихерче кулына бирмәс. Бу акылга сыймас эш булыр иде. Аннан соң, йөзе җыерчыкланып бетсә дә, күзләреннән яшьләрчә нур бөркелгән бу имче карт аңа яманлык кылмас.

Имче табиб исә Сәеткә ишек катыннан урын күрсәтте дә, аны бөтенләй оныткандай, үз эшенә керешге. Өстәлдән нәни генә ак керәч савыт алды, аңа пыяла шешәчекләрдән онга охшаш берничә төрле матдә салды, аларны бармагы белән аралаштырып карады, кечкенә генә тукмак белән бик тырышып тагын бер кат изде дә савытны Сәеткә сузды:

— Менә шушыны аз-азлап кына тел астына сал. Гәүдәңне тоймый башлагач, тәнеңдә очып китәрдәй җиңеллек тойгач туктарсың,— диде ул серле тавыш белән.— Калганын үзебез башкарырбыз... Йә, тәвәккәллә!..

Сәет әчкелтем онның ачысыннан башта йөзен чытып куйган иде, тора-бара бу тәм бетте, бөтен буыннарына рәхәт бер җиңеллек таралды, кулларын канат итеп җилпеп зәңгәр күкләргә күтәреләсе, аккошлар белән ярышып очасы, мендәрдәй кабарынкы болытларга чумып уйныйсы, мәтәлчек атынасы килә башлады. Ул үзенең тәнен тоймый, гүяки мамыктай җиңел, өрсәң очып китәрлек бер каурыйга әйләнгән иде.

«Табиб әйткән чиккә җиттем. Башка капмаска кирәк, бу сихерле онның касәфәте тия күрмәсен»,— дип уйлап куйды ул һәм күзләрен йомып тәнен чолгаган изрәткеч рәхәтлеккә бирелде. Башындагы уй-фикерләре бер-берсенә ялганып, җирдән өермә суырып алган тузан бөртекләредәй зыр-зыр килеп әйләнергә, бөтерелергә тотынды: «Мин моны бердәнберем... мәхәббәтем хакына эшлим барысы да яхшы әле йөз бәлиш акчам бар тормыш корырбыз әгәр җир йөзендә Гөлйөзем атлы кыз юк икән миңа җирдә яшәп торуның да мәгъ нәсе юк тырр р йа тәң ре ем тәң ре ем яр дә мең нән таш ла аа мааа...»

Күрше бүлмәдән табиб ярдәмчесе чыкканын, үзен иләп кенә икенче хөҗрәгә күчергәннәрен, ятакка китереп салганнарын ул инде сизми иде. Барысы да аксыл томанга төренеп юкка чыкты, Сәет моңарчы бер дә татымаган тирән һәм татлы йокыга талды.

Ул, имеш, ниндидер сихерле бер дөньяда йөзә, су дисәң, су түгел, күк дисәң күк түгел, Идел өстендәге вак томандай сыек та, үтә күренмәле дә бер җисем. Тәнендәге җиңеллек аңа барча дөньядан өскә күтәрелергә, канат кагып очарга, әле күптән түгел генә булып үткән вакыйгаларны ерактан торып, чит кеше күзләре белән күзәтергә мөмкинлек бирә имеш. Ә вакыйгалар шулкадәр тыгыз һәм шулкадәр тиз агылалар, кеше зиһене дә өлгерергә, җитешеп барырга мөмкин түгел икән. Ләкин аларда бер эзлеклелек юк иде әле. Менә ниндидер бер яшь баһадир егет Идел төбенә китте, капчыкны тишеп суга чумды, ярминкәдә көймәләргә бодай төяде, Кабан күле ярында җир фәрештәсенә тап булды... Аһ, ни аяныч, аның кулыннан ул кызны йолкып алып киттеләр. И бичара! Ничекләр генә түзәр инде! Менә бер сәләмә киемле егет урман юлыннан бара. Аркасында биштәр, кулында кәкре таяк... Чү! Тукта! Бик тә, үтә дә таныш нинди егет соң бу? Кайдадыр күргәне, аралашканы бар ич...

Куклардан моны күзәтеп торган Сәет шаккатты. Сәләмә киемле, баһадир сынлы чибәр егет ул үзе икән ләбаса!

Әле генә бер-берсенә бәйләнмәгән чуалчык вакыйгалар кай арада билгеле бер тәртипкә тезелделәр дә салмак елга агымыдай киң ярларны тутырып акрын гына ага башладылар. Күз алдында соңгы көннәрдә күреп танышкан, ярдәм кулы сузган яисә кабахәтлек кылган затларның сурәтләре яңара башлады. Алар сөйлиләр дә сөйлиләр, сүзләре колакка кереп тә тормыйча баш миенең үзәгендә яңгырый, шунда язылып кала имеш.

Яхшы хөллә, сәхтиян читек кигән мәһабәт бер зат пәйда булды. Бакты, шаккатты. Бу — Казан сәүдәгәрләренең иң абруйлыларыннан Әҗем ага иде.

Ә җ е м а г а. Карт балыкчы җибәргән кешене кире борыр хәлем юк. Мин дә синең шикелле үк аңа гомерем белән бурычлымын. Мәгъшукаң илә кавышуда үзеңне ирләрчә тота алсаң, сәүдә юлында, тормыш коруда ярдәмемнән ташламам. Бер игелек кешене мең бәладән йолыр ди. Тыңла, бер кыйсса сөйлим.

Борынгы мәмләкәтләрнең берсендә яшәгән ди бер хөкемдар Саилчеләрне, теләнеп гомер сөрүчеләрне бер дә аямаган, сөймәгән. Фәрман игълан иткән бу. Кем дә кем саилчегә хәер бирә, белеп торсын, ике кулы да төбеннән үк кисеп алыначак. Халык бик курыккан. Беркем дә хәерчеләргә, теләнчеләргә, мохтаҗларга якты йөз күрсәтми икән, аларга ярдәм итү генә түгел, хәтта читләтеп уза башлаганнар имеш.

Шушы мәмләкәттә яшәгән ди бер гүзәл кыз. Көннәрдән бер көнне моның янына хәерче бер адәм килеп керә, сорый: «Өч көн инде авызыма ризык капканым юк. Ярдәм ит сана»,— ди. Кыз әйтә: «Мин сиңа ничек ярдәм күрсәтим, патша хәзрәтләре сизсә, ике кулымны да төбеннән үк кисеп атачаклар». «Алла хакы өчен сорыйм, зинһар, бир сана бер-бер ризык. Рәхимле Аллаһ онытмас, ул үзеңә ярдәм итәр». Шулай дип гозерләп сорагач, кыз аны бик кызганган да ике кулына ике көлчә тоттырган. Бу хәбәр көне-сәгате белән хөкемдарга барып та җиткән, кызны чакыртып, ике кулын да кисеп атарга боерган.

Берзаман патшаның өйләнәсе килә башлый. Әнисенә әйтә: «И анам, миңа мәрхәмәтле, кеше хәленә керә белүче җефет кирәк. Аны кайдан табыйм?» Анасы әйтә: «Бездән ерак түгел нәкъ шундый бер кыз бар. Шуннан да яхшысы табылмас, ди.— Тик аның ике кулы да юк». «Аны күрергә телим, яныма китерсәгезче,— дип патша. Кызны китерәләр.

Бик гүзәл икән. Бер бите ай, бер бите кояш ди. Патшаның шунда ук аны үзенеке итәсе килә. Никах укытып, зөфаф кичәсен үткәреп тә куялар. Айлар үтә. Озакламый бу хатын айдай йөзле угыл бала таба. Моннан патшаның бүтән хатыннары көнләшә башлый. Чөнки патша моны бик якын итә. Хөсетлекләренә, көнләшүләренә чыдый алмый патшага хат язып җибәрәләр, кулсыз хатының зиначы, сиңа хыянәт итә дип. Хөкемдар хатынны угылы белән бергә кеше яшәми торган далага илтеп ташларга әмер бирә. Хатын мескен, бичара, нишләсен, аглап-еглап дала буйлап китә инде. Бик эчәсе килә. Күрә, алдында мул сулы инеш агып ята. Агым уртасына кереп, иелеп эчә башлауга, муенына аскан биләүдән баласы төшеп тә китә. Бичара хатын элеккедән дә ныграк еларга, аһ орып кычкырырга тотына. Шул вакыт карый, яр буеннан айдай йөзле ике адәм үтеп бара. Сорыйлар: «Ник елыйсың?» «Муенымдагы биләүдә углым бар иде, суга төшеп китте»,— ди бу. «Телисеңме, без аны табып бирәбез». «Алла хакы өчен үтенеп сорыйм, ярдәм итегез сана», ди хатын «Бисмилла-иррахман иррахим»,— диеп ай йөзле кешеләр судан баланы тартып чыгаралар. Ул куркырга да өлгермәгән имеш. Янә сорыйлар: «Телисеңме, Аллаһы тәгаләдән кулларыңны кире кайтаруңы ялварабыз». Ул мескинә нишләсен, «Телим»,— дип җавап бирә инде. Тегеләр гыйбадәт кылуга хатынның куллары үсеп чыга, хәтта элеккеләреннән дә матуррак имеш. Шуннан теге адәмнәр тагын әйтәләр: «Син безнең кем икәнебезне беләсеңме?» Бичара: «Белмим. Белсә, бер Алла беләдер»,— дип җавап бирә. Шуннан ай йөзле кешеләр әйтә: «Алайсаң белеп тор, без син кайчандыр саилчегә биргән ике көлчә булырбыз,— диләр.— Хәерең ике кулсыз калуга сәбәп булган иде. Инде рәхимле вә шәфкатьле Аллаһы тәгалә аларны сиңа кире кайтарды».

Ш ә һ и т. Әҗәм картны кара мыеклы, зур елтыр күзле, гаскәриләр киемендәге чибәр егет сурәте алыштырды. Аның янында сары чәчле, чабаталы, сәләмә киемле икенче берсе пәйда булды.

Мыеклы чибәр егет әйтте: «Син кем? Каян киләсең? Кая юл тотасың?» «Мин карт балыкчы яныннан киләм, Казанга барышым. Үзем урыс сәүдәгәрләре кавеменнән, исемем Александр». Сәет күреп торды, Санька гаскәри киемледән бераз шикләнә, андый-мондый зыян салмагае дип шөбһәләнә иде. Гаскәри исә моны сизде, елмаеп җавап бирде. «Курыкма, Казан мәмләкәте сәүдәгәрләрне хуплый. Без сиңа зыян китермәбез. Балыкчы карт юньсез адәмнәрне

безгә юлламый. Инде минем дә кемлегемне бел: тоткавыл Шәһит булырмын. Кулдан килгән ярдәмне күрсәтербез».

Сәет күрде, аңлады: Шәһит тә Санька да бер-берсен яраттылар, күңелләрендә «Мин шушы егет белән дус булсамчы!» дигән теләк уянды. Буй-сыннары, килеш-килбәтләре вә фикер сөрешләре дә бер-берсенә бик йогышлы иде. Сәләмә киемнән булса да, Саньканың йөзендә, үз-үзен тотышында затлы нәсел баласы икәне күзгә ташланыр иде.

Тагын икенче сурәт килеп чыкты. Бер төркем атлылар тыныч кына гәпләшеп урман юлыннан юрттыра. Алда, Шәһит янында бурлы айгыр өстендә Санька бара имеш. Казан җирендә тапкан беренче дустына куанып, бәхет кошы тоткандай сөенеп бара. Мондый дус егетләр барында инде беркем дә куркыныч түгел, Гөлйөземне кем урлаганын да, аңа ни-нәрсә булганын да тиз белеп булыр. Шәһит шаяртып сөйләшүчеләрдән түгел, тугры йөрәкле, үткен сүзле, пәһлеван егет. Әйтте бит, ярдәмемнән ташламам, диде. Озакламый Гөлйөземгә кул күтәргән җаһилләр алларында аунап гафу үтенер. Бары тик исән генә булсын! Табыйк кына...

Җиңелчә генә ат тыпырдый. Әңгәмә җебе сүтелә дә сүтелә. Санька башыннан кичкәннәрне бәйнә-бәйнә сөйли. Шәһит тыңлый. Игътибары вакыйга җебендә.

«Шул кызны минем кулымнан кара төндә йолкып алып киттеләр. Инде ни кылыйм. Йөрәгем парә-парә телгәләнә. Казанга ут йотып кайтып барам»,— диде Санька. Шәһитнең кара мыеклы, кара кашлы чибәр йөзеннән тагын да карарак күләгә йөгереп узды. Борылып сорады: «Ул кызның аты нинди? Кайда аерылдыгыз? Кемнәр шулай рәнҗеттеʔ» — диде. «Ул гүзәлнең исеме Гөлйөземдер. Ярминкә җыенында атлылар алып китте. Кем икәннәрен дә белмәдем»,— диде Санька. Кинәт Шәһит атына камчы белән китереп орды, алга ыргылды да борылышта күздән югалды. Аның артыннан ияргә омтылган Саньканы башка егетләр кычкырып туктатты: «Кирәкми. Барма. Ул нишләгәнен үзе белә».

Бераздан Шәһит аларга килеп кушылды. Йөзе кырыс, караңгы, олы кара күзләре сәер елтырый иде. Санька янына килеп колагына әйтте: «Әле генә дуслар идек, инде көндәшләр икәнебез ачыкланды. Бел: Гөлйөземне урлап китүче ул мин». Саньканың ирексездән читкә тайпылуын күргәч тагын әйтте: «Курыкма, асла сиңа зыян китермәм. Гәрчә белеп торуың артык имәс, мин Казан мәмләкәтендәге дүрт куәтле ыруның да иң куәтлесеннән — ширин ыруыннан, ак-

сөяк морза баласымын. Хәзер үк сәне богаулап әсирлеккә сата алсам да, кулым күтәрелми. Гөлйөзем хакына тыелып калам. Күрик, белик. Гөлйөзем безнең кайсыбызны сайлар. Аның хөкеменә бирелик. Ул кемне сайласа, ничек хәл итсә, шулай булыр».

Казанга җиткәнче егетләр бүтән сүз алышмады. Атлылар төркеме Санькага үтергеч карашлар ташлады, әмма зарар салмады. Шәһит сүзе аларга канун иде.

Г ө л й ө з е м. Тагын яңа күренеш.

Казан каласының һөнәрчән осталары, алтын куллы зәргәрләр яши торган мәхәлләсендәге биек ташпулат каршына бер төркем яшь атлылар килеп туктады. Акрын гына капка шакыдылар. Аны хезмәтче хадим ачты. Аңа: «Гөлйөземне чакыр. Зинһар, чыксын! Шикләнмәсен, аңа бер-бер начарлык кылынмас!» — диделәр.

Капка уентыгында зәгъфран сарылары иңгән чибәр йөз күренде. Бу — Саньканы шашып елар дәрәҗәгә китереп җиткергән пәри кызы Гөлйөзем иде. Ул җайдакларның әле берсенә, әле икенчесенә бакты, сагышлы йөзенә үзгәреш чыкмады. Кинәт ул сәләмә киемле сары чәчле егеткә карады, авызын учы белән каплап бер аваз бирде: «Аһ!» һәм аның гәүдәсе акрын гына җиргә чүгә башлады. Шәһитнен йөзен кара болыт каплады, әмма китмәде. Егетләренә ым какты. Тыңлаучан җайдаклар атларыннан сикереп төштеләр, ачуташлар иснәтеп кызны һушына китерделәр. Санька илә Шәһит каршына бастырдылар. Шәһит әйтте: «И җанымның бердәнбере, тыңла да хәл ит. Каршыңда ике көндәш торабыз. Кайсыбызны үзеңә тиң күреп кабул кыласың? Барысы да синең кулда. Хөкемеңә буйсынырбыз. Сайла!» — диде.

Гөлйөзем бер сүз дә әйтмәде, очынып Санька янына килде дә кулыннан алды. Гафу сорагандай Шәһиткә карады. Шәһит барысын да аңлады. Камчы белән кунычына сукты, атына сикереп атланды. Җайдаклар тавышсыз-тынсыз чаптырып китеп бардылар. Ерактан Шәһитнең тавышы ишетелде: «Дустым идең, көндәшем булдың. Инде бүтән арабызда берни калмады. Бүтән юлыма очрама. Үкенерсең. Аллам сабырлык бирсен, үземне тыя алмавым бар...»

Г а л и ә к б а р а б з ы й. Җирдәге гөнаһлы бәндәләрдән аерылып каядыр өскә, югарыга күтәрелгән Саньканың җаны аңлады: Гөлйөземнең әтисе аның каршына ватылмас чикләвектәй каты мәсьәлә куйды. Бер кулы белән рөхсәтне бирде, икенчесе белән кисте: «Бердәнбер кызымның, багалмамның, җанга якын күңел җимешемнең теләгенә кар-

шы килә алмыйм. Инде җаныңның яртысы итеп сине сайлаган икән, каршы килмим. Шул ук вакытта колагыңа киртлә: минем кызым бары тик хак мөселманга гына тиң яр булачак. Башкасын белмим! Алга таба нишлисен үзең хәл ит!»

Сәет Сәлим углы гәүдәсендә җиңеллек, каты арып йоклаганнан соң була торган рәхәтлек тоеп ятагыннан кузгәрелде. Гаҗәпләнеп як-ягына каранды. Ул таныш түгел хөҗрәдә, ярым караңгы бинада берүзе ята икән. Аның кыштырдаганын ишетеп булса кирәк, ишек ачылды, анда имче табибның йөзе пәйда булды:

— Йә, углым, тордыңмы? Инде үзеңне ничек хис итәсең? Теләгәнең тормышка ашты: хәзер син җаның белән генә түгел, тәнең белән дә хак мөселманга әйләндең. Шөкер, җәрәхәтең тиз төзәлде,— диде.

— И изге имче табиб! Ничек кенә рәхмәтләремне белдерим! Үлгәнче онытмам. Оҗмах ишеген ачучыларның берсе булдың. Мин әле генә җәннәт бакчаларында йөреп кайттым бугай. Аларны сөйләп тә, аңлатып та бетерерлек түгел. Инде хәзер мин нишләргә тиеш?..

— Анысы үз иркеңдә... Сораганың үтәлгән. Ни кылсаң да язмышың үз кулыңда, углым. Аллаһы тәгалә куәт вә мәдәт бирсен! Син саф мөселман углы... Аллага тапшыр да теләгәнеңне үтәргә кереш!

— Мин озак йокладыммы? — дип сорады Сәет тәрәзәдән балкыган кояш нурларын тоеп. Чөнки ул кергәндә көн кичкә авышкан иде инде.

— Өч көн, өч төн йокладың, углым. Үзеңне аяп шундый дару биргән идек. Балигъ булганнарның гаурәте үтә сизгер нәрсә... Зыян китермик дидек...

Сәетнең йөзенә куе кызыллык йөгерде. Йоклаган арада үзе белән ни кылганнарын аңлап алган иде ул. Әмма оялу хисе тиз үтте, бөтен күңелен горурлык, шатлык, шушы изге күнелле затлар белән бер төрле булудан туган куаныч хисе биләп алды.

Ярминкә тәгәлләнер көннәрдә базар әһелләре Казанның иң бай һәм абруйлы сәүдәгәре Әҗемне сары чәчле, җете зәңгәр күзле, әле юньләп мыек та чыгып өлгермәгән яшь бер сәүдәгәр белән күрделәр. Сер сыйдырыр кеше булмарак, ул җаен тапты, Казан малтабарларына, һөнәрчән ил агаларына:

— Ерактагы туганымның углының углы, зәргәр Гали-

әкбарның кияве... Сәүдә эшендә үзенә юл сапмакчы,— дип таныштырды.— Миңа ышангандай ышана аласыз... Рибачы түгелмен, әмма Сәет угланны минем канат астында дип исәпләрсез.

Казан мәмләкәтенең базар әһелләре арасында яңа малтабар пәйда булды.

ШОМЛЫ КӨННӘР

«...И казанцы, сидящие в крепости,
Никакого врага не боялися:
Даже если б все царства соседние
На Казань поднялися общей силою
Они взять не сумели бы города[1]
Крепче же стен были люди казанские
Всегда в битвах искусные, храбрые »

«Казан патшалыгы турында риваять»
Егерме ел Казан ханлыгында әсирлектә булган билгесез урыс авторы.
XVI гасыр.

961 елның* җәе коры килде. Язгы ташулар үтеп, җир өсте куе яшеллеккә күмелгәннән соң ник бер яңгыр тамчысы төшсен дә, ник күк йөзендә бер болыт әсәре күренсен. Күтәрелеп килгән игеннәр сабагында саргая башлады, сусыл үләнле болынлыклар корыды, агачларның яфраклары бөреште. Әмма ул гына түгел, казанлылар күңеленә шом салырлык башка сәбәпләр дә бар иде. Көн белән төн тигезләшеп, җәй челләсенә якынлашып килгәндә шәһәрдә имешмимешләр куерды. Алар вакытлар үтү белән кимеми генә түгел, киресенчә, тагын да ишәеп, куркынычрак һәм дәһшәтлерәк яңа ваклыклар, төгәллекләр белән тулыланып өйләргә генә сыешмыйча, тыкрыктан-тыкрыкка, урамнан-урамга күчтеләр, кешеләр күңелендәге шомны тагын да куерта төштеләр.

Баштарак аларның чынмы-ялганмы икәненә диван әһелләреннән нә раслап, нә кире кагып бер-бер фикер ишетү мөмкин булмады. Чөнки хаким затлар үзләре дә төгәл белеп бетерми һәм кирәксез сүзләрнең зыян гына китерүеннән шикләнәләр иде, күрәсең.

Һәм, ниһаять, көннәрдән беркөнне чуан тишелде.

Атын ак күбеккә батырып куалаган Чапкын морзаның

* 961 ел (һиҗри) — миляди буенча 1552 ел.

Казан капкасыннан атылып керүенә чагдавыллар гына түгел, шаһит булган дистәләрчә казанлылар да сәерсенеп, тел шартлатып карап калган иде. Мәскәү кенәзенә хезмәткә күчкән хыянәтче дип исәпләнелгән, әһле Казан тарафыннан ләгънәтләнгән морзаның каравыл башына ниндидер кәгазь күрсәтеп, колагына пышылдап җай гына үтүе тагын әллә нинди имеш-мимешләр чыгуга сәбәп булды.

Чапкын морза тирләгән атын яндырудан да шикләнмичә, уңлы-суллы камчылап кала урамнарыннан туп-туры хан сараена юнәлде. Аны шыгавыллар* туктатмады. Нәрсәләр сөйләгәндер, нәрсәдән хәбәр җиткергәндер — анысы шәһәр халкына нәмәгълүм, әмма ул кайтканнан соң ярты көн дә узмады, шәһәр гөж килде:

— Мәскәүдә гаскәр туплыйлар!..

— Казан өстенә киләселәр, ди...

— Хыянәтче Шаһгали яшь Иванның саргәскәре, имеш!

— Казанлылардан канлы үч алачакмын, дигән

— Иванга тугрылыкка ант эчкән зөбанидан ни көтәсең?!

Корылыклы елның ачлык белән янавыннан шөбһәләнеп яшәгән шәһәр халкы, якын-тирә авыллар өстендә икенче, тагын да куркынычрак, имәнечрәк афәтнең аяусыз күләгәсе пәйда булды.

Сәүдәнең, базарның рәте китте. Малтабарлар ашлыкка бәяне күтәрде, аның артыннан башка малларның да хакы күзгә күренеп үсте. Казан диварлары эчендә генә бикләнеп калмаган шомлы хәбәрләр саладан калага, каладан салага күчә-күчә мәмләкәтнең ерак чикләренә барып җитте, аларны үтеп чыкты. Артык сак һәм кирәксез тәвәккәллектән шикләнгән базарчылар Казанны әйләнебрәк узу җаен карый башлады.

Идел боздан арчылып, беренче көймә кәрваннары килүгә үк бураларындагы ашлыгын озатып өлгергән Сәет сәүдәгәр ярык тагарак янында утырды да калды. Иван белән агасы Василийның кисәтүен санга сукмавы сәбәп булдымы, еллар иминлегенә ышанычы артык зур идеме — әмма сәясәттән читтәрәк торырга тырышкан алыпсатарыбыз быел алдатты, бар малын ашыгып сатып җибәрүе белән шактый зыян күрде. Хәер, ул аңа артык борчылмый, калган кадәресе гаиләсенә әле берничә ел кытлык күрми яшәргә җитәрлек, алла теләсә, башка төр мал-туар белән дә

---

* *Шыгавыл* — ишек сакчысы.

оста гына көн күрер җае бар. Аны башкасы борчый, башка уйлар җанын кимерә.

Сәет базарга чыкмас булды, үз эченә бикләнде. Шәһәр хәлләрен, дөнья хәбәрләрен хәзер улы — сәүдә тукталгач үз ирегендә калган Җәгъфәр алып кайта. Хәбәрләр исә берсеннән-берсе шомлырак, хәвефлерәк. Күңелдә бөреләнгән өмет учак кузысы күк пыскый башларга да өлгерми, яңа хәбәр аны пыран-заран китереп ташлый.

Юк! Казан өстенә моңарчы күрелмәгән олы яу килгәндә Кырым-йорт ярдәмсез калдырмас, солтан күз йомып тормас, диделәр. Сәет тә моңа ышана, элек еллардагыча, урыс Казанга килеп җиткәнче үк таркалып качар, дип өметләнә иде.

Җәгъфәр хәбәрләрне ташый да ташый. Егетнең йөзе суырылып калды, әллә ничек күз алдында олыгаеп китте. Күзләре генә ут яна. Гөлйөземнекенә охшаган зур кара күзләрендә ашкынып торган кыю дәрт тә, чаялык та, теләсә-нинди хәтәр адымга тәвәккәллек тә тоемлана. Сәетне улындагы әнә шул дуамал тәвәккәллек борчый да инде. Әмма кистереп кенә бернинди киңәш бирә алмый. Алай әйтсә дә, болай әйтсә дә, Казанны үлеп яраткан, аның һәр тыкрыгын, йортын, хөр күңелле кешеләрен, базарларын яшәешенең бер өлеше итеп кабул иткән, Кабанына, Болагына, мул сулы Иделенә гашыйк егетнең күңеленә яра ясар иде. Төзәлерлек кенә түгел, мәңгелек җөй, җәрәхәт салыр иде. Балага үз акылыңны биреп булмый.

«Без сугыш кешесе түгел, тыныч кына өйдә ят!» — дип аңа ничек әйтмәк кирәк?! Аңлармы ул аны, әллә этисен куркаклыкта, хыянәттә гаепләрме? Нинди куркыныч янаганын белми, аңламый ич ул! Урыстан саклан дисә, анысын хәзер Җәгъфәр үзе дә белә булыр... Тагын ни әйтәсең?.. «Үзең урыс син, урыс булгансың!» димәсме? Сәетне иң куркытканы, йөрәген кысылып-кысылып авыртырга мәҗбүр иткәне шушы шиктер, ахрысы... Җитмәсә, Василийның өйгә килеп керүе нинди тәэсир калдыргандыр... Ни-нәрсә сөйләшкәнне улы белми. Үз вакытында аңа әйтүне кирәк тапмаган иде. Инде менә хәзер... Әйтсә, ышанырмы? Әйтсәң дә, әйтмәсәң дә — берсе да Сәеткә аклану бирә алмый иде инде.

Ә хәбәрләр килә торды. Төрек гаскәре, тупчылары белән берләшеп, мең-мең атлы җайдакны әйдәп Мәскәүгә яу чапкан Кырым ханы Дәүләт Гәрәйнең Тула янында урыслардан җиңелүе турындагы шомлы хәбәр күңелдәге соңгы өметне дә сүндерде. Бетте! Барысы да челпәрәмә килде.

Көч туплаган, хәтәрлеген, усаллыгын көннән-көн арттыра барган Мәскәү кенәзенә казанлыларга япа-ялгыз каршы торырга туры киләчәк иде. Башка яктан көтәр өмет, ышаныч калмады.

Гаиләсенә татулык, тынычлык, ил-көнгә иминлек, балаларына һәм газизе Гөлйөземгә бөтенлек бәрабәренә бар мөлкәте, байлыгы, соңгы алтыныннан ваз кичәргә әзер Сәет берни дә эшли алмады. Дәүләт Гәрәйнең җиңелүендә ул яман фал күрде, җанын газаплы көтү ачысы биләп алды.

— Дошман чирүе Иделне кичеп чыккан. Казанга киләләр!..

Бу хәбәрне җиткергән Җәгъфәрнең бите кызарып чыккан, еш-еш сулый, кая басарга, үзен кая куярга белмичә үрсәләнә иде. Аның бөтен шәһәр буйлап йөгереп кайтканы, этисеннән — үзе өчен иң зур абруй булган кешесеннән — ниндидер хәлиткеч сүз көткәне әллә каян күренеп тора иде.

Сәет коелды да төште, авыз эченнән дога сүзләрен эвәләштермәкче булды, ләкин зиһене таркау — белгәне бер генә дә хәтеренә килми иде.

— Ни язган, шул булыр,— диде ул аптырагач.

Җәгъфәр этисенә сәерсенеп карады да, һәр сүзен өзеп-өзеп, ашыгып-ашыгып сөйләргә тотынды.

— Мин синең әйткәнеңә ышанмыйм... Ни язганны көтеп яту... ул... куркаклар эше...

Сәетнең йөрәгенә пычак кададылармыни! Бөтен бәгыре куырылып килсә дә, авыртуын тышка чыгармады. Кыяфәтен аклар өчен, табигатенә хас булмаганча, уенчаклыкка күчте. Үзе дә сәерсенде, теленнән углы ишетәсе килгән сүзләр чыкты:

— Ышанмый дөрес эшлисең, улым! Казан-йорт көчле, халкыбыз тәвәккәл. Кальга ныклы... Торырлар-торырлар да китәрләр. Кайда гына йөрмәдем, ниләр генә күрмәдем — мондый куәтле, ныклы ныгытмаларны очратмадым,— диде. Ул туктый алмый, сүзләре агыла да агыла иде.

Җәгъфәрнең күзләре елтырый башлады. Очынып, кабынып күргәннәрен тезәргә кереште:

— Урыслардан илчеләр килгән. «Ханыгызны, карачы, морзаларыгызны бәйләп безгә китерегез, сезгә берни дә булмас»,— дип әйткәннәр ди. Кальга өстеннән безнекеләр бер сүз белән авызларын каплаганнар: «Сез — дуңгыз ашаучылар,— дигәннәр.— Казанга баш булу кая, сез аны якыннан күрергә дә лаек түгел. Чөнки җаныгызда иман, денегездә нур юк,— дигәннәр.— Ә инде патшабызга килгәндә,

без аны үзебез сайлап куябыз. Тәхетебездә тумыштан хөкемдар гали затлар утыра. Сезнең нәселсез кенәзләрегез ишене без якын да китермибез, китермәячәкбез дә,— дигәннәр...— Казан — хөр мәмләкәт, хөр булып калачак та».

— Улым, тукта, ашыкма! Илчеләр җибәрерлек булгач, алай ук начар ният белән килмәгәннәрдер...

Җәгъфәр бер тында әйтте дә ташлады:

— Урысның кайчан изге ният белән килгәне бар?! Ашаган табагына... төкереп...— Аның бите бер агарды, бер кызарды. Атасына ярамаганны ычкындырганны сизенеп булса кирәк, бермәлгә тын калды, ни әйтергә белмичә, еш-еш сулап алды һәм басынкы тавыш белән әйтеп бетерде.— Яхшы ниятле кеше ханыгызны бәйләп китерегез дип киләме?

Дөрес сүзгә җавап юк иде. Сәет бер Гөлйөземгә, бер улына, бер кызы Галиягә карады да җавап таба алмыйча кул селтәде. Соңгы чарасы итеп Гөлйөземгә текәлде:

— Сиңа әйтәм, нишлибез? Мин — чарасыз... Алар килеп җиткәнче авылдагы йортка — сәйфиягә* дә күченмәдек, ичмасам...

Сорау сәер, хәтта мондый көнне мәгънәсез дә иде кебек. Ләкин башка чарасы булмаган Сәет үзе дә белештермичә дилбегәне Гөлйөземгә тоттырды.

Гөлйөземгә — кайчандыр чибәрлеге белән генә түгел, чаялыгы, үткенлеге белән дә Казан егетләренең күзен яндырган Гөлйөземгә әллә нәрсә булды. Иренең сыгылып төшүе, югалып калуына үртәлде, эче пошты, аның белән ике арага күтәреп булгысыз авыр нәрсә ятты кебек. Ләкин, бер мизгелдә күңелендә кайнап алган хисләрне авызлыклап, ул үзен кулга алды һәм сабыр итеп, ләкин кистереп фикерен белдерде:

— Кеше ни эшләсә — шуны эшләрбез. Яу килгәндә кулына корал алмаган ир — башына бүрек кияргә оялыр... Нәселебездә куркаклар булмады.

Гаилә киңәше шулай тәмамланды.

Үз-үзен кая куярга белмәгән Сәет ашыгып урамга чыгып китте. Аңа фикерләрен тупларга, нинди дә булса бер карар кабул итәргә, ни кылырга кирәклеген ачыкларга кирәк иде. Кая басканын, ничек атлаганын тоймыйча урамнар буйлап йөрде дә йөрде. «Чыннан да, хәрәмзадәләрнең сүзе дөрескә чыктымыни соң?!» Ул — мәмләкәттә сыеныр

* *Сәйфия* — дача.

урын, әһле базар арасында гына түгел, гавамда абруй казанган Сәет-сәүдәгәр ни эшли ала? Теленә йозак, күңеленә богау салып тагын ялгыштымы? Вакытында диван әһелләренә, инде алардан шикләнсә, үзенә хәерхак булган, иң өметсез чагында баласыдай күреп ярдәм кулы сузган Кол Шәриф хәзрәткә сиздерсә — үкенече дә бу кадәр авыр булмас иде.

Ул үзенең кайсы урамда, нинди төбәктә йөргәнен дә абайламый, чигәсен бораулап кергән соравыннан газапланып, дивана хәленә калган адәмдәй, бернинди максатсыз атлый да атлый иде.

Кинәт колак төбендә туптан аткандай яңгыраган думбаклар гөрселдәвеннән сискәнеп китте, авырттырып кысылган йөрәгенә чыдый алмый күкрәгенә тотынды. Кайда килеп чыгуын шунда гына абайлап алды Сәет. Хан сарае алдындагы киң мәйданда шаулашкан, гөҗләшкән кешеләр арасында икән ләбаса. Алар нәрсәдер кычкыралар, ачулы кыяфәт белән йодрыкларын төйнәп урысларга хурлау, каргыш, ләгънәт сүзләре яудыралар иде. Думбак тавышлары аларның барысын да күмеп китте, бер мизгелгә мәйданда авыр тынлык урнашты. Шул чакта һәммәсе дә хан сараен мәйданнан аерып торган таш дивар капкасына борылды. Ялтырап торган тимер башлык, тимер көбә кигән, түгәрәк калкан, үткен айбалталар тоткан чагдавыллар үзләренә генә мәгълүм ниндидер әмергә буйсынып, тимер капканы каерып ачып җибәрделәр, мәйданга җайдаклар ыргылып чыкты. Аларның кулларындагы озын сорнай-көрнәйләрнең җизендә кояш нурлары чагылды, йөзләрендә кырыслык, кыяфәтләрендә кыюлык, шушы мизгелдә үк утка-суга ташланырга әзерлек чалымнары иде. Чая егетләр атларын уйнатып алдылар да берничә төркемгә бүленеп кала урамнарына чаптырып кереп киттеләр.

— Сөрәнчеләр! Сөрәнчеләр килә! — дип кычкырды кемдер.

— Тыңлагыз, оран салучылар чыкты...

— Олуг хан галиҗәнабларының ярлыгын, ил-көн өстенә канлы гарасат янаганда олуг хан сүзен, диван фикерен ирештерәчәкләр...

Сәетнең тирә-ягындагы кешеләр шулай сөйләште.

Мәйдан уртасында ялгызы калган сөрәнче егет атын тыеп, өзәңгеләрендә күтәрелде дә сорнай-көрнәен ирененә тигереп, сузып-сузып оран салды:

— Газиз кардәшләр, куркусыз илдәшләр, кыю йөрәкле казанлылар, батыр җирдәшләр! Тыңлагыз! Тыңлагыз олуг

хан — галиҗәнаб Ядегәр хан ярлыгын! Диван әһелләре, сәетләрнең сәете изге Кол Шәриф хәзрәт сүзләрен сезгә җиткерәбез...

Без Мәскәү кенәзеннән дә, аның саранча өере булып төшкән явыннан да шүрләмибез. Кыяларга бәрелеп шаулаучы диңгез кеби аның аяусыз, канлы гаскәре. Әмма безнең кальгабыз кыядай нык, диварлары биек, капкалары тимер. Нидән куркыйк?! Таш кыяга ташланып күбекләнүче дулкыннанмы?! Яугирләребез, кешеләребез җитез, кыю, пәһлуандай куркусыз. Базларыбызда ун елга җитәрлек азык-төлек. Арабызда денсез кяферләр юк. Динебез, илкөнебез, хөрлегебез, балаларыбыз, чал картларыбыз, аналарыбыз хакына җаныбызны аямабыз. Кулыбызда корал тотарлык көч барында безне моннан беркем дә әсир-кол итеп алып чыга алмас! Урыска кол булудан да түбән, җирәнгеч нәрсә юк.

И горур казанлылар!

Ыру тамырлары безнекеннән сай, диннәре вә деннәре безнекеннән түбән хрәстияннәргә кол булырбызмы?! Юк!!! Аллаһы тәгалә моңа юл куймас!

Мәйданда җыелган халыкның сөрәнчене хуплап бер тын белән кычкыруыннан Сәетнең тамырларында бозга әйләнә башлаган каны җылынды, җанына тынычлык, өмет һәм ышану иңде. Якты дөньяны томалаган шик пәрдәсе таралып, күз аллары яктырып китте. Ничек башыннан чыгарган соң ул: сугышта әсир булуга караганда үлемне артыграк күрүче казанлылар тәҗрибәсез, мәнсез Иванга баш иярме? Юк, әлбәттә...

Мәйданны меңнәрчә бугазлардан берьюлы ургылып чыккан ярсулы авазлар күмеп китте:

— Юк! Кол булмабыз! Булмабыз!

— Урыс астында калганчы, яу кырында үлүең мең артык!..

Морза балалары, яугирләр, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, шәкерт вә таләбәләрдән алып кол-чураларга кадәр барчасы кулларын йодрыклап өскә күтәрде, сүзнең һәр иҗеге саен йодрыклары белән күккә, фараз кылынган дошманга кизәнгәндәй селтәнделәр. Мондый берлек-бердәмлекне, меңнәрчә бугаздан берьюлы ургылган дәһшәтле авазларны ишеткәне булмаган Сәет, казанлыларның тәвәккәл батырлыгына, кискен җавабына хәйран калды, сокланды, алар белән бергә тамагы карлыкканчы, күзеннән яшь чыкканчы илерә-илерә кычкырды:

— Казанны бирмәбез! Бирмәбез!

— Баскыннарга ләгънәт! Мең ләгънәт! Ләгънәт!

Гомум шаукымга бирелгән, үз-үзен белештермичә ярсып-ярсып кычкырган җиреннән ул кинәт туктап калды. Башына күсәк белән ордылармыни!.. Кылт итеп Иван-сәүдәгәр, аңа биргән вәгъдәсе исенә төште, үзең булмасаң, улыңны беләбез, җиде кат җир астыннан эзләп табарбыз, дип зәһәр пышылдаганы миен көйдереп узды. «Ул бала кайда йөри икән?» Бүз углан булып үсеп килүче Җәгъфәрне аяп, ул аңа янаган куркынычны белдермәде, эченә йотты, азмы-күпме сакланып йөрергә кирәклеген дә искәртмәде ич. «Йа хода! Инде аңа карата бер-бер хаинлек, кабахәтлек кылынмаса ярар иде. Хәрамлык, хөсетлек утында янган, сугыш әләме күтәреп килгән Иваннан барысын да көтәргә була. Казанда шымчылары булмый калмас. Тәгаен бардыр. Аллам сакласын!»

Сәет пышылдап дога укыды һәм, аяклары тартмаса да, мәйданнан чыгып китәргә, кайтып тизрәк Җәгъфәрне күрергә, күңелен тынычландырырга ашыкты. Кабаланып, чаба-йөгерә диярлек сәүдә рәтләре ягына төшеп китте. Салмаклыгы, кеше белән аралашуда вәкарьлеге белән танылган Сәет-сәүдәгәрнең болай пырдымсыз кылануын башка вакытта күпләр сәерсенеп карап калыр, бер-бер хәл булгандыр дип фараз итәр, ярдәмгә ашыгыр иде. Әмма бөтен Казан таяк тыгып болгаткан кырмыска оясыдай кайнаган бу мәлдә аңа игътибар итүче дә, әйләнеп караучы да табылмады.

Чат саен сөрәнчеләрнең авазлары, әйтерсең, аны эзәрлекли, дошман алып килгән дәһшәтнең ачылыгын исенә төшерә, күңелендә кайнаган каршылыклы уйларны тагын да болгата, зәһәррәк төсләр бирә-бирә артыннан ияреп килә иде.

— Тәнендә җаны булган азамат ирләр, чая егетләр, кавырсыны ныгыган бүз балалар ил өстенә афәт килгәндә күләгәдә калырмы?!

— Мөхтәрәм казанлылар! Дары базларында дары җитәрлек...

— Барыгыз да коралга! Күзе үткеннәргә — мылтык, укҗәя, беләге ныкларга — кылыч, бәдәне тазаларга — сөңге, айбалта, гөрзи!..

— Изге калабызны этләрдән талатмыйк, дуңгыз ашаучылардан нәҗесләтмик!

Ләкин ничек кенә бәргәләнмәсен, җанын кыйнамасын, үрсәләнеп иренен чәйни-чәйни бәддога укымасын — Сәет инде берни дә эшли алмый, бер генә нәрсә дә аңа бәйле

түгел иде. Үзен сыендырган, байлык һәм муллык биргән, тәүге һәм бердәнбер мәхәббәте бөреләнеп чәчәк аткан, канынннан яралган газиз балалары тәпи баскан шәһәрне, бөек Казан патшалыгын, җирдәге җәннәткә тиң изге мәмләкәтне саклап, яклап калу өчен ул хәзер инде берни дә эшли алмый иде. Кайчандыр булган мөмкинлекне кулдан ычкындырды, тар күңеллелек, курку колына әйләнде. Гомерендә бер мәртәбә кулына мылтык алып атмаган, кылыч белән кеше канын коймаган, җан кыймаган, базар әһеле булып тыныч кына яшәп яткан сәүдәгәр Сәет ике ут арасында торды да калды.

Җанын изгәне шул: һәр ике як та аңа бердәй якын, һәр ике як та аңа газиз, кадерле. Күкрәк сөте имезеп үстергән, телен ачкан анасына, уналты ел хәләл икмәген-тәгамен ашаткан атасына, бер ятакта аунаган карындаш агасына кул күтәрсенме, яисә җанының яртысы — хәләле Гөлйөземгә, җир йөзендә кеше иткән, үчне-хөсетлекне белмәгән, туганыннан якын күреп үз араларына алган Әҗем картка, кайчандыр сукбай егеткә фатихасын биргән Кол Шәрифкә, бәгыреннән өзелеп төшкән балаларына хыянәт итсенме?!

Пошамангa калырлык та бар. Ничек кенә сәер тоелмасын, Сәетнең моңа кадәр бу хакта тирәннән уйланганы, төн йокыларын калдырып, газапланып баш ватканы булмады. Ә гомер дигәнең койрыклы йолдыз шикелле үткән дә киткән ләбаса! Яшьлектәге хаталар, комарланып дөнья куу, искә-өскә алмаган әллә ни кадәр вак-төяк ялгыш адымнар Сәетне чишә, сүтә, ерып чыга алмаслык катлаулы, гаять тә четерекле мәсьәлә алдында япа-ялгыз калдырды. Барып сыеныр кешесе дә юк бит ичмасам. Хәер, алай ук түгел. Алар бар. Күп тә хәтта. Хәлбуки, дус, иш булсалар да, алар Сәетне аңламас, ул кичергәнне төшенмәс, газапларының серенә керә алмас. Чапкын-күзәтчеләрнең әйтүләре хак булса, Казан капкасы төбендә йөз илле меңлек урыс явы корал шалтыратканда Сәетнең шик-шөбһәсе, икеләнүенең ни бәһа торачагын дивана кеше дә бер сүз белән әйтеп бирә алыр иде.

Аңа хәзер бер генә юл — эчендәген тышына чыгармау, авызга су кабып шым булу! Башка чара юк! Берьюлы ике куян койрыгын тотып булмаган шикелле үк, ул күңеленнән ике якны да якын күрә, әмма бер якка да авыша алмый. Бизмәнгә артык зур, кеше гакылы колачлый алмастай олы төшенчәләр — яшәү һәм үлем, намус һәм кабахәтлек, мәхәббәт һәм нәфрәт салынган. Мәхәббәтне сайласа, үлчәү

тәлинкәсенең икенче ягындагы нәфрәт калкып чыга, яшәүне алыйм дисә, бизмәндәге үлем якыннарына, газизләренә яный башлый. Намусын саклыйм дисә, икенче бер тарафтан кабахәтлек баш күтәрә. Йа хода! Нинди гөнаһларым өчен җибәрдең миңа мондый җәзаларны?!

Җир йөзендәге дүрт кыйтганың сәүдә кыйбласы Казан-йорт бу афәттән исән-аман котылырмы? Хәзер барча мөэмин-мөселманның җанын шушы сорау кыйный. Сәет яхшы белә: Казан-кальга Кырым, Әстерхан мәмләкәтләренең, нугай урдасының, даладагы күчмә төркиләрнең калканы гына түгел, үсеп, көчәеп килүче Мәскәү кенәзлегенең ярсуын Ливония, Швеция, ләх короленнән читкә юнәлтеп торучы олы көч, бөек мәмләкәт тә ул. Әгәр, күзәтчеләр расла-ганча, яшь Иван бар куәтен-көчен Казан-йортка ташлаган икән, димәк ки ливониялеләр, ләхләр, шведлар да тик ятмас, хуҗасыз калган йортка тәмгысын сузучылар табылыр. Шулай булгач, бәлки әле урыс гаскәренең Идел, Казан суы буйларында котырган эт өередәй айкалуы озакка бармас... Ләхләр яисә ливониялеләр кузгалуга артын-алдын уйламаган Иван тупларын, азык-төлек төягән көймәләрен, арбаларын сача-сача Мәскәвенә чабар.

Ул гына да түгел... Кара диңгез ярларын дер селкетеп торучы солтан, кардәш Кырым-йорт, Әстерхан хакимнәре Казанның ялгызы канга батып урыс белән чапырылышуын тыныч кына карап ятарлармы?! Юк, әлбәттә! Димәк, артык борчылырга, үзеңне ватарга ярамый. Афәтле кара көннәр үтәр дә китәр, янәдән Казан суы ярларына дөнья малтабарларының бихисап кәрваннары агылыр. Ничек тә күзгә-башка чалынмыйча сак кына, сабыр гына кара көннәрне үткәреп җибәрергә кирәк. Иншалла! Барысы да бетәр, үтәр... Урыс белән татарның беренче бәрелеше генә түгел. Азау ярган малтабарлар әйтмешли, Казанда әлиф* дип әйтсәләр, мәскәүлеләр би* дияргә мәҗбүр, ә инде әлиф-бидән соң ливониялеләргә бер генә юл — ти* дияргә генә кала... Элек шулай иде, шулай булыр, шулай дәвам итәр. Амин! Шулай гына була күрсен!..

Миендә чәбәләнгән, чуалган йомгак хәлендәге уйларының эзлекле агымга керүе Сәетнең күңелен күтәреп җибәрде. Буыннарына хәл керде, күтәрә алмастай хәсрәттән сыгылган гәүдәсе турайды, сынын төз тотып, егетләрчә җитезлек белән юлын дәвам иттермәкче иде... Олы урам

* *Әлиф, би, ти* — гарәп әлифбасындагы беренче өч хәреф.

чатыннан Аталык тыкрыгына борылуга, күкрәгенә гөрс иттереп нәрсәдер килеп бәрелде.

— Күзең чыкканмы әллә? Ат астына керәсең... Гомереңне урыс белән сугышырга сакла! — дип гөрелдәде калын күкрәк тавышы.

Әле яңа гына ак-караны аерыр хәлгә килгән Сәет керфекләрен челт-челт йомды. Каршында түшенә каешлар белән калын табак зурлыгында тимер ат калканы беркетелгән озын торыклы чаптар басып тора иде. Маңгае белән калканга килеп төртелгән Сәет аны-моны аңламыйча, артка сикерде.

Тагын җайдакның калын тавышы ишетелде:

— Ә-ә... Синмени әле бу мөхтәрәм Сәет Сәлим углы... Кая шулкадәр ашыгасың?..

Шушындый көндә, иң кирәксез чакта, йөрәге алгысуга түзә алмыйча үзен кая куярга белмәгән мизгелләрдә нәкъ менә аны очратырмын дип башына да китермәгән Сәет телсез калды. Ат өстендә күптәнге танышы, кайчандыр көндәшләр булган би углы Шәһит утыра иде. Аның тавышында мыскыллау чалымнары, астыртын көлү сиземләгән кебек булды Сәет. Бәлки алай да булмагандыр. Әмма күңеле тулы шик аңа шулай тоемларга куша иде. Дөресен әйтергә кирәк, моңарчы да юллары кисешмәде түгел. Ләкин ни Сәет-сәүдәгәр, ни Шәһит морза бер-берсенә этлек эшләмәде, нәкъ кирәк микъдардә генә ташлама ясый белделәр, күзгә-башка бәрелмәслек иттереп кенә кирәксез очрашулардар кача килделәр. Әйе, шулай иде. Гөнаһысына керәсе юк, Казан-йортта сүзе үтүчән абруйлы нәселдән булса да, Шәһит үчлек кылмады, хөсетле адәм түгел иде. Ә менә бүген... нигәдер аның гөбедән чыккандай тавышыннан йөрәге дертләп китте, анда, әйтерсең, төрттерү, яшерен киная бар иде. Сәет аны нәкъ шулай, үзенең үткәненә, дошманнар белән кардәшлегенә төрттерү дип кабул итте.

Миеннән яшен тизлеге белән шундый уйлар узды. Авызына су капкандай тору уңайсыз иде, аны бит башкача аңларга да мөмкиннәр, җавап бирергә ашыкты:

— Әйе, мин фәкыйрегезмен, Шәһит морза... Мондый көндә... ничек ашыкмыйсың...

— Җавабыңны хуплыйм, тәкъсир! Кулыңда сөңге тотарлык җегәр тойсаң, йөрәгеңдә яугир утын алтын чыңы томаламаса, рәхим ит, минем алаемда* урын табылыр. Рәхим-шәфкатьсез дошманга ялгыз чыкмассың ич...

* *Алай* — полк.

Шәһит сүзләрен әйтеп бетерде дә җавап көтеп тә тормастан үкчәсендәге типкеләрен* түземсезләнеп ал тояклары белән җирне тырнап торган ярсу атының кабыргаларына батырды. Дөл-дөл кыяфәтле, ялыннан бәкәленәчә ап-ак төстәге чапкыр кешнәп арт аякларына басты һәм җайдагын Аталык капкасы ягына очыртып алып та китте.

Саргәскәрнең** ялгыз юлаучы белән сүз алышканын сабыр гына көтеп торган пәһлуаннар тезгеннәрен бушатты һәм бүәлеп торган ташкын ургылып Сәет яныннан агыла башлады. Аларның тимер көбәләрендә, очлы тимер башлыкларында, ат дирбиясенең шомартып ялтыратылган җиз өлешләрендә кояш нуры уйнады, киң урамны ташка бәрелгән меңнәрчә тояк тавышлары күмеп китте. Сафлар өстендә яшел ефәк әләмнәр, сөңге сабына күтәрелгән тулар*** җилфердәде. Гаскәр ярсу иде, ачулы иде, көче-куәте ташып торган тоташ агым иде, сүзсез иде.

Аларны үткәреп җибәрү өчен янәшәдәге йортның капкасына сыенган Сәетнең әллә нәрсәдән тәне калтыранып куйды, йөрәге кысылды. Үз көнен үзе күргән һәм инде малтабарлыкта — базаркәнлектә иң югары баскычка ирешеп тыныч кына яшәп яткан, гаскәрилектән бихәбәр кешенең Казан урамнарында мондый зур көчне, дәһшәтле ташкынны, таш манараларны селкетер куәтне күргәне юк иде әле.

Күңелендә урнашып өлгергән тынычлану хисен кул белән йолкып алдылармыни: тагын шикләр өермәсе кузгалды, күңелендә курку, бу тыелгысыз ташкын сытып-изеп үтәчәк кан-кардәшләрен кызгану дулкыны күтәрелде. Сугышның котылгысыз икәнен белгән хәлдә дә ул аны булдырмас өчен җанын-тәнен кызганмаска әзер иде. Әмма хисләрен авызлыклап тыя алмаган кебек, үзенең чарасыз икәнен, вакыйгалар колы икәнен дә яхшы аңлый. Яннарына сыендырып кеше иткән, ил-көн арасында дәрәҗә, мал-мөлкәт биргән, нан**** һәм дан уртаклашкан казанлылар газиз һәм якын булган кебек, урыс кавеме дә аңа дошман түгел, якын һәм газиз иде, һәр ике якка миһербан, шәфкать һәм

---

* *Типке* — шпор

** *Саргәскәр* — гаскәр башлыгы.

*** *Ту* — борынгы төрки халыкларда ат кылыннан ясалып, башына ай сыны урнаштырылган байрак.

**** *Нан* — икмәк

мәрхәмәт, бер-берен аяуны теләп кемнәргә генә баш орырга!!!

Әгәренки шушы мизгелдә «Син — дөньялыкта Сәет Сәлим углы, ә тумышың, чыгышың илә Александр Савельич Булгаков, җаныңнан ваз кичсәң, барысы да үз урынына кайтыр, урыс явы кубарылып кайтып китәр, казанлылар тынычланып элеккечә көн күрә башлар. Ризамы шушына?» — дисәләр, ул ике дә уйлап тормый каланың иң биек манарасына менеп йөз, мең мәртәбә кычкырыр иде.

— Риза, риза, мең кәррә риза! Тик хәләлем Гөлйөзем сау булсын, газизләрем Җәгъфәр илә Галия генә ачылып җитмәгән чәчәк көйгә харап булмасыннар.

Кешеләр! Сез — адәми зат, аллаһы тәгаләнең сөекле коллары, табынуыгыз төрлечә булса да, бер кодрәт иясенең балалары, туктагыз, акылыгызга килегез, җир йөзендә урын җитмиме әллә,— дип сөрән салыр иде.

Аһ, ни аяныч! Бу аның кулыннан килми. Күзләрен кан баскан, җан һәм кан даулап, гөнаһлы дөньялыкта үзләренә җәннәт кора алган казанлылардан җир-су яуларга килгән явыз урыс Иванны айнытыр көч юктыр, күрәсең. Мондаен дәһшәт каршында казанлыларга бер генә юл: канга — кан, үлемгә үлем белән җавап бирү, изге каланы яклап соңгы сулышкача дошманны кыру, юк итү, җир өстендә эзе калмаслык итеп себереп түгү.

Гаскәр үткән арада Сәет шуларны уйлап өлгерде. Соңгы атлы чаттан борылуга юлын дәвам иттермәкче булып кузгалган гына иде, олы урамның аргы башында тагын бер төркем атлылар күренде. Алар дәртле тавышлар белән һайһулап бөтен киңлекне тутырып чаптыралар иде.

— Нөгәрләр* алае, угланнар төркеме,— диде кемдер, шатланып хәбәр салды.— Һай, ничек матур киләләр!..

Сәет яңадан капка куышлыгына ешынырга мәҗбүр булды.

Ә угланнар төркеме, чыннан да, матур иде. Сөлектәй атларда зифа сынлы яшь егетләр... Гәүдәләре төз, кыяфәт көяз. Әле мыек та чыгып өлгермәгән иреннәре арасыннан ак тешләре күренә дә, йөзләрендә кырыс чаялык тоемлана.

Ерактан томырылып килгән яшьләр хан сарае мәйданына җитәрәк атларын тыя төштеләр, бер-берсен дәртләнде-

---

* *Нөгәр, нугәр* — морза, би балаларының дус егетләре. Алар, гадәттә, бер алайда сугышкан.

реп ярсып кычкырышулары, шаярышып әйтешкәннәре тагын да ачыграк ишетелә башлады.

— Канга — кан, үлемгә — үлем!..

— Казанга яу белән килгән, яудан әҗәлен табар!..

— Әй, мөхтәрәм җирдәшләр, илдәшләр! Чын ир затлары барында Казан саклаучысыз, яклаучысыз калырмы?!.

— Меник ярсу атларга, хөр Казанны сакларга!

Алгы сафларда иптәшләрен дәртләндереп, кычкырып барган егеткә арадан берсе шаяртып төрттерде:

— Кулыңда сорнай түгел, сөңге! Әллә оныттыңмы, җыручы-чичән?

Җыручы-чичән дигәнгә кәефе килдеме, атын уйнатып барган киң күкрәкле егет, тирән сулыш алып, бәрхеттәй йомшак, әмма көчле, калын тавыш белән җырлап та җибәрде:

Без капкадан чыккан чакта
Гөрселди урам ташы.
Гөрселдәсен урам ташы,
Калтырар дошман башы...
Һай!

Аны йөзләрчә угланнарның дәртле, яшь тавышлары күтәреп алды:

Һай!
Гөрселдәсен урам ташы,
Кыелыр дошман башы...

Җыенга баргандай чиста, ак-пакь киенгән, кулларына кылыч, сөңге тоткан, аркаларына ук-җәя аскан, коралчы кулыннан яңа гына төшкәндәй көмеш аклыгы белән ялтыраучы калканнар аскан нөгәрләрнең дәрте, ярсуы урамдагы узгынчыларга да тәэсир итми калмады. Берәүләр аларның чаялыгына, көязлегенә сокланып тел шартлатты, икенче берәүләр дога укып егетләргә җиңү, дан, кыюлык теләде, яшь кызлар ат тояклары астына тәңкә сиптеләр, чәчкәләр ыргыттылар.

Бер көн эчендә оешып, тупланып өлгергән гаскәрнең күплегенә, дошмани көчләрнең бинибая зур куәт белән кала капкасы төбендә генә ярсып азынуына да карамастан, көр күңеллелегенә Сәет тә хәйран вә вәйран иде. Кинәт аның йөрәге жу итеп китте, күргәненә ышанмыйча күзләрен угалады. Нөгәрләр сафында аның газизе, бердәнбер улы Җәгъфәрнең йөзе балкый иде.

Ата белән улның күзләре очрашты. Җәгъфәр өзәңге-

сендә күтәрелде һәм сөңгесен болгап әтисен сәламләде. Аның бөтен кыяфәте, гәүдә тотышы «Әти, күр! Мин дә кала саклаучылар арасында. Йөзеңә кызыллык китермәм!» дип сөйли, шуны белгертергә тели иде кебек.

Җәгъфәр җәйләүләргә чыгып, үзе тәрбияләп, карап үстергән алмачуар айгырны иярләгән, дирбияләрнең иң асылын, кыйммәтлесен сайлаган иде.

Үзе өчен иң кадерле затның — багалмасының дәһшәт эчендә югалып калмавы, киңәшми-нитми нөгәрләр алаена керүе Сәетне бер яктан сөендерсә, улының кыюлыгыннан горурландырса, икенче яктан ут йотарга, аның язмышы өчен борчылып кыйналырга мәҗбүр итә иде.

Атлылар үтеп китүгә бушанган урамда Сәет уйлары белән ялгызы гына басты да калды. Бу мизгелләрдә ул, чыннан да, ялгыз, бөтен Казан мәмләкәтендә япа-ялгызы иде, күрәсең. Әллә каян Җәгъфәрнең бала чагы — туп кебек йомры, ак шалкандай чиста, садә чагы, сөеп туймастай чагы исенә төште.

Уртак мәхәббәт җимеше, каннарын кушып яралган нәни йомарламнан да кадерле, аннан да тансык, газиз нәрсә юк иде ул чакларда Гөлйөзем белән Сәеткә. Ай бу гомер дигәнең! Бала бишектә чакта сөйдерә, аннан төшсә көйдерә, дигәннәр. Хактыр, шулайдыр!..

Җәгъфәр тугач, ике арадагы якынлык, мәхәббәт хисе кимемәде генә түгел, тагын да нығыды, азмы-күпме аларның татулыгыннан көнләшеп йөргәннәрне дә сокландырыр дәрәҗәгә җиткән иде. Дөньялыкта шулай бит ул, әллә каян гына килеп чыккан берәүне тиң күргәнче, үз араларына кабул иткәнче күпләр аны баштарак сөйми һәм бу сөймәүне яшереп тә тормый, һаман-һаман читкә кагарга тырыша. Ә инде бернинди хөсетлеккә карамый үзенекен иткәнен, юлыннан тайпылмаганын күрсәләр, сокланып сөйли башлыйлар, үрнәк итеп куярга да күп алмаслар. Чыннан да, шулай. Мәхәббәттән нәфрәткә бер адым булган кебек, нәфрәттән мәхәббәткә дә бер генә адымдыр, күрәсең!

Ничек кайтып кергәнен дә сизмәде Сәет. Капканы ачып баш игән хезмәтчегә күтәрелеп тә карамыйча йортка үтте. Тизрәк, тизрәк Гөлйөзем янында тынычланасы, рухын, җанын изгән газаплы уйлардан арынасы килгән иде. Яшь чакларындагыча бар дөньяны онытып, хатынының назлы кочагында эрисе, яратып әйткән сүзләрдән изри-изри дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичәргә иде бит!

Гөлйөзем дәшмәде. Куе керфекләре арасыннан күз сирпеп алды да читкә борылды.

Ни эшләргә белмәгән Сәет: «Әй, сагынып та кайттым соң үзеңне»,— диясе урынга, бер сулыштан яңа хәбәрне әйтте дә салды:

— Җәгъфәр нөгәрләр алаена язылган. Угланнар арасында күрдем,— диде.

— Әйе, аңа мин рөхсәт бирдем,— диде Гөлйөзем басынкы тавыш белән. Күзләренә тутырып карагач, тагын өстәп куйды.— Ил өстенә гарасат янаганда әнкәсе куенында ятас!

Сәетнең йөрәгенә пычак кададылармыни!..

Гомерендә, күтәрелеп, иренә үпкә йә кинә белдермәгән Гөлйөземнең сүзләрендә киная ачык, артык дәрәҗәдә аңлаешлы иде.

Гаилә башы нә хуплау җәһәтеннән, нә каршы төшү җәһәтеннән өздереп бер сүз дә әйтә алмады.

— Ә-ә... Шулаймы?! Алай булса, ярар,— диде дә Гөлйөземнең күзенә туры карамас өчен, ашыгып түр бүлмәгә кереп китте.

«Утырып бер сөйләшергә, аңлашырга кирәк. Болай ярамый ласа. Гаскәри түгелмен. Минем хәлне ул аңламаса, кем аңлар?! Эчемдә янган утны белми. Телем йозакта, кулым богауда... Нишлим?»

Сәетнең эчендәге ут кимемәде генә түгел, бөтен әгъзаларын яндырып, котырып ялкынланырга кереште. Гөлйөземнең аны куркак дип, яисә урыска каршы барырга теләми дип бәяләячәген ул белми түгел, белә һәм хәзер моның нәкъ шулай икәнлеген дә төшенеп өлгергән иде инде. Хәер, бөтенесе дә, чыннан да, шулай да бит... Аңламыйлар, белмиләр... Кем өчен өзгәләнгәнен белмиләр. Әле дә ярый Җәгъфәр белән Галия сиздерми. Әгәр алар да шуны әйтсә, шикләнгәннәрен белдерсә?!.

* * *

Казанның һәр тарафын кара чиру булып урыс гаскәре чорнап алды. Кальга өстеннән караганда баштарак мыжгып торучы тоташ бер куч шикеллерәк кенә күренгән яу хәзер тагын да якыная төште, иярләренә үлек эт башы аскан кызыл киемле, очлы башлы бүрек кигән сугышчыларның кырыс чырайларын, алай-алай булып урнашкан төркемнәр өстендә җилфердәгән кызыллы-зәңгәрле әләмнәрне дә абайларга мөмкин.

Дошман ләшкәренең* иге-чиге юк. Болак аръягындагы болынлыктан алып офыкта күгелҗемләнеп торган урманнарга хәтле ара кызыллы-каралы чуар атлылар, җәяүле укчылар белән тулы. Урыс озакка дип килгән. Утрау-утрау итеп калдырылган ачыклыкларда авыр, юан көпшәле туплар, мичкә-мичкә дары өемнәре. Алар янында атлы сакчылар таптана. Укчылар һаман агыла да агыла. Әйтерсең Мәскәү кенәзе үз кул астына кергән кенәзлекләрдә бер генә ир затын да калдырмыйча чиргенә куып керткән.

— Билләһи, шулай бу! — Алмачуарын дус егетенә калдырып кальга өстенә менеп баскан Җәгъфәр күңелендәген кычкырып әйткәнен сизми дә калды. — Их, Аталык манарасындагы авыр туптан дары мичкәләренә бер ядрә тондырырга иде!.. Көлләре күккә очсын иде.

Янындагы тупчылардан берәү яшь угланның кычкырып хыяллануын әллә хуплап, әллә яратып бетермичә кырыс кына әйтеп куйды:

— Урыслар да дивана түгел. Кала тупларының ни арага ата алуын исәпләгәннәр диярсең, нәкъ ядрә җитмәс җирдә чокыналар! Юкса, күрсәтер идек!

Ике арадагы дәһшәтле тынлык, һәр ике якның ашыгаашыга сугышка, тәүге бәрелешкә әзерләнүе картрак, дөнья күргәнрәк гаскәриләрнең күңеленә шом салса да, аларның ни уйлавыннан, ни кичерүеннән бихәбәр Җәгъфәр тагын киңәш биргәндәй үзенекен сукалады:

— Дарыны күбрәк салсаң да җитмиме?

Тупчыларның әле генә сукранганы кызыксынып егеткә карап алды да җилкәсен җыерды. Иптәше җавап бирде:

— Туп үзенекен сорый ул. Артыгын салсаң, ядрә белән бергә үзең дә җәһәннәмгә олагырсың. Белдеңме?! — Тагын бер кат текәлеп карап куйды да ачуланмый гына мыгырданды. — Күпне белсәң, тиз картаерсың. Йә, бар! Күп тыкшынып йөрсәң, дошман шымчысы дип кулыңа богау салмасыннар. Ясавылларның ачуына юлыкма!

Дустанә әйтелсә дә, аның соңгы сүзләре Җәгъфәрнең йөрәгенә ук булып кадалды, битенә куе кызыллык йөгерде, билендәге хәнҗәренә тотынганын сизми дә калды.

— Кем шымчы? Кем?.. Сүзеңне үлчәп әйтмәсәң...

Ләкин әйтеп бетерергә ирек бирмәделәр, яуга кермәс борын кайнарлыгын күрсәтә башлаган егетнең кыланышы калай этәчнекедәй чыкты булса кирәк, тирә-юньдәгеләр шаркылдап көлеп җибәрде:

---

* *Ләшкәр* — гаскәр.

Йә, йә... гайрәтеңне дошманга калдыр! Ашыкма!..

Уңайсыз, көлке хәлгә таруын аңлаган егеткә тупчылардан читкә кыяклаудан башка чара калмаган иде инде. Ул ачуын эчкә йотты, кызрачлыгына уртәлә-уртәлә койма өстендәге ачыклыкка менеп басты да урыс гаскәрен күзәтергә кереште. Күзләре талчыкканчы, ачытып яшьләнгәнче карап торды. Кыяфәтләреннән, йөзләреннән, йә булмаса үзләрен тотышларыннан ниндидер куркыныч сыйфат, дошманлыкны белгертүче нинди дә булса бер әшәке хасият табарга тели иде. Күпме тырышмасын, ул әлегә андый нәрсә абайлый алмады. «Ерткыч та бит тыныч чакта тыштан караганда бик сөйкемле, матур күренә. Болар да шулайдыр... дошманлыклары эчләрендәдер»— дип үзенчә нәтиҗә ясады. Һәрхәлдә, үз иркендә булса, казанлыларга афәт янамаса, сугыш хәле игълан ителмәсә, бу ят киемле кешеләр белән ул һич кенә дә сугышып тормас иде. Беткәнмени җир йөзендә башка кавемнәр?! «Әйдә, яши бирсеннәр!»,— дияр иде.

Хәлбуки, бу фикере үзенә табигый тоелса да, атасының урыс кына түгел, дистәләрчә башка кавемнәр белән сәүдә итүен, мал алышуын белгән егет дөньяда бар нәрсәнең дә үзе уйлаганча гади генә түгеллеген дә яхшы аңлый иде, әлбәттә. Кешелек тарихының даим сугышлардан, кан коешлардан торганлыгына да мәгълүматы бар, яшенә күрә шактый ук тәрбия алган, белем җыйган углан ич ул!

Уйларына йотылган Җәгъфәр коймә өстендәге укчыларның тавыш-тынсыз гына имән бүрәнәләр ышыгына сыенып посуын да, тупчыларның тыз-быз йөренә башлавын да сизми калган иде. Сәер тынлыктан айнып Болак аръягына күз ташлауга, моның сәбәбен дә аңлап алды.

Әле күптән түгел генә ялга туктаган җыенчылар шикелле төркем-төркем утырган дошман гаскәре хәрәкәткә килгән, казанлылар күз алдында сафларга тезелеп, нәрсәдер эшләргә җыенып яталар иде. Менә каяндыр җигүле атлар килеп чыкты, арбалардан бүрәнәләрне араталап беркеткән кечкенә салларга охшаш җайланмалар төшерделәр. Бил тиңентен чишенгән әзмәвердәй ирләр аларны ярдан Болакка шудыртырга кереште. Урысларның көпә-көндез елга аша күпер салып маташуын күсәк углы күсәк булмаган теләсә-кем аңларга тиеш иде бит инде.

— Нишләп туплардан берне тондырмыйлар, нәрсә көтәләр,— дип үрсәләнде Җәгъфәр.— Нигә һич югы мылтыклардан күмәк атышка боерык бирмиләр? Кемне көтәләр?!

Ул гасабиланып, үртәлеп йодрыкларын кысты, ярсып-ярсып имән бүрәнәгә суккаларга тотынды:

— Нигә атмыйлар соң инде?!

Кызыксынып, бу сәер тынлыкның сәбәбен аңларга, имән диварлар артына посып һәрберсе сәгатькә тиң авыр мизгелләрне санаучы тупчыларның битараф тынычлыгын төшенергә тырышып карады. Әмма берни дә аңлый алмады. Тупчылар, әйтерсең, кунакка килгән таныш түгел мөсафирларны кабул итәргә әзерләнә, йөзләрендә салкынлык, ичмасам, ник бер төкләре селкенсен!

Акрынлап алардагы салкын канлылык Җәгъфәргә дә күчте. Ныгытмадан ерак түгел калдырган Алмачуары белән дус егетен барлап күз салды да тагын дошманның ни кыланачагын күзәтергә, өлкән укчылар, сабыр тупчылар шикелле түземлелек белән вакыйганың ни юнәлеш алачагын көтәргә булды. Тәҗрибәле гаскәриләр белми эшләмидер!

Болакта салчылар чупырдашты. Каланы саклаучыларның бер аваз белән, мылтыктан яисә туптан атып бу эшкә мөнәсәбәтләрен белдермәве аларның әрсезлеген тагын да арттырды, Казан ныгытмаларыннан ярты чакрымлап кына ераклыкта кычкырыша-кычкырыша, бер-берсен дәртләндереп кайнашуларын белделәр. Койма өстеннән аларның текә яр астында ни майтарулары күренми, әмма киң бүрәнә күпернең су уртасына ук узганын абайларга була иде инде.

Әйтерсең лә Җәгъфәр өчен вакыт акмый, үтми, бетми торган ниндидер сәер халәткә әверелде. Аның мизгелләре дәкыйка*, дәкыйкалары сәгатькә әйләнде. Дошманның мәкерен, ут белән, кылыч белән өстеңә сикерергә әзерләнүен күреп, белеп, көтеп ятудан да газаплырак нәрсә юктыр җир йөзендә. Ни эшләргә, мәртәт дошманның юлына ничек киртә куярга белмәгән егет үртәлеп, үрсәләнеп, «Ичмасам, тизрәк бу ярга чыксыннар иде инде»,— дип уйлап куярга да өлгерде.

Озак көтәргә туры килмәде. Күпернең әзер кисәкләрен, күрәсең, алдан ук бер-берсенә яраштырып, җайлаштырып килгәннәр, Җәгъфәргә кимендә алты-җиде сәгатьтәй тоелган ярты сәгать эчендә Болак суы ярларын шактый ук тотрыклы кичү тоташтырды.

Күпер коручы салчылар судан чыгып та өлгермәде, җәяүле урыс гаскәре кичүгә ургылды. Сөңге, гөрзи, озын

---

* *Дәкыйка* — минут.

туры кылыч, айбалта һәм ук-җәя, мылтык белән коралланган сугышчылар бер-берсен дәртләндереп кычкыра-кычкыра текә ярдан үрмәләделәр, чыгып җиткәннәре исә, алдаучы хәрәкәт ясаулары идеме, каланы саклаучылар көткәнчә ныгытмаларга түгел, Арча кыры ягына агыла башлады.

Җәгъфәрнең артык карап торырга түземе җитмәде, тешләрен кысып, йөрәкләнеп, баскычтан иптәшләре — нөгәрләр янына йөгерде. Өч-дүрт басманы бер итеп төшеп җиткәндә, угланнар инде атларына менгән, кылычларын айкап, һай-һулап һөҗүмгә әзерләнәләр иде. Түземсезләнеп, ал аяклары белән җирне казып бетергән Алмачуарның иярене сикереп Җәгъфәр дә аларга кушылды.

— Менә-менә... хәзер... Капкалар ачылыр да атлылар ташкыны мәкерле дошман чирүен Болак суында тончыктырыр!..

Әмма угланнарны яуга чакыручы юк иде әле. Капка төбендә үзләре генә түгел, атларын да тимердән киендергән Шәһит морза алае. Сугышчыларның һәр хәрәкәте саен тимер чыңы яңгырый, йөзләрендә кырыслык, күзләрендә нәфрәт уты, хәрәкәтләрендә сабырлык. Алайның алдына баскан Шәһит морза кинәт шам кылычын кынысыннан тартып чыгарды һәм калын күкрәк тавышы белән кискен итеп кемгәдер әмер сүзләрен кычкырды:

— Беренче булып минем алай чыга! Ег-гет-ләр! Ә-зерлән! Капка ачылуга — алга! Дошман өстенә!

Атлы гаскәр шым булды. Янәшәсендәге икенче бер төмән башына* иелә төшеп, Шәһит морза киңәш иткәндәй акрын гына әйтеп куйды. Алардан ерак түгел атын тыеп тезгенне күкрәгенә тарткан Җәгъфәр барысын да ишетте, шан-шәүкәтле саргәскәрнең сүзләре аңа да килеп иреште.

— Угланнарны саклагыз! Чыгармагыз! Бу бәрелештә карап торсалар да ярар.

— Шәһит морза! Баланы суга салмыйча йөзәргә өйрәтеп булмый. Җиңелчәрәк бәрелештә чирканчык алсыннармы соң әллә?! Һәрхәлдә зыяны булмас!..

Баштагы сүзләрдән эчендә кайный башлаган үпкәне, гарьлекне сүндерергә тырышып, Җәгъфәр саргәскәрнең ни җавап бирәчәген ут йоткандай түземсезләнеп көтәргә кереште. Анысы ашыкмады. Камчы сабы белән итек кунычына беркетелгән тимер тасмага суккалап торды да бер сулыштан хәл итте:

---

* *Төмән башы* — гаскәр башлыгы.

— Ышандырдың!.. Ләкин бездән соң... Урысны какшаткач, таркаткач... Иравыллардан соң*...

— Хуп! Тыңлыйм, буйсынам.

Җәгъфәрнең эченә җылы йөгерде. Үзе дә аңламыйча, ни өчендер ул нәкъ менә шушы сугышта, бәрелештә катнашырга тели иде. Күз алдына Алмачуары белән дошман сафын ерып алга омтылуы килде, кылычы белән әле уңга, әле сулга селтәнде. Селтәнгән саен очлы бүрекле башлар аска тәгәрәде, аның янындагы дошман калтырап, артына да карамый Болак ярыннан ташланды. Ә Җәгъфәр: «Менә сезгә, менә сезгә Казан, менә сезгә Кабан, менә сезгә безнең хан»,— дип кабатлый-кабатлый шашынып алга омтылды.

Күрәсең, сугыш хәрәкәтләренә тагын да дәрәҗәлерәк, олырак саргәскәр җитәкчелек итә иде. Бәлки әле яшь хан — галиҗәнаб Ядегәр үзедер. Манара очында тимер тун** өстеннән яшел хөллә*** кигән, тимер башлыклы мәһабәт сын күренде, кулы белән чагдавылларга ниндидер ишарә ясады. Шуны гына көтеп торгандай, калын тимер капкалар шыгырдап ачылды, Болак белән кальга арасындагы ачыклыкка казанлыларның тыелгысыз атлы гаскәре ябырылды, ул юлындагы бар нәрсәне изеп-сытып үтәр ташкындай алга ыргылды.

Урыслар Казанда бу кадәр көч барын көтмәгәннәр идеме, әллә көтеп тә күпердән чыгып өлгермәгәннәр идеме — кояш нурында ялык-йолык килүче тимергә чорналган дулкын алдында бер мәлгә каушап калдылар. Хәер, үзләрен бик тиз кулга алдылар. Дошман күпердән дә, йөзеп тә Болак аша сугыш кырына агылуын дәвам итте. Аларның иге-чиге юк сыман, кара болыт булып бөтен мәйданны тутырдылар. Кайсы мылтыктан, кайсы җәядән атарга керешге. Ике арада канлы бәрелеш башланды, атлар кешнәве, кешеләрнең ярсып кычкыруы, тәненә сөңге кадалган яугирнең үлем ачысы белән илереп үкерүе, корычның корычка бәрелеп чыңлавы... барысы да буталды, аралашып һич аңламаслык, кабатлап булмаслык дәһшәтле күренеш тудырды.

Әле бер як, әле икенче як өстенлек алгандай тоелды. Менә-менә инде урыс сафлары артка тәгәри башлады ди-

---

* *Иравыл* — алдагы отряд артыннан баручылар.

** *Тимер тун* — панцирь, көбә.

*** *Хөллә* — өс киеменең җәйге пәлтә, плащ кебегрәк бер төре.

сәң, алар тын Идел өстеннән күтәрелгән калын дулкын шикелле тагын алга ташланалар, казанлыларны кысрыклыйлар. Тимер киемле атлылар Шәһит морзаның һәр әмереннән корыч йодрык булып тупланалар да, дошманның иң куе җиренә ярып керәләр. Аларны камарга теләгән дошман зәһәрләнеп чиный-чиный сафларын тыгызлый. Казанлыларга исә шул гына кирәк тә, иравыллар яңа көч белән алар өстенә ыргыла. Башлар җиргә оча, канлы гәүдәләр лапылдап җиргә барып төшә.

Озакламый өстенлек тулысынча казанлылар ягына күчте. Соң чигенә тарттырылган җәя бавыдай киеренкелек белән әмер көткән Җәгъфәрнең кылыч тоткан кулы, бармаклары тирләп чыкты, йөрәге күкрәк читлеген ватып чыгар дәрәҗәгә җитте. Әгәр шушы мәлдә чакырмасалар, ялгызым утка ташланам дип торганда гына нөгәрләр сафы өстендә сугышчан оран яңгырады:

— Угланнар! Алга!!!

Түземсезләнеп авызлык чәйнәп ярсыган яшь чапкырлар тезгеннәре бушауга үзләре кебек үк яшь җайдакларны бер ыргымда дошман сафлары арасына алып кереп тә киттеләр.

Җәгъфәр Алмачуарның муенына сыенды да атны ерактан ук шәйләп өлгергән дошман өеренә юнәлтте. Кызыл киемле бер төркем өч-дүрт атлыны чолгап алган, һәр егылган урынына дулкын булып тагын яңа сугышчылар калка иде. Уртада калган казанлылар арган, әмма бирешмичә, уңга-сулга кылычларын уйнатып, дошманны турыйлар. Тагын аз гына шулай дәвам итсә дә, урыс өеренең аларны изеп узачагы көн кебек ачык иде.

Чаптырып барган уңайга аның кылычы ялтырап очлы бүрекләр өстеннән узды, башы өзелгән муеннан ургылып кан чыкты. Җәгъфәрнең бер мәлгә бөтен буыннары көзән җыергандай тартышып килде, күзен кан басты, үзен-үзе белештермәс хәлдә ул селтәнде дә селтәнде. Кылыч тимере ниндидер йомшак нәрсәләрне кисеп, тишеп, кыеп узды, тимергә бәрелеп чыңлады... Ул инде бернәрсәне аермый, күз алдында тоташ бер кызыллык — кан, кан, кан, кызыл киемле дошман! Әгәр ул бер генә мизгелгә тукталса да, үзен шулай ук чөеп атачаклар, йөрәген очлы сөңге белән тишеп чыгарачаклар, ак, чиста гәүдәсен чаба-чаба тураклаячаклар, пычрак аяклары белән ул кисәкләрне таптап узачаклар иде.

Маңгаеннан туктаусыз тир ага, аны сөртеп алыр чама юк. Күзләре ачыта башлады. Селтәнгән җиреннән җиңе

белән маңгаен сыйпап алганчы узган арада, аз гына, эһ дигәнче генә берни дә күрми торды. Күзләрен ачса — каршында үзеннән өч-дүрт яшькә генә өлкәнрәк урыс егете. Аның тиргә манчылган җитендәй озын чәчләре маңгаена сыланган, бүреге бер якка кыйшаеп төшкән, зур, куе зәңгәр күзләрендә әҗәлен тойган болан баласыныкыдай томанлы элпә иде. Җәгъфәр шуларны абайлап өлгерде. Карашлары очрашты. Шул ук мизгелдә урыс егетенең авызы ачулы кыйшайды, бугазыннан илереп зәһәр тавыш чыкты. Җәядән ычкындырылган уктай алар бер-берсенә ташландылар. Алмачуар, өстендәге җайдагын күкрәге белән сакларга теләгәндәй, алга сикерде, урыс егетенең җирән айгыры арт аякларына басты. Озак та үтми алар тирә-якта ни-нәрсә барлыгын белештермичә кылыч уйнаталар иде инде.

Җан көченә кизәнеп сугудан калканнары яньчелде, ямьшәйде, атлары ак күбеккә батты, әмма берсенең дә өстен чыгарлыгы сизелми иде әле. Шулчак Җәгъфәр күз ачып йомганчы хәйләкәр адым ясады: атын тезгенләп артка чүктерде дә, уң як үкчәсендәге типкене Алмачуарның кабыргасына батырды. Хуҗасыннан мондый усаллык көтмәгән айгыр соң көченә киерелеп, сул якка ыргылды, чүккән җайдакка ташланам дип ыргылган дошман сугышчысы исә кылычы белән бушлыкны айкап үтте дә тыела алмыйча алга томырылды.

Җәгъфәргә шул гына кирәк тә иде инде. Хуҗасының ни теләгәнен бер хәрәкәтеннән аңлый торган тыңлаучан Алмачуар яшен тизлегендә җирән айгыр артыннан сикерде. Урыс, атын борып турылаганчы, Җәгъфәр аны куып та җитте, сул ягына төшеп кысрыклап, кылычын селтәде.

Үзе өчен иң уңайсыз хәлдә калган мизгелдә дошман кинәт мәкерле итеп көлеп җибәрде, тешләре ыржайды, ул ярсыган атын борырга азапланган арада шам кылычның үткен очы аның күкрәген кыеп узды. Җәгъфәр бер чапты, кизәнеп торып тагын чапты, көлүне күтәрә алмаган җаны тыела алмый, ул һаман кизәнә иде әле. Шулчак якында гына нәрсәдер лапылдап җиргә барып төште, тимер чыңлады.

— Айа, углан, булдырдың! Инде суына төш!

Таныш тавыш, калын күкрәк тавышы ишетелмәсә, Җәгъфәр инде ияреннән сыгылып төшкән гәүдә өстендә тагын күпме кизәнгән булыр иде, үзе дә белми.

Шунда гына айнып китте, борылып карады. Шәһит морза җәпләренә кадәр батып кергән сөңге очын яшел чирәм

өстенә җәйрәп төшкән корбаны гәүдәсеннән суырып алды да Җәгъфәргә елмайды, үз итеп дәште:

— Сугышта онытылма! Дошман бераү генә түгел! Юкса, әнә кара!..

Үзенә нинди куркыныч янаган булганлыгын егет шунда гына аңлап алды. Урыс егете юкка елмаймаган икән.

— Рәхмәт... асылзадә!..

Тезгенен бушатып китәргә укталуга, аны Шәһит морзаның салмак, сугыш барышында кирәгеннән артык тоелган сабыр кул ишарәсе туктатты.

— Ашыкмасаң да буладыр... Әнә, качалар...

Җәгъфәр сугыш яланының бушап калуын шунда гына күрде. Казан гаскәре дошманны бөтен кыр буена кысрыклап, Болакның текә ярларына китереп кыскан, кызыл киемле яугирләр бер-бер артлы аска төшеп гаип булалар иде.

Нәкъ менә шул мизгелдә кальга манараларыннан бер-бер артлы авыр гөрселдәү авазлары ишелеп төште. Болак өстендә болганчык су баганалары күтәрелде, инде тына төшкән иңрәү, үкерү, ат кешнәү авазлары яңгырады. Бераздан ядрәләр алга күчеп, инде елга аръягында, бер-берсен изеп-сытып качып баручы дошман өере өстендә шартлый башлады.

Аларга урыс туплары җавап бирде. Әмма алар казанлыларны зарарламый, ядрәләр калага җитә алмыйча ике арадагы бушлыкка төшә, зыян-зәүрат салмыйча куе чирәмлектә йотыла иде.

Җиңүчеләр яралыларны һәм кяфер кулыннан шәһит киткән изге батырларның гәүдәләрен җыеп, кире кальгага әйләнеп кайттылар.

Олуг мәмләкәт — дөнья сәүдәсенен үзәге, хөр Казан патшалыгыннан кан даулап, җир, мал, нан яуларга килгән урыс гаскәре, аларга сатылган хыянәтчел Шаһгали хан кавеменең беренче һөҗүме әнә шулай тәмамланды.

Казан халкы батырларны чәчәк, сусыннарын басарга ширбәт, тамакларын туйдырырга тәгам белән каршы алды. Уен-көлке, җыр-көй башланды. Җиңү исерткеч дәрәҗәдә саллы тосла, куанып җырларлык дәрәҗәдә татлы иде. Йөз илле меңлек чирү белән килдем дип мактанган явыз Иванның сүзе аяк астына салып тапталды, хакы булмаган килеш чар* дигән олуг исемне дәгъвалаган, тәмгысы, нәфесе чиксез яшь кенәзнең горурлыгы сындырылды.

---

* *Чар* — патша. Казанны яуларга килгәндә Иванның әле рәсми рәвештә патша титулы булмый. Ул бары тик Казанны, ягъни патшалыкны буйсындырганнан соң гына бу исемне үзләштерә, үзен Казан патшасы дип тә атый башлый.

Нечкә күңелле бүз углан Җәгъфәр генә бәйрәм сыенда катнаша алмады. Укшыды, күңеле болганды. Ризык күрүгә күз алдына җитен чәчле урыс килде, яраларыннан ургылган канның укшыткыч исен тойган кебек булды.

Иптәшләреннән аерылып, ул манара төбендәге куаклык арасына, кеше күзеннән ераккарак барып ятты. Тәне калтырый, үзеннән-үзе җирәнә иде. Моңарчы гомердә татымаган газаплы халәте әле шактый озакка сузылды.

Шау-шу басыла төшкәч, ботакларны аралап чыккач та ул үзенең яудашларын — нөгәрләрне тапмады. Күрәсең, алар да аның шикелле үк кичерешләрен кешеләргә күрсәтергә теләмичә, кайсы кая таралышкан иде.

Шәһәрдә бәйрәм тантанасы дәвам итте.

УРЫС СТАНЫНДА

— Барып, сиңа ни кылдым?
Берең ике булмасын!
Йортың-караң калмасын!
Ханнан ханны мин ектым,
Хан булып син дә калмассың!
Сөт урынына кан койдың,
Канымны түгеп ни кылдың?
Казан, Кырым, Аждаркан,
Кунымны сорап купканда,
Ни булганын анда күрерсең!

«Идегәй».
Борынгы татар дастаны.

Кальгадагы туплар тынып калды. Хан гаскәренең соңгы атлылары капкадан кереп югалды.

Болакның текә ярыннан кысрыклап төбе лайлы салкын суга чумдырылган сугышчылар дөньяда булган, үзләре белгән иң ачы каһәрләү, сүгенү, ләгънәтләү сүзләреннән буылып бер-берсен эзләргә, дусларын, белешләрен, якыннарын барларга керештеләр.

Бөек кенәз галиҗәнаблары карамагындагы сайланма полк бу бәрелештә катнашмады. Иван-сәүдәгәр тәкъдиме, аның кодалавы белән шушы полкка азык-төлек, атларга солыдыр, печәндер юнәтүче итеп тәгаенләнгән Василий боларны читтән, Болакның сул ярындагы ачыклыктан — арбалар өстенә өелгән печәнлектән күзәтеп торды. Беренче тапкыр сугыш дәһшәтен үз күзләре белән күрде, казанлыларның ярсу гайрәтен, атлыларның уктай атылып гаскәр

эченә керүен, аны урталай ярып тураклый, тарката белү сәләтен күрде. «Дөрес сөйлиләр, казанлылар кыю, батыр, сугышка маһир халык икән»,— дип уйлап куярга өлгерде ул.

Шул мизгелдә Санька исенә төште, сафлар арасына текәлеп, күзе авыртканчы энесен эзләде. Сөлектәй чаптар өстендәге һәр пәһлуан аңа Санька булып тоела, аның һәр селтәнүеннән йөрәге кысыла, ачуы, нәфрәте күкрәгенә генә сыешмыйча, авызын ачса, күкләргә ургылыр сыман иде. Ләкин текәлебрәк караган саен күрде: боларның берсе дә Санька түгел! Болар — чын гаскәриләр, ат өстендә коеп куйгандай утыручы оста, маһир сугышчылар! Ул аларның кара мыеклары астында ялтыраган ак тешләрен дә, ачудан зур булып ачылган күзләрен дә абайларга өлгерде кебек.

Шунда тагын әллә нәрсә булды, аксыл чәчле татар сугышчысын күрүгә чак кына «Санька!» дип кычкырып җибәрмәде, кан чыкканчы авырттырып иреннәрен тешләде. Кырыйдан якынлашып килүче сөңгеле урыс атлысын күрмичә, ул каршындагы пәһлуан белән алыша, кылычларыннан очкыннар чәчри, калканнарының бәрелүеннән күкләр дөберди кебек иде.

Үзенең гаскәри түгеллеген, монда бөтенләй башка максат белән килүен онытып, Василий исерткеч ярсуга, сугыш-һәлакәт шаукымына бирелүен сизми дә калды. Аксыл сары чәчле татар аста кала башласа йөрәге кысылды, бөтен буыннарын яндыргыч курку өттереп алды. Аны Саньканың урыс кулыннан үтәчәге рәнҗетә, туганының казанлылар сафында булуы үрти, моны булырга тиеш түгел, гайре табигый эш саный иде. Шул ук вакытта ул Саньканы җәлли, үлемен дә теләми иде. Урысның кылычы күтәрелгән саен ул тешләрен шыкырдатты, үз ирегеннән башка бугазыннан кыргый авазлар чыкты:

— А-а-а-а!..

Менә атлы урыс килгән шәпкә сөңгесен сары чәчленең күкрәгенә батырды, киерелгән гәүдә бер генә мизгелгә өскә омтылгандай тартышып куйды да башы каерылып аска салынып төште. Йөрәге бер учка сыярлык булып кысылган Василий Казан кешесенең кәгазьдәй ак йөзендә сызылган кара мыекны, куе кара кашларны күреп алды.

— Ю-у-ук! Бу Санька түгел, Александр түгел! Тү-үгел! — дип илереп кычкыруын сизми дә калды, тиле кешедәй чүмәлә өстендә сикергәләргә, үзен-үзе йодрыклары белән тукмакларга кереште.

— Ю-у-ук! Санька түгел! Буйга да кечерәк, җилкәләре

дә ул кадәр киң түгел. Санька түгел бит!.. Минем җан кисәгем, нигә үләргә тиеш ди әле ул?!

Кинәт ул тилереп сикергәләгән җиреннән таш кебек катты да калды. Әле күптәнме генә үзе өчен дошман санаган, улына үлем белән янаган, элек газиз туганы булган, хәзер исә татарларга сатылган хыянәтче бер җан өчен инәлүен, йөрәге шуңа бәргәләнүен аңлап-абайлап, куырылып килде, авырткачы киерелеп ачылган авызындагы шатлыклы авазлар ыңгырашуга охшаш өн белән алышынды.

— Мин ниш-ли-им! Дошман өчен инәләмме соң әллә?! Аһ, нинди хурлык — икебез ике якта!..

Башыннан ургылып, котырынып уйлар ташкыны узды.

Энесенә ачуыннан чак кына буылмады Василий. Бер карында яралган, тамырларында бер үк кан агучы туганының казанлыларга тугрылыгын, чыгырыннан чыгып пычакка-пычак килгәндә дә сүзен бирмәвен, салкын канлылык саклап, үз фәлсәфәсен Василийга, аңа үткәрергә тырышуын күтәрә алмады.

Ул аны аңларга тырышып карамады түгел, уйланды, бихисап йокысыз төннәр үткәрде, ләкин барыбер энесен аклар сәбәпләр тапмады. Тапкан хәтлесе исә ышандырырлык, туганыңнан баш тартырга мәҗбүр итәрлек дәрәҗәдә саллы түгел иде.

Бер ятакта тәгәрәп үскән, ерак илләр гизәргә, мал төяп күз күрмәгән, колак ишетмәгән мәмләкәтләргә сәяхәт кылырга хыялланган яшьлек дусты, туганы башка, бөтенләй башка кеше иде инде. Хикмәт аның сакал-мыегын татарча китәреп, Казанча киенүендә генә дә түгел Кыяфәтендәге үзгәрештән бигрәк, Саньканың үзен тотышындагы сәер басынкылык, Василий инанган, табынган нәрсәләрнең аңа чит-ят булуында, иң сәере — аңларга теләмәвендә иде.

Идел буендагы текә ярда тәгәри-тәгәри елап, үксүен чыгармас өчен иреннәрен тешли-тешли үч алырга, энесенең һәлакәте өчен казанлылардан канлы үч кайтарырга ант эчкән тугры җанлы Василий уңҗиде ел аймыл яшәү дәверендә мондый очрашу булыр, булса-калса мондый да дәрәҗәдә салкын булыр дип күз алдына да китермәгән иде.

Инде менә... Күр, сөен, шатлан йә булмаса ачуыңа буыл, үзеңне кыйна!.. Санька бар да кебек, әмма шул ук вакытта инде ул юк та. Әллә булганыннан булмаганы яхшырак идеме соң? Якты, кадерле истәлекләр белән яшәвең мең тапкыр артыграк түгел идеме? Һай, Идел чоңгылларында тончыккан булса, бу кадәр интегелмәс тә иде.

Болакны кичеп Арча кырына таба үтәсе полкларның хурлыклы чигенүе кызу канлы, сүзе аста калганны бер дә күтәрә алмаган Иоанн Васильевичны ярсытыр, күзенә ак-кара күренмәс хәлдә тагын-тагын яңа гаскәрләрне яуга ташлар дип көткәннәр иде. Әмма яшь кенәз бу юлы үзенә хас булмаганча салкын канлылык күрсәтте. Каладан ук һәм ядрә җитмәс ераклыкны чамалап, полклар кирәк-яракларын, җиһазларын урнаштырырга кереште, гаскәрнең бер өлеше атларга төялеп башка яклардан урау юллар эзләргә чыгып китте. Җиңелү ничек кенә ачы булмасын, Казанга килү һәм чыгу юлларының күпчелеге инде урыслар кулына төште. Һәр тарафтан камалышта калган казанлылар хәзер тышкы дөнья белән аралаша алмый, алар бары тик җыйган маялары, туплаган азык-төлекләре һәм кирәк-яраклары белән генә канәгатьләнергә мәҗбүр булачак. Камауның озакка сузыласы, яшь кенәзнең барысын да алдан уйлап, ныклы әзерлек белән килгәнлеге сугыш һөнәреннән хәбәре-мәгълүматы булмаганнарга да ачык аңлашылырлык иде инде.

Сугышчылар киндер чатырлар корырга кереште, Мәскәү хөкемдарының үз чатыры исә гаскәрнекеннән бер ук очышы ераклыкта, кечкенә генә калкулыкта урнаштырылды. Аның тирәсенә сайланма полктан — кенәз, воевода балаларыннан оешкан төркемнән сак куелды. Алар үзләре танымаган беркемне дә чатыр янына якын җибәрергә тиеш түгел иде.

Казанга каршы олы яу белән кузгалыр алдыннан митрополит Макарийның изге фатихасын алган һәм Мәскәү чиркәүләрендә ике көн, ике төн дога кылудан башлаган яшь кенәз монда да алла сүзен алга куйды, гаскәр урнашкан болыннарда киндердән чиркәү чатырлары корылды, түбәләренә изге сулар сибеп, тәреләр беркетелде.

Арыган гаскәр, ашчылар, олаучылар, гаскәрне азык-төлек белән тәэмин итәргә ялланган сәүдәгәрләр арыпталып, соң гына йокыга талдылар. Аларны иң сөендергәне шул булды: күз алдында иге-чиге күренмәгән чирүнең тыныч кына чатыр корып ятуына казанлыларның әллә ни исе китмәде кебек. Алар үз көчләренә, кальганың алып булгысызлыгына артык нык ышаналар идеме, әллә бер-бер яктан ярдәм, өстәмә көчләр килүен көтәләр идеме — моны беркем дә фараз итеп тормады. Арулары чиктән ашкан, иң беренче теләк — тизрәк башны мендәргә терәү иде.

Җеп өзәрлек тә хәле калмаган Василий бик озак йокыга китә алмады. Гаскәриләр корган чатырда урын табылса

да, ул Казан суы өстен Идел тамагынача тутырган көймәләрдә урнашуны артыграк күрде. Анын, бердән, сугышчылар белән бергә ятып, төнен, казанлылар яу чапса, тормышын куркыныч астына куясы килми, икенчедән, төятеп килгән малга да күз-колак булырга кирәк. Сакка куелган гаскәргә ул тамчы да ышанмый, әгәр җае килсә, аларның бер төн эчендә ярты көймәне беренче очраган нәфесле шайтанга аткарачакларына иманы камил иде. Шуның өстенә, көймә төбендәге имән мичкәләрдә чымырдаган ачы бал, күз яшедәй саф аракы бик күпләрнең күңелен инде күптән кытыклый, ымсындыра. Монысын да истән чыгарырга ярамый. Дөрес, исерткечне гаскәр башлыгы рөхсәте белән генә саттыралар, әмма елгыр, үткенрәк саргәскәрләр үзләре дә, гади сугышчылар да мичкә тирәсенә сугылып узуны гаепкә санамый. Бер чәркә кемгә зыян китергән. Эчеңне тишмәс әле. Авызыннан аракы исе бөркелгән ул адәмнәргә башлыклар күз йома. Мөселманнардан яулап алыначак кала, андагы иксез-чиксез байлыкның озакламый кулга төшәчәгенә өметләнү — барысына да берникадәр дәрәҗәдә масаю, кәләйлек өстәгән, күбесе ни кыланганын белми иде. Чиркәү чатырларында урысларның өстенлеге, татарның басурманлыгы, түбәнлеге хакында поплар, руханилар җибәргән агулы сөрем һәммәсенең акылын томалаган, барысы да Казанның ансат кына җиңелүен, камалышка түзә алмыйча тезләнүен, ефәк мендәргә салып шәһәр капкасы ачкычын чыгарып бирерләр дип көтә иде.

«Татарлар аракы эчми. Диннәре кушмый, - дип уйлап алды Василий һәм көлемсерәп куйды. - Казанны алгач, бу мичкәләрнең һәрберсе алтын бәрабәренә китәчәк әле. Иван белеп әйтә. Шанлы урыс гаскәре шатлыгын аракыга батырып юачак»...

Никадәр генә уңайлырак урын сайламасын, ятагының җаен таба алмады. Йә аркасын нидер кырды, йә аягы нindидер очлы әйбергә барып бәрелде... Чикмәнен башыннан ук бөркәнсә, тынына буылды, ачса колак төбендә без--ләгән, канга сусаган черки өере битенә, тәненең ачык өлешләренә ябырылды.

Урыс гаскәренең казанлыларга шул черки өере шикеллерәк котылгысыз җәфа икәнен күз алдына китереп янә елмайды һәм теш арасыннан сүгенеп, бөгәрләнеп ятагына сеңде. Саташулы, бимазалы төн йокысы барыбер үзенекен итте: бераздан күзләре йомылды, Идел ягыннан искән салкынча җилдән бөрешеп көймә төбенә сеңгән гәүдә өстендә

черки болыты котырды. Очлы безләрен корбанның итләч муенына батырып, алар туй итәргә кереште. Әмма ике-өч көн рәттән юньләп йокы күрмәгән Василий инде моны сизми, ул, әйтерсең лә караңгы, төпсез упкынга чумды, якты дөнья белән бәйләп торучы бөтен нәрсә шартлап өзелдемени, гырлап йоклап та китте.

Менә Казанны алганнар, имеш... Биек таш манаралардагы туплар гөрселдәп бәйрәм уты ата, урамнар урыс гаскәре белән тулы. Шәһәрдә бер генә татар заты калмаган — челтәр тәрәзәле, олы, якты ташпулатлар, бодай белән, арыш белән тулы амбарлар, мал тулы лапаслар, кызыл мал, асылташ, алтын-көмеш чыңлаган бай кибетләр — барысы да урыс кулында. Гаскәр бәйрәм итә. Көймәләргә бәйләп кол тутырганнар: кәнизәк кызлар, һөнәрчән куллы хатыннар, яшүсмерләр, балалар... алардан читтәрәк аяк-куллары богаулы осталар, һөнәрчеләр... Аһ, ни шатлык! Дөнья базары шау итәчәк, Мәскәү сәүдәгәрләре кесәсенә, урыс кенәзлеге хәзинәсенә әле тагын күпме алтын агылачак!..

Василий да үзенекен ычкындырмаган, имеш. Менә ул кальганың дошманнан тазартылып бетүен вәкарь белән генә көтеп алды, басмалардан яр өстенә аракы мичкәләрен тәгәрәтергә боерды. Бер тустаган эчемлеккә сусаган сугышчылар, хезмәтчеләр аның авызына гына карап торалар, имеш. Алар бер-берсенә утызар чиләк сыешлы авыр мичкәләрне ыһ иткәнче чыгарып та куйдылар. Китте сәүдә, китте алыш, китте биреш, китте бәйрәм... Бер чәркәсе бер алтын! Казан малын имеп баеган, көчле дошман белән алышып арыган гаскәр акчасын җәлләми. Әйдә, эч, бәйрәм ит, бие, җырла, уйна! Мәскәүгә кояшны каплап торгандай көнчыгыштагы сәүдә юлларына хуҗа булган Казан — безнеке! Үзебезнеке! Урысныкы!..

Җиңү шаукымыннан исергән Василий үзе дә чүмечләп аракы чөмерә, әмма күпме эчмәсен, башына китми, имеш. Авызын киң ачып кычкыра: «Кутәр мичкәсе белән! Агыз чишмә иттереп! Йөзсен халык колач салып»...

Шул чакта әллә нәрсә булды, үзле балчыкка түгелгән аракыдан аягы таеп китте дә басма буйлап аска, көймә төбенә тәгәрәде. Басмага беркетелгән тупсалар кабыргасын санап чыкты, лып итеп такта идәнгә килеп төште, сыны катты. Аягына басарга өлгермәде, өстенә бөкесе дә ачылмаган юан мичкә тәгәрәде, аны тибеп җибәрсә, икенчесе төште. Әйтерсең лә җан ияләре, мичкәләр төрле яктан аны кысрыклый, һөҗүмгә күчкән татар атлы гаскәре җитезлеге

белән әле бер, әле икенче ягына төшәләр, авырттырып бәрәләр иде.

Авыртуга, кысрыклауга чыдый алмый, Василий бар көченә кычкырып җибәрде, бугазыннан ургылган куркулы ачы авазларга мичкәләр дөбердәве кушылды. Мөмкин булса, ул ике колагын кысып теләсә кая — урманга, болынга, тау араларына качып китәргә әзер иде инде. Бары тик тавыш кына булмасын! Әмма кыймылдый алмас хәлгә җиткән, мичкәләр аны ике яктан кысып, менә-менә уклау астындагы камырга әйләндерәчәкләр иде.

— Бу ни бу? Нәрсә булды?!

Аның кешедән бигрәк үзенә атап әйтелгән соравына, җан ачысы белән бәргәләнеп кычкыруына җавап бирүче булмады. Көймәдә мәхшәр... Бәйләреннән ычкынган мичкәләр тәгәри, җилкән колгалары җилдә уйнаклаган камыш сыман бөгелеп сызгыра, әллә ничә йөз батман сыйдырышлы көймә үзе упкынга эләккән йомычкадай уйный, янтайган саен кырыеннан ургылып болганчык су ташкыны керә иде. Күрәсең, тимер чапага — ыргакка тарттырылган арканнар өзелгән, эреле-ваклы көймәләр бер-берсенә бәреләләр, корбанына ташланган бүредәй һич көтмәгән яктан өскә сикерәләр, юлда очраган бар нәрсәне җимереп, ватып, изеп, сытып баралар иде.

Казан ягыннан котырып җил исә, ул авыз ачарга да бирми, тынга каплана. Күк йөзен кара тузан болыты каплаган. Иртәнге кояш аның аша тутыккан кызгылт бакыр таба шикелле таплы-таплы булып күренә, җир йөзе кичке эңгердәгедәй караңгылыкка чумган, офыктан-офыкка җен туе — канлы өермәләр йөгерә. Алар инде ярым баткан көймәләрне өерләп Иделгә, тау-тау актарылган дәһшәтле дулкыннар кочагына куалар иде.

Василийның йокысын кул белән йолкып аттылармыни... Мие котырып эшли башлады: «Бу афәттән, гарасаттан, бу мәхшәрдән ничек котылырга?! Ләкин өстенә ишелгән мичкәләрне аралый-аралый күпме баш ватмасын, котылыр чара юк иде. Алда да, артта да, уңда да, сулда да мәкерле Казан суы, шашкын дулкыннар, болганчык чоңгыллар. Үзе шикелле бәргәләнүче көймәчеләр, сәүдәгәрләр ярдәмгә килә алмый — аларның кайберләре инде сытылып мичкә астында калган, кайберәүләр кычкырып болганчык суга ташлана, әмма чыкканнары күренми. Хәер, аларны карарга ара юк, чак кына авызыңны ачтыңмы, шашынып чайкалучы көймәдәге мичкәләрнең берсе өстеңә төшәчәк, сытып ташлаячак.

Шулчак дулкыннар өстендә чайкалып, иелгән саен су чумырып баручы көймә туктап калды, бер якка янтаеп авышты, аның өстеннән калын су ташкыны шаулап узды. Аракы мичкәләре камыш бөкеләрдәй су өстенә күтәрелде, аларның берсен иярләп өлгергән Василий да дулкын иркенә буйсынып агып китте.

Җыясы ризыгы бетмәгән икән әле, кучкыл төскә кергән таудай дулкын аны иң өстенә күтәреп селтәде дә Казан-су тамагының комлы-ташлы ярына китереп бәрде. Аяк астында каты җир тойган сәүдәгәр авызына тулган ләмле балчыктан, судан тончыга-тончыга алга үрмәләде, тешләре, тырнаклары белән үлән тамырларына, талларга ябышты. Икенче, тагын да көчлерәк, тагын да дәһшәтлерәк дулкын куып җитте һәм аның акрын кыймылдавына үртәлгәндәй, җилкәсенә күтәреп яр кырыена ук чыгарып ташлады. Артык хәле калмаган Василий тагын берничә адым шуышты да ниндидер калкулыкка менүен абайлап, җиргә сузылды. Күз алдында утлы боҗралар биеште, тәне, аяк-куллары үтереп сызлый иде. Котырып аккан су буенда бер йотым су эчәргә тилмереп, кипшергән телен авыз куышлыгында йөрткәләде. Әмма кушучлап шул суны эчәргә, тагын яр буена үрмәләргә аның көче дә, теләге дә калмаган иде инде. Башында бер уй бәргәләнде: «Су куркыныч, судан читкәрәк!» Берничә мизгелдән ул үлектәй сузылып ятты, онытылды.

Һушын җуеп саташулы халәттә күпме яткандыр, белми, колак төбендә яңгыраган ачулы тавыштан айнып, уянып китте.

— Артына тибеп кара, бәлки исәндер...

Күзен ачса, янында Иван-сәүдәгәр белән бер төркем кораллы укчылар басып тора.

— Аллага шөкер! Исән икәнсең әле,— диде Иван,— тора аласыңмы?..

Аңа җавап бирмичә генә Василий уфтанып ыңгыраша-ыңгыраша аягына басты, җанын, миен бораулап торган сорауны бирде:

— Ни булды? Көймәләр... ничек?

— Бат-ты-лар,— теш арасыннан бүлеп-бүлеп чыгарды Иван.— Татарның сихерчеләре явыз, кабахәт җаннар... Сихерләп җил-давыл чакырдылар. Күрдеңме, өермәләр алар ягыннан килде...

— Барысы да баттымы? — дип илереп җибәрде Василий.— Минекеләр дәме?..

— Улама! — Иванның тавышына ачу, кыяфәтенә усал-

лык чыкты.— Бер син генә зыян күрмәгән. Җитәр! Тор да, әнә, ярдәм ит! Калган, таралган малны җыярга кирәк...

Василий шунда гына атлы олауларны, ярны буеннан-буена иңләп килүче кораллы кешеләрне абайлап алды. Алар дулкын чыгарып ташлаган мичкәләрне, капчыкларны, көймә калдыкларын, мәетләрне җыеп, арбаларга төйиләр иде. Әле кичә генә шау яфракта утырган урманлы-куаклы җир ачык яланлыкка әйләнгән, төбе-тамыры белән кубарылган агачлар, шәрәләнгән куаклар — барысы да коточкыч зилзилә үтүе турында сөйли иде. Бөтен кыр капланып ташланган йөкләр белән тулган. Арбаларда тау-тау өелеп торган печән кибәннәренең эзе дә калмаган, бөртегенә хәтле өермәгә уралып Идел аръягына очкан иде.

«Күрәсең, камау барып чыкмас! Иписез, печәнсез, ачялангач калган гаскәр белән әллә ни кыра алмассың,— дип уйлап куйды Василий. Йөрәген үкенеч, бар малыннан колак кагу ачысы кисеп үтте.— Аһ, ни аяныч! Казан патшалыгының әкияти хәзинәләре кул сузымында гына юкса! Бер йодрык белән бәрергә иде дә, диварларын изеп, манараларын аударып, төнге ташкындай ыргылып керергә иде. Югалту ачысы да бу кадәр газаплы булмас иде!..»

Аның уйларын сизгәндәй, Иван сәүдәгәр тавыш бирде:

— Йә, таш сындай катып торма! Хәзер икенең бере — йә Казанны тончыктырып малны кайтарабыз, йә булганны җыеп эшкә җигәбез. Кыймылда!

Тәнендәге авырту, сызлануны җиңеп, Василий аларга иярде. Укчылар акрын гына үзара сүз алыштылар:

— Казанны алла кодрәте яклый инде әллә?

— Яклый пычагым, ишеттең бит инде, сихерчеләре, кабих җаннар, җил-давыл чакыра беләләр...

— Ни булса да, ризыксыз монда озак тора алмабыз. Суган суы суырып кына сугыша алмассың...

— Анысы шулай, күрәсең, иртәгәдән дә калмый кирәдән өйгә, Мәскәү якларына кыякларбыз. Хурлыгы ни тора!...

— Җитте сезгә, юкка лыгырдамагыз! Әмер бирсәләр, ач көе дә сугышырсыз,— дип кемдер ачулы кычкырып куйды.— Иң яхшысы, таралган-чәчелгән малны күбрәк җыегыз. Һич югы, бүген тамагыгыз тук булыр. Барысы да бөек кенәз Иоанн Васильевич галиҗәнаблары иркендә...

Һәм, чыннан да, барысы да Иоанн кулында иде, күрәсең. Азмы-күпме әйбер-кара җыелып, югалтуларны барлау-

га, азык-төлек юнәтүчеләргә гаскәр башлыгының фәрманын җиткерделәр:

— Кичекмәстән иң чыдам, түзем, җитез атлар белән Мәскәүгә, Зөягә чабарга, бөтен шәһәрләрдән икмәк, җылы кием-салым төяп яңадан Казан тарафына сәфәр чыгарга!

Фәрман нигезендә һәр бояр кимендә бер полклык мал бирергә мәҗбүр ителә, патша казнасыннан кирәгенчә алтын-көмеш алырга рөхсәт ителә иде.

Василий моңа бик сөенгән иде. Иртәнге гарасаттан ул, дөресен әйтергә кирәк, шактый шүрләде, Казанны, чыннан да, сихерчеләр яклый, аны гади корал белән генә алып булмыйдыр, дип уена беркетеп куйды. Әмма моны кемгә дә әйтергә базмады, эченә бикләнде. «Менә, ниһаять, котылу юлы күренде. Мәскәүдән урап килгәнче ни генә булмас та, тагын нинди генә җил-давыл чыкмас. Һәрхәлдә, сугыш кырыннан читтәрәк булуың хәерле. Шуның өстенә, дәүләт казнасыннан агыласы алтын-көмеш тә бармакка йокмый калмас. Иван белеп сөйли»...

Ләкин иртәрәк шатланган булып чыкты. Уйларының очына да чыга алмады, Иван касыгына төртте, күз кысып, башкалардан читкәрәк, кырдан җыелган мал өемнәренә таба кире китәргә ымлады.

Тирә-ягына каранып, ашыгып пышылдарга кереште:

— Мин Мәскәүгә китүчеләргә башлык итеп тәгаенләндем...

Василийның авызы колагына җитә язды. Хуплап баш селкеде. Әмма Иван аны күрмәгән дә сыман үзенекен дәвам итте:

— Син... монда каласың. Аң бул, йоклап йөрмә! Менә бу исәбе алынмаган туздырылган байлык хәзер синең кулда,— диде ул мичкәләр, капчыклар, чыпталар өеменә күрсәтеп.— Дөнья хәлен белеп булмый, алай-болай без килгәнче Казан кулга төшсә, форсатны ычкындырмассың... Ә Мәскәү малыннан тамганы — минем кулда. Борыныңа киртлә: бары — бергә, югы — уртак.

Василий кара коелды.

— Нишләп мин? Беткәнме берәр...

Иван аңа әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде, йодрыгын ияк астына терәде.

— Шым бул! Оныттыңмы? Күпме бурычың бары исеңнән чыктымы? Энеңнең казанлыларга сатылган хәсис икәнен белсәләр, Иоанн Васильевич беренче очраган ботакка астыра бит сине. Әйдә, сайла! Кайсысы күңелеңә якынрак?...

Василий телен тешләде. Күпме генә бәргәләнмәсен, пәрәвезгә эләккән чебендәй чапаланмасын, ул үзенең Иван сәүдәгәр ихтыярыннан чыга алмаячагын тагын бер кат аңлады. Күрәсең, чабатага тагылган киндерә шикелле мәңге аның артыннан сөйрәлергә туры килердер, ахрысы. Санька гаепле... Аның качып китүе, юк, качу түгел, пычрак хыянәте этисен шушы адәмгә гомерлек бурычлы итте, ул гүргә кергәч, бурыч Васяга күчте. Ләкин иң гаҗәбе шунда, еллар үткән саен ул кимеми генә түгел, артканнан-арта бара иде. Әҗәтле буласы килми. Ялыктыргыч, алҗыткыч бәйлелектән котылу, Казан малына кинәнеп Иванның бугазына тыгу теләге китерде дә бит Васяны Казан сугышына! Юкса, болай йөрер идеме?!.

Иван, кирәген аңлатып бетергәч, яңадан күз кысып елмайды:

— Борыныңны төшермә! Беләсең килсә, Казанда нибары утыз мең гаскәр бар, диләр. Безнең көчкә каршы торырлыкмы? Атна-ун көннән ялынып үзләре чыгачак... Төшендеңме?..

Сөйләшү шуның белән тәмамланды.

Атна үтте, ун көн дә узып китте. Ә казанлылар бирелергә уйламый да. Урыс явы һай-һулап, әләмнәрен болгап, туп атып һөҗүмгә чыгуга кальга капкалары ачыла, ярсу атлылар ташкыны юлында очраган бар нәрсәне изеп, сытып, турап уза да яңадан калага кереп бикләнә. Аларның җитезлеге, елгырлыгы шәһәрдә беркемнең дә ачка интекмәвен күрсәтеп тора. Шуның өстенә, туплары тынгы бирми, бер-бер полк якынлашса, ядрә яудырырга тотыналар, мылтык аталар, яңгыр булып уклар коела.

Урыс гаскәрендә һәр кисәк икмәк санаулы. Мәскәүдән көймәләр, олаулар килеп җиткәнче бар нәрсә үлчәүдә. Зөядәге икмәк ачка үтермәслек кенә. Якын-тирә татар авылларында ашлык юк. Аны йә күмгәннәр, йә яндырганнар, суга агызганнар, юк иткәннәр. Явыз дошман кулына эләкмәс өчен барысы да качып беткән. Авыллар буш, авыллар үле. Ирләре яуда, хатын-кыз, бала-чага йә урманда, йә тагын да ераграк якларга күчеп киткән.

Василийның Санькага ачуы кабарганнан-кабара, кайчагында буылыр хәлгә җитеп аны сүгә башлый, каргый, ләгънәтли. Зиннәтле йортында балда-майда йөзеп яшәүче энесе, казанлыларның үҗәтлеге җенен котырта.

Мең чакрым юл үтеп кил дә ачка койрык чәнчеп ят менә! Ә ул, хыянәтче, сатлык, хаин, басурман татарлар белән әҗе-гөҗе килеп, сыгылып торган табын янында урысларны

каргыйдыр әле. Ничек каргамасын?! Чын татар булып беткән бит!

Дөрес, ризыкка, икмәккә хуҗа буларак, Василий тилмереп ятмый. Тамак тук, өс бөтен дигәндәй. Әмма казнаның ярлылыгы, бар нәрсәне гаскәриләр тикшереп, үлчәп тору, барысына килеп тыкшынулары саруын кайната. Үз малыңа үзең хуҗа булмагач!.. Кая монда Иван әйткән керем? Кая табыш? Кая Казан байлыгы, алтын-көмеш, хәзинә?!.

Юкса, үз өендә, якыннары арасында, бай табын янында гына утырасы кеше дә бит.

Табын сүзе исенә төшүгә энесе йортындагы мул сыйлы өстәл күз алдына килде. Гөлйөземнең ниндидер таныш түгел ризыклар, тәгамнәр белән сыйлавын хәтерләп, төкерәген йотып куйды. Һай, бар иде ул андый чаклар, кайсын кабарга микән дип сайланып утырган көннәр.

...Сәер, бик сәер барып эләккән иде ул Саньканың гаиләсенә...

Кәрван-сарайдагы саташулы төшкә охшаган очрашудан соң аны гомеремдә күрмәм, рәнҗеттем, үпкәләттем, кайда яшәвен дә белми калдым, дип уфтанган иде.

Иртән аны Иван-сәүдәгәр уятты. Махмыры чыга башлаган Василий икенче якка борылып ятмакчы иде, дусты өстенә бер чиләк салкын су китереп койды.

— Нәрсә, шаштыңмы әллә? Нишлисең?.. — дип тешләрен шыкырдатты Василий. Ә Иван көлде генә.

— Тор, тор! Кая барырга кирәклеген әйтсәм, рәхмәт укырсың әле,— диде ул һаман аны йолыккалап.

Василий күкрәгендәге йонны ышкый-ышкый торып утырды, күзләрен уалап сорады.

— Беркая да бармыйм. Кая, тап булмаса берәр чәркә...

— Өмет тә итмә! Чәркә булмый. Соңыннан...

Иванның сүзеннән кайта торган кеше түгеллеген белгәнгә, буйсынып сорарга мәҗбүр булды:

— Кая барыйм соң?

— Бар, юын, чистарын,— диде Иван аның сүзләрен ишетмәгәндәй.— Санька янына барырсың. Өен, балаларын күрерсең... Сез туганнар бит. Аралашып яшәргә кирәк!..

Василийның йокысын, махмырын кул белән юып алгандай булды. Шикләнеп кенә сорады:

— Кая... ничек? Йортын белмибез, үзе чакырмады...

Иван хәйләкәр елмайды да, гадәтенчә, күз кысты.

— Анысы синең эш түгел. Әзерләнүеңне бел!

Саньканың йортына Иван озатып куйды. Ике катлы

ташпулат иде ул. Төсле пыялалары белән балкыган тәрәзәләре, ак, яшел һәм зәңгәр төсләрне аралаштырып буялган түбә кыеклары, аның астында ярымайга охшатып эшләнгән тәрәзәчек, өй алдындагы җимеш бакчасы — барысы да энесенең җитенкелекле мул тормышта яшәвен сөйли иде.

Иван үзе кермәде, әмма Василийны өйрәтеп, ни-нәрсә сөйләшергә кирәклеген аңлатып кертте.

— Кичәгедәй дуамалланма,— диде ул кинәт мыскыллы тавыш белән.— Син тузынсаң, ул да шулай җавап бирергә күп сорамас. Безгә аның ышануы, ярдәме кирәк. Алдан сөйләшкәнне онытма. Ничек тә ризалаштыр, алтын-көмеш вәгъдә ит, Мәскәүдә мул сәүдәгә юл ачылыр, дип котырт. Сәүдәгәр кеше кызыксынмый калмас.

Кинәт аның тавышына янау, усаллык галәмәте чыкты, сүзләрен теш арасыннан чыгарып, колагына иелеп пышылдады:

— Мин үзем генә түгел, без күбәү диген. Әгәр риза булмасаң, нәселең урамга чыгарга куркып яшәр, диген. Өркет! Малаен күрдек, беләбез. Кайда да булса пычакка килеп кадалмас дип кем әйтә ала.

Василийның аркасыннан салкын су койдылармыни, бөтен тәне чирканыч тартышып куйды, әмма каршы әйтергә, Иванны туктатырга аның көче юк, ул тулысынча аның ихтыярында иде.

— Йә, бар! Миннән сәлам әйт,— диде Иван аның аркасыннан этәреп.— Туганнарча кочаклашып үбешергә дә онытмагыз.

Аның тавышына тагын мыскыл төсмере чыкты.

Үзен мәче тырнагына эләккән, аның канлы уенчыгына әйләнгән тычкан хәлендә сизгән Василийның әле махмыры чыгып җитмәгән, Иванның астыртын мәкере дә миенә барып ирешмәгән иде. Ул кыюланып, күптән көтелгән кунактай, дәрт белән ишек шакыды.

Аны Сәет ачты. Йөзенә башта кара күләгә йөгерде, ләкин бу хәле озакка бармады, ачылып елмайды.

— Син... Вася... Ничек табасы иттең?.. Кичә... аңлашып та бетермәгән идек,— дип сөйләнергә кереште.— Әйдә, үт, рәхим ит!..

Болары өтек-төтек кенә истә калган. Василийның күз алдында табын күренеше кат-кат яңара, ул андагы ризыкларның ят яңгырашлы исемнәрен исенә төшерергә азаплана иде.

— Монысы пылау,— дип елмайган иде Гөлйөзем, нин-

дидер саргылт төстәге җимешле, итле, дөгеле, таралып торган хуш исле ризыкка күрсәтеп.— Белмим, ошармы...

Ул чакта пылаудан бигрәк Гөлйөземгә таң калган иде Василий. Озын, куе керфекле серле кара күзләр, биленнән узган калын кара толым, чиста, ап-ак йөз... сыгылмалы зифа буй-сын... Ике бала табып үстерсә дә, инде утызның бу ягына чыкса да, энесенең хатыны яшь кызлар шикелле чибәр иде әле. Бер карауга ук аннан ниндидер җылы нур бөркелгәндәй була, шул талгын дулкын күңелне иркәли, тынычландыра сыман иде. Әйе, килен тиешле кеше матур, сөйкемле генә түгел, бик ягымлы, мәхәббәтле дә иде. Василий аңа карап телсез калуын, онытылып соклануын сизми дә калды.

— Йә, ризыктан авыз итик,— дип, аны сәер халәтеннән Санька чыгарды.— Ничә еллар күрешмәгән туганнарның очрашуы бәйрәм түгелмени?!...

Василий исә күзен Гөлйөземнән ала алмый, энесенең шушы чибәр аркасында Казанда калуын, эти-әнисе, туганнарыннан ваз кичүен уйлый, олуг хыянәтенең сәбәпләрен аңларга тырыша. «Санька урынында булсам, мин нишләр идем икән?!»

Нечкә борынлы, өсте нәни мендәрчек белән капланган керәч савыт тотып кергән Гөлйөземнең бер елмаюы барысын да хәл итте: күңелендә көнләшүгә охшаш хис кыбырсый башлады. «Әллә мин Санькадан кимме?! Әллә мин бу чибәрне карата алмаган булыр идемме?.. Кирәксә, Казанда да кала алыр идем...» Уйларыннан үзенә үк кызык тоелып китте, ирен чите белән елмаеп куйды һәм кирәксез фикерләрне башыннан чыгарып ташларга теләгәндәй, сиздерми генә кул селтәп, Гөлйөземнең тылсымга охшаш салмак хәрәкәтләрен күзәтергә кереште.

Гөлйөзем исә чынаяк савытларны бер куйды, бер алды, күктән төшкәндәй назлы тавыш белән сөйләнде дә сөйләнде:

— Чәй эчкәндә күктәге илаһи затлар белән сөйләшкәндәгедәй рухи тынычлык кирәк. Бөтенебез бер булып, табигатькә кушылып, искән җилнең иркәләвен, аккан суның талгын пышылдавын, яфракларның шыбырдавын аңлар дәрәҗәдә үз-үзеңә йотылу сорала. Янында утырган якыннарыңның җанын үзең белән бер итеп тоярлык рухи тынычлык, җан сабырлыгы булганда гына эчемлекнең тәмен, канга сафлык бирүче ләззәтен тоярсың...

Василий боларны аңлый да, аңламый да кебек. Гади бер эчемлек эчкәндә шушындый бөек мәгънәле сүзләрнең таби-

гый яңгыравы, Гөлйөзем йөзендәге тантаналы сабырлык аны сәерсендерә, әмма шул ук вакытта тылсымга бирелгәндәй аңа буйсынырга да мәҗбүр итә иде.

Гөлйөзем чынаякларны нечкә борынлы савыттан кайнар сыекча белән чайкап алды, аны өскә күтәрә төшеп яңадан тутырды да иң элек Санька алдына, аннан Василий алдына китереп куйды.

— Ягез, инде авыз итик, кадерлеләрем. Күңелегезгә хушлык иңсен, җаныгызга мәрхәмәт, каныгызга мәхәббәт керсен!

Санька үзенә сузылган савытны ике куллап алды да учларын җылыткандай бераз тотып торды, шуннан соң гына иреннәре янына китерде.

Беренче йотымны ясаганнан соң Василийга борылып пышылдады:

— Чәйнең беренче йотымы — беренче мәхәббәт кебек саф, беренче үбү кебек үк нәфессез булыр... Чәйнең җитмеш чиргә дәвасы бардыр...

Тантаналы, артык озакка сузылган йоланың мәгънәсен аңлап бетермәгән Василий аның үзе шикелле үк пышылдап сорады:

— Нинди эчемлек соң бу? Шулкадәр затлы нәрсәмени?!

Санька үзалдына елмаеп куйды. Ул ике арада урнашкан татулыктан рәхәт чигеп, изрәп мендәргә таянды, хатынына баш селкеп эндәште:

— Гөлйөзем, сиңа әйтәм, пешермәгәнен дә алып кер әле. Күрсәтик. Бәлки, ошап та китәр... Урыс халкы бал эчә, квас, хәмер эчә. Чәйне белми...

Василий аның бу сүзләренә кичәгечә үртәлеп куйды: «Үзе урыс түгелме әллә?!» Әмма үзен бик тиз кулга алды, ризалашып баш иде.

— Һәр халыкның үз эчемлеге... Әйе!..

Гөлйөзем ак керәч савытта ниндидер кара-көрән төстәге кипкән яфрак алып керде, аны нечкә ак бармаклары белән уып алды да өстәлгә таратып салды.

— Бик затлы эчемлек. Сихәтле әйбер,— дип сөйләп китте Санька.— Чин якларыннан кайтартабыз. Бәһасы алтын белән үлчәнә. Сирәк нәрсә... Хәер, нигә әле кунакны һаман сүз белән сыйлыйбыз? Әйдә, эчик, авыз итик... Үзең бәяләрсең...

Аны Гөлйөзем бүлдерде:

— Йә инде, Сәет, артык мактанып ташладың түгелме?!

Иренә яратып, балага карагандай наз белән күз тө-

шерде, озын керфекләре дерелдәп куйды, йөзенә алсулык йөгерде.

Боларны да Василий күреп, тоеп утырды, алар арасындагы татулыктан көнләшеп, кызыгып калганын да сизде. Ә Гөлйөзем иренең агасына ярарга тырыша иде кебек, табындагы иң тәмле ризыкны аңа таба этеп куя, зур кара күзләренең ачык карашы Василийның бәгыренә үтеп керә, үрсәләндерә, уттан алып суга, судан алып утка салгандай эчтән куырылырга, үзе өчен тыюлы, энесенең хәләл җефетенә әйләнгән шушы затның ягымлы карашын күрергә, ягымлы тавышын ишетергә теләп тагын-тагын аңа борылырга мәҗбүр итә иде. Икенче бер нәрсә дә гаҗәпләндерә: кичә ире белән нәрсә булганны беләме бу, белмиме? Белсә, ничек шулай якты йөз күрсәтә ала? Фәрештә кыяфәтле татар хатынының эчендә бер-бер мәкер, хәйлә ятмыймы? Әмма Василий берничек тә соравын кычкырып әйтә алмый иде, әлбәттә.

— Мин Сәеткә күптәннән әйтеп килә идем инде,— дип куйды Гөлйөзем аның уйларын сизгәндәй.— Дөньялар имин, ил-көн тыныч чагында Угличка кайтып килик, танышыйк, дип. Кайчан да булса бер аңлашырга тиеш идек ич инде...

— Гөлйөз-е-е-ем,— дип сузды Санька.— Онытылган нәрсәләрне искә төшереп, җанны кыйнамыйк. Беләсең ич, мин кайта алмый идем... Мин алар өчен үлгән идем инде... Ә теге дөньядан кире кайтмыйлар. Юлы юк.

Сүзне дәвам иттерә алмадылар, бүлмәгә озын буйлы яшь егет килеп керде. Василий, авызына кабарга күтәргән ризыгын ярты юлда туктатып, егеткә карап катты да калды. Аның каршында Санька, моннан унҗиде ел элек югалган Санька басып тора иде. Шул ук буй-сын, бәдәненең төзлеген тагын да зифарак итеп күрсәтүче киң җилкәләр, мәрмәрдән уелгандай нык муен, ак йөз, ап-ак тешләр, куе кашлар. Хәтта аяк атлауларына кадәр таныш, Саньканыкыча иде. Ләкин бер үк вакытта Санька да, Санька түгел дә кебек үзе. Үсмердә нindидер икенче бер затлылык, ул чакта Санькага хас булмаган башкача бер матурлык та бар иде, ахрысы. Ныклабрак карагач, тагын-тагын күздән кичергәч кенә Василий аңлап алды, гаҗәпләнүеннән, гадәттәгечә чак кына маңгаена сугып куймады. Егеттә Санькага хас ирлек чалымнары Гөлйөземнең үтә нечкә, затлы, хатын-кызларча нәфислеге белән үрелгән. Ишек катында ир белән хатынның иң яхшы төсмерләрен берләштергән, аларның яхшыртылган нөсхәсе басып тора иде. Тагын шу-

нысын да абайлап алды: күзләре җете зәңгәр түгел, ә Гөлйөземнеке шикелле сер яшергән зур, кара күзләр иде.

«Шушы баланың җанын кыяргамы?! Мин шушы балага кул күтәрергә тиешме?» Иван әйткәннәр исенә төшеп, Василий тетрәнеп куйды. Үзе өчен ике газиз җан — Санька белән Гөлйөземнең бәгырьләреннән өзелеп төшкән бу зат та аңа хәзер якын, бик якын, кадерле тоела башлаган иде.

«Чәйләре тәмле иде. Баштарак авызны бөрештергән кебек тоелса да, соңыннан тәнгә рәхәтлек бирә, җиңеллек китерә икән... Гаҗәп эчемлек»,— дип уйлап куйды Василий. Аның фикере, уйлары бер эзгә төшә алмый, үткәннәр арасында бутала, күңелендә кайнаган ачуның зәһәре башка истәлек-хатирәләрне юып алып китә иде.

Чыннан да, гаҗәп бит. Чәй эчкәч, ишегалдына чыктылар. Шул чакта Василий гәүдәсендә рәхәт җиңеллек тойды, башы ачылып китте, әйтерсең, сиздерми, күзгә күренми генә басып, изеп торган билгесез чир-сырхаудан котылды.

Бакчада алмагачлар, кура җиләге, шомырт, карлыган куаклары. Уртадагы ачыклыкта ак мәрмәрдән шактый гына олы хавыз* ясалган. Аның бер як кырыендагы таш улактан челтерәп су агып тора, хавызда исә төрле суүсемнәр чайкала, төбендәге төрле төстәге чуерташлар, вак дулкыннар аркылы, биеп торучы ниндидер җан иясләрен хәтерләтәләр. Шушы тын почмакка килеп утыргач, Василий әкрен генә Иван-сәүдәгәр әйткәннәрне сүтәргә керешә, сакланып кына сорау бирде:

— Кичә сөйләшкәннәрне хәтерлисеңме?

Сәетнең битенә куе кызыллык йөгерде, зәңгәр күзләреннән кара шәүлә узды.

— Мин ул хакта бүтән сөйләшергә теләмәс идем,— диде ул агасының күзләренә туп-туры карап.— Мин инде Казан кешесе, күреп торасың — динем бүтән...

— Анысы әһәмиятле түгел,— дип бүлдерде Василий.— Динең бүтән булса да, җаның урыс ич. Без бит туганнар... Аңлыйсыңмы, туганнар!.. Кан тамырларында безнең кан, урыс каны ага. Динсез дәһри булсаң да, басурман булсаң да, тагын әллә нинди курчакларга табынсаң да белергә тиешсең: урыс — кайчан да урыс булып кала. Әгәренки син үз кавемеңә ярдәм итмисең икән, синең бу дөньяда яшәргә хакың юк. Урыс башкача яшәргә тиеш түгел. Аңлыйсыңмы син шуны? Беләсеңме?..

---

* *Хавыз* — бассейн.

— Яхшы, бик яхшы аңлыйм, Василий. Әмма сез әйткәннәргә күнә алмыйм. Унҗиде ел татар арасында яшәп, алардан бер кәррә яманлык күрмәдем. Хәзер шуңа этлек белән җавап биримме?! Булмый! Онытма: хатыным татар, улым, кызым татар... Мин аларның бердәнбер яклаучысы, саклаучысы...

Сәет бераз уйланып торды һәм үзе өчен авыр, гаять авыр нәрсәне хәл итеп бетергәндәй маңгаен учлап авыр сулады да тагын дәвам итте:

— Мине теләсә ни эшләтә аласыз... Хатыныма, балаларыма гына тимәгез... Туган икәнсең, бер нәрсәдә килешик: иң яхшысы — бу сөйләшү булмады дип уйлыйк. Сез әйтмәдегез, мин ишетмәдем. Җаныбызга гөнаһ алмыйк. Мин сезгә зыян китермәм, ишеткәннәремне кемгә дә чыгармам. Шушының белән бетерик! Калганы барысы да алла кулында. Теләсә ярлыкар, кирәксә җәзасын бирер.

Василийның тагын ачуы кабарды, энесенең басынкы сабырлыгы, бөтен тәкъдимне читкә тибәреп, юкка чыгарып баруы аны үрти, үрсәләндерә иде. Йомышын үтәми кайтсаң, Иваннан игелек көтмә. Анысы да күңелендә авыр таш булып ята. «Үзенә яхшылыкка әйтәбез юкса. Казанга нинәрсә янаганын чынлап аңламыйммы, аңламамышка салышамы?! Дивана түгел ләбаса!» Ачуын эчкә йотып, аның үзе шикелле салмаклык белән сөйләргә тырышты, иң каты, мәкерле соравын бирде:

— Ә Казан урыс кулына калса? Тагын урыслыкка чыгарсыңмы? Безнең дингә күчәрсеңме?

Мондый сөальне көткән идеме, әллә инде күптән җавабын әзерләп куйган идеме, Санька бер тында әйтте дә салды:

— Илгә ни булса, безгә шул булыр... Башкасын көтмим!

Озак сөйләштеләр, әмма аңлаша алмадылар. Санька тискәре, үз сүзендә каткан үҗәт адәмгә әйләнгән иде. Василийның соңгы фикере шундый булды. Хушлашканда Иван өйрәткәнне үзәгенә үтәрлек итеп әйтергә тырышты:

— Кара аны, әгәр белгәнеңне хан сараена тишсәң, үзең түгел, улың җавап бирер... Аны үзеңнән артык яратканыңны сизәм... Аның җаны белән түләрсең. Калагызда бездән башка да кешеләребез җитәрлек. Ник туганыңа үкенерсең! Йә, инде хәзер ни дисең? Бәлки, кире уйларсың?.. Без ике сөйләмибез...

Саньканың йөзе кәфендәй агарды, иреннәре калтырап куйды, кулы билендәге хәнҗәргә үрелде.

— Чыгып кит! Хәзер үк чыгып кит! — дип пышылдады ул. — Эзең булмасын! Без туганнар түгел, тү-ү-ге-е-л!

Василий исә аны үртәүдән, котыртудан тәм таба башлаган иде инде, юри аңламамышка салышты:

— Ә, әй-йе, китәм. Гөлйөзем белән, улың белән хушлашыйм да... Бәлки, аларга да әйтергә кирәктер... Киңәшләшик!.. Әле тагын кайчан күрешәбез...

— Һеркайчан да, — дип кычкырып җибәрде Санька һәм кинәт мәче җитезлеге белән Василийны җилкәсеннән эләктереп алды да җилтерәтеп таш капкадан чыгарып та ташлады.

Урамда Василий энесе ишетсен өчен башта кычкырып көлде, бераз киткәннән соң ачуына буылды, тешләрен шыгырдата-шыгырдата кире килеп, капкага тибәргә, йодрыклары белән төяргә кереште. Эчтән җавап булмады. Инде нишләргә дип кенә торганда урам чатыннан бер төркем атлылар — шәһәр сакчылары килеп чыкты. Алар, нәрсәдер дөбердәгәнне ишеткән, күрәсең, ачулы кыяфәт белән Василийга таба якынлаша башладылар. Василий баш киемен салып, буйсынучан кыяфәт белән аларга баш иде һәм, инде берни дә майтара алмаячагын чамалап, кәрван-сарайга атлады. Китүе яхшыга булды. Урамның икенче башыннан да атларын юыртып тагын бер төркем чагдавыллар менеп килә иде.

«Аһ, шул чакта ялгыштым, — дип уйлап куйды Василий. — Иванга ирек куйсам, кызлар кебек чибәр әнчеген тотып бирәр җиргә япсак, Санька да хәзер тик ятмас иде. Казанлыларның дары базларын күккә очырса, без дә болай җәфа чигеп ятмас идек. Әле кайчан басурманнар җыйган байлыгын ашап бетерә?..Казанлыларны ачка тилмертеп кенә шәһәрләрен алып булмый. Беләм мин!.. Казан бай, артык бай шәһәр. Бер Ташаяк ярминкәсе генә күпме мал бирә, керем бирә...»

Казанлылар, чыннан да, камалыштан артык борчылу сиздермиләр иде. Гадәттәгечә, морҗалардан төтен күтәрелә. Бөҗра булып урнашкан урыс гаскәре өстенә җил искән саен пешкән икмәк, кыздырган суган, ит, балык исе килә. Тау башындагы каладан балык исе килүгә урыслар аптырый, бот чаба, коры җирдән балык табуларына шаккаталар. Телдән-телгә сүз йөри: имеш татарларның сихерчеләре бар. Шулар таба, шулар ярдәм итә.

Бәлки шулайдыр да. Юкса, йөз илле меңлек чиру камаган кала халкы шулай тыныч, сабыр кала алыр идеме?! Яу кырында күзгә-күз очрашканда бер татарга биш урыс

туры киләсен белгән казанлылар түземлек, сабырлык күрсәтәләр, нидер көтәләр, нәрсәгәдер өметләнәләр иде булса кирәк. Хәер, аларны аңлап була. Урыс үзе ачка тилмереп кайтып китмәгәе!.. Казанлылар — акыллы, алдан уйлап эш йөртә торган халык. Белмичә, алдан уйламыйча кыланмыйлардыр...

Инде ике көн сугыш кырында тынлык. Урыс һөҗүм итми, татар атмый. Сәер, шомлы, дәһшәтле тынлык.

Эч пошуга чыдый алмаган, түземе, тәкате беткән Василий азык-төлек чатырында ята. «Нигә дөньясы кадалып китми шунда! Иваны да кайта белмәде, ичмасам!..»

Он тутырган капчыкка башын куеп черем итә башлауга тышта сугышчыларның, олаучыларның куркынган тавышлары ишетелде:

— Тагын сихерче чыкты...

— Сихерче... Сихерче!

Керфекләренә, күз кабагына кадаклы гердәй баса башлаган йокы шаукымын кул белән алып ташладылармыни, Василий сикереп торып тышка чыкты.

— Кайда? Кая? Кем ул?..

Олаучылардан берсе Казан өстендә сөңгедәй күккә үрелгән иң биек таш манарага төртеп күрсәтте.

— Әнә ич, әнә!

Күпме генә тырышмасын, Василий бернәрсә дә аера алмады. Очына алтын ярым ай куелган, җиде катлы манарага текәлде, аның катларын санарга керешге. Астагы өчесе дүрт кырлы, өстәге дүртесе сигез кырлы итеп кызыл кирпечтән эшләнгән таш әнә җансыз, тавышсыз иде. Аны казанлыларның аеруча хөрмәт иткәннәрен, кадерләгәннәрен дә белә Василий. Ире Сафагәрәй ханның кабере өстенә төрбә-мәчет итеп аны татарның яраткан хөкемдары — Сөембикә патшабикә салдырган, имеш.

Манараның катларын, бизәкләрен, тәрәзәләрен санап маташкан җиреннән кинәт шым булды, эченә җирәнгеч бер курку керде, бала йоннары кабарды. Манараның иң очындагы тәрәзә уентыгында, чыннан да, кемдер бар, ап-ак киемле башын сузып, кулын кашларына куеп ул еракка — урыс гаскәре артында каралҗымланып торучы шомлы куе урманга текәлгән иде. Менә аның кулында берсе яшел, берсе кызыл ике әләм пәйда булды, аларны болгап сихер кылырга, шайтани көчләрне, тәмуг җаһилләрен ярдәмгә чакырырга керешге. Әнә яшел әләм баш биеклегенә өскә күтәрелде, аннан көнчыгышка борылды, кызыл әләм исә кискен аска төшеп китте, тәрәзә астында болганды.

Шушы хәрәкәтләрне сихерче өч тапкыр кабатлады һәм, әләмнәрне аркылы-торкылы китереп болгагач, уентык караңгылыгына кереп югалды.

— Бер-бер афәт килгәнне көт тә тор хәзер,— диде кемдер.

— Сихерләде, безне сихерләде,— диеште олаучылар.

Казан тылсымчысының кул хәрәкәтләрен өнсез күзәтеп торган төркем өстендә шом канат җәйде, күңелләрендә курку хисе борын төртте. Камый башлауның икенче көнендәге зилзилә, гарасатлы давыл исләренә төшкән саен һәркемнең йөрәге калтырап куя иде.

— Аллам сакласын! Спаси и сохрани! — Олаучылар, сугышчылар белгән догаларын укырга, тәре үбеп чукынырга керештеләр.

Сихерче тәрәзә уентыгына кереп югалуга ярты сәгать үттеме-юкмы, урман ягында күк күкрәгәндәй тавышлар ишетелде, меңнәрчә атларның такыр җиргә дөп-дөп басуыннан туган бу аваз каныңны бозга әйләндерерлек дәһшәтле, шомлы, куркыныч иде. Көбә, очлы тимер башлык кигән җайдаклар, аларның ялтырап торган калканнары һәм алга төбәлгән, җилдә сызгырып килүче сөңгеләре, тимер ташкын сыман алга ургылуы иң салкын канлы, гайрәтле сугышчыны да тетрәндерер иде. Сафлар өстендә әләмнәр, ярым айлы сөңге сабына беркетелгән тулар җилферди, атлы гаскәр тыелгысыз дулкын булып урыс явы өстенә якынлашып килә иде.

— Ура! Кама!..

Бер ук атар ара калуга, меңнәрчә бугазлардан берьюлы ургылып чыккан көчле тавыш урыслар сафын таркатты, кайсы йоклап, кайсы ял итеп яткан гаскәриләр коралларын ташлап кача башлады, атлылар тупланып, каршы торырга әзерләнде. Әмма әзерлексез гаскәр тиз арада җыела алмады, татар ташкынын туктатыр көч юк иде инде.

Үлем белән, котылгысыз яу белән беренче тапкыр күзгә-күз очрашкан Василий кинәт хәлсезләнде, тез буыннары йомшарды, куллары калтырый башлады.

— Нишләргә, нишләргә? Кая качып котылырга?! — Үзе дә белмичә ул бертуктаусыз шул сүзләрне кабатлый, бәргәләнеп котылыр әмәл эзли иде. Миен яшен тизлеге белән телгән уйдан шашынып сикерде дә чатырга чапты, ашлыктан бушаган чыпта капчыкка кереп, авызын эчтән умырып тотты да тынды. «Татар капчыкны кисмәс, капчыкка кадамас. Җансыз әйбердә, капчыкта аның үче юк!»

Көтелмәгән яу ничек тиз килгән булса, шундый ук тизлек

белән эреп юкка да чыкты, тояк тавышлары яңадан урман ягына китеп югалды.

Әле бик озак чыгарга базмый ятты Василий. Ниһаять, тәвәккәлләп чыптадан башын тыкты һәм тирә-яктагы тынлыкны күреп, җиңел сулап куйды. Эчендә шатлыклы хис котырды: «Мин исән! Исән! Тагын исән калдым... Алла ярдәменнән ташламады!..» Аның канлы гәүдәләр арасында биисе, сикерәсе, тамагы ертылганчы кычкырасы килде. Тыелгысыз бу хистән ул котыла алмый, аяклары чыпта эчендә үзеннән-үзе тыпырчына иде.

Шул ук мизгелдә икенче якта ат тояклары дөпелдәде. Соңга калган урыс гаскәрләре һай-һу кычкырып, бер-берсен дәртләндереп сызгыра-сызгыра урман ягына чаптырып китеп барды. Әмма куе агачлар арасындагы һәр сукмакны, киек җанвар эзләренә кадәр биш бармагыдай белгән татар белән урманда алышып кара! Бу — урысларның җавапсыз калмас өчен үзләрен дәртләндерергә маташулары гына иде, әлбәттә. Моны сугыш һөнәреннән бихәбәр Василий да яхшы аңлады. Тагын бер нәрсәне ачык төшенде Василий: шанлы Казанны канга тончыктырып үзләрен коллыкка төшерергә килгән урысларга карата татарлар аяусыз, мәрхәмәтсез булачак, канлы үч алырга тырышачак'

Сөңгедәй манара очында сихерче көн саен күренә, ул кереп китүгә урыс гаскәренең әле бер, әле икенче ягында, бөтенләй көтелмәгән җирдә тотылмас атлылар пәйда була. Алар күз ачып йомганчы дошман баскан кырны өермәдәй иңләп үтәләр дә урман ешлыгына кереп югалалар.

Шул көннәрдә тагын бер аяныч хис кичерде Василий, үзен битәрләде:

— Их! Санька белән килешеп булмады. Үҗәт җан! Сатлык! — дип энесен дөньяда үзе белгән барлык әшәке сүзләр белән сүкте, каһәрләде.

Сәбәбе бик гади иде. Гаскәриләр әйтте, манарадан күренүче кеше сихерче түгел, күзәтче икән. Урман артында посып калган татар гаскәренә кайдан һәм кайчан һөҗүм ясарга кирәклеген белгертә, урысның йомшак ягын күрсәтә. Утыз мең атлы белән Япанча-морза урысның артында шуның өчен махсус калдырылган, имеш. Ул гына да түгел, күзәтче дигәннәре әләмен болгап алар белән сөйләшә, кирәк хәбәрләрне дә тапшыра икән. Тагын сүзләр йөрде: имеш, бөек кенәз хәзрәтләре шул телнең — әләм теленең серен ачкан кешегә алтын, теләгәнчә мал, дәрәҗә вәгъдә иткән. Дөрестерме, юктырмы, әмма воеводалар гына түгел, гади сугышчылардан алып олаучы, аш-сучыларга кадәр барысы

да манарада уйнаган әләмнәрнең серен аңларга тырышып баш ваталар, һәр хәрәкәтне үзләренчә аңлатырга җай эзлиләр, бәхәсләшәләр иде.

Әгәренки Санька ризалашкан булса, бу телне дә беләлыр идем ич,— дип үрсәләнде Василий.

Ә сер чишелмәде. Япанча атлылары урыс гаскәренә бер генә көнгә дә тынгы бирми бимазалый, үрти, даими киеренкелектә тота, яшь кенәзне гасабиланып тешләрен шыгырдатырга мәҗбүр итә иде.

ХЫЯНӘТ ҺӘМ ҮЧ

И потом хитрецы эти фряжские
Приступили к деянию главному,
До того на Руси не бывавшему:
Стали строить подкопы подземные.
. . . .
А казанцы того и не ведали.
И не знали все воины русские,
Кроме фрязинов тех с воеводами
Да строителей дела подземного...

«Казан патшалыгы турында риваять».

XVI гасыр.

Иван-сәүдәгәр җитәкчелегендә Мәскәүгә җибәрелгән олаучылар әйләнеп кайтты. Алар ашлык, ысланган ит, балык, җылы кием-салым, дары һәм байтак сугыш кирәкяраклары төяп килгәннәр иде. Тагын берничә көннән Иделдән йөк көймәләре килеп җитәсе. Мәскәүдә яңа полклар оешкан, алар юлга чыккан.

Болардан тыш та яңалыклар шактый иде. Йөкчеләрне, сәүдәгәрләрне озата барган гаскәриләр үзләре белән бер төркем телсез мөһәндисләр* ияртеп килгәннәр. Алары исә кальга-кирмән алуның яңа, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән ысулларын беләләр, Казанның менеп булгысыз биек диварларын алуда, су тутырылган тирән урларын кичүдә шулар ярдәменә таянасылар имеш.

---

* *Мөһәндис* — инженер. Урыс, көнбатыш халыкларының телен аңламаганлыктан, аларны телсез дип атаган. Немец сүзе шуннан килеп чыккан. Немой — немец.

Чатыр корып инде ничәнче көн түшәмгә төкереп ятучы, эшсезлектән, ачлыктан һәм көчсезлектән, Япанча би атлыларының туктаусыз һөҗүменнән арыган, алҗыган һәм озакламый Мәскәү ягына кыяклау турында хыялланган гаскәрне алыштырып куйдылармыни — китте көлеш, китте уен, китте мәҗлес. Бөек кенәз бу тузынуга күз йомды, саргәскәрләр сугышчыларның дәррәү кузгалып бушануын күрмәмешкә салышты. Көчләрнең тигезләшүеннән күтәрелгән бу дәрт, яугирлык галәмәте аларга да йоккан иде булса кирәк.

Василий да гомум шаукымнан читтә калмады. Аның кулына күз иярми. Юан кәүсәле йөзъяшәр имән ябалдашы астына тәгәрәткән саллы мичкәләрдән чүмечләп ачы бал чумыра, балчык кувшиннарга аракы бүлә.

— Әйдә, җырла, бие, урыс!.. Синең көнең килде. Тиздән Казан безнең кулда буласы. Ә инде анда болай гына туй итмәбез... Утыз көн уен итеп, кырык көн туен итеп... Шулаймы? Әйдә, ябырыл!

Үзен чорнап алган кешеләргә дәртләнеп кычкыра-кычкыра аның тамагы карлыгып бетте, көмеш, бакыр акча саный-саный бармаклары талды. Билендәге янчык авырайганнан-авырайды. Дөнья яңадан матурланды, яңадан киңәйде. Их! Яшәп күрсәтәбез әле бер!..

Шушы мизгелдә ул тагын Санькасны, чибәр Гөлйөземне, аларның зифа сынлы яшь пәһлуан улларын исенә төшерде, кызганып куйды. «Бу кадәр чирүгә хәзер каршы тора алырсызмы? Без дә күрсәтербез әле!» — дип масайды, аларның бу муллыкны, бу иркенлекне, көч-гайрәтне күрә алмауларына үртәлде. «Күрсеннәр иде, тезләнеп каршына килсеннәр, ялынсыннар иде. Юк! Вася аларны куып чыгармас иде. Сыйлар иде. Янчык-янчык акчаларын чыңлатып күрсәтер иде. «Йә, татарга әйләнеп ни оттың? Инде хәзер ялгышканыңны белдеңме», — дип котыртыр, үртәр иде. Казанны алгач тагын ниләр булачагын уйлап аның хыялы котырды, күз алдына тау-тау байлык, алтын-кәмеш, затлы күннәр, чибәр кызлар, кәнизәк-җарияләр килде. Шуның өстенә Василийның хәтта Иван-сәүдәгәр дә белмәгән яшерен хыялы, өмете бар. Әле сабый чагында ук этисеннән ишеткән сүз ул. Дөрестерме, юктырмы — анысын тәгаен генә әйтә алмый, әмма этисенең сүзенә ышанмаска да мөмкин түгел. Имеш, Казан сәүдәгәрләренең иң кәттәләрендә ниндидер яшерен тамга була. Шул тамга аларга теләсә кайсы базарның, каланың ишеген ача, бернидән курыкмый, шикләнми сәүдә итәргә юл саба. Ул тамга иясе теләсә кай-

чан һәм үзен базар агасы санаган теләсә кемнән теләгән хәтле акча алып тора ала, ярдәменә таяна. Шәрык базар агалары ул тылсымлы тамганы иң абруйлы, иң бай, иң гадел, акыллы сәүдәгәрләргә генә бирә имеш. Аңа ия булсаң... дөньялыкта кайгың бетте дигән сүз. Әтисе аны сурәтләп тә биргән иде. Сәмруг кош сурәте төшерелгән көмеш тәңкә имеш. Чын сәүдәгәр аннан үлгәнче аерылмый имеш. Үлсә үлә, әмма тамганы сатмый, алыштырмый, теләсә кемгә белгертми дә...

Василийның хыялы шул — Казанда тылсымлы тәңкә, базар тамгасы кулга төшереп булмасмы?!. Кем белә... Эчемлек парыннан үрләгән, бәргәләнгән хыялның чиге юк, бу мизгелләрдә ул бөтен җиһанны колачлый иде.

Гаскәр ял итте, бәйрәм итте. Алар хәтта энәдәй очлы манарада күзәтче тору ихтималын да, Япанча бинең теләсә кайсы мизгелдә яшен тизлеге белән өсләренә ташлану мөмкинлеген дә онытканнар иде. Сакка куелган укчыларга хәтле уяулыгын җуйды, җырлады, биеде.

Гаскәр ял итте. Шул ук вакытта һәр ике якның үзегендә кайнар бәхәс бара иде.

Бөек кенәз чатырына боярлар, воеводалар, полк башлыклары кереп тулды. Яшь хөкемдарның алар фикерен, тәкъдимен ишетәсе килә. Ләкин белә — берсеннән бер юньле сүз чыкмаячак. Урыс белән татарның сугыш сәнгате бер төрле. Таш кальга эчендә соң чиккәчә көрәшергә ант эчкән көчле һәм усал гаскәр. Шуның өстенә артта ни кыласын тәгаен белеп булмый торган җитез атлылар — Япанча морза алайлары.

Сугыш һөнәрен татардан ким белмәсәләр дә, воеводалар азмы-күпме өстенлек бирерлек нинди дә булса гайре табигый фикер, яңа алым тәкъдим итә алмаячаклар. Бар белгәннәре камауны дәвам иттерү. Анысын Иоанн үзе дә белә. Әмма камауның да бер чиге булырга тиеш ләбаса. Һәр куагы, һәр агачы урыска янаган рәхимсез татар җирендә күпме торып була Алда пыскак көз, аннан зәмһәрир суыклары белән кыш килер Җылы ташпулатларга кереп оялаган, үз җирендә, үз илендә һәр таш, һәр агач, һәр инеш ярдәм иткән басурман дошман белән якалашып кара!

Иванны иң гаҗәпләндергәне шул — тау башындагы кальга инде ничәнче көн камалышта. Очар кошлардан гайре анда беркемнең дә кергәне дә, чыкканы да юк. Әмма казанлылар ачка интегү генә түгел, сусауларын да сиздермиләр. Юкса, Болак, Кабан, Казан-су — барысы да безнең кулда, якын-тирәдәге чишмәләргә кеше түгел, чыпчык та

үтеп керә алмаслык сак куелган. Кара акыл белән исәпләгәндә дә, күп дигәндә бер атнадан сусаган, бер йотым суга тилмергән казанлылар яшь ханны бәреп төшереп, Иван алдына тезләнергә тиешләр иде. Икмәксез торып була, ә менә сусынны басу — башка мәсьәлә.

Иван йокысызлыктан кызарган ачулы күзләрен бер воеводадан икенчесенә күчерде, һәркайсының миендә ни кайнаганын белергә теләгәндәй, озак итеп, бәгыренә үтәрлек итеп карап торды. Авыр карашны күтәрә алмасалар да, күзләрен читкә тәбәмәделәр. Иванның моны яратмаганын, күзгә туры карамаганны өнәмәгәнен алар яхшы беләләр иде инде.

«Йә, инде ни әйтерсез?» — дип эчтән генә уйлап куйды яшь кенәз, әмма тынлыкны бозарга ашыкмады.— Инде азык-төлек җитәрлек, сугыш кирәк-ярагы, җылы кием-салым бар, дары һәм гаскәр хәттин ашкан... Алга таба ни эшлибез? Нигә авызыгызга су каптыгыз?! Барысын да мин генә хәл итимме? Тәкъдим әйтергә, фикерегезне белгертергә өркәсезме?!»

Шулчак чатыр тышында кемнәрнеңдер шаулашканы, сакчыларның айбалталарын бер-берсенә бәреп, ачулы әмер биргәне ишетелде.

— Галиҗәнаб бөек кенәз беркемне дә кертмәскә кушты. Артка! Артка чигенегез дим!..

— Мин мөһим хәбәр белән. Галиҗәнабка җиткерегез! Ашыгыч сүзем бар... Кабул итми калмас!

«Һа, кара син аны, үз-үзенә ничек ышана!» Иван үзалдына көлемсерәп куйды. Сакчыларга кычкыручы яшь тавыш иясенең кемлеген ул инде күптән танып алган һәм аның киңәшмәдә түгелегенә күптән эче пошып утыра иде. Алексей Адашев — кенәзнең ышана, якын күрә торган бердәнбер киңәшчеләреннән иде. Моны сакчылар да белә булыр. Әмма боерыкны алар катгый үти. Шулай кушылган. Воеводалар сөйләшкәндә кем дә комачауларга тиеш түгел.

Иван, сизелер-сизелмәс кенә баш кагып, ишек төбендәге сарай хадимнәренең берсенә ишарә ясады:

— Кертсеннәр!

Хөкемдардан күзләрен дә алмый, аның һәр ымын, кул хәрәкәтен күзәтеп торган хадим «Аңладым!» дигәндәй бил бөкте дә ишектән чыгып югалды.

Күп тә үтмәде, чатырга еш-еш сулап, ярсыган Адашев килеп керде. Әдәп йөзеннән, сарай йоласы кушканча, иң элек бөек кенәзгә, дәрәҗәләренә карап аның тирәсенә тер-

ле ераклыкта утырган боярларга башын иеп сәлам бирде һәм ашыгып сөйләргә кереште:

— Бөек хөкемдар! Казаннан якыннары белән Камай морза безнең якка күчте. Төнлә шәһәрне ташлап чыгу җаен тапканнар. Аның сез галиҗәнабка гына җиткерәсе сүзләре бар...

— Нинди сүз ул? Нигә үзең генә сорашмадың? — Иванның йөз-кыяфәтенә шикләнү, ярсу һәм усаллык галәмәте чыкты, кашлары җыерылды, маңгаенда тирән сырлар барлыкка килде.

Алексей Адашев, барысы да сезнең ихтыярда дигәнне аңлатырга теләгәндәй, иңбашларын җыерып куйды да басынкы тавыш белән аңлатырга кереште:

— Камай морза Казанда хан сараена якын көчле шәхесләрнең берсе... Аңа карата вакытыннан элек, сезнең әмердән башка, усаллык, катылык күрсәтергә базмадым...

Кенәзнең йөзендә елмаюга охшаш нәрсә күренде, маңгаендагы җыерчыклар югалды, сөякчел бармаклары белән ияген угалап алды. Кинәт күзләре киң ачылды, теш арасыннан кысып, кискен өзеп сорау бирде:

— Тентедегезме?

— Әлегә юк, бөек хөкемдар! Боерыгыз!

Иванның канәгатьсезлеген сизгән Адашев ишеккә таба чигенде.

— Хәзер... хәзер... барысын да эшлибез!..

Камай морзаның бите кәгазьдәй агарган, борын тишекләре киңәйгән, калтыранган бармаклары хөббәсенең көмеш төймәләрен эләктерә алмый азаплана иде. Сарай итагатенең бөтен шартын китереп иелеп сәлам биргәннән соң, ул утлы карашын Иванга төбәде.

— Урыс җиренең бөек хөкемдары Иоанн Васильевич! Мин синең янга чын күңелдән, намусым кушканга, изге теләк — ике арада кан коюны туктатырга ярдәм итү теләге белән килгән кеше. Беләсез: мин Бөек Казан мәмләкәтенең морзасы, тамырларымда аксөякләр каны ага...— Аның тавышы бер күтәрелә, бер төшә, фикерен югалтмас өчен барысын да тизрәк әйтеп калырга ашыга иде кебек.— Мине... бөек асылзатлар белән мәҗлестәш морзаны... кара колдан, чурадан түбән куеп, чишендереп тентесеннәр әле... Оят! Иоанн Васильевич, оятың кая куярсыз? Мин... мин... ул кешеләреңне җәзага тартуны таләп итәм.

Морзаны анадан тума күз алдына китереп, Иван мыек астыннан гына елмаеп куйды, әмма аны бүлдерергә дә, хупларга да ашыкмады. Нинди максат белән килүе тәгаен ачыкланып җитмәгән казанлыга карата фикере урнашып өлгермәгән иде әле. Кинәт күңелен сөенеч хисе биләп алды: «Әгәр олуг морзалары безнең якка күчә башлаган икән, димәк, хәлләре мөшкел. Бусы — әйбәт фал!» Морзаны тынычландырырга теләп, сул кулын өскә күтәрде. Теленнән балдай татлы сүзләр агылды:

— Сине яхшы беләм, олуг морза! Дан-шөһрәтең Мәскәүдә дә билгеле. Тынычлан! Сиңа карата андый хөсетлек кылган холоп бүгеннән җәзасын табар — башы үләксәлектә черер!.. Без сине тыңларга әзер... Иң элек беләсем килә: безнең якка галиҗәнаб Казан ханы бөек Ядегәр ирке белән килдеңме? Хан ярлыгын китерүчеләрне без олуг кунак, иң зур хөрмәткә лаек затлардан саныйбыз...

Бераз тынычлана төшкән Камай морзаның битенә куе кызыллык йөгерде, бердән кечерәеп калгандай, гәүдә тотышындагы горурлык, турылык күзгә күренеп кимеде, акрын гына баш чайкады:

— Юк, бөек галиҗәнаб! Мин үз ихтыярым белән килдем!..

Иван чыраен сытып куйды. Мәҗлестә утыручы воеводалар сәерсенеп бер-берсенә карашып алдылар. Бернинди җиңелү, бирелү галәмәте сиздермәгән, кыю һәм горур казанлыларның хәле, алар уйлаганча, шактый нык, өметле иде ич әле. Һәм көтмәгәндә... беренче качкын! Гади сугышчылардан булса бер хәл. Ә монда... хан сараена, диванга якын даирә кешесе — морза басып тора. Аларның күз карашыннан шундый уйларны укып булыр иде.

Шуларны сизгәндәй, Камай морза ашыгып тезә башлады:

— О бөек хөкемдар! Урысларның җиңелү белмәс олуг патшасы! Мин артык каршы торуны мәгънәсезлек дип саныйм. Сезнең гаскәрнең күплеген, урыс коралының көчен беләм. Әгәр, мәрхәмәт күрсәтеп кабул кылсагыз, соң сулышымача сез галиҗәнабларга хезмәт итәргә әзермән!.. Аягыгыз астында туфрак булыйм...

Камай артыннан кереп ишек катында басып калган Алексей Адашев җирәнгәндәй йөзен чытып куйды, морзага мәсхәрәле караш ташлады. Аның бу хәрәкәтен күреп калган Иван дусты, фикердәшенең йөз кыяфәтен кабатлый язды. Ләкин бик тиз үзен кулга алды. «Сәясәттә уй-той-гыларыңны тышка чыгармау фарыз. Юк кына сүзнең, мәгъ-

нәсез бер хәрәкәтнең, өнәмичә төбәлгән карашның эшкә зыян китерүе бар. Бәлки әле бу Камай морзаны файдаланып булыр... Кем белә... Сатлык җаннар үз халкына зыянзәүрат салмыйча гына дәрәҗәгә ирешә алмый. Ә бу, күрәм, дан-дәрәҗәгә, шан-шәүкәткә күнеккән адәм. Шул юлдан чыгасы килмәстер, шәт...» Тавышына ягымлылык төсмере салырга тырышып, сүзне дәвам иттерергә булды.

— Без сугыш кануннарына таянып эш йөртәбез. Корал көче кырда сынала, батыр яуда беленә... Без казанлылар белән ачыктан-ачык сугышырга әзер. Чыксыннар ачык мәйданга: алышыйк, сынашыйк...

— Бу минем ихтыярымда түгел. Диван әһелләре соңгы сугышчы шәһит киткәнче каршы торырга җыена...

— Ядегәр ханның кыюлыгын хуплыйм. Әйе, хуплыйм,— диде Иван алтын шарлы таягына таянып.— Татар гаскәре көчле, йөрәкле, кыю... Монысын беләбез. Әмма урыска каршы торыр көч бармы хәзер?!

Камай аның сүзләрен раслагандай сыгылып баш иде.

— Әйе, бөек хөкемдар! Урыс олуг гаскәр белән килде. Көчләр тигез түгел...

Иван ачулы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Белгәч, нигә каршы торасыз? Нигә кальга капкаларын ачмыйсыз?! Минем сабырлыгым, түземлегемне сыныйсызмы?

— Казанда берничә елга җитәрлек азык-төлек бар, бөек хөкемдар...

— Ә су... су безнең кулда... Бер генә кешене дә суга якын җибәрмәячәкбез. Белеп тор!

Камай морза үзе өчен нәрсәдер хәл итте, күрәсең, Иванга туп-туры карап, ашыгып пышылдарга керешге:

— О бөек хөкемдар, ялгышасың... Казанлыларның суы бар. Күз яшедәй чиста, саф сулы чишмәләре агып ята...

— Кайда ул, тау башыннан агып ятамы? — дип мыскыллы елмайды Иоанн Васильевич.

Аның мәсхәрәле тавышын ишетмәгән дә кебек Камай һаман үзенекен тезде:

— Юк, юк, падишаһым! Ул тау куышында, Казан суы буенда. Халык җир асты юлыннан йөри. Сусауны белми дә... Нургали капкасы яныннан яшерен юл бар...

Ниһаять! Үзен борчыган сорауга җавап тапкан Иоанн Васильевич җиңел сулап куйды, ирен чите белән генә елмайды һәм алтын шарлы таягын тәхеткә сөяп, ике тапкыр кул чапты. Чатыр ишегендәге пәрдә чайкалып куйды, ачык-

лыкта баштанаяк коралланган ике сакчы күренде. Алар тавыш-тынсыз Камай морзаның ике ягына килеп бастылар һәм ишеккә таба ымладылар.

Камай кискән агачтай җиргә ауды, кулларын тәхет ягыга сузып ыңгыраашты:

— Бөек хөкемдар! Ни өчен? Мин үз ихтыярым белән килдем...

— Ә син батыр йөрәклеләрдән түгел икән, морза! Курыкма! Без әле очрашырбыз, диде Иван һәм сакчыларга ымлады. Алар исә ярым үле, ярым тере гәүдәне сөйрәп чатырдан чыгып та киттеләр.

Иван тагын бер мәртәбә кул чапты. Сарай хадимнәреннән икәү берьюлы ишеккә ташланды. Хөкемдарның һәр хәрәкәтен сүзсез аңларга өйрәтелгән бояр балалары берничә мизгелдән сәер киемле, җилкәләренә төшеп торган озын бөдрә чәчле бер төркем кешене ияртеп керделәр. Болар —мәгърип* илләреннән чакырылган телсез мөһәндисләр иде.

Воеводалар аларның тәннәренә сыланган тар чалбарларына, шунлыктан артык нечкә күренүче сыйракларына һәм кабартып тутырган мендәр сыман өс киемнәренә, барысыныкы бер төсле ак көдрәләренә сәерсенеп карап алдылар, гаепләгәндәй баш чайкап куйдылар. Тукыманы җәлләмичә мулдан тегелгән озын җиңле урыс киемнәре янында боларның өс-башы гайре табигый, ямьсез һәм шөкәтсез тоела иде.

Әмма мөһәндисләр үз дәрәҗәләрен яхшы беләләр иде булса кирәк. Алар уң аякларын барысы берьюлы алга чыгарып, кулларын як-якка җәеп, артык кабалану һәм ашыгу күрсәтмичә Иванга, боярларга баш иделәр, аңлашылмаган ят телдә берничә сүз әйтеп алдылар.

— Сез галиҗәнабләргә җиңү, байлык, сәламәтлек, дан һәм шөһрәт телиләр,— дип тәрҗемә итте баштанаяк кара киемгә төренгән озын буйлы тылмач.

— Теләкләрен кабул кылдык. Әйт: бер-беребезгә мактау һәм дан җырлап утырыр чак түгел. Кальганы күрделәр. Камауда ни майтарып күрсәтерләр икән?..

Тылмачны башларын кырын салып тыңлаган мөһәндисләр үзара тагын нәрсәдер сөйләшеп алдылар. Арадан берсе, башкалардан өлкәнрәге — анысы башлыклары иде булса кирәк, иптәшләрен аралап алга чыгып басты һәм тылмачка

---

* *Мәгърип* — көнбатыш.

әйләнеп тә карамыйча, туп-туры Иванга текәлеп сөйли башлады.

Тылмач ашыгып тәрҗемә итәргә кереште:

— Нәрсәдер башкару өчен без исәп-хисап ясарга, кирмәннең төзелешен белергә тиешбез, диләр. Мөһәндислек — төгәл хезмәт. Өйрәнмичә, белмичә нидер хәл итү безнең кагыйдәдә юк. Һәрхәлдә, мондый нык кальга-кирмәнне әлегәчә күргәннәре юклыкны әйтәләр.

Иван тәхетендә калкынып куйды, чит ил кешеләрен күрмәгән дә шикелле тылмачка ысылдады:

— Акыл өйрәтмәсен! Туктат! Монысын гына үзебез дә беләбез.— Аннан соң кенәз Серебряныйга борылып, бер мизгел эчендә үзгәргән ягымлы тавыш белән әйтте.— Кальганың төзелеше белән таныштыр! Чишмә турында да әйтергә онытма. Башларын ватсыннар. Йөзләрчә алтын түләп юкка чакырмадык...– Һәм артык бер сүз дә әйтмичә тәхетеннән төшеп, чатырның калын зәңгәр постау белән бүленгән эчкәре ягына кереп тә китте.— Фикерләре өлгергәч чакырырсыз...

Василий Серебряный бөек кенәзнең мөһәндисләргә артык ышанып җитмәвен, алар белән вакланасы килмәгәнлеген күптән аңлап алган иде инде. Эчендәген сиздермәскә тырышып, ул почмактагы тимер сандык өстендә яткан кәгазь төргәген алды һәм мөһәндисләргә кальганың эчке, тышкы төзелешен, ныгытмаларның үзенчәлеген, кайдан нинди юл барлыгын, казанлыларның гайрәтен, хәйләсен, түземлеген аңлатырга тотынды. Аның тиз-тиз сөйләгәненә тылмач чак өлгереп бара иде. Ниһаять, чират тау куышы, чишмә, җир асты юлына җитте.

Баштарак ялыктыргыч гадәти бер нәрсә тыңлагандай сызымнар өстенә битараф иелгән мөһәндисләр бер-берсенә карашып алдылар, күзләре ялтырый башлады, үзара нидер пышылдаштылар. Өлкән мөһәндис сөякчел бармагын сызымда күрсәтелгән манарага сузды, «Нурали, Нурали?» — дип куйды.

— Әйе, Нургали капкасы шул булыр,— дип җөпләде Серебряный. Аның ни әйтергә теләгәнен ул тәрҗемәсез дә аңлап өлгергән иде инде.

Мөһәндисләр бер-берсен бүлдерә-бүлдерә тагын нәрсә хакындадыр бәхәсләшеп алдылар. Эшсез калган боярлар, воеводалар авыз ачып кычкырып исни, урыннарында кырын ята төшеп, чит-ят кешеләрне сәерсенеп күзәтәләр иде.

Менә өлкән мөһәндис кулларын җәеп кәсептәшләрен

туктатты һәм Серебряныйга карап, үзләренең әзер икәнлеген, бөек кенәзне күрергә теләгәнлеген белдерде.

Шуны гына көтеп торгандай, зәңгәр постау артыннан Иоанн Васильевичның озын какча гәүдәсе күренде. Аның йөзендә мәсхәрәле һәм бер үк вакытта канәгать елмаюны, сабыр, салмак хәрәкәтләрен күреп воеводалар җиңел сулап куйды. Арадан берсе күршесенә төртте.

— Йөз алтынга бәхәсләшә алам, ул теге якта барысын да тыңлап, тәрҗемә иттереп торды...

Күршесе исә пышылдап җавап бирде:

— Күп сөйләшмә! Иванның колагы һәркайда...

Ул арада өлкән мөһәндис галиҗәнаб кенәз каршына килеп баскан иде инде. Ул тагын бер мәртәбә кергәндәге сәер хәрәкәтләрен кабатлады һәм һәр сүзен үлчәп алтын тәлинкәгә салгандай саллылык белән бәян итәргә тотынды:

— Без әмәлен таптык, бөек кенәз! Хәйләкәр татарлар үзләре үк юл күрсәтә. Алар казыган җир асты юлын без казый алмыйбызмы?! — Аның йөзенә тәкәбберлек, үзеннән разый-канәгать кешеләрдәгечә салкын елмаю чаткылары чыкты.— Сугыш сәнгатендә бу безнең өр-яңа сүзебез, олуг ачышыбыз булачак. О тарихи мизгел!

Иванның йөзе караңгыланганнан-караңгылана иде. Кинәт мөһәндис тотлыгып калды һәм хөкемдарның йөзенә карап тиз генә үзен төзәтергә ашыкты:

— Әйе, бөек кенәз! Бу урыс гаскәренең сугыш сәнгатендә әйткән яңа сүзе булачак... О бөек урыс гаскәре!..— һәм ул олпатлыгын онытып, ашыга-ашыга сөйли башлады.

Ярты сәгатьлек тәнәфестән соң чатырга Иоанн Васильевичның ышанычлылары җыелды. Аларга бөек кенәзнең яшерен фәрманы игълан ителде. Олуг хөкемдарга дан һәм мактау яудырылган чачаклы-чуклы сүзләрдән, аның ихтыярын шанлаудан соң фәрманның эчтәлеге кыска, мәгънәсе ачык иде: «Атлы һәм җәяүле гаскәр белән көн саен һөҗүм ясап, утка тотып татарны алҗыткан арада, Таһир мунчасы ягыннан җир асты юлы казып, чишмәне шартлатырга. Мөһәндисләргә үзләре сораганча җир казучы бирергә. Казуны үлем куркынычы астында һичкем белергә тиеш түгел. Серне ачучыга — әҗәл! Баз янына якын килгән һәр чит кешегә — ук! Сакчыларны агулы уклар белән коралландырырга. Житәкчелек, сер саклауны тәэмин итү кенәз Василий Серебряный һәм Алексей Адашевка йөкләнә.»

Киңәшмәдән соң, һөҗүм башланганнан бирле беренче тапкыр, Иоанн Васильевич тыныч күңел белән чатырында бикләнде. Озакламый казанлыларның соңгы таянычтан

мәхрүм калачагы җанына ял бирде, аяк-кулларын ятагына таратып тирән йокыга талды. Чатырда ятак сакчыларыннан — яшь бояр угланнарыннан гайре беркем дә калмады.

Ә воеводалар әмерне үтәргә ташланды. Гаскәрдән таза беләкле, нык бәдәнле сугышчыларны сайлап Таһир мунчасы янына кудылар. Тимер көрәкләр, тире капчыклар китерелде. Кич җитүгә телсез мөһәндисләр әмеренә буйсынып, алар өненә кереп качкан сукыр тычканнардай, җир тишегенә кереп югалдылар. Тирә-якка ук-җәяле сакчылар басты.

Бөек кенәзнең ихтыяры нигезендә, казу бары тик төннәрен генә алып барылачак, чыккан туфрак капчыкларда еракка, Казан-су ярына илтеп түгеләчәк иде.

— Тукта! Кем килә?

Каршында җир астыннан үсеп чыккандай пәйда булган пәһлеван гәүдәле сакчының тавышыннан Василий сискәнеп китте, кемлеген белдерергә ашыкты:

— Мин бу! Аш ташучы... сәүдәгәр Василий...

— Анаңны... кабер тактасына...— Сакчы сүгенү сүзләрен ярсып, теш арасыннан кысып, пышылдап чыгарды:— Белмисеңмени... Сак янына килгәндә тамак кырып, кемлегеңне әйтеп киләсе... Йөрәгеңә ук аласың киләмени?..

— Гафу, гафу... Онытылып киткәнмен. Сезне болай якында ук дип белмәдем...

— Кара аны! Икенче килгәндә кемлегеңне сорап тормам.

Василий изүенә төкеренеп алды да сыртына аскан капчыгын рәтли-рәтли каравыл яныннан тизрәк китәргә ашыкты. «Аллам сакласын! Патша полкы башкисәрләре күп сорап тормас!»

Чыклы үләндә тая-тая җир тишеге янына килеп җитте. Борынына юеш балчык, сөрем, атналар буе юынмаган ирләрнең авыр тир исе килеп бәрелде. Кеше биеклегендә казылып барган куышлыкта сумалалы кусәкләр дөрли, еракта, чокыр түрендә кемнәрнеңдер сүгенгәне, тимер көрәкләрнең ташка бәрелеп чыңлаганы ишетелә иде. Василий капчыгын җайлаштырды, кулындагы мичкәне икенчесенә алыштырып тотты да белгәннәрен укып куышлыкка атлады.

Иван сәүдәгәргә җен ачулары кабарган иде аның. Инде тыныч кына Казанның бирелүен көтеп ятарга җай чыккач, тагын кабахәт җан аны мәхшәр уртасына китереп тыкты. «Көндез йокы симертәсең, төнлә нибары бер мәртәбә саф һава сулап кайтасың, имеш. Кайттың менә! Үзеңне китерәсе

иде... Сулар иден саф һава,— дип эчтэн генэ Иванны каһэрлэде, аның белэн бэхэслэште.— Җаһиллеген кара! Кайда нишлэп йөрүенне эт тэ белергэ тиеш түгел, имеш... Алексей Адашев белэн шаярырга ярамый. Бөек кенэзнең сөеклесе, тугры дусты, имеш. Адашев булмагае, шайтаным булсын. Нигэ мин сэүдэгэр башым белэн йомышчы малай сыйфатында йөрим ди...»

Эчтэн сүгенсэ дэ, Адашев кына түгел, Иван сэүдэгэр белэн дэ шаярырга ярамаганлыгын бик яхшы белгэн Василий карышып бер сүз дэ эйтэ алмаган иде. «Йөр менэ хэзер... селкетеп»,— дип куйды ул һэм чертлэтеп җиргэ төкергэч, йомышын тизрэк йомышларга ашыгып адымнарын кызулатты. Чокыр түрендэге ут яктысында бил тиңентен чишенгэн казучыларның тирле гэүдэлэре, ялкын нурында җирдэ уйнаучы шомлы шэүлэлэре күренэ башлаган иде инде.

Бер мизгелдэн аны битлэре сөремгэ, корымга буялган җир казучылар уратып алды. Аларның усал ялтыраган күзлэрен, каклаган дуңгыз итенэ батып керэчэк сары тешлэрен күреп, Василий тетрэнеп куйды. «Болар белэн шаярырга ярамый!»

— Озак йөрисең, сэүдэгэр! Йокың туймадымы эллэ?

Алып гэүдэле казучының усал тавышы шөбһэсен тагын да көчэйтэ төште. Эле генэ Иван сэүдэгэр белэн бэхэслэшүен онытып, киң күңеллерэк җавап бирергэ ашыкты:

— Юл ерак, йөк авыр, туганнар! Килегез! Барысы да бар: каклаган ит, кабарып пешкэн арыш ипие... Мичкэмдэ ачы бал чымырдый.

Җир казучылар аны хуплап шаркылдаштылар. Көчле куллар аркасыннан капчыкны, бармакларыннан мичкэне ычкындырды. Карлыккан тавыш ишетелде:

— Йэгез, бөек кенэз Иоанн Васильевич хөрмэтенэ...

* * *

Ярты көнен диярлек таш манараның күзэтү мэйданчыгында үткэргэн Кол Шэриф хан сараенда булмаса да, анда ни барын, ни эшлэнүен күреп, белеп торды. Иртэдэн бирле сарай янында саргаскэрлэр таптанды, каланың төрле ягыннан чапкыннар килде, берсе керде, икенчесе чыкты. Урыс гаскэренэ көчле ярдэм килэсеннэн инде күптэн хэбэрдар Кол Шэриф моның шулай булырга тиешлеген дэ белэ, диван эһеллэренэ ни киңэш бирергэ, изге Казанны саклап,

яклап калу өчен ни кылырга кирәклеген уйлап баш вата иде.

Күрмәде түгел, күрде, урыс станында ни майтарып ятуларын да күзәтте. Алар да чарасыз иде, күрәсең. Ничә көн дәвам иткән камау урыска бер карыш та алга барырга мөмкинлек бирмәде. Ничек торган булсалар, һәнүз шул көенчә тора бирәләр. Көчләр тигез. Көчләр нисбәте казанлыларның калын, ныклы диварлары, урысның сан ягыннан күпкә артык булуы белән тигезләшә, бер якка да өстен чыгарга ирек бирми. «Ниндидер гайре табигый, сугыш һөнәрендә моңарчы күрелмәгән бер-бер яңа алым, хәйлә кулланмасак, бу ялыктыргыч камау чиксез дәвам итәчәк. Диванда шуны әйтергә кирәк булыр»,— дип уйлаг куйды Кол Шәриф һәм зурайткыч пыялалардан ясалган ерактан күрсәтүче көпшәсен урыс станына төбәде.

Кенәз чатыры янына көчле сак куелган. Воеводалар бер керә, бер чыга. Инде озак утыралар. Ниндидер сәер киемле кешеләрне алып кереп киттеләр. Дөньялыкта күп нәрсәне танып белгән Кол Шәриф бу адәмнәрнең мәгърип ягыннан килгәнлеген дә, урысларга киңәшче сыйфатында чакырылуларын да тәгаенләми калмады, әлбәттә. «Болар безгә бер-бер хөсетлек, таныш түгел бер-бер хәйлә әзерли. Чит мәмләкәтләрдән үк укымышлы затларны юкка гына китертмәсләр»,— дип уйлап куярга өлгерде. «Монысын белеп тору зыян итмәс. Дошманның мәкерен алдан сизенү хәйләләрен сүтәргә ярдәм итәрдер... Сарайдан кайткач румнарның, мәгърип илләренең сугыш тарихларына янә күз йөртеп чыгарга кирәк булырдыр. Нинди дә булса күзгә чалынмаган хәйлә-мәкерләре тасвирланмаганмы...»

Хан сараенда иртәдән бирле дәвам иткән ыгы-зыгы сүрелде, төшкә кадәр барлык гаскәрдән мәгълүмат тупланды, биек манарадагы хәбәрчеләр әләм болгап Япанча би күзәтчеләре белән сөйләшеп алдылар. Хәл кискенләште. Урыс яңа көч белән Казанга ташланачак. Хәер, моны саргаскәр һәм яшь хан Ядегәр генә түгел, кальгадагы бар кеше дә яхшы аңлый иде инде.

Ядегәр хан алтын тәхетендә җәйлап утырды һәм бизәкле күн мендәрләр салынган урындыкларга ике яклап тезелешкән саргаскәрләргә, диван әһелләренә сораулы караш ташлады. Аның тау халыкларыныкыча текә ак маңгае җыерылган, зур кара күзләре гаять тәшвишле хәбәр әйтергә җыенган кешеләрдәгечә борчулы елтырый, куллары гасабиланып тәхет читендәге култыксаларны сыйпый иде.

Кол Шәриф шунысына да игътибар итте: иң авыр, чете-

рекле хәлләрдә дә тынычлыгын, сабырлыгын югалтмый, горур кыяфәтен саклый белгән яшь хан бүген үз-үзен тыя алмый, сүзен ничек башларга белми изалана иде кебек. Ниһаять, ул җанын кыйнаган уйларының очына чыкты булса кирәк, сынына элеккеге мәгърур турылыгы, төзлеге кайтты, игътибар таләп итеп, уч төбе белән тәхет култыксасына сугып алгач, калын, көр тавышы белән эндәште:

— Мөхтәрәм диван әһелләре, карачылар, саргәскәрләр... Бөек һәм изге Казанның ышанычлылары! Язмышыбыз, киләчәгебез хәл ителгән, һәр сәгате, һәр дәкыйкасы елга тиң шушы кара көннәрдә мәшәкатегездән аерып, барчагызны бергә киңәшкә чакыруымның аерым сере бар.— Кинәт аның тавышы калтырап китте, күзләреннән ачулы очкын чәчрәде.— Исемнәрен әйтмим, алдан ук сезнең нәфрәткә дучар итәсем килми... Үзара киңәшепме, әллә үзбаш кына уйлапмы — анысы миңа караңгы — хыянәтчел тәкъдим белән керделәр...

Диван әһелләре бер-берсенә карашып алды, тавышсыз гына пышылдаштылар:

— Нинди хыянәт?

— Кемнәр... Нәрсә бу?..

— Ашыкма, тыңлыйк! Ишетербез... Аттан ала да туа, кола да туа,— дип куйды арадан берсе пышылдашуны бүлеп. Чапкын морза исә сикереп торды:

— Олуг хан галиҗәнаблары! Әйдәгез, табышмаксыз гына сөйләшик. Хыянәткә җәза бирерлек көчебез, колак салырлык фикере булса, уртаклашырлык ихтыярыбыз бар дип беләм. Без изге Казанның бөек халкы алдында җавап тотабыз...

— Алайсаң тыңлагыз. Уртага салып сөйләшик. Ул тәкъдимдә күпме мәгънә, күпме акыл орлыгы бардыр, үзегез хәл итәрсез.— Ядегәр хан урыныннан торды һәм күн читек табаннарын шыгырдата-шыгырдата калын келәм өстендә йөренә башлады.— Беләсез булыр, кальгадан Кабан күле ярына чыгучы яшерен юл бар. Җир асты юлы... Япанча бинең хәбәр итүенә караганда, ул юл чыккан җирдә, Кабан буенда дошман чирүе юк. Алар кальга төбендә. Тәкъдим мондый: урыс яңа көч килүен бәйрәм итә. Сизгерлеге ташка үлчим. Төнен бөтен гаскәр белән Казанны ташлап чыксак, алар иртәгәсен буш шәһәргә һөҗүм итәчәк... Ә без караңгылык пәрдәсенә төренеп еракка — Арча урманнарына кереп югалырга өлгерербез...

Гөмбәзләнеп менгән биек түшәм астында чебен очса да ишетелерлек авыр тынлык урнашты.

Беренче булып тагын Чапкын морза телгә килде:

— Гөнаһсыз сабыйларны, хәлсез карт-корыларны залим дошман туена калдырыпмы?! Аларның гомере бәрабәренә ирек алыйкмы? — Аның куе, калын тавышында тимер чыңы яңгырый башлады, биек гөмбәз астында кайтаваз булып кабатланды: — Сабыйлар бәрабәренәме?..

Әле генә шомлы тынлыкка чумган ындыр табагыдай олуг бүлмә умарта күчедәй гөжли башлады.

— Качып киткән ил булмас, куркак егет ир булмас...

— Ажгырган айгырны өердә сына, мин-мин дигән егет не өендә сына. Өебездә сынатырбызмы?..

— Аягы яман түрне болгар, авызы яман илне болгар

— Үчен ирләрдән ала алмаган дошман Казанда бер җан иясен исән калдырырмы?.. Ипи тотып ант итәм, барысын кылычтан үткәрәчәк.

— Халыкны чыгара алмыйбыз. Ни генә кылсак та кулыбыздан килми...

— Тавыш! Туктагыз! Сабырлык! — дип кул чапты Ядегәр хан.— Бу тәкъдим белән керүчеләрнең гөнаһы үз намусларында калсын. Шулай да мин аны әйтеп бетерергә тиеш табам... Янәсе, мондый юл бар: кальганы ташлап чыккан гаскәр Япанча би атлыларына кушылып, бер йодрык белән урыска китереп бәрә...

— Һы! Кальгага кергән, кирмән ныгытмаларына поскан урыска бәреп кара аннан,— дип көлде кемдер.— Йөз илле мең дошманга без ике селтәнүгә дә җитмибез...

— Җәннәттән чыгып тәмугка кермиләр,— дип сәерсенеп җилкәсен җыерды икенчесе.— Кальгада чагында без — көч! Яланга чыксак, берәм-берәм тотып сыту чүпкә дә тормый. Монысы көн кебек ачык ич.

Саргәскәрләрнең аптырау катыш ачулы сүзләрен, тәкъдимнең ничек тәэсир итүен күреп канәгатьләнгән Ядегәр хан Кол Шәрифкә борылды.

— Изге Кол Шәриф хәзрәт! Диван әһелләренең синең фикерне дә ишетәсе килә булыр. Тыңлап багыйк!

Әле генә бер-берсен бүлдерә-бүлдерә шаулашкан морзалар мәмләкәтнең акыл иясе исеме чыгуга бердән тыелып калдылар, яңадан урыннарына утырышып, Кол Шәрифкә текәлделәр. Башына ак чалма чорнаган, килеш-килбәтеннән олпатлык, киң җилкәле таза гәүдәсеннән көч-куәт, куе калын кашлары астындагы күзләреннән акыл нуры бөркелгән бу кеше, әйтерсең, бөтен шик-шөбһәләрне берүзе хәл итә ала иде.

— Игътибарыгызга тәшәккер әйтәм,— дип башлады

Кол Шәриф ашыкмый гына.— Аңлавымча, диван дөрес юлда... Тәкъдим кертүчеләр уйлап әйткәнме, уйлап җиткермичәме — анысы миңа караңгы. Әмма бер нәрсәне ачык тоемлыйм, бу сүзләр астында яшерен хыянәт тоемлана, астыртын мәкер бар сыман... Яуга каршы торудагы иң зур өстенлегебез — таш кальганы калдырып китү, ул — шәһәрне урыска бушлай бирү дигән сүз. Беләм, кайберәүләр солых төзергә дә каршы түгелдер. Әмма алар бер нәрсәне оныта — Иван бу юлы солых төзүгә бармас. Теләсә дә бармаячак. Яшь хөкемдарның артында митрополит Макарий, аның иярченнәре тора. Алар ничә ел инде Иванны Казанга каршы котыртты, фәтва бирде, дөньялыкта ук изге пәйгамбәргә тиң зат булырсың дип күңеленә вәсвәсә салды. Шуның өстенә кенәзнең хөсетлеге, явызлыгы, мәкере җитәрлек, ул көч туплап килгән. Дөнья мәмләкәтләренең Казанга согылнуы, сәүдә юлларының Казанга илтүе аны көнләштерә, күзен кыздыра, көнчеллеге җанын яндыра. Шушы байлык тарта аны. Ач бүредән сарык мәрхәмәт көтә аламы?! Белегез! Урыс чирүе солых түгел, кан даулап килгән...

Кол Шәриф диван әһелләрен берәм-берәм күздән кичерде. Төпле, белекле затлар. Ни әйтергә теләвен ярты сүздән аңласылар. Аларга түгел, күбрәк Ядегәр ханга сөйләве белкеварның. Шәҗәрәсе аксөяк хөкемдарлар нәселенә барып тоташкан, гыйлемле, дәүләт идарәсендә, сугыш эшендә мәгълүматлы булса да, Казан тәхетендә әлегә тәҗрибә, салкын канлылык җитеп бетмәгән яшь, кызу егет утыра. Дөрес, диван әһелләре, саргаскәрләр ашыгып-кабаланып карар-фәрман чыгарырга ирек бирмәс. Әмма да ләкин олуг хан исеменнән халыкка әйтеләсе сүзгә хөкемдарның үзенең инануы, аны үз бәгырендә яралган татлы вә затлы кәлимә итеп кабул итүе кирәк. Шуңа тырыша Кол Шәриф.

— Бөтен мәмләкәт хакимнәренең күзе бездә — Казанда,— дип дәвам итте ул.— Сер бирмәскә, сәясәтләрендә сиздермәскә тырышып авызларына су капсалар да ләх тә, Ливония дә, Литва да, еракгагы швед та, мәгърибтәге башка дәүләтләр дә безнең җиңүне, урысның хурлыклы качуын тели. Безне сөймиләр. Диннәре башка. Әмма теләктәшлекләре безнең якта. Ни өченме? Сәбәбе, сере бик гади. Әгәренки нәфесе шашкан Иван Казанны буйсындыра калса, аның мин-минлеге котырачак. Бусы шиксез. Нәфесе Казан мәмләкәте белән генә чикләнмичә, канлы кулы алар ягына сузылачак. Урыснын золымын үзенә тартып торган Казанның җимерелүе алар өчен һәлакәт үк булмаса да,

фәлакәткә* тиң. Моны яхшы беләләр. Ярдәм итә алмыйлар, ә көтәләр. Алар әле бәлки Казан малын имеп симергән Мәскәү кенәзенә каршы торыр көч табар. Ә Казанга сыенып көн күргән, мәҗүсилектән чыгып та бетмәгән, курчакка табынучы ар, чирмеш, мукшы, башкорт, чуаш нишләр?' Бәгъзеләре сахраларга качар, бәгъзеләре урыстан мәрхәмәт сорап бил бөгәр, ярлыкагыл диеп хрәстиянгә баш орыр. Татарга үч итеп, Иван аларны сыендырыр, ташлама ясар, ясагын ким куяр. Әмма азга гына. Бераз күнектерүгә аларны да боргычлап сыга башлар.

Башка халыкны савып яшәргә күнеккән кавемнең рухы сына, табигате ялкаулана, мие сыеклана да үзен гали, бөек, асыл кавем дип исәңгери. Тирә-яктагы чынбарлыкны аермас хәлгә килә, ялган бөеклегеннән исереп яши. Андый халык сихере чыкмаган бер мәхлук кеби, аны айныту, дөньяга аек карарга өйрәтү кыен, ай-һай кыендыр.

Инде янә шунысын да фараз итик, Казан кеби көчле, шанлы, тамыры нык мәмләкәтне тар-мар китергән көч ургылып Идел буйлап китәр, Хазар, Азак, Кара диңгез ярларына таралыр. Ары таба — көн чыгышына таба тамыры нык мәмләкәтләр юк. Җәйрап ятучы сахралар, урман-күлләр, чәчәкле далалар бөеклектән исергән кавемнең бушлай табылган биләмәсенә әйләнер, типкелектән килгән мул рызыктан бу кавем котырып үрчер... Хәзергә без сан ягыннан бер чама. Тора-бара икеләтә, соңра өчләтә, янә дүртләтә кимербез. Коллыгыбыздан котылмасак, тора-бара бишләтә, алтылата... Шулай дәвам итәр. Иң яхшы угыл-кызларыбыз коллыктан котылу өчен хрәстиян кавеменә күчәр... Без шушыны телибезме?!

Кол Шәрифнең тавышы көчәйгәннән-көчәя, ул үзе инанган, танып-белгән, караңгы төннәрдә ялгызы калып газапланган уйларын, шик-шөбһәләрен барысын да бәйнә-бәйнә сөйләргә тели иде. Җан ачысы белән бәргәләнеп уйлану, кычкырып фикер йөртү иде бу.

— Мин борынгы бабаларыбыз — болгар, сувар, кыпчакларның тарихын өйрәндем, галәм агышында дәһшәтле гарасатларның кабатланып торуын беләм. Без шундый чорга кердек. Йолдызлар шулай күрсәтә. Изге дисбе шуны раслый. Ялгышаммы, дөрес сизенәмме — белмим. Әмма шунысы хак: халкыбыз киләчәктә дә хөр, азат калсын өчен безгә түземлек, түземлек, һәм тагын бер кәррә түземлек

* *Фәлакәт* — олуг афәт.

кирәк. Шунда гына җиңүгә ирешә алачакбыз. Бүген без урыстан көчсезрәк. Кырым, Әстерхан, нугай берләшә алмады. Хакыйкатькә күз йоммыйк. Бары тик түземлек, сабырлык, Казаныбызны бирмичә саклау бәрабәренә генә җиңүгә ирешә алачакбыз.— Ул бераз тын торды, нәрсәнедер әйтергәме-әйтмәскәме икеләнгәндәй талпынып алды да Ядегәр ханга карап тагын дәвам итте: — Инде боларын да әйтеп бетерим... Тар күңеллелек, куркаклык күрсәтеп дошманга бирелсәк, халыкка... бүгенгесенә генә түгел, киләчәгенә хыянәт иткән булырбыз. Йолдызлар белгертә: әгәр җиңелсәк, сугыш барган һәр көн ун ел коллык булып кире кайтачак. Бер көне — ун ел коллык! Аның ни китерәсен уйлыйк. Хөр күңелле, иректә яшәргә өйрәнгән казанлыларның рухы чыдармы, киләчәктә сарык хәленә төшмәсме?..

Юлыбыз бер генә — соңгы сулышка, соңгы тамчы кангача көрәш! Көрәш! Көрәш! Коллыкта яшәгәнче хөр яугир булып үлүең мең артык!

— Мең артык! Мең артык! — дип кабатлады диван әһелләре. Алар тылсымга бирелгәндәй Кол Шәрифнең һәр сүзен йотлыгып тыңлыйлар, ул әйткән һәр гыйбарәне күңелләренә беркетеп баралар иде, күрәсең.

— Тагын шунысы да мәгълүм булсын,— дип дәвам итте Кол Шәриф.— Казанда хыянәтчеләр калмады. Бүген соңгысы дошман чатырында кенәз Иван каршында тезләнде...

Белкевар сүзләрен әйтеп тә бетермәде, дисталәрчә бугаздан берьюлы нәфрәтле сорау ургылды:

— Кем? Кем ул?!

— Хыянәтченең исемен атап телемне пычратасым килми... Арагызда кем юк? Карагыз!

Диван әһелләре, сарай итагатен онытып, гаҗәпсенеп бер-берсенә караштылар.

— Камай морза!.. Әйттем исә кайттым, ул түгелдер ич,— дип шикләнеп кенә сорап куйды кемдер.

Кол Шәриф хәзрәт аның дөрес юлда икәнлеген раслап, керфек кагып куйды.

Сарайда бер көн эчендә инде ничәнче тапкыр авыр тынлык урнашты. Тәхет янында басып торган Ядегәр ханның кинәт йөзе агарды, ирен кыры тартышып куйды, Чапкынга борылды.

— Камай?! Камай! — дип кабатлап торды да кискен итеп сорады.— Җир асты юлын ул беләидеме?

Хыянәтнең бәһасын, кальгага янаган куркынычның дәһшәтен әле генә аңлап алган саргәскәрләр җавап көтеп Чапкын морзага текәлделәр.

Ул исә дистәләрчә карашның авырлыгын күтәрә алмагандай башын аска иде, маңгаен тотып уйга чумды, авыз эченнән нәрсәдер сөйләнеп алды һәм кинәт күзен киң ачып Кол Шәрифкә, Ядегәр ханга карады.

— Юк! Ул Камайга мәгълүм түгел иде.

Барысы да җиңел сулап куйдылар.

— Әгәр сез әйтмәгән булсагыз, мин әйтмәдем,— дип өстәде Чапкын морза.

Диван әһелләре тагын бер-берсенә караштылар. Чебен очарлык тынлыкта тагын Чапкынның сүзләре яңгырады.

— Телем йозакта калды... Көтмәгәндә чыгып дошманны таркатыр идек, дип ялан-ялан сөйләнүендә әллә нинди ясалмалык, гайре табигыйлек сизеп килдем. Ялгышмаганмын... Йа тәңрем, телемне тешләргә сабырлык биргәнсең, мең шөкер сиңа! Әмма шунысын да әйтми булдыра алмыйм, ул нидер сизенә иде кебек. Тәгаен белми, әмма сизенә иде...

Диван мәҗлесе тәмамланып кешеләр таралыша башлагач, Ядегәр хан сиздермичә генә Кол Шәриф белән Чапкын морзага ым какты. Бу аның: «Калып торыгыз»,— дигән аңлата иде.

Тәрәзә янына килеп бастылар. Кулларына Казан мәмләкәтенең язмышын хәл итү тапшырылган өч бөек шәхес бер-берсен сүзсез дә аңлыйлар, иңнәренә өелгән җаваплылыкның күтәреп булгысыз авырлыгын бик яхшы беләләр иде. Ядегәр ханнаң тавышы карлыгып чыкты:

— Хәзинә урнаштырылып беттеме?

Чапкын би җавап бирде:

— Кичә соңгы мичкәне төшердек. Казна буш!

Кол Шәриф исә сүзсез генә баш иде һәм бармаклары белән чигәсен угалап, арыган тавыш белән әйтеп куйды:

— Мәмләкәткә азатлык килмичә, Кабан серләрен беркемгә дә, беркайчан да ачмаячак! Хәзинә — Казанныкы! Аятелкөрси укып үзем юлга тәгаенләдем, фатиха бирдем. Фәрештәләр шаһит, күңелебездә, намусыбызда бер кәррә хөсетлек, нәфес вә комсызлык юк. Алла ярдәм итсен! Амин!

Өч хөкемдар изге сүзне кабатлап битләрен сыпырды.

Хушлашканда Ядегәр хан Чапкын морзага әмерен җиткерде:

— Хәзер инде ул юлның булмавы хәерлерәк. Ышанычлыларың белән чарасын күр! Казаннан чыксак, йә җиңүче булып, йә мәет булып кына чыгасы. Башка юл юк...

— Әмерең үтәлер, галиҗәнаб хан! Күңелең тыныч булсын!

Күзлеккә кереп баручы, язмышы кыл өстендәге шәһәр сугыш заманы кагыйдәләренә буйсынып яшәвен дәвам итте. Тагын бер көн узды. Сүрәнләнә башлаган кояш Ослан тавы ягына тәгәрәп, кургашындай авыр болытларны кан төсенә манчуга шәһәр урамнарына, мәйданнарга сөрәнчеләр чыкты. Сорнай кычкырта-кычкырта, казанлылар күңелендә өмет уятып, шик-шөбһәләрне таратып оран салдылар:

— Газиз кардәшләр, илдәшләр! Явыз дошманга каршы хәлиткәч яуга күтәрелик! Һәр өй кальга-кирмәнгә, һәр ишегалды ныгытмага әйләнсен! Кулына корал тотардай ир заты мәмләкәткә куркыныч янаганда көтеп ятырмы?! Барыгыз да коралга! Яуга! Изге газаватка!

Шәһәр төн пәрдәсен ябынды. Әмма ул йокламый, ялны белми. Мәйданнарда, остаханәләрдә учаклар дөрли. Тимерчелек һөнәреннән азмы-күпме хәбәре булган һәр ир заты сөңге очы чүки, ук ясый, кылыч коя. Хуҗалыктагы һәр тимер кисәге исәптә, һәр бакыр йә җиз гөрзи-чукмарга әверелә.

Кальга тышында һәр дүрт тарафта шомлы ялкын уйный. Яңа көч алган, камау башланганнан бирле беренче кат лыкынганчы ашаган тук дошман гаскәре бәйрәм итә, кальганың биек диварларына ташланып үҗәт татарны изепсытар мизгелләрнең якынаюын көтеп исерткеч ләззәттә йөзә.

Сызылып таң атты. Тәрәзә капкачындагы челтәр бизәкләр аша кояш нурлары Сәетнең күзенә төште, аны уятырга теләгәндәй, керфекләрендә уйнаклады.

Башы чуенга әйләнгән, газаплы уйларыннан таң алдыннан гына черем итеп алган Сәетнең торасы килми, дәһшәтле чынбарлыкны куасы, яңадан тыныч көннәргә кайтасы иде бит... Юрганыңны ябын да онытыл иде. Дошман явы да, күңелне кыйнаган, үртәгән шик-шөбһәләр дә бетсен, таралсын иде. Их, ничекләр матур, мәгънәле яшиләр иде бит! Улы Җәгъфәрне бер чибәргә өйләндереп, Галиясен батыр угланга кияүгә биреп, ил агасы булып кына йөрер чакларда...

Галиясе искә төшүгә ятагыннан сикереп торуын сизми дә калды. «Ул балага ничек ярдәм итәргә соң?! Нинди могҗизалар табарга?!»

Җилкәсенә тунын салып, аш бүлмәсенә чыкты. Гөлйөзем анда иде инде. Хатынының суырылып калган йөзенә, күз төпләрендәге шәмәхә күләгәләргә Сәет беренче тапкыр күргәндәгедәй сәерсенеп карап куйды. Сыек яшел төстәге яу-

лык бөркәнгән Гөлйөзем бүген икенче төрле, башкача, яңа, ча күренә, гадәттәге Гөлйөзем түгел кебек иде. Яулык аның муенын, маңгаен күренмәслек итеп каплаган, ияк астыннан тыгыз итеп бәйләп куйган. Моны күрсә дә Сәет аның сә бәбен сорамады, тел очына инде атна буе борчыган сөаль килде·

— Ничек? Хәле җиңеләймиме?

Гөлйөзем авыр сулап баш селкеде.

— Ничекләр җиңеләйсең?!. Су урынына агу эчергәч

Сәетнең җилкәләре бөрешеп, тараеп калды, гәүдәсе сы гылып төште сыман.

— Бигрәкләр дә нәзберек зат шул! Ниләр генә кылыйк?!

Һөҗүм башланган көннән ир белән хатын арасына кара күләгә ятты. Дөрес, Гөлйөзем теле белән бернәрсә дә әйтми, элеккечә кайгыртучан, ягымлы ана, тугрылыклы, эшчән хатын булып кала белде. Әмма күзләр!.. Күзләр башка... Алар хисләрне яшерә алмый. Озын керфекләр артына качкан җан көзгесе барын да әйтә, сөйли, җавап сорый, Сәеттән тәвәккәллек, ирлек таләп итә иде. Элек аның күзләренә багып, аларны сихри күлгә охшатып, газизенең җан җылысында коенырга яраткан Сәет, хәзер аңа туры карый алмый Әрнүне, газапны, юк, юк, аларны гына түгел, әнә шул таләпне күрәсе килми аның.

Чишмә шартлатылып, өйдә тамак чылатырлык та чиста су калмагач, Гөлйөзем тагын үз эченә бикләнде. Аның ни өчен алай итүен яхшы, үтә яхшы аңлый иде Сәет. Әмма үзе белән берни дә эшли алмый. Идел төбеннән балыкчы карт тартып чыгаргач биргән анты исенә төшә: гомеремдә кулыма корал алмам, кеше җанын кыймам дигән иде Гомере буе антына тугрылыклы калды лабаса!

Хатынына күтәрелеп карамыйча Галия бүлмәсенә кереп китте. Кыз уттай яна. Иреннәре чабырып, яргаланып беткән. Юрган өстенә чыккан нәзек куллары тагын да нечкәреп калган, юка тиресе аша кан тамырлары зәңгәрләнеп күренә. Йөзенә, тәненә хаста сарылыгы иңгән. Сәет үзен белештермичә җан ачысы белән иңрәп эндәште:

— И кызым, кы-з-ы-ы-ым!..

Ата кеше бармаклары аша аңа көчен, сәламәтлеген бирергә теләгәндәй кулын кызның маңгаена куеп торды. Юк! Булмый! Кешегә андый көч, сәләт бирелмәгән.

Менә Галиянең күзләре ачылды, атасын танып, елмаерга итте. Әмма ул елмаю түгел, ә газаплы, интегүле бер ымга охшаган иде.

— Су, су-у...— диде кыз кипшергән иреннәрен ялап.

— Хәзер, хәзер, кызым. Әнием керә.— Ишеккә борылып эндәште: — Сиңа әйтәм, Галия уянды. Су сорый. Су керт!.. Әмма үзе өйдә бер йотым чиста су булмаганны бик яхшы белә иде. Яңгыры да яумый бит ичмасам!

Коточкыч ул көн искә төшкән саен бик күпләр дертләп, саташып уяна. Сәет тә шулай. Сугышның тынып, камау һөҗүменең туктабрак торган бер мәле иде ул. Кинәт аяз көнне күк күкрәде, Таһир манчасы ягында берьюлы меңнәрчә яшен ташы атылды, күккә ут ургылды, диварның бер өлеше ялкынга уралып болытларга менеп китте. Таш, тузан өермәсе купты. Күз ачып йомганчы булган бу мәхшәрдән кешеләр телсез калды, шартлау дулкыны аларны аяктан бәреп екты. Тагын берничә мизгелдән күктән олы-олы ташлар, бүрәнәләр, балчык кантарлары ишелеп төште. Күпләр аның астында калып әҗәлен тапты.

Күп тә үтмәде, ишелгән койма ягында дошман гаскәренең канны бозга әйләндерерлек дәһшәтле авазы яңгырады, кырны тутырып, ачудан йөзләре кыйшайган меңнәрчә сугышчылар агыла иде. Әгәр дивар өстендәге татар гаскәре, каладагы барлык ир-ат тиз арада һушына килмәсә, моның ничек бетәсен әйтү кыен иде. Ләкин казанлылар тиз айныды. Убылып күккә очкан җимерек дивар аша беренче урыс сугышчылары күренүгә, мәхшәр онытылды, җирдә иң газиз нәрсәсен — хөрлеген, туган җирен яклаган пәһлеваннар ташкыны күкрәге белән ачыклыкны каплады. Урыс чигенде. Ашыгыч төстә диварны ямадылар, урыс уклары астында бүрәнәләрдән яңа ныгытма корылды, ике арага таш, балчык, ком тутырылды. Барысы да яңадан үз урынына кайтты. Бары тик камау газапларын авырлыксыз, сусауны белмичә күтәреп барырга ярдәм иткән бердәнбер чишмә генә күмелеп җир астында калды.

Галиянең хасталыгы шуннан. Ничә көн, ничә төн казып шәһәр кешеләре сасы сулы бер генә чыганак таба алдылар. Кальгада сусызлык башланды, яман су эчүдән чир таралды. Су түгел, эрен иде, үлек су иде ул.

«Юк! Алга таба болай яшәп булмый. Берни кылмыйча, ни килгәнен көтеп яту, күз алдында газиз кызың, җаныңнан өзелеп төшкән, тәнеңдә синең каның аккан баланы үлемгә дучар итү үзе үк антыңа хыянәт түгелме соң? — Сәет авыру янында үз-үзен белештермичә сөйләнде дә сөйләнде.— Балыкчы карт, син, игелек күрсәтеп миңа яңадан тормыш биргән изге карт, син нишләр идең? Яуда йөреп балаларыңнан, хәләлеңнән мәхрүм калган кеше, син, ни киңәш итәр идең?!

Яуда катнашу гөнаһ, беләм. Илеңә дошман килгәндә катнашмау — тагын гөнаһ. Әллә соң шул гөнаһлар өчен җавапны адәм баласыннан дөньялыкта ук алалармы? Әҗере авыр, ай-һай, авыр икән!..»

Кылт итеп исенә Кол Шәриф хәзрәтләре төште. «Ул ни әйтер иде икән?! «Мөселманлык шәфкатьле һәм мәрхәмәтле, бөек һәм бердәнбер Аллага табыну ысулы гына түгел, ялгышма, ул яшәү рәвеше, ул тормышның үзе»,— дигән иде түгелме соң изге Кол Шәриф? Казанлылар пәйгамбәргә тиң күргән зат! Әйтче миңа, бу сугышта катнашу — антымны бозу буламы? Карындашым урыс белән кан коешу миңа лаземме? Лазем булса, аны ничек аклармын?.. Хак дин — ислам дине, дидең. Әмма хак тәгалә ялгышкан угыллары урысларга да мәрхәмәт итә ич. Монысын ничек аңларга?! Бер яктан да катнашмый, ни язганын сабыр гына көтеп тору дөресрәк түгелмени соң, и изге Кол Шәриф. Җавабын син генә беләсең... Бәлки, болар миңа кылган гөнаһларым өчен җибәрелгән җәзадыр???»

Кинәт Сәетнең күз алдындагы томан таралды, әйтерсең, тәрәзә капкачларын берьюлы ачып җибәрделәр, бүлмәне нурга манчып күз камаштыргыч аклык пәйда булды. Түр башында сәетләрнең сәете Кол Шәриф хәзрәтнең яшел чапанга төренгән мәһабәт сыны басып тора иде.

— Ялгышасың, улым! Ялгышасың! — диде салмак, сабыр тавыш.

Сәетнең аяк бармакларына хәтле бөтен тәне чымырдап китте, кычкырып җибәрмәс өчен шытырдатып тешләрен кысты, кулларын кушырып тораташтай катты да калды. Күз алдында Кол Шәриф сыны балыкчы картныкына әйләнде, ул сөякчел бармакларын Сәеткә таба сузып, үпкәле, рәнҗүле тавыш белән эндәште:

— Куркак икәнеңне белгәнче, судан тартып чыгармаган булсамчы!..

— Куркак түгел! Курыкмыйм, вөҗданым кушмый,— дип илерде Сәет.— Туганнарыма кул күтәрә алмыйм. Аңла!..

— Туганнарың бәйләп көймәгә салмадымы?! Килеп янамадыларамы?!. Улыңның җанын кыймас иделәрме? — Балыкчы картның тавышы калтырый башлады, ак киндер күлмәкле озын сын тагын томанга төренеп югалып килә иде.

— Тукта! Тукта! Китмә! Аңлат, нишлим,— дип пышылдады Сәет балыкчыга омтылып. Ләкин гәүдәсе тыңламады, аяклары буйсынмады.— Әйт, зинһар, ни кылыйм? Әллә үземә кул салыйммы инде...

Томан эченнән зәгыйфьләнгәннән зәгыйфьләнә баручы өн килеп җитте:

— Күңелеңә кем якынрак, шулар ягына бас! Башкасын белмим. Ни-нәрсә хакына Казанга килгәнеңне онытма. Оны-ы-ыт-ма-а!..

Икенче караштa балыкчы карт урынында яңадан Кол Шәриф иде инде. Ул иреннәрен кысып, сүзсез генә башын чайкады, Сәетнең уйларын хуплагандай елмайды да ашыкмый гына әйтте:

— Гаделлек ягында булсаң, беркайчан да ялгышмассың. Гаделлек кем ягында? Уйла! Миннән фатиха! Фатиха-а, улым!

Сәет күзләрен уды, авырта башлаганчы почмакка карап торды, әмма анда беркем дә, томан да, ак пәрдә дә юк иде инде. Кинәт җиңел сулап куйды, бөтен гәүдәсендә, аяк-кулларында сәер бер җиңеллек барлыкка килде, үзен унҗиде яшьлек егетләрчә җитез, көчле, елгыр итеп тоя башлаган иде ул. Иреннәре бертуктаусыз «Изге Кол Шәрифтән, балыкчы карттан атиха! Алар мине яуга өнди, гаделлек ягына басарга чакыра»,— дип пышылдый иде.

Атналар буе йөзеннән китмәгән караңгылык, кайгы ни эшләсен белгән батыр ирләрдә генә була торган кискенлек белән алышынды, күзенә элеккеге нуры кайтты.

Шул мизгелдә урамда атлылар чабышканы ишетелде. Тояк тавышлары йөзләрчә думбакка бәргән ешлык белән тар урамнарда, тыкрыкларда бәргәләнде.

— Яу килә! Яу! Батыр ирләр, куркусыз егетләр! Яу килә. Барыгыз да коралга! Изге калабызга афәт яный...

Утыз дүрт яшендә хәлсез картка әйләнә башлаган һәм кинәт, күз алдында яңадан унҗиде яшьлек халәтенә кайткан Сәет каударланып чоланга ташланды.

— Тизрәк, тизрәк! Моңарчы кул кушырып ятканның үчен бүген чыгарырга! Бүген ак көнем, пакь көнем. Фәрештәләр дөрес юл күрсәтә.

Биленә хәнҗәр, кылыч тагып чыкканда чак кына Гөлйөзем белән маңгайга-маңгай бәрелешмәделәр. Хәер, бу Гөлйөзем түгел, ә аңа бер тамчы судай охшаган чибәр яугир егет иде. «Чү! Күземә күренәме соң әллә?» Сәет гаҗәпләнүеннән чак кына кычкырып җибәрмәде.

— Син?! Гөлйөзем! Нишлисең?

Гөлйөзем озын толымнарын кисеп ташлаган, өстенә Җәгъфәрнең киемнәрен кигән, биленә кыска хәнҗәр таккан иде. Ул еш-еш сулап Сәеткә текәлде һәм кинәт балаларча ачылып, иренең кочагына ташланды.

— Ак канатым!

Ул башка бер сүз дә әйтә алмады, Сәетнең күкрәгенә капланды да тынды. Җилкәләренең калтырап-калтырап куюыннан аның тыела алмыйча, җан ачысын чыгарып тавышсыз гына елаганын Сәет күптән аңлап алган иде инде. Үзенең дә күзләренә яшь тыгылды, аркасыннан назлап сөясе, битеннән, маңгаеннан, кайнар иреннәреннән шашып үбәсе килде. Әмма тыелып калды, кысып кочаклады да хатынны читкә этәрде.

— Гөлйөзем! Син йөрмә! Җәгъфәр белән без китик! Шулай яхшырак булыр...

Кинәт Гөлйөземнең йөзенә кискен кырыслык чыкты, кул аркасы белән яшьләрен сөртә-сөртә өздереп әйтте:

— Юк, Сәет! Мин өйдә ята алмыйм. Тупчыларга ярдәмчеләр җитми, ди. Икесенең берсе йә яралы, йә үле. Мин анда барам!..

Сәетнең сулышы кысылды, ни әйтергә белми аптырады.

— Ә Галия? — дип куйды ул кара коелып.

— Мин табиб карчыгы белән сөйләштем. Ул кереп утырыр... Борчылма...

Сәет Гөлйөземнең үҗәт үсмер егетләрнекенә охшап калган йөзенә карап аптырау катыш соклану белән елмайды да, сүзеннән кире кайтмаячагын аңлап, кул селтәде.

— Аллага тапшырдык!..

Урамга чыгуга, аларны кораллы халык агымы бөтереп алып китте. Аяк астында җирне тоймый йөгергән Сәет сугышчылар арасында ирләрчә киенгән кызларны, яшь хатыннарны абайлап өлгерде. Ул күзләре белән Гөлйөземне эзләде, аның белән хушлашырга, дәртләндереп кул изәргә тели иде. Әмма таба алмады. Күрәсең, алар кала туплары куелган манараларга таба чапканнар иде инде. Бераздан аны атлылар төркеме куып җитте. Шактый сирәгәя төшкән нөгәрләр алаенның башында Алмачуарны иярләгән Җәгъфәр сызгырып узды. Сәетнең бугазына кайнар төер тыгылды, күзе яшьләнде. Ләкин ул моны тоймый, ат өстендә коеп куйгандай утыручы улына сокланып елмая, үз-үзен белештермичә ярсып кычкыра иде:

— Алга, туганнар, алга!

* * *

Василий ябыкты, яңаклары эчкә батты. Суырылып калган йөзендә ачулы ут булып зәңгәр күзләре яна. Иван сәүдәгәр сүзенә алданып, аның колына әверелеп ут эчендә калуына эче пошты, кат-кат үзен тиргәде, әшәке сүзләр белән сүкте.

Камау озакка сузылды. Эссе җәйдә юлга чыккан гаскәргә кием җитми. Көндезләрен әле түзәрлек, төннәрен исә кырау төшә, тиргә, суга манчылган киемнәре иртән торганда шыкранлапката.

Учак өстендә күшеккән кулларын җылытып утырган җиреннән Василий тагын эчтән генә сүгенеп куйды:

— Алырсың бу Казанны! Тот капчыгыңны, әзерләп куйганнар ди. Чишмәләрен шартлаттык, убылган дивардан шәһәргә күпме гаскәр ургылды. Шунда да нығып кала алмадылар. Татарлар барысын бергә кысрыклап, изеп чыгарды.

Уйга бирелеп, җиңенең көя башлавын да сизмәгән икән. Борынына янган постауның әчкелтем исе бәрелгәч кенә, кулларын ялкын өстеннән тартып алды, җиргә суккалап, утны сүндерергә кереште. Тагын бер кат әче итеп сүгенеп куйды. Аның үтереп йокысы килә, Санька өендәге мамык түшәкләр җәелгән ятакны күз алдына китерә. Әгәр анда барып әләксә, бернигә карамыйча өч көн, өч төн рәттән йоклар иде, колак төбендә туптан атсалар да тормас иде...

Үзе дә сизми: энесенә булган ачу, нәфрәт акрынлап кызгану хисе белән алышына бара. Чибәр Гөлйөзем, зифа сынлы бүз углан Җәгъфәрне күз алдына китерә дә тыела алмыйча сыкрый башлый. Аларның да гомере киселерме?! Чыннан да, Иоанн Васильевичның нәфрәте шул кадәр көчлеме, усаллыгы, җаһиллеге чиксезме?! Бөек кенәзнең өлкән воеводалардан соңгы олаучыга кадәр җиткерелгән фәрманының һәр сүзе миен көйдереп ала. «Казанда бер генә татар җаны да калмаячак. Бар йортлар, кибетләр — бар байлык сезнеке, алтын-көмеш, мал-туар сезнеке. Кемне кулга төшерсәгез — ул сезнеке. Барысы да өч көнгә сезнең ихтыярга бирелә. Яшь кызлар, киленнәр — җария, кәнизәк, угланнары кол булыр. Тездән югары һәр ир заты кылычтан үтәр... Татарның тамыры корысын! Әмерем шундый. Казан җире мәңгегә урыс җиренә әйләнер».

Онытылып утырган Василий урман ягыннан шаулап чаптырып килүче атлыларны күреп сискәнеп китте. Алар бер төркем татар сугышчысын куалап киләләр иде. Мәҗрух-

ларның кулларын алга кушырып бәйләгәннәр, озын арканнар кылдай тартылган. Атка җитешә алмаган тоткыннар тузанлы юлга барып төшә дә капчык шикелле сөйрәлә. Егылмаганнары аларга ярдәм итә алмый, тешләрен шыгырдата-шыгырдата, еш-еш сулап чаба бирәләр. Тирә-яктагы гаскәриләр аларны үртәп кычкыра, камчы белән мал куалагандай мәҗрухларның сыртларын каезлый.

«Араларында Санька юкмы? Җәгъфәр эләкмәгәнме?!» Василийның миен шундый уй яндырып узды. Йокысызлыктан шешенгән, кызарган күзләре тоткыннар арасыннан таныш чалымнар эзләде.

Кемдер кычкырып боерык бирде. Атлылар учак яныннан шаулашып уздылар да Мәскәү гаскәре ныгытмаларының алдына чыгып туктап калдылар. Каяндыр озын бүрәнәләр сөйрәтеп китерделәр. Аларны очлы башлары белән көзге яңгырдан йомшаган сыек җиргә кага башладылар. Менә бер-берсеннән өч-дүрт терсәк чамасы ара калдырып җитмешләп казык кактылар. Казыклар янына тоткыннарны алып килделәр дә йөзләре белән Казанга каратып, аларны бүрәнәләргә каерып бәйләргә тотындылар.

«Аңлашылды! — дип уйлап куйды Василий.— Урыс гаскәренә татарлардан тере калкан ясыйлар. Иоанн Васильевичның башы йомры...» Тагын шунысын да абайлап өлгерде, кирмән өстендәге татар сугышчылары да бу аңлаешсыз эштән хәйран калган иде булса кирәк. Аларның сүзсез-өнсез карашы, тавышсыз нәфрәте кемнең дә күңеленә шом салырлык куркыныч, дәһшәтле иде. Бер мизгел эчендә барысын да канлы измәгә әйләндерә алырлык дәһшәтле көч берни дә эшли алмый, газиз туганнарының хурлыклы түбәнлеккә дучар ителүен карап торырга мәҗбүр иде. Әсирләр тавышсыз гына каршылык күрсәтте. Әмма авызларыннан ник бер ләгънәт, бер үтенү, ялыну-ялвару чыксын! Алар горур иде. Карашларын яшермичә, үч һәм нәфрәт кайнаган күзләрен дошманнарына туп-туры төбәп тордылар. Казыкка каерып бәйләнгән кулларның сөякләре шыгырдады, яраларыннан тамган каннан җир өсте ал төскә манчылды.

Менә, ниһаять, соңгы мәҗрухны — егылып, арканда өстерәлгән яшь егетне сөйрәп алып килделәр. Аның хәле юк, аягында басып тора алмый иде. Өч-дүрт гаскәри казык янына бастырмакчы булып иелүгә, егет авыртуын җиңеп сикереп торды да эре адымнар белән казык янына килеп басты, кулларын артка сузды. Ул иреннәрен тешләгән, иягенә нечкә җеп булып кызыл кан ага иде. Кан тамчыла

ры аның түшенә, күлмәк изүенә төште, күз алдында ак тукыма буй-буй бизәк белән капланды.

Үзе дә белми, нишләптер, Василий аны Җәгъфәргә охшатты. Шундый ук яшь, чибәр, тормышның чын тәмен дә татып өлгермәгән бүз углан иде ул. «Ә бит аның урынында Җәгъфәр булырга да мөмкин иде! Бәлки инде ул дөньяда юктыр. Дошман угыннан егылып җан биргәндер. Санька белән Гөлйөзем ут йотып аны көтәләрдер... Эзлиләрдер...» Василийның тәне тартышып куйды, үле Сәетне, яраланып ауган Җәгъфәрне, яшьләренә буылган Гөлйөземне күз алдына китерде. Аның күңелендә кайчандыр үзе ләгънәтләгән якыннарына бер кәррә дә дошманлык юк иде. Аның урынын кызгану, вөҗдан газабы биләп алды. Аларны ни көткәнен, Казан алына калса, ниләр буласын яхшы белгән Василий күңел тынычлыгын югалтты. Тешләрен шыгырдатып кенәз каршында җирдә аунаса да, чәчләрен йолкып үрсәләнсә дә, ул аларга берничек тә ярдәм итә алмаячак. Монысы шиксез!

Шулчак көтелмәгән хәл булды. Егет күзләрен зур ачып карап торды да авызындагы канлы лайланы лач итеп каршындагы сугышчының йөзенә төкерде. Анысы бер адым артка чикте, җиңе белән битен сөртә-сөртә яралы ерткычтай үкереп кылычына ябышты.

— Ах син, хәшәрәт, татар калдыгы... Сытам!..

Ул кизәнеп сугарга өлгерми калды, янындагы воевода аны кискен җикереп туктатты.

— Артка! — һәм, сугышчының ярсуын басарга теләп булса кирәк, акрын гына өстәп куйды: — Әле вакыты җитмәгән... Ашыкма!..

Монда ниндидер сер, мәкер бар иде, ахрысы. Юкка гына мәҗрухларны ныгытма каршына чыгарып тезмәгәннәрдер!.. Василий шуларны уйлап куярга өлгерде.

Озак көтәргә туры килмәде. Бер төркем воевода атларын уйнатып мәҗрухлар сафы алдыннан үттеләр дә чаптырып кала диварлары ягына китеп бардылар. Бераздан аларның кирмән өстендәге кешеләргә кычкырганы ишетелде:

— Казанлылар! Безнең сүзгә колак салыгыз! Иоанн Васильевич әгәр аңа буйсынсагыз, шәһәр капкаларын ачсагыз, бу тоткыннарга тормыш вә ирек, ә сезгә шәфкать һәм мәрхәмәт вәгъдә итә. Дошманлыгыгызны ташлагыз! Бөек хөкемдар олы җанлы, ул барыгызны да гафу итәр...

Воеводаның калын тавышы тынып калган мәйдан өстендә кайтаваз булып яңгырады:

— Га-а-фу-у и-и-тә-ә-әр...

Кинәт урыс ныгытмалары ягыннан ургылган көчле аваз воеводаның тавышын күмеп китте:

— А горур казанлылар! Алданмагыз! Нәҗес кяфер сезне тозакка төшермәкче. Явыз хрәстиян кулыннан үлгәнче, үзебезнең саф мөселман кулыннан шәһит китүебез мең артык! Урыныбыз җәннәттә буласы... А горур казанлылар! Соңгы мәрхәмәтегездән ташламагыз — атыгыз безгә ук! Үлик саф мөселман кулыннан! Урыс астында кара кол булганчы, үлүең мең артык. Алданмагыз! Алданмагыз!

Сугыш кырында үле тынлык урнашты. Кальга өстендәге гаскәриләр югалып калды, аларның бер-берсенә иелеп нидер сөйләшүе күренде. Казанлылар нәрсәдер киңәштеләр, аларның икеләнеп калганы ачык сизелә иде.

Баганаларга бәйләнгән тоткыннар тагын барысы беравыздан кабатлады:

— Алданмагыз! Безне барыбер газаплап үтерәселәр. Укларыгызны да, безне дә кызганмагыз. Атыгыз! Пычрак кавем корбаннары буласыбыз килми.

Воевода тагын үзенекен кабатламакчы булып авыз ачуга, әсирләр барысы берьюлы кычкырырга тотындылар:

— Алданмагыз! Алданмагыз!

Һәм, ниһаять, казанлылар нәрсәдер хәл итте булса кирәк, кирмәннең буеннан-буена ук-җәяле ирләр чыгып басты, алар күзгә күренмәгән кемнеңдер әмеренә буйсынып, барысы берьюлы укларын күтәрделәр. Бер үк мизгелдә җәя баулары зеңләде. Казыкларга бәйләнгән йөзләгән мәҗрух үз туганнары кулыннан үлем кабул итте. Канлы урыс кылычын, әсирлек түбәнлеген алар шулай кире какты.

Яу кырында үлем газабын, михнәтен татыган гаскәриләр бер мәлгә тын калды, бераздан меңнәрчә бугазлардан берьюлы ургылган оран күкләргә очты. Татар әсирләренең үлемне өстен күрүе, горур батырлыгы аларны таң калдырды.

Ә Василий сынын тота алмады, сыгылып төште. Дошманының битенә кан төкергән яшь егет күз алдында иде әле. «Юк! Мондый халыкны җиңеп булмый. Җиңелсә дә, ул баш бирмәячәк, тезләнмәячәк, кол булмаячак!» Миендә инде ничәнче кат шушы фикер бәргәләнде. Ашыгып чатырга атлады. Аңа ялгыз калырга, уйлаганын, ниһаять, эшкә ашырырга кирәк иде.

Ул калтыранган кулларына кәгазь алды, кауры й каләм-

не үткен пычагы белән очлап карага манды, ашыгып язарга тотынды. Теләсә-кайсы мизгелдә сәүдәгәрләрдән йә сакчылардан кем дә булса килеп керүе бар... Йөрәге шашынып типте. Туган кавеменә хыянәт итүен дә аңлый иде ул, ләкин белә, шушы адым һәр ике якка хөрлек китерәчәк, Василийның үзен дә, туганнарын да пычрак хурлыктан коткарачак.

Башы котырып эшли, уйлаганын хәзер үк башкармаса, икеләнәчәген, туктап каласын сизенә һәм.. аның ничек тәмамланачагын күз алдына китерә алмый иде. Ашыгып чатырда эзләнергә кереште. Түр почмакта кемдер онытып калдырган садак* белән җәя күргәч, күз аллары яктырып китте. Язмыш үзе үк аңа ни эшләргә кирәген күрсәтә түгелме?! Почмакка сикерүен, кулына җәя алуын сизми дә калды. Ук сабына хатны урап, тарттырып бәйләде дә тышка атылды. Кеше-кара күргәнче кальгага якынрак килергә, хатны аткарырга! Аннан соң барысы да язмыш иркендә... Һәрхәлдә, кулымнан килгәнне эшләдем, дип җаным тынычланыр.

Ул тирә-ягына каранды. Бәхетенә, якында гына беркем дә юк иде. Укны җәягә куеп киерелеп тартты да атып җибәрде. Ялгыз ук һаваны ярып айлы манаралары балкыган, җимерелсә дә тезләнмәгән якты калага очты.

Өстеннән авыр йөк төшкәндәй җиңеллек килде. «Хәзер менә Санька каршында намусым чиста! Кулымнан килгәнне эшләдем. Ак йөз белән каршына чыга алам»,— дип уйлап куйды Василий һәм соңгы көннәрдә беренче тапкыр үзендә җиңеллек, рәхәтлек тоеп кире чатырга таба атлады. Әмма ерак китә алмады, каршына чабып килүче гаскәр агымы аны бөтереп алды. Ниндидер воевода кылычын болгап усал итеп кычкырды:

— Кая барасың?! Борыл!.. Алга диләр сиңа! Алга! Анаңны ач этләр талагыры...

Василийга башка чара юк. Каршы килсә, котырынган воевода кылыч белән чабып үтәргә дә күп сорамас. Ул кулын селтәде дә гомуми ташкынга кушылып алга йөгерде. Бар нәрсәне изеп, сытып килгән укчылар арасыннан аңа артка таба юл калмаган иде инде.

Казанның киереп ачылган капкаларыннан татар гаскәре ургыла. Тимер киемнәргә төренгән сугышчылар арасында гөрзи, сөңге тоткан шәһәр кешеләре, әле мыек та чыгып

* *Садак* — ук савыты.

җитмәгән яшүсмерләр, иреккә чыгарылган коллар бар иде. Алар барысы беравыздан урыска аңлашылмый торган дәһшәтле сүзләр кычкыралар, ул исә сугыш авазы булып тоела иде:

— Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр, лә-илаһе иллалла!

Дәһшәтле авазлардан Василийның каны бозга әйләнде. «Беттем! — дип уйлады ул. — Шушы бәрелештән исән чыксам, ныгытмалар янына якын да килмәс идем». Тагын берничә мизгелдән ике агым бергә кушылыр, бугазга-бугаз килер, очлы кылыч, үткен сөңгеләр кемнәрнеңдер җылы тәннәрен тишеп үтәр, кара җир өстенә кайнар кызыл кан елгасы агар. Үзенең хөрлеген, туган җирен, изге каласын, динен вә денен, балаларының киләчәген саклау, яклау өчен күтәрелгән татар гаскәрен туктатыр, артка алып ташлар көч юк иде инде.

Кол Шәриф ике кул яссуы чамасында калган тишеккә соңгы кирпечне урнаштырды, сыгылып чыккан измәне калагы белән кистереп алып ташлады да кулларын киндер алъяпкычына сөртә-сөртә бер читтәге тәбәнәк урындыкка барып утырды. Инде тынычлап ял итәргә дә була. Китап йортының иң асыл хәзинәсе тупланган мәгарәгә төшү юлы калын дивар артында калды. «Саклаганны саклармын дигән!» Ул үз эшенә тагын бер кат сокланып карап куйды. Кирпечләрнең әле яңа гына салынганы искеләреннән берни белән дә аерылмый, шундый ук төстә, шундый ук тәртиптә тезелгән иде. Моның серен Кол Шәриф үзе генә белә. Шәкерт-таләбәләрдән иске ташлар, кирпечләр ташытты, тиз ката торган үзле измәне исә агач ялгашларда иренмичә үзе болгатты. Казан мәмләкәтенең, укымышлы затларның гына түгел, Казан халкының иң зур байлыгы, борын-борыннан килгән хәзинәсе — рухи хәтере ышанычлы урынга яшерелде. Алдагы көннәрдә ни буласын тәгаен гына беркем дә белми. Моны хәтта Кол Шәриф үзенә әйтергә дә шикләнә. Әмма киләчәк көннәргә, галәм агышына күз салырга акыл куәте җиткән изге зат Казанга кара көннәр якынлашуын шактый ачык тоемлый иде.

Кирпечне өеп бетергәннән соң ул тузандай вак ком белән бөтен диварны тоташ эшкәртеп, бер кат каплатып чыкты. Иң тәҗрибәле оста ташчы да монда кайчандыр ишек булган дип әйтә алмас иде. Төргәк-төргәк калын кулъязмалар, чөй язулы таш такталар, җиз дисбеләр, көмеш каптырмалы, тышлары асыл ташлар илә бизәлгән китаплар — барысы да якты көннәр килгәнчегә кадәр ыша-

нычлы урында саклаңыр. Дистәләрчә буыннарның күз нурын түгеп, берәмләп, бөртекләп җыйналган асыл хәзинәгә бер генә кәррә дә куркыныч янарга тиеш түгел.

Утырып хәл алгач, Кол Шәриф хәзрәт китап йортының ишегалдына чыкты. Анда беркем дә юк иде. Шәкертләр, хәлфә-мөгаллимнәр — барысы да гаскәр арасында. Гыйлем җыясы, киләчәктә мәмләкәтнең рухи байлыгын үстерәсе, аны янәдән яшь буыннарга тапшырасы яшьләрне ничек кенә сакларга теләмәсен, Кол Шәриф аларны Казанны як ларга җибәрмичә булдыра алмады. Хәер, коточкыч һәлакәт янаган көннәрдә аларны халык арасына җибәрмәсә, ул аларның күзенә туры карый алмаячак иде. Монысын бик яхшы, үтә яхшы аңлый иде сәетләрнең сәете.

Кала өстендә туплар гөрселди. Һәр ике яктан сызгырып авыр ядрәләр оча. Казан җимерелде, ай-һай, нык җимерелде. Калын ташпулатлар элегә түзә, ә агачтан җиңелчә итеп, бизәп, челтәрләп чалынган нәфис йортлар бетте, пыран-заран килде, янды. Еракта казанлыларның тәкбир әйткәне ишетелде, урыс гаскәренең кыргый улауга охшаш ярсулы өне килеп җитте. Ныгытма кырыенда каты бәрелеш, канлы дау бара. Шәһәр урамнары буш. Олысы-кечесе, яшекарты, кулына корал тотардай хәле булган һәммә кеше кирмән өстендә. Казанның язмышы шунда хәл ителә. Берәүләр, көченнән килгәнчә, гаскәргә ярдәм итә, икенче берәүләр җимерелгән диварларны ямый, таш, ком, бүрәнә, балчык ташый, өченчеләр яралыларны куркынычсыз җиргә күчерешә.

«Йа тәңрем, гаделлек ягында булсаң, кулыбызга көч, җаныбызга дәрман бир. Сиңа гына сыгынган бәндәләреңне ярдәмеңнән ташлама!» дип уйлап куйды Кол Шәриф һәм акрын гына капкага таба атлады. Ләкин бер-ике адым да атларга өлгермәде, шапылдап капка ачылды, аннан каты йөгерүдән тыны кысылган яшь кенә егет килеп керде. Хәтәр ашыгудан булса кирәк, аның йөзе кәгазьдәй агарган, күзләре зур булып ачылган иде. Егет бер сүз дә әйтеп тормыйча кулындагы кәгазь кисәген Кол Шәрифкә сузды. Ниһаять, тыны ачылды, телен көчкә әйләндергәндәй авырлык белән эндәште:

— Изге Кол Шәриф хәзрәт! Урыс ягыннан укка тагып мәктүп аттылар. Хан сараена чаба алмадым, сиңа китердем. Укып багасыңмы?!

Егетнең беләгендә терсәктән түбән күлмәк җиңе ертылган, ак чүпрәк аша саркып кан тама иде.

— Яралангансың түгелме, улым! Әйдә, башта җәрәхә-

теңне бәйлик,— диде Кол Шәриф егетнең кулыннан кәгазьне алып.

— Зарар юк... Шушы ук сыдырып китте. Ярасы тирән түгел. Батыр ярасыз булмас...

Егетнең шаяртырга тырышып сөйләнүеннән үзалдына елмаеп, Кол Шәриф бөтерелгән кәгазь кисәген сүтеп җибәрде. Бер-ике юл укуга ук аның кыяфәтенә җитдилек, олуг җаваплылык тойган кешеләрдәгечә сабыр кызыксынучанлык чыкты. Кәгазьне тагын бер кат шомартып алды да йотылды. Бераздан сөаль бирде:

— Укырга өлгердеңме?

— Юк, хәзрәт... Беренче юлларын күрдем дә туры монда йөгердем.

— Рәхмәт сиңа, егет! Әйбәт хәбәр китергәнсең. Тыңла, ни язалар. «Галиҗәнаб Казан патшасы! Сиңа түземлегеңне җигәргә генә калды. Озакламый Иоанн Васильевич Казан каласын хурлыклы ташлап китәр. Ашлык, азык-төлек төягән барлык көймәләрне Иделдә сезнең кешеләр батырып бетерде. Гаскәр ач. Тагын шуны да белеп тор: кирмән астына җир асты юлы казыла, кальганы шартлатырга. Саклана алсагыз — җиңү сезнең якта»,— ди. Яхшы! Аллаһым үзе мәдәт бирсен! Инде тагын ниләр яза?.. «Хөкемдар вә урыс гаскәре шәһәрне ташлап киткәч, мин дә аларга иярермен. Тик озакка түгел. Бераз юл үткәч, аерылып Казанга килермен һәм, бөек хан, тугрылыклы хезмәтчең-чураң булырмын. Бу хәбәрем өчен мине, тугры колыңны сакла, бөек падишаһ, сөй һәм юмарт бүләкләрсең дип тә өмет итәм.

Син хөкемдар каршында баш орып Углич сәүдәгәре Василий Булгаков дип белерсең». Йә, нәрсә диярсең, углым?! Бу хәбәрең өчен иң беренче нәүбәттә сине бүләкләргә кирәк түгелме икән әле?

Кәгазьдән аерылып башын күтәрүгә, Кол Шәриф шомланып кычкырып җибәрде. Яшь егет күз алдында сыгылып төште, гәүдәсе җансыз капчык шикелле лапылдап җиргә ауды, аяк-кулларын эченә җыеп бөгәрләнде дә тынды, ирен-нәре арасыннан канлы күбек бәреп чыкты.

Инде берничә тапкыр мондый сәер үлем белән очрашкан Кол Шәриф эшнең серен тиз төшенде, ирексездән пышылдады: «Агулы ук!.. Ни аяныч: яхшы хәбәр һәм агулы ук!..» Кулындагы кәгазен бөтәрләп кесәсенә тыкты һәм ашыгып егеткә иелде. Ләкин яшь, таза, чибәр сын җансыз иде инде. Хәзрәт укны алып әйләндергәләп карады, яшелләнә башлаган тимер очына күз салды, иснәп карады. Әйе,

ялгышмаган! Аннан урыслар куллана торган көчле агуның баш әйләндергеч татлы да, бер үк вакытта сасы да тоелучы зәһәр исе килә иде.

Дога укырга дип кулларын бите янына китергән Кол Шәриф тәүге тапкыр егетнең йөз чалымнарына, киң маңгаена, газаплы авыртудан җыерылып калган иреннәренә игътибар итте. Чү! Нәкъ менә шушындый йөзне, нәкъ шушыңа охшаган егетне кайчандыр бер күргәне бар иде түгелме соң?! Ул егет тә ниндидер газаплы уйлары белән уртаклашырга, Кол Шәрифтән ярдәм сорарга килмәгән идеме? Кылт итеп кайчандыр, Казан белән Мәскәү арасында мөнәсәбәтләр җылынган елларда урыс егетенә мөселманлыкка күчәргә хәер-фатиха биргәне, канун дәрәҗәсендәге кагыйдәсеннән читенеп, аңа ташлама ясаганы исенә төште. Йөрәген әрнү, кызгану хисе яндырып алды. «Димәк, ул чагында ялгышмаганмын,— дип уйлап алды ул эчке бер уфтану белән. Ләкин бу уй-тойгыларында шатлык та, сөенү дә юк иде инде. Нәкъ шул көнне борынгы дисбенең серенә төшенгәне, йолдызларның Казанга афәт белгерткәне исенә төште. Әйе, барысы да раслана, юраган юш килә. Хәтта шул көнне очраган урыс егете һәм аның нәселенә дә шул афәт яный, күрәсең. Ләкин котылу юлы бар әле! Бар! Ул — җаһилгә, күз күрмәс киңлекләрдә җәйрап яткан ил-дәүләтләргә золым китерәчәк явыз затка соң чиккәчә каршы тору, тешең-тырнагың белән ябышып каланы саклау. Хатта язылганнар дөрес булса, көтәргә күп калмаган. Түземлек, чыдамлык, тагын бер кат түземлек бир, ходаем!

Кол Шәриф мәетне торыпша белән ябып куйды һәм хан сараена, диван әһелләре, олуг саргаскәрләр янына ашыкты. Урыс ягыннан килгән хәбәрнең дөреслеген тикшерергә, бер-бер чара күрергә кирәк иде.

Ә бу вакытта үлем, кан һәм газап китерүче ике дулкын Арча кыры ягында бер-берсенә килеп капланган иде инде. Кылычлар үтмәсләнде, сөңге саплары шартлап сынды, үзара чапырылышып беткән урыс вә татар сугышчыларының йөзләрчә тамактан чыккан аһы, каргышы, ләгънәте, әйтерсең, күкләргә менеп җитте. Әмма күктән бер якка да ярдәм килмәде. Табигать җанияләренең бер-берсенең бугазын чәйнәвенә битараф калды.

Ук-җәя белән генә коралланган, үзе дә сизмәстән иң алдагы сафларда татар арасына барып кергән Василий йодрык сугышында бер чарасыз торда да калды. Ни җәядән ата алмый, кулында хәнҗәре, сөңге, кылычы да юк, ич-

масам. Ул гаҗизләнеп тирә-ягына каранды. Бер генә мизгелгә уяулыгыңны югалту да үлем бәрабәренә тиң мәхшәр иде бу. Менә алдында ниндидер сугышчының үле гәүдәсе күренде. Аның күкрәген аркылы тишеп чыккан сөңге тырпаеп калган иде. Бер селтәнүдә аны тартып чыгарды, җәясен атып бәрде дә сөңгене күкрәгенә терәп алга ыргылды. Йә үзең үләсең, йә сине үтерәләр. Башка юл юк. Күзләрен кан баскан Василий берни дә аермый, башка сугышчылар белән бергә ярсып чаба да чаба. Каршында җир астыннан үсеп чыккандай ниндидер татар углы пәйда булды. Хәер, ул гаскәри түгел, яуга чыккан шәһәр кешесе иде булса кирәк. Якалары аерылып төшкән, Василий шикелле үк сөңге тотып аңа каршы йөгерә. Шулчак Василий аның ачык изүендә, муенында ялтыраган көмеш тамганы күреп алды. Башыннан яшен тизлеге белән әллә ничә фараз йөгереп узды: «Татарның иң олы сәүдәгәрләре йөртә торган серле тамга!.. Базар капкаларын ачучы тылсымлы көч! Тамга!» Күзе шул тәңкәдән гайре бернәрсәне дә күрмәс булды. Ничә еллар өметләнеп, саташыр дәрәҗәдә хыяллланган серле тамга иясе үз аягы белән һәлакәтенә, аның сөңгесенә йөгерә түгелме соң?!

Ул кыргый авазлар чыгарып кычкырып җибәрде һәм сөңгене җан көче белән тамгалы адәмнең корсагына батырып айкады, шашынып кабатлады: «Тамга! Тамга!..» Шул ук мизгелдә күкрәгенә яндыргыч авырту килеп кадалды — тамгалы адәмнең пычактай нечкә очлы сөңгесе күкрәк сөякләрен шатырдатып йөрәге янына кереп тә китте. Гомеренең соңгы сулышында ул тагын бер мәртәбә «Там-га-а» дип гырылдады. Канлы ярадан зәңгәрләнгән эчәгеләре тышка бөселгән дошманның «Ва-а-а-ся-а-а! Васи-ли-ий!» дип илереп ыңгырашуын ул инде ишетми иде.

Ә тирә-якта исә канлы бәрелеш дәвам итте.

1989—1990



ЭЧТӘЛЕК

Серле тамга 3
Чакырылмаган кунаклар 15
Пәри кызы 39
Ата белән ул 68
Көймәдә 86
Гөлйөзем 105
Качкынлыкта 127
Билгесез көндәшләр 141
Кол Шәриф 167
Мөселманмы сән 190
Шомлы көннәр 205
Урыс станында 229
Хыянәт һәм үч 251

Литературно-художественное издание

Флюс Латифи
(Латыпов Флюс Фатыхович)

ИЗМЕНА

Роман

(на татарском языке)

Редакторы **Н. Вәлитова**
Художество редакторы **А. Тимергалина**
Техник редакторы **М. Абитова**
Корректорлары **Ф. Вафина, С. Мифтахова, М. Хәйруллина**

ИБ № 6421

Җыярга тапшырылды 14.01.93. Басарга кул куелды 5.07.93. Форматы 84×108¹/₃₂. Типогр. кәгазе № 2. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 15,12+форзац 0,21. Шартлы буяу-оттиск 15,65. Нәшер-хисап табагы 16,38+форзац 0,36. Тиражы 50 000 экз. Заказ П-5. Бәясе ирекле.

Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.

Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгының
К. Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе.
420111. Казан, Бауман ур., 19.

ВНИМАНИЮ САДОВОДОВ!

ГОССТРАХ — филиалы страховой фирмы «ТАСФИР» заключают договора страхования садовых домиков и иных строений. Могут быть застрахованы все имеющиеся строения. Страховую сумму при оформлении договора заявляет сам страхователь.

По договору страхования считаются застрахованными на случай их уничтожения или повреждения, происшедшего от любой причины, кроме: военных действий, народных волнений, забастовок, конфискаций, реквизиции, ареста; умышленных действий страхователя или члена его семьи; сноса строений по распоряжению исполнительных органов; повреждения строений червями, грызунами, насекомыми, грибками.

При заключении договора страхователь может застраховать строения отдельно:

1. на случай пожара;
2. кражи, хищения;
3. прочих происшествий.

После первого года страхования страхователю предоставляется скидка с платежа 10%, 2 лет — 20%, 3 лет — 25%, 4 лет — 30%, 5 лет — 35%, 6 лет — 40%, 7 лет — 45%, 8 и более лет — 50%. Для получения скидки с платежа страхователь должен предъявить страховые свидетельства за предыдущие годы.

Имущество, находящееся в садовом доме и на участке, принимается на страхование по отдельному договору. Страхование имущества проводится на случай его уничтожения или повреждения в результате стихийных бедствий, пожара, взрыва, наезда транспортных средств, падения деревьев и летательных аппаратов, а также похищения имущества и уничтожения или повреждения его, связанного с похищением либо попыткой похищения.

Телевизоры и холодильники считаются застрахованными также на случай их возгорания (независимо от причины).

Как и строения, имущество можно застраховать сразу на случай наступления всех перечисленных выше событий или по отдельным из них:

1. на случай пожара и стихийных бедствий;
2. хищения, кражи.

По этому виду страхования предусмотрена скидка с платежа до 50%, по нормам, применяемым для строений.

По специальному договору на страхование принимаются строительные материалы, выделенные страхователю для индивидуального строительства.

Договор страхования строений, домашнего имущества, строительных материалов можно оформить в филиале страховой фирмы «Тасфир» по месту жительства, работы страхователя и по месту нахождения садового домика.

СТРАХОВАНИЕ ЖИВОТНЫХ
сельскохозяйственных предприятий, арендаторских и фермерских хозяйств

Татарская республиканская страховая фирма «ТАСФИР» проводит добровольное страхование животных, принадлежащих сельскохозяйственным предприятиям, арендаторам, фермерским хозяйствам.

На страхование принимаются: свиньи, пушные звери и кролики в возрасте от 4 месяцев, домашняя птица яйценоских пород в возрасте от 5 месяцев (птица на фабриках, специализирующихся на производстве бройлеров,— в возрасте от 1 месяца), крупный рогатый скот, овцы, козы в возрасте от 6 месяцев, лошади в возрасте от 1 года, а также семьи пчел (в ульях). Указанные животные считаются застрахованными на случай гибели (падежа, вынужденного убоя или уничтожения) их в результате болезней, пожара, стихийных бедствий и несчастных случаев.

Страхование молодняка животных, не достигших вышеуказанного возраста, проводится только от стихийных бедствий, пожара и действия электрического тока.

По желанию страхователя по животным дополнительно может быть заключен договор страхования на случай хищения.

Животные принимаются на страхование не более 80 процентов их стоимости на день подачи заявления.

Договор страхования заключается сроком на 1 год или на неопределенный срок с ежегодным перерасчетом стоимости животных, а со страхователями, деятельность которых носит сезонный характер, договор заключается на срок от 3 месяцев до 1 года.

Хозяйствам, страховавшим животных данного вида в полной стоимости не менее 3 лет без перерыва, предоставляется месячный льготный срок для заключения нового договора.

А при страховании всех видов животных более 3 лет и за это время не производилась выплата страхового возмещения предоставляется скидка страховых платежей до 40 процентов.

О подробных условиях страхования и заключения договоров можно ознакомиться в районных страховых филиалах фирмы «ТАСФИР».